# казан утлары

9
СЕНТЯБРЬ·1969

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**9**

СЕНТЯБРЬ
1969

## *Бу санда:*

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

**Д. СИРАЙ. Аның сүзе. Ишкәкче. Эзләр. Йөз еллык иманнәр. Язмыш аны үзе саклаган.** Шигырьләр . . . 3
**Кояш турында легенда.** Саамчадан М. Садри тәрҗемәсе . . . 5

РОМАН, ШИГЫРЬЛӘР, ЯЗМАЛАР

**А. РАСИХ. Каһарманнар юлы.** Роман . . . 6
**Н. ДӘҮЛИ. Көндәшләр. Минем бүләгем. Кое.** Шигырьләр . . . 94
**К. МОСТАФИН. Ачкыч. Инженерлар. Безнең исем... Без серләрне югалтабыз... Китапларны язалар да... Болгар кызы. Эмигрант. Фантаст Хуҗалар.** Балладалар. **Урал бик зур.** Шигырьләр . . . 97
**Г. ШӘРӘФЕТДИНОВ. Сусыз дәрья.** Солдат язмалары . . . 103
**К. ЛАТЫЙП. Шыртам. Кылыч. Эллада. Олы юлда бер шәһәр бар. Камышлыдан аккош киткән.** Шигырьләр . . . 134

РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

**Р. САБИРОВ. Хәзинә эзләп.** Очерк . . . 136

ЭШ КҮРСӘТКӘН ИРНЕ ИЛ ОНЫТМЫЙ

**Ә. СИНЕГУЛОВ. Җыр — бомба** . . . 149

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

**С. ХӘКИМ. Шигырьнең көче — фикердә,** хистә . . . 155

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

**Н. ИХСАНОВ. Гадиләрнең берсе.** Очерк . . . 157

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

**Н. ХӘКИМУЛЛИН. Хермә илендә.** Очерк . . . 162

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ЯҢА КИТАПЛАР

Р. БАТУЛЛИН. Вәгъдә һәм омтылыш . . . . . 173
Т. КАМАЛИЕВ. Йолдызлар ничәү! . . . . . . 176

ТӨРЛЕСЕННӘН

Ю. ӘХМӘТҖАНОВ. Табыннарыбыз турында . . 178

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. ГАЛИЕВ. Шәпшә. Яңгыр яуганда. Ничә мәче! Зөһрә. Борын. Җәен. Шигырьләр . . . . . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Р. ФӘИЗОВ. Биш минут. Хикәя . . . . . . . . 187
«Казан утлары» 1970 елда . . . . . . . . . . 189
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 12/VI-1969 ел. Басарга кул куелды 19/VIII-1969 ел. ПФ 05100.
Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 81346 экз.
Заказ В-379. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.




*ЛЕНИН —
БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

## Дифгать Сирай

### Аның сүзе

«Шигырь язасыңмы? — дип сорый күк,
Күзен төбәп дәфтәр битенә.—
Ил турында уйлап иҗат итү
Ләззәтле дә, улым, читен дә.
Тик баш имә кыен чакларда да,
Ялкынлансын дәртең йөрәктә.
Без дә шулай яңа Россияне
Иҗат иткән идек көрәштә»...
Як-ягыма карыйм.
Беркем дә юк.
Тик чыңлый күк сүзе колакта:
— Каләмеңне нык тот,
Бәхет өчен
Көрәш кебек авыр иҗат та!

### Ишкәкче

Идел уяу.
Давыл дулкыннарны
Китереп суга сөзәк ярларга.
Суда көймә.
Ишкәкләрен киереп,
Ильич бара кебек аңарда.
Карашында — туар таңнар нуры,
Омтылышы — чыгу диңгезгә.
Чал дулкыннар ярсып күкрәк кага,
Юк дигәндәй бер көч тиң безгә.
Ничә тапкыр алар усалланып,
Ишкәкләрне читкә чөймәде!
Ләкин Ильич зәңгәр киңлекләргә
Алып чыкты барыбер көймәне...

## Эзләр

Ак таш бина.
Һәрчак күрәм аны
Килгән саен туган Казанга.
Очрар кук миңа яшь Ульянов,
Шул тирәдән үтеп барганда.
Ул биредән куптән киткән инде,
Эзе ләкин калган ташларда.
Киткән Ильич моннан ялкынланып,
Чын бәхетнең серен ачарга...
Килгән саен Казан каласына
Шул бинага төшә күзләрем.
Атлаганда
Ильич эзләренә
Туры килер кебек эзләрем.
Аяк тавышын тоеп өсләрендә
Кузгалыр кук урам ташлары...
Россиянең яңа тормыш юлы
Ильич салган эздән башланды.

## Йөз еллык имәннәр

Җил йөри шаярып-шатланып,
Бөредә утыра имәннәр.
Яшьтәше бит алар Ильичның,
Дөньяга бер көнне килгәннәр.
Як-якка таратып бөдрәсен
Имәннәр бүген дә шау килә.
Йөз яшьлек Ильичны тәбрикләп,
Йөз еллык имәннәр баш ия.
Сынмассың давылда, диләр кук,
Тугансың син охшап корычка.
...Имәннәр картаеп үләрләр,
Мәңгегә үлем юк Ильичка.

## Язмыш аны үзе саклаган

Фин култыгы.
Бозлар өсте — көзге,
Бер карала, тагын агара.
Ильич шуннан түше белән шуышып
Чыккан, диләр, күрше ярларга.
Кешеләргә булган мәхәббәтен
Йөрәгенә салып үткән ул.
Бәхет юлын якынайту өчен,
Ерак юлны якын иткән ул.
Дулкыннары өскә күтәргәннәр,
Ватылса да бозлар, батмаган.
Бәхетебезгә, бөек юлбашчыны
Язмыш үзе безгә саклаган.

# Кояш турында легенда

*Саамчадан кыскартып бирелә*

Хәбәр килде ерак илдән
Суамаландыга безнең:
Ленин килә икән тиздән,
Бозларын кичеп диңгезнең.

«Ленин, Ленин? Кем икән ул?» —
Сораштылар тундрада.
«Ленин иң көчлеләрнең дә
Көчлесе бөтен дөньяда!»

Саамнар җир яңгыратты:
«Ленин — кояш, тормыш биреп,
Нурга бизә безнең якны».

Инде тәмам куркып калган,
Коты чыккан, калтыранган,
Алдашып йөрүчеләрнең,
Талап көн күрүчеләрнең,
Өерләре безгә янап,
Яшәр өчен һаман талап,
Тавышлана, җәнҗал ясый,
Чиксез ачу белән ярсый.
Мурман кала утта кала,
Чит-ят дошман камап ала.

Чумнарны басып дошманнар
Туйганчы мыскыл иттеләр,
Саамнар һәм боланнарны
Каядыр куып киттеләр.

Тундрада еллар үтте,
Кышкы ачы җилләр исте,
Котырган генералларны,
Талаучы инглизләрне —
Килмешәк кансыз җаннарны,
Кыю Ленин куа китте.
Тундраны нур урады,
Яр буе иркен сулады...

«Әй, чәчәк ат, мүк җиләге,
Пеш, карлыган, тулып-тулып,
Бөек көрәшчебез, Ленин,
Безгә кил син кунак булып!»

Тагын бер ел үтеп китте,
Кемдер менә хәбәр итте:
Тундра кояшы сүнгән:
Киң күңелле Ленин үлгән...
Ышанмый моңа беркем дә,
Учак ягып салкын көндә,

Көйләп-җырлап көн дә, төн дә,
Котәләр диңгез артыннан
Кояшның монда килүен,
Яңа тормышны күрүен:

Бозлы диңгездә
Бар бик зур атау,
Зәңгәр атауда
Бар биек бер тау.

Биек тауның бар
Якты кояшы;
Ул кояш син бит,
Безнең юлбашчы!

Куып байларны
Ерак диңгезгә,
Тундра һәм диңгез
Бирдең син безгә!

Тиңсез зур кеше —
Безнең Ленин син,
Син төзгән бу ил
Рәхәт, матур, киң!

Нинди үрчеде
Болан көтүе!
Әйбәт бит болай
Гомер итүе!

Бик яхшы безгә,
Искиткеч яхшы,
Үзебез таза,
Көнебез якты!

Безнең Ленин син,
Безнең зур кеше,
Чиксез бәхетебез —
Ул синең эшең!

Диңгез дулкыны
Ярларны юа,
Салкынны җылы,
Шаян җил куа.

Йөрәкләр тели
Бәхетен сөйләргә,
Кунак булып кил
Безнең өйләргә!

МӨХӘММӘТ САДРИ тәрҗемәсе.

Атилла Расих

# КАҺАРМАННАР ЮЛЫ

РОМАН[1]

## XIII

Әхмәдиев Халит үзе дә тынгысыз, кешегә дә тынгы бирми торганнардан иде. Әлбәттә, кешедәге бу сыйфат, кирәк белән кирәкмәсне аера белү сәләтенә күрше булса, бик әйбәт. Тик Халит андыйлардан түгел иде шул. Альфред бер вакыт: «Укытучыларны артык эш белән күмәргә ярамый, аларга эштән соң уйлану өчен дә вакыт калдырырга кирәк иде», дигәч, ул бик аптырады.

— Солдат, эше булмаса, нишли? — дип сорады ул.

— Белмим шул. Нинди солдат бит? — диде Альфред.

— Ә-ә, минә белмисең шул,— диде Халит, бер күзен кыса төшеп,— башың яшьрәк әле.

— Анысы дөрес,— дип килеште Альфред,— мин сезгә караганда яшьрәк. Ләкин безнең укытучылар солдат түгел ич, Халит абый.

— Юк, алар солдат. Алар белем бирү солдатлары.

— Ни әйтсәгез дә, мин сезнең тезисыгыз белән килешә алмыйм. Чын укытучы, минемчә, укудан һәм укытудан тыш, көн саен ким дигәндә ичмаса бер сәгать үзенең эше турында уйланырга тиеш.

— Ә без синең белән ни өчен кирәк соң? — диде Әхмәдиев, тагы бер күзен кыса төшеп.— Менә болай инде, Альфред Яхич. Алар өчен менә без уйланыйк и үз указаниеләребезне биреп торыйк. Ни өчен соң дәүләт безгә акча түли?!

Директорның зур башлы тәбәнәк гәүдәсе ишектә күренгәч әле Альфред Халитның йөзендә һич хәер-хаһлык күрмәде. Нишлиләр икән дип, тикшерергә кергәндер, дигән фикер килде аның башына. Ләкин директор керү белән ялтыр галошларын салып ташлады да шактый тыныч һәм хәтта көтелмәгән дустанә бер тон белән: «Сәлам һәм хөрмәт бу өйгә»,— диде. Альфред урыныннан сикереп торды, Халитның пальтосын алып элгечкә асты, үзен түргә чакырды. Бу вакытны Луиза да директор каршында яктырып кунакчыллык күрсәтергә тырыша иде.

[1] Ахыры. Башы 2 санда. Әсәр кыскартылып басыла.

— Я, нихәлләр соң? — диде Халит.— Яшьләрнең хәлен белми ярамас, ял көннәрен ничек уздыралар, мин әйтәм.

— И-и, ял дип әйтерлек түгел инде ул, Халит абый,— диде Луиза,— Җәзилә апа авырып китте дә үзебезне ике кулсыз итте.

Директор, утырып, Альфредка таба ияк какты.

— Җитмәсә бу да кирәкмәгән эшләр белән шөгыльләнеп, ярдәменнән мәхрүм итте, диген.

Луиза кинәт йөзе үзгәреп киткән иренә карап алды.

— Юк, алай димәс идем, Халит абый. Ул булдыра алганча тырыша инде тырышуын. Тик нәрсә ул ир кеше, Халит абый, өй эшендә! Үзегез соң Гайникамал апага аш-су карауда, керләр ууда күпме ярдәм күрсәтә аласыз? Аннан бала карыйсы да бар ич әле.

— Шулай инде анысы,— дип куйды директор, үзенең сүзләрен җөпләүче табылудан өмет өзеп,— ну, шулай да, мәктәп эшенә зыян килерлек булмасын инде.

Ул Альфредка сынап карап торды.

— Я, теге беркөн сөйләгән ахмак уйларыңны башыңнан чыгарып ташладыңмы инде?

— Ташладым.

— Ташларга кирәк, ташларга. Юкса үкенерсең,— диде Әхмәдиев.

— Нәрсә ул? — дип кызыксынды Луиза.

— Юк, болай гына, үзара гына,— дияргә ашыкты Альфред.

Альфредның Луизага үзенең мәктәптән китәргә җыенуын әле һаман әйткәне юк иде. Моның сәбәбе бар. Чөнки авылда туып үскән, авылны сагынган һәм авыл шартларында рәхәт яшәргә хыялланган Луизаның бу теләккә каршы киләчәген ул белә иде. Альфред сүзне икенчегә борырга ашыкты.

Халит та, моны аңлагандай, башка темага күчте, өстәлдә таралып яткан язулар белән кызыксынды.

— Бу язуларны әйтәсезме? — диде Альфред, ачылып.

— Әйе,— диде Халит,— бу инде синең теге... ничек диләр әле? Хоббимы?

— Алар татар бригадасы турындагы материаллар,— диде Альфред.— Теләсәгез, Халит абый, шуларның берәрсен укып күрсәтәм.

Альфред сораулы караш белән Халитка текәлде. Егетнең күңелендә мондый кыю фикер кинәттән генә туды. Ә кем белә, бәлки шул эш Халитның бәгырен җылытыр, уйландырыр.

— Нәрсә соң ул? Яле,— диде Әхмәдиев.

Альфред, җанланып, кулъязмаларның берсен тиз генә кулына алды.

— Мин әле моны күптән түгел генә Казаннан алып кайттым. Музей фондыннан, күчереп...

Альфред хатынына күз ташлады.

— Син, Луиза, чәй әзерлә инде, пожалысты. Без Халит абый белән чәй эчә-эчә укырбыз.

— Я, давай, укып кара, нәрсә белән шөгыльләнәсең икән син? — диде директор, эре генә, көлемсерәп.

Альфред иплебрәк утырды да кычкырып укый башлады.

— Беренче аерым Идел буе татар бригадасының командиры Ибраһимов Йосыф Ихсановичның бригада турында истәлекләре.

— Ну, ну,— диде директор.

— «Мин 1919 нчы елның февралендә Төркстан якларыннан Мәскәүгә әйләнеп кайттым. Анда мине Милли эшләр халык комиссары Сталин җибәргән иде. Мин кайту белән үземнең Хәрби-диңгез эшләре халык комиссариаты каршындагы Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең члены итеп билгеләнгәнемне белдем. Күп тә үтмәде, мине Сталин үз янына чакыртты да болай диде:

— Колчак үзенең контрреволюцион өерләре белән Иделгә ашкына. Ул поплар, хирувимнәр белән бара. Аңа каршы Идел буендагы хезмәт иясе татарларны да күтәрергә кирәк. Сез моңарчы бирелгән заданиеләрне әйбәт үтәдегез. Партия һәм Хөкүмәт бу заданиене дә намус белән үтәп чыгарсыз дип ышана,— диде.

— Партиянең әйткәннәре минем өчен закон, мин барлык көчемне куярмын,— дидем.

Икенче көнне вакытлыча командир хезмәтен башкарган Крымов урынына минем Бригада командиры итеп билгеләнүем турында приказ булды. Һәм минем уйларым, фикерләрем Мәскәүдән еракта, Идел буйларында, формалашып яткан Бригадага күчтеләр. Күзем нәрсәгә генә төшмәсен, минем беренче уем Бригада ихтыяжы турында булды».

Альфред, язуны таный алмыйча булса кирәк, гөртелеп тукталып калды.

— Әйдә, әйдә, син нәрсә? — диде Халит.

— Бик ашыгып күчергән идем,— дип акланды Альфред. Бераздан нинди сүз язылганлыгын чамалап белде, комбригның истәлекләрен тагы укый башлады. Командир бригада оештыру буенча үзенең беренче адымнарын ничек ясавын, Мәскәүнең Зур театрыннан Казанга музыкантлар алып китүен, Казанга кайткач, штабны ничек оештыруын, штаб начальнигы итеп Литва татары Тальковский билгеләнүен, бригада политбүлегенең эше язучы Шамил Усмановка тапшырылуын һәм башка бик күп вакыйгаларны язган иде.

Истәлекләрдән көньяк группаның командующие Михаил Васильевич Фрунзе җанлы булып күз алдына килеп басты. Менә бригаданың төрле шәһәрләрдә оештырылган полклары һәм башка бүлекчәләре. Алар барысы да соңыннан Самара шәһәренә җыелалар. Менә ул, бөек яу башлыгы Фрунзе, татар бригадасының парадын кабул итә...

1918 нче елның июль ае. Генерал Мелесон командалыгындагы Британия гаскәрләре Каспий арты тигезлегенә һөҗүм башлыйлар. Алар Ашхабад, Красноводск, Мерв шәһәрләрен басып алалар. Күп корбаннар исәбенә яуланган Совет власте биредә бетерелә. Җирле феодаллар, контрреволюционерлар, фанатик диничеләр газават байрагын күтәреп, басмачылар хәрәкәтен оештыралар. Җир дөрләп яна, аяк асларында кан дәрьялары ага. Ләкин бу вакыт яшь Совет дәүләтенең андагы халыкларга төрле яклардан ярдәм кулы сузарга ашыгыч мөмкинлеге булмый. Ниһаять, унтугызынчы елның җәендә Төркстан республикасын теше-тырнагы белән яклаучыларга ярдәм кулы сузыла. Шул уңай белән бригада да Төркстанга таба походка чыга.

Табын әзерләргә керешкән Луиза шушы урында укуны бүлдерде.

— Я, туктагыз инде, бераз укыдыгыз, житкән,— диде.

— Хәзер, хәзер, менә бу турылары бик кызык,— диде Альфред. Ул, сайлап-сайлап, үзенчә кызык тоелган урыннарны укыды.

«...Менә без фронтта, окопларда. Әле хәзергә оборонада ятабыз. Әле хәзергә бригада формалашу чорында тәгаенләнмәгән эшләребезне бетерәбез. Безнең участокта әле хәзергә тынычлык, ләкин Астраханьны саклаучы безнең унберенче армиябез Черный яр янында каты сугышлар алып бара, ул контрһөҗүм башлый. Андагы һөҗүм тынарга өлгерми, Деникинга каршы сугышучы көньяк фронтка ярдәм йөзеннән Уральск-Калмыков районында безнең дүртенче армиябез һөҗүмгә күчә. Фрунзе яңа операциягә җыена. Ул Актүбә районында генерал Беловның армиясен чолганышта калдырып, юк итәргә карар кыла. Без һөҗүмгә әзерләнәбез... Без Урал елгасын кичәбез. Бу 1919 нчы елның унберенче августында була. Бригада дошман уты астында елга кичә».

Луиза «җитәр инде» дигәнне аңлатып, иренә тәнбиһле караш ташлады. Альфред, моны тоеп, сорау белән Халитка текәлде. Директор ялыкмаган кебек иде, Альфред укуын тагы дәвам иттерде. Тагы бер-

бер артлы утлы көннәр күз алдына килеп басты. Авыр сугышлар җанланды, андагы каһарманлыклар сурәтләнде. Батыр командирлардан Хөсәен Мәүлүтовка, Хөсәен Шәйхетдиновка, Әхмәт Алимбекка һәм башкаларга дан һәм мактау сүзләре әйтелде.

— Шунда мин битне яптык та чәй эчә башладык,— диде Луиза, кулъязмага үрелеп.



## XIV

Альфред укуын бүләргә мәҗбүр булды. Луиза өстәлгә кайнап торган чәйнеген китереп куйды.

— Син Халит абыйны үзеңнең тарихың белән тәмам ялыктырдың инде.

Альфред, әгәр теләми икән, мин укымаска да риза, дигәндәй, Әхмәдиевкә текәлде. Ләкин директорның йөзендә берни дә аңлатмый торган елмаю гына чагыла иде. Альфред моны үзенчә юрады, чәй ясалгач, тизрәк суынсын өчен чәйне чынаяк тәлинкәсенә койды да тагы язуларына үрелде.

— Мин истәлекнең соңгы битләреннән генә бераз укыйм. Бик кызык. Менә ул! — диде.— «...Тиздән без командующийдан яңа приказ алдык. Һәм эшелоннарга төялеп, Ташкентка киттек. Без инде яңа, егерменче, елны Ташкент шәһәрендә каршылаячакбыз. Менә ул Ташкент каласы!

Без, бригада башлыклары, вагоннардан төшү белән Төркстан коммунистлар партиясе Үзәк Комитетына юнәлдек. Төркстан Үзәк Комитеты аша Урта Азия халыкларына: үзбәкләргә, төркмәннәргә, таҗикларга, казакъларга, кыргызларга, кара-калпакларга үзебезне бирегә җибәргән бөек Лениннан сәлам тапшырдык. Без ярдәм итәр өчен килгән Төркстан фронтының хәле чыннан да хәтәр иде. Ул бер яктан инглиз интервентларына һәм Каспий арты вакытлы хөкүмәтенә каршы сугышлар алып барса, икенчедән, Җидесу якларында оялап калган генерал Дутов һәм Анненков ак бандалары белән сугышырга тиеш. Моның өстенә, төркмән ханы Җонаид-хан һәм илне эчтән таркатучы басмачылар белән Хива һәм Фергана якларында көрәш алып барырга мәҗбүр. Болары фронтның реаль оператив юнәлешләре. Ләкин барлык контрреволюцион көчләрне үзенә туплаган Бохара әмире дә дөньяда әле. Ул, бүген булмаса иртәгә, Советлар Төркстанының аркасына пычак кадаячак.

Татар бригадасын Фергана үзәнлегенә басмачыларга каршы көрәшкә җибәрделәр. «Басмачы» дип аталган атлы һәм коралы бу кешеләр үзләренең вәхшилекләре белән җирле халыкның үзәгенә үткәннәр иде инде. Алар «Коканд автономиясе» вакытында оешканнар. Бу буржуаз хөкүмәт озак яшәмәгән, ләкин ислам флагы астына барлык контрреволюцион көчләрне, барлык бандит һәм каракларны җыеп өлгергән. Шуннан бирле бик күпләп басмачы отрядлары Фергана үзәнлегендә мыж кайный. Алар авылларның, кечерәк шәһәрләрнең хуҗасы булып кыйланалар. Халыкны талыйлар, суялар, кызларны, яшь хатыннарны урлап алып китәләр, көчлиләр, мәсхәрә итәләр. Болар арасында җидешәр мең коралы җайдагы булган Мадаминбек кебек отрядлар бар. Корал — инглизнеке. Аларга Бохара әмире, Әфганстан, рус патшасының төрле контрреволюцион калдык көчләре ярдәм итә. Соңыннан Төркиядән Әнвәр паша килеп аларга булышлык итәм дип, үзенең әҗәлен юкка гына үзбәк җирләрендә тапмады бит. Юкка гына башкорт милләтчесе Зәки Вәлиди, басмачыларга кушылып, шул бандитлар дустына әверелмәде бит».

Альфред бригаданың Әндижан каласына килеп төшүе, анда башланган политик һәм хәрби көрәш турында укып китте. Бригада командованиесенең басмачыларны безнең якка аударыр өчен алып барган сөйләшүләре, басмачылар урнашкан җиргә барып йөрүләре тасвирланды.

— Туктыйсыңмы син бер, юкмы? — диде Луиза, ниһаять.

— Бер генә деталь, нәни генә, бик кызык ул.— диде Альфред, бик үтенеп. Ул бу юлы Холхуҗа исемле басмачылар атаманы һәм аның җәллады турында укый башлады. Палач чыннан да үзенең кешелек сыйфатларын бөтенләй югалткан ерткыч икән. Ул әле күптән түгел генә 80 әсирне суйган. Кеше чалу аның өчен хәзер көндәлек ихтыяҗга әверелгән. Ул һәр суелган кешенең колагын кисеп путасына кыстыра торган булган.

— Бәлкем, чыннан да шушы турыда тукталырсың,— диде Әхмәдиев, көлемсерәп.— Әллә ниткән куркыныч нәрсәләр чыга башлады. Төшеңә керсә, юләр!

Альфред тирән итеп көрсенде дә бригада командирының истәлекләрен читкә куйды. Аныңча, бу истәлекләр белән кызыксынмау мөмкин эш түгел иде.

— Менә,— дип куйды ул,— якташларыңның шундый героик юлларын өйрәнми ничек түзеп торырсың!

— Кызык юл узганнар. Ярый, ярый. Башларыннан күпне кичергәннәр, берни әйтер хәлең юк,— диде Халит.

— Үкенечкә каршы, бу истәлекләрнең авторы исән түгел. Әгәр ул исән булса, мин аның янына бармый калмас идем,— диде Альфред.

— Әгәр без рөхсәт итсәк,— диде Халит, елмая төшеп.

Әлбәттә, Альфред ял вакытында аннан рөхсәт сорап тормас иде. Ләкин шулай да кызыксынды.

— Рөхсәт итмәс идеңме, Халит абый? Кайбер нәрсәләр белән таныштың бит инде. Моннан соңгылары әле тагы да гаҗәбрәк. Татар бригадасының беренче полкы Бохараны штурмлауда бик актив катнаша. Ул полк беренче булып крепость эченә керә. Андагы вакыйгалар — үзе бер роман. Ә шулай да син минем бу эшемә ничектер ирония белән карыйсың. Рөхсәт итмәс идеңме?

Халит, киеренкелекне йомшарту өчен, чәен бер чөмерде дә мин бит шаяртып кына дигәндәй, артык тавышланмыйча гына көлеп куйды.

Ул, Луизага гына карап, авыл тирәсендәге соңгы хәбәрләрне сөйли башлады. Ниһаять, ул тынды, чынаягын каплап куйды.

— Ярар, бик шәп булды. Рәхмәт,— диде, кузгала башлап.— Мин сезгә болай гына, ял көне итеп кенә кергән идем.

Ул, пальтосын һәм кепкасын киеп алгач, сүзара гына әйткәндәй, Альфредка мөрәҗәгать итте.

— Син, Альфред Яхич, ял көне булса да, бүген кичке алтыларда мәктәпкә килеп чык әле, бераз сөйләшеп утырасы бар иде.— Ул ирония аша елмаеп:— Төп эш турында,— дип өстәде.

Директор Альфредның җавабын көтеп тормады, ишеккә таба атлады. Кунак артыннан ишек бикләп кергәч, Луиза үпкәләгәндәй, аскы иренен бүлтәйтеп, күзләрен чекерәйтте.

— Менә мә, без синең белән клубка кино карарга бардык инде болай булгач!

# XV

Яшьләр ял көненең кичке өлеше бозылуга кайгырышкан минутларда Хәбибрахман абзый үзе дә хәзер эчтәлеген оныта башлаган күптәнге кулъязмаларының соңгы битен укып утыра иде. Аңарда тыелгысыз

булып кинәт бер теләк туды. Ул да булса — хәзер үк әлеге теге отставной янына барып, кулдагы материалларны болгый-болгый нотык сөйләү, алдакчыны оялту. Кулъязмаларның күпчелеге исталекләрдән тора иде. Хәбибрахманның хатларына каршы килгән җавап хатлар иде болар.

Әлеге Хәмзә турында әйбәт, җылы берәр сүз шуларда язылган булсынчы! Хатка имза куйган кешеләр Хәмзә Бакировның батырлыклары турында язарга барысы да «онытканнар». Ул кешенең ялганчы икәнлеге, башкалар эшләгән батырлыкны үзләштерергә теләве көн кебек ачык. Хәбибрахман хәзер, Хәмзә янына барып, барысы турында да әйтергә тиеш. Бу эшнең ләззәтен тоеп, рәхәт минутлар кичерә башлады инде ул.

Хәбибрахман Хәмзәнең адресын кичә үк белде. Күптәнге Казан кешесе икән ул Бакиров. Үзе бик ерак та тормый икән.

Хәбибрахман урыныннан торды да кабаланып кәгазьләрен портфельгә тутыра башлады. Менә ул эшен бетерде, өстенә вельвет пиджагын киеп алды. Стенадагы көзгегә карап бермәл, әллә галстук та тагыйммы, дип уйланды. Ләкин кирәкмәс, артык кыланчыклык булыр дигән фикергә килде. Портфелен кочаклап тоткан хәлдә олы бүлмәгә чыкты. Кадрия пианино уйнап утыра иде.

— Кызым!

«Кызым» диюгә, диванда уенчыклары белән мәш килеп уйнап утырган нәни Ләйлә дә башын күтәрде. Ләкин аның әйбәт, үзен һәрвакыт иркәли торган бабакае бу юлы ничектер артык эшлекле бер кыяфәттә иде, аны санга сукмады.

— Кызым, мин бер җиргә барып кайтам,— диде Хәбибрахман.

Кадрия, кинәт пианино клавишаларыннан кулларын алып, йөзен чытты.

— И-и, эти җаным, харап иттең инде алайса! Мин бит театрга билет алган идем. Без үзебезнең сотрудниклар белән бергә культпоход оештырабыз. Мин сиңа аны кичә үк әйткән идем бит.

Чыннан да, ул Хәбибрахманга кичә әйткән иде шул. Кара инде син аны, онытып җибәргән ләбаса!

— Бәлки мин Ләйләне үзем белән алып китәрмен,— диде карт, югала төшеп.

— Син озаккамы соң? Шулкадәр кичектерергә бер дә ярамый торган эшмени?

— Һич кичектерергә ярамый, кызым. Һич ярамый!

Кадрия, теләмичә генә, пианино яныннан торды да Ләйләне киендерергә тотынды. Нәни кыз, әлбәттә, мондый эшкә бик шат иде. Бабасына ул тәмам ияләшеп беткән һәм, Хәбибрахман кая гына бармасын, Ләйләгә аның белән күңелле булачак.

Тиздән алар икәүләшеп өйдән чыгып киттеләр. Ләйлә өзлексез тәкелди, һәрбер яңалык турында төпченеп сораша, ул ара да булмый, балалар бакчасында булган берәр кызыклы хәлне бабасына сөйли башлый. Хәлбуки Хәбибрахманның йөзе җитди, ул озакламый булачак авыр, күңелсез очрашу турында гына уйлана, борчыла һәм шул ук вакытта җиңү ләззәтен алдан ук тоеп эчтән генә юана да иде.

Алар троллейбуска алдан гына кереп урнаштылар. Ләйлә: «Үзем-үзем!» — дип, бабасы биргән акчаны тимер савытка төшереп билет алып килде.

Тәкелдек кызчык иярткән пөхтә киемле, эшләпәле картны хәзерге минутта сугышчан бер рухтадыр дип берәү дә уйламас иде. Ләкин Хәбибрахман шундый гайрәтле иде хәзер. Ул, зур җанҗал кузгатырга кирәк икән, суд каршына басып ялкынлы речь сөйләргә кирәк икән, анысына да әзер иде бу минутта. Алар ике тукталыш арасын үзгәч төштеләр һәм күп тә бармадылар, дүрт катлы өй арасында кирәкле квартира номерын эзләп йөри башладылар.

Менә ул! Хәбибрахман бераз авыр сулап торганнан соң каты итеп звонок төймәсен басты.

Көттерәләр каһәрләр. Әллә сизенәләр инде!? Ниһаять, Хәмзә үзе ишек ачарга чыкты. Ул буй-буй зәңгәр ефәк пижамадан, киез башмаклардан иде. Урта буйлы булса да, юанлыгы аркасында буе кыска күренә, такыр башлы, түгәрәк йөзле. Аның күзлек пыялалары аша күренгән кап-кара күзләре башта аңгармыйча, аннары аптырый төшеп, Хәбибрахманга текәлделәр. Тик бу хәл озак дәвам итмәде, Хәмзә кордашының нинди эш белән килгәнлеген сизенде булса кирәк, иркен елмаеп, ишекне төбенә кадәр ачып җибәрде.

— Рәхим итәсез!

Хәбибрахман тамак кырып коры гына исәнләште дә эчкә кереп, кызчыгын аяк араларына кыскан килеш:

— Мин сезгә сөйләшеп утыру өчен килдем,— диде.

— Рәхим итегез. Без кунакка һәрвакыт шат.

Хәмзә, кунакчыллык йөзеннән, чишенгәндә кунакларга ярдәм күрсәтә башлады. Ләйләгә үзләрен болай җылы каршы алу бик ошый иде. Ул бабасының һаман салкын һәм үтә эшлекле бер кыяфәттә калуына гына бераз сәерсенгәндәй булды. Идәненә хәтфә келәмнәр түшәлгән зур бүлмәне узып, тагы да эчтәрәгенә керделәр. Анда да шундый ук кыйммәтле җиһаз — дербия иде. Ләкин бу бүлмәнең ял өчен генә түгел икәне күренеп тора, чөнки кызыл агачтан ясалган әйбәт язу өстәле өстендә кәгазь кыстырылган язу машинкасы да үзенең клавишаларын ялтыратып утыра иде.

Хуҗа аны тиз генә өстәлдән алды да тагы бер тапкыр: «Рәхим итәсез»,— дип, Хәбибрахманга култыксалы йомшак кәнәфи тәкъдим итте. Хәбибрахман башта өстәлгә үзенең дәү сары портфелен салып куйды. Бу — аңа көч-куәт биргәндәй иде. Аннан ул кәнәфигә утырып тезенә кызчыгын алды да сугышчан бер кыяфәттә хуҗага күз атты. Хәмзә дә утырды. Ул өстәлнең ян ягына урнашкан иде. Сорау белән, мин ни әйтсәң дә әзер дигәндәй, кунагына карады.

— Менә нәрсә, иптәш Бакиров,— диде Хәбибрахман ничектер кинәт карлыгып киткән тавыш белән.— Гаделлек дөньяда җиңми калмый бит ул. Мин дә теге вакытта хаксызга гаепләнеп озатылган җиремнән күптән кайттым инде.

Хәмзә сагая төште.

— Я, моның белән нәрсә әйтмәкче буласыз? Мин сезнең тел төбегезне аңламыйм.

— Тел төбем менә нәрсәне аңлата, иптәш Бакиров,— диде Хәбибрахман,— сез дөреслекнең бер җиңми калмаячагына ышанмыйча яшисез булса кирәк. Менә бу сезне башаягыгыз белән юкка чыгара да ташлый.

— Сез, зинһар, ачыграк әйтегез әле,— диде Хәмзә,— мин андый шарадалар белән сөйләшергә яратмыйм. Вәхаләнки сез ачыктан-ачык, карт большевикларча сөйләп бирегез. Әгәр нинди дә булса берәр хата киткән икән, мин төзәтермен. Әгәр сез нидер аңламыйсыз икән, шулай ук мин сезгә аны аңлатырга тырышырмын. Без сезнең белән уртак тел тапмый калмабыз дип уйлыйм. Без бит бер полкта хезмәт иткән, Совет власте өчен бергә кан койган кешеләр, без бер платформада көрәш алып баручылар. Без, минемчә, аңлашмый калмабыз. Туп-туры әйтегез. Сез минем квартирама ниндидер претензияләр, дәгъвалар белән килдегезме? Тик, зинһар, гадирәк итеп әйтегез. Югары материяләр турындагы сафсатаны яратмыйм. Мин солдат.

Хәбибрахманның ачуы йөрәгенә капты, бугазы киселгәндәй булды. Бик шома, оста иде бу Хәмзә атлы кеше, аны, мөгаен, мондый сөйләшүләр белән генә акылга китереп булырдай түгел иде. Тик шулай да

Хәбибрахман, хис ялкынына артык бирелмәскә тырышып, сүзен дәвам иттерде.

— Әйе, мин сүземне шул ук рухта дәвам иттерәчәкмен. Безнең вакытлыча булмый торудан файдаланып, сез безнең хезмәтебезне, көрәшебезнең абруен үзләштергәнсез... Күрәсезме сез шушы портфельне? Анда документлар һәм төрле истәлекләр. Мин теләсәм кайсы минутта сезне шулар ярдәмендә фаш итә алам!

Хәбибрахман портфельгә таба үрелде. Әйтерсең лә, ул хәзер үк шуны ача да ялганчының көлен күккә очыра башлый. Дөреслектә, әлбәттә, портфельдәге истәлекләр арасында Хәмзәне турыдан-туры фаш итәрлек бернәрсә дә юк иде. Ләкин шулай килеп чыкты ки, Хәбибрахманның артык тәвәккәллеге һәм кискенлеге Хәмзәгә ике төрле уйларга урын калдырмады.

— Сабыр итегез, шашмагыз,— диде ул, агарына төшеп.— Мин сезгә барысын да аңлатам. Ләкин сабыр итегез.

Ул, еш-еш сулап, калтыранган кулларын яшерергә тырыша иде. Хәбибрахманның да киеренкелеге соңгы ноктага җитте, йөрәген нидер кысып авырттыра башлады, йөзендә исә кан әсәре калмагандай булды. Ул портфельгә сузылган кулларын кире алды, көтелмәгән шау-шуга аптырап, куркынып янтыгына сыенган Ләйләне кочаклады.

— Туктагыз, зинһар, сабыр итегез,— диде Хәмзә, ни өчендер маңгаен уып. Күрәсең, аның башы бик каты авырта башлаган иде.— Әйдәгез әле, без теге олы якка чыгып иркенләбрәк утырыйк,— диде ул кинәт.— Мин сезгә барысын да сөйләячәкмен.— Ул урыныннан торды һәм, «хәзер» дип, урта ишекне ачык калдырган килеш, күрше бүлмәгә чыкты. Бакировның сервanttан ниләр алуын, аларны өстәлгә куеп табын әзерләвен Хәбибрахман каршыдагы көзгедән күреп утырды. Ул хәтта Хәмзәнең шешәдән вино агызып тиз генә эчеп җибәрүен дә абайлады.

— Әйдәгез әле, менә шушы якка чыгыгыз әле. Без сезнең беләң иркенләп сөйләшик. Сез барысын да аңларсыз. Сез, минемчә, аңламастай кеше түгел,— диде Хәмзә.

Хәбибрахман кызчыгын ияртеп алгы бүлмәгә чыкты. Өстәлгә кыйммәтле вино, тәмле салкын закускалар һәм ваза белән сап-сары эре алмалар куелган иде.

— Утырыгыз әле,— диде Хәмзә, артык кайгыртучанлык күрсәтеп.— Ә бу матур кызчыкны менә шушында утыртыгыз. Өйдә беркем дә юк. Пенсионерның хәлен беләсез...

Хәбибрахман эченнән «Ялагайланма, тик син мине барыбер кире якка аудара алмассың»,— дип уйланды.

— Сез мине аракы белән сыйларга җыенасыз, ахры, анысы кирәкми, мин эчмим,— диде ул, утырып.

— Юк, без сезнең белән аракы эчмәбез. Бу бик әйбәт вино. Кавказда минем олы улым тора. Шуның күчтәнәче.

— Барыбер. Вино да ярамый,— диде Хәбибрахман.

— Утырыгыз әле, һич булмаса, кызыгызга әнә конфетын, алмасын бирегез.

Ул, Хәбибрахманның хәрәкәтсез тик утыруын, баядан бирле кызыгып өстәлне күзәткән оныгына игътибарсыз булуын күреп, Ләйләгә иң матур алманы үзе алып бирде.

Хәбибрахман нидер әйтергә теләп йотлыгып куйды, мәгәр дәшмәде, сорау белән Хәмзәгә текәлде.

— Әгәр инде сүзне турыдан-туры алып барабыз икән,— диде Хәмзә,— сез бездән минем дус булып китәчәксез. Мин моңа ышанам.

— Ни өчен? Ялганлый белгәнегез өченме?

— Сабыр итегез. Сез мине тыңлагыз башта. Менә болай. Вәхаләнки, мин бу эшне иң изге теләкләрдән чыгып эшләдем.

Хәбибрахман ачы елмаеп башын боргалады.

— Әйе, әйе. Сез аңларга тиеш,— диде Хәмзә.— Мин үзем дә татар бригадасында булган кеше...

— Ничәнче полкта?

— Беренче полкта. Аның турында, минем беренче полкта булганлыгымны сез 1949 нчы елның маенда басылып чыккан истәлекләр җыентыгыннан укып белә аласыз.

— Ә ни өчен соң сез 1920 нче елның башында Ошка барып эләктегез? Сез бит үзегезнең теге журналдагы өченче истәлегегездә Беренче полк белән китүегез турында язгансыз.

Хәмзә, бу бик гади нәрсә бит дигәндәй, җилкәләрен генә җыерып куйды.

— Булса ни,— диде ул.— Мин беренче полкта хезмәт итә идем, Казалинскида тиф белән авырып егылдым. Менә шул. Минем полкым китте. Мин икенче полкка эләктем. Мин анда ялгызым гына түгел идем. Ул чак авырып шулай полкын алыштырырга мәҗбүр булган кеше аз булмады. Хәтеремдә, минем белән безнең ротада Шәфигуллин Хәлим бар иде, аннан тагы Шәймәрдәнов. Алар да шулай икенче полкка эләктеләр.

Хәбибрахманның башында нидер яктырып киткәндәй булды.

— Туктагыз әле, кем иде әле ул Шәймәрдәнов?

— Ул безнең беренче полкта теге Урал елгасын кичкәндә бик зур батырлыклар күрсәткән егет иде. Без аның белән соңыннан дуслашып киттек. Әгәр исегездә булса, ул шул Урал суын кичкәндә минем белән бергә беренче булып аргы якка чыкты. Без аның белән әллә ничә казакның башына җиттек. Яраланса да мылтыгын кулыннан төшермәде.

— Аның беренче булып кичкәнен хәтерләдем. Тик сезнең бу эшкә бернинди дә катнашыгыз юк. Сез ичмаса миңа алдап сөйләмәгез инде.

Хәбибрахман ап-ак кашларын җыерып хуҗага текәлде.

Хәмзә исә шартлатып шешәдән бөкене чыгарды да каударланып рюмкаларга чия суыдай кызыл вино сала башлады.

— Яхшы,— диде ул, эшен башкаргач.— Алайса дөресен әйтим. Мин Урал суын беренче булып кичмәдем.— Ул сынаулы караш белән Хәбибрахманны күзәтте.— Бәлки, сез, ни өчен соң син башкалар эшләгән каһарманлыкларны үзләштерден, дип сорарсыз?

Хәбибрахман, аны-моны уйламастан, рюмканы алып үз алдына куйды.

— Тик «үзләштерден» түгел. Ни өчен сез шундый җинаятьле юлга бастыгыз?

— Мин моны әз генә дә алай дип уйламыйм.— Хәмзә нидер әйтергә ымсынып тамак төере хәрәкәтләнә башлаган Хәбибрахманны тагы туктатты.

— Сабыр итегез, тыңлагыз башта. Сез беләсезме, безнең бригаданың алты мең километрлык данлыклы юлы сезгә генә түгел, минем өчен дә бик кадерле истәлек икәнен. Ул халыкның горурланып сөйләрлек бер тарихи сәхифәсе. Исегездәдер, безне Ленин үзе җибәрде, дия торган идек без Урта Азия халыкларына, вәхаләнки ул шулай булды да. Безне Ленин үзе җибәрде. Без Урта Азия халыкларына булдыра алган ярдәмнең барысын да эшләдек.

— Безнең ул интернациональ бурычыбыз иде.

— Бурычыбыз иде. Без аны шәп үтәдек. Инде хәзер уйлап карагыз. Безнең тарих, безнең юл язылмаган килеш калды. Без, шул тарихны үз куллары белән ясаучылар, берәм-берәм юк була барабыз бит. Хәзер инде мин якыннан белгән бер генә кеше дә калмады диярлек. Берәве шәхес культы шаукымына эләкте, икенчесе авырып үлеп китте. Инде ул да булмады, сугышлар чоры, авыр, газаплы сугышлар чоры, социализмның фашизм белән якалашу чоры башланды. Вәхаләнки анда безнең

полкташ иптәшләр генә түгел, аларның балалары да күп кырылды. Инде шуннан соң мин ялгыз үзем торып калдым. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды. Ләкин минем күптәнге теләгем һаман үзгәрмәде. Мин гражданнар сугышында кургәннәребезне яшьләргә язып калдыру теләге белән элеккечә һаман яндым. Ничек кенә булмасын, аның турында язып та, сөйләп тә халыкка җиткерү хакында бик күп уйландым. Ул бит безнең бурыч, без эшләмәсәк, аны кем эшләргә тиеш!?

— Ләкин шулай да тарих дөрес булса гына тарих ул. Тарих дөреслеккә туры килмәсә, ул тарих була алмый!

— Бәлки ул сезнең карашыгыздыр. Вәхаләнки тарих ул агым су кебек тоташ бер хәрәкәт. Мәсьәлә шул агымның юнәлешен билгеләүдә.

— Гаҗәп икән!

— Әйе, әйе, зинһар, аптырамагыз, әгәр бераз уйлансагыз, сез барысын да аңларсыз. Менә мин дә бик күп баш ваттым, һәм шундый бер фикергә килдем. Ахыр чиктә батырлыкның кем тарафыннан ясалуы әһәмиятлемени? Эш бит ахыр чиктә батырлык ясау фактында. Вәхаләнки безнең егетләрнең батырлыгын мин үз күзләрем белән күреп тордым. Алар турында, әйтик, хәзер берниндн ачык язмалар юк, ди. Әйтик, шул җөмләдән сез дә күренмичә, югалып калгансыз, ди. Нишләргә кирәк иде миңа? Я, әйтегез. Юк, бездә берниндн дә батырлыклар, фидакарьлекләр булмады, дип язаргамыни? Мин, беләсегез килсә, барлык җаваплылыкны үз өстемә алып, фактны әз генә дә үзгәртмичә, безнең егетләрнең каһарманлыкларын яшь буынга сөйләп бирдем. Аңлагыз, ул минем үземне күрсәтү өчен кирәкми иде. Ул менә гражданнар сугышындагы батырларны күрсәтү өчен кирәк иде.

Хәмзә ихлас күңелдән сөйли иде, ахры. Ул, гасабиланып, алдындагы винаны эчеп җибәрде һәм иелә төшеп сүзен дәвам иттерде.

— Ярый, сез кайттыгыз. Ә кайтмаган булсагыз? Кемнең моңа күзе җитте? Я, әйтегез!

— Мин бәлки кайтуыма өмет өзгән булганмындыр. Ләкин кайчан булса да дөреслекнең җиңәчәгенә минем һәрвакыт күзем җитте.

— Һем... сез мәсьәләне алай куярга телисез икән. Мин монысына да җавап бирим. Сез Бөек Ватан сугышында катнашмадыгыз, андагы хәлләрне белмисез. Вәхаләнки эш болай тора. Сугышта хәлләр башта бик начар булды. Без кыл өстендә генә калдык. Барысы да картага куелды. Барлык материаль байлык, барлык рухи байлык. Рухи байлыкның иң мөһимнәренең берсе ул безнең тәҗрибә, ул безнең баштан кичкән тарих иде. Фронттагы солдатны рухландыру өчен без үзебезнең узган героик юлыбызны хәтерләргә, шундагы мисалларга таянырга тиеш идек. Алай академизмга бирелеп, абстракт рәвештә гадел, я гаделсез дип баш ватарга безнең мөмкинлек юк иде. Әйткәнемчә, безнең язмышыбыз, миллион корбаннар аша яулап алынган казанышларыбыз кыл өстендә иде.

Хәмзә, сүзен шунда бүлеп, тагы үзенең рюмкасына вино салды. Ул үзен һич берниндн хәрәкәтсез тыңлап утырган Хәбибрахманның да рюмкасына бер күз атты. Ләкин кыстауны кирәк тапмады.

— Менә шундый ситуация иде ул елларны. Вәхаләнки минем дә үз тәҗрибәбездән файдаланасым килде. Бүгенгесе белән генә түгел, ә менә кичәгесе белән дә дошманны кыйныйсым килде. Минем үзебезнең яшьләребезгә, без дә төшеп калган кешеләр түгел, безнең дә революция һәм ил каршында ниндидер хезмәтләребез бар, дип әйтәсем килде. Һәм мин җаваплылыкны үз өстемә алдым. Ахыр чиктә үзегез уйлап карагыз. Минем мәкаләмдә әйтелгәннәр барысы да эшләнгән эшләр бит. Анда берниндн уйдырма юк. Мин үз исемем аша аларга бары гражданлык хокукы бирергә генә теләдем.

— Сезнең сүзләрдән мин шуны аңладым: сез начар ысул белән яхшы эш эшләргә теләгәнсез.

— Шулай аңлый бирегез. Эш ахыр чиктә ысулда түгел, ә максатта.

— Менә шушы урында без синең белән, иптәш Бакиров, аерылышабыз да инде, күрәсең. Без кешеләрчә, яшен яшәгән, ашын ашаган, акылы да озак гомер сөрү аркасында чарлана төшкән житди кешеләрчә сөйләшик. Сезнең менә халык алдында миңа сөйләгәннәрне ачыктан-ачык кабатларга батырлыгыгыз житәме хәзер?

Хәмзә әрнеп елмайды да тагы шешәсенә тотынды.

— Минем сизенүемчә, сез үзегезне граф Монтекристо итеп тоясыз. Вәхаләнки...

— Юк, мин беркемгә дә ияреп эш итмим. Мин бары үземнең намусым кушканны гына башкарам. Әйтегез: халык алдында дөресен әйтеп бирергә көчегез житәме?

Хәмзә рюмкасына тагы вино тутырды да, эчеп, конфетка үрелде. Аның бармаклары калтырый иде.

— Сез бу эшнең мөмкин түгеллеген үзегез дә аңлыйсыз,— диде ул.— Мин сезгә иң акыллы, иң шәп, Сөләйман пәйгамбәрнекедәй, бәхәсне жайлы гына итеп чишү юлын өйрәтәм.

— Ягез, өйрәтеп багыгыз.

— Авыру килеш, вакыт һәм нервы исраф итеп, бәхәс куптарып йөрүләр нигә кирәк сезгә? Моның белән нинди дер абруй, я булмаса ниндидер капитал тупламакчы буласызмы сез?

— Мин бик авыру, ихтимал, күп яши дә алмам. Ләкин сез мине ялгыз дип уйламагыз. Минем хәзер яшь ярдәмчем бар. Әйе, әйе, ул яшь, укымышлы! Альфред Хәйретдинов дигән кеше ул. Укытучы, үзе аспирант.

Хәмзә, миңа барыбер дигәндәй, ирония белән елмаеп, иңбашларын күтәрде.

Хәбибрахман, өстәп, Альфредның университет кешесе булуын да әйтмәкче иде, тик ул уеннан кире кайтты. Йокымсырый башлаган Ләйлә бабасының кинәт артка чигенүеннән уянып китте һәм көйсезләнеп:

— Бабакаем, кайтыйк инде,— диде.

Ләкин Хәбибрахманның күзләре ярсудан тонык ланып калган иде, ул оныгының сүзләрен ишетмәде дә.

— Намуслырак булырга кирәк иде сезгә, иптәш Бакиров,— диде ул, нәтижә ясап.

— Намусның биредә бернинди катнашы юк,— диде Хәмзә,— сез мине башта аңларга тырышыгыз әле, мин бик үтенәм.

«Ярый, тыңлап карыйк» дигәндәй, Хәбибрахман тагы Бакировка текәлде.

— Әйдәгез, без болай иттерик. Сез хәзер зур жанжал куптарып барысын да исбат иттегез, ди. Сез минем кайчандыр ялганлавымны, үземне Бригада каһарманнарының берсе итеп күрсәткәнлегемне, ә дөреслектә бары шунда катнашкан бер рядовой кеше генә булганлыгымны исбат иттегез, ди. Моннан кемнәр генә отачак соң, сез шуның турында уйлыйсызмы? Мин бит сезгә нинди максатлар белән, ни өчен андый юлга басканлыгымны әйттем. Минем теләкләрем изге икәнлеген аңларлык йөрәк юкмыни сездә? Ул тарих бит әле жансыз әйбер түгел, ул бит ахыр чиктә безнең халкыбызның бер коралы да. Вәхаләнки мин булдыра алганымча, шул коралны сакларга тырышканмын икән, әйдә, кайбер детальләрен аның алыштырырга туры килсә дә, ди, ул бит үзенең корал булуын югалтмады. Менә мин әйтәм, әгәр сез безнең арадагы конфликтны куертып йөрсәгез, ул бары бригада тарихын бетерүгә юнәлгән бер эш кенә булачак. Ул тарихтан бөтен кеше шүрли башлаячак, тарихчылар аңа кул селтәячәкләр. Ә бу килеш безнең узган шанлы юлыбыз үзенә билгеле бер гражданлык ала, ул тора-бара

халкыбызның зур хәзинәсенә, үткәндәге мактаулы бер сәхифәсенә әйләнәчәк.

— Миңа, зинһар, андый сафсата сатмагыз,— диде Хәбибрахман, тәкатьсез калып.

— Юк, сез шулай да уйланыгыз, ашыкмагыз. Нигә кирәк ул эш сезгә! Сезгә аның бөтенләй кирәге юк. Нигә кирәкмәгән эш белән шөгыльләнеп йөрергә!?

Хәмзә кинәт урыныннан торды да Хәбибрахманга таба иелеп күкрәгенә кулын куйды.

— Менә мин сездән үтенәм, чын күңелдән үтенәм!

Хәбибрахман кызчыгын идәнгә төшерде, аягүрә басты.

— Мин андый үтенечне кабул итә алмыйм.

Ул Ләйләне житәкләп коридорга таба атлады.

— Зинһар, уйламый эш итмәгез, зинһар,— диде Хәмзә, аның алдына чыгып.— Аннан портфелегезне онытмагыз.

Кинәт ул, исенә нидер төшергәндәй, бер мизгел тынып яктырып торды. Аның йөзендә хәтәр эшкә барыр алдыннан туа торган бер тәвәккәллек чагылды.

— Туктагыз, туктагыз,— диде ул, портфельгә үрелеп.— Әгәр батыр икәнсез, күрсәтегез миңа... документларыгызны. Сез аларның кайсысы белән мине фаш итмәкче буласыз?



## XVI

Хәбибрахман абзый Хәмзәләрдән, әлбәттә, дуслык тойгылары төяп кайтмады. Ләкин ул хәзер Бакировка карата ничектер усаллык тойгылары да кичерми иде. Өстәвенә, аңарда ялганчыны фаш итәрлек документ та юк иде бит. Бу хәлне Хәмзә дә аңлады булса кирәк. Картның күңелендә хәзер ниндидер чуалчык тойгы үскәннән үсә бара иде. Сизгер күңеле аңа Бакировның хаталы юлга начарлык итү яки карьера өчен басмаганлыгын әйтә. Ләкин шул ук вакытта бу күренеп торган җинаять кебек үк бер нәрсә бит, Хәмзә — хәзер үк үзенең җәзасын алырга тиешле кеше.

Хәбибрахман юлда да, өйгә кайткач та үзе ишеткән-күргәннәрен бәяләргә кереште. Әлбәттә инде тегене фаш итәргә кирәк иде. Бу бәхәссез. Ләкин ничек?

Хәбибрахман бер ноктага текәлеп уйга чумды. Ләйлә өстәлдәге уенчыклары белән бабасы янындагы утыргычта тезләнгән килеш, нидер сөйләнә-сөйләнә, мәш килеп уйный иде. Аңа бабасының шундый житдиләнүе, моңарчы бары үзе белән генә мавыккан, нәни кызчыгын бик яраткан бабакаеның игътибарсыз булып китүе үтә сәер тоелды. Нигәдер ул хәзер чит, ят, күңелсез тоела башлады.

— Мин хәзер телевизор карыйм,— диде Ләйлә, бармагын авызына кабып. Аның күзләрендә үҗәтлек чагылып китте. Ул утыргычыннан сикереп төште дә телевизор торган якка чыгып чапты.

Кызчык телевизор төймәләрен әйләндерә башлагач кына, Хәбибрахман уйларыннан айнып китте. Бу шаян иркә бер тапкыр шулай телевизорны яндырган иде инде. Карт шуны хәтерләде һәм авырткан буыннарын сыкратып урыныннан кубарга мәҗбүр булды. Ул бераздан Ләйләне итәгенә утыртып кочаклаган килеш уйлана башлады. Аңа авыр иде. Аңа хәзер кем белән булса да сөйләшергә, киңәшергә кирәк иде. Үзеннән-үзе аның хәтеренә мәрхүмә хатыны килде. Алар бит бер-берсен бик аңлыйлар иде. Ул хатын гына түгел, сердәш тә, киңәшче дә иде. Ләкин ялгыз калган елларында сырхаулаган һәм үлеп тә киткән. Ә бит иң күркәм, иң матур чагы иде аның. Бергә яшәгәндә бер-берсенең сүзеннән чыкмадылар, аерылышкач, Хәбибрахман һәрвакыт аны үз

янында итеп тойды. Аның җылы сулышын, ягымлы карашын һаман тоеп яшәде. Менә хәзер ул янында булсын иде!

Нишләргә икән? Бакиров бит аларның иң мактаулы хезмәтен, җан аямыйча ясаган каһарманлыкларын урлаган һәм шуны үзенчә аклый да әле. Ә бит Хәбибрахманнан, син үз гомереңдә нинди яхшы эш башкарә алдың соң, дип сораганда, ул иң элек әнә шул, илдә яңа тормыш таңы аткан чакларны хәтерли. Ул беркайчан да үзенең аяусыз булуы, батырлыклары белән мактанмады. Ә бәлки әле бу начардыр да? Тәгаен, ул чат саен үзенең каһарманлыкларын искә алып сөйли торган булса, Хәмзә кебекләргә соңыннан авыррак булыр иде.

Хәбибрахман портфеленнән бер кульъязма чыгарды. Бу истәлек иде. Ул аны сөргеннән кайткач язды. Ул аны журналга да биреп карады. Ләкин, кызганычка каршы, мондый мәсьәләләр буенча консультант дәрәҗәсенә ирешеп, ышаныч казанган Хәмзә аны юкка чыгарды.

Карт, күзлеген киеп, кульъязманы алдына ачып салды.

«Ак Булактан безнең полк Ташкент аша Яңа Бохарага китте. Яссы түбәле балчык өйләр, яшел каргалар, кавын исе аңкып торган һава. Без билгеләнгән урынга егерменче елның тугызынчы июнендә барып җиттек. Ә август аеның соңгы атналарында Бохара хезмәт иләре баш күтәрде. Без аларга ярдәмгә барабыз. Әмирнең гаскәрләре һәр җирдә безгә каршылык күрсәтә. Алар юл өстендәге һәрбер кышлактан аталар. Һәрбер гарнизонны кан коеп алмыйча торып алга хәрәкәт итү мөмкинлеге юк. Ә һава чәчләр көярлек кызу. Җир кызган таба кебек. Авызлар кибә, хәлләр бетә. Су юк. Дошман су юлларын җимергән. Бөтен тирәюньдә ком чүле. Ком дулкыннары арасында зәгыйфь саксаул куаклары. Ком күзләрне чагылдыра, атлаган саен ишелә, шыгырдый. Ком авызга, күзләргә керә, теш арасында шытырдый. Егетләргә алга бару бик читен. Ләкин алар сынатмыйлар. Чөнки халык, юлыбызда очраган, әмир тарафыннан, басмачылар тарафыннан күп җәбер күргән гади халык, безне сагынып көткән, алар безне кадерле кунак итеп каршы алалар. Пәрәнҗә битлекләре аша безгә яшь матур күзләр өмет белән текәлгән. Без гасырлар буе ир һәм шәригать тарафыннан җәберләнгән хатын-кызга ирек алып киләбез. Кулларыннан китмән төшмичә, гомер буена тир түгеп газап чиккән диһканнар безне үзләрен азат итүче итеп каршылыйлар. Аларның ярдәме, өметләре, ышанычлары безне дәртләндерә. Идел буйларыннан килгән татар егетләре сынатмыйлар, алар утлар аша, үлем аша, чиксез зур авырлыклар аша алга, үзенең пәрәвез җепләрен үрмәкүч оясыдай төрле якка тараткан, халкын урта гасыр коллыгында тотучы Бохара әмирлегенә каршы баралар.

Менә без канлы сугыштан соң Бохара янындагы тимер юл станциясен алабыз. Алдыбызда Бохара шәһәренең коймасы. Ул сигез метр биеклектә, сигез метр калынлыкта итеп, балчыктан ясалган. Аның теге ягында Бохара. Анда хисапсыз күп мәчет манаралары күренә. Без төнне Бохара янында уздырабыз, удар армиянең башка частьлары да килеп җиткән икән инде. Әнә, бронепоезд да килде. Иртәгә һөҗүм. Шомлы төн. Еракта-еракта шакаллар улаганы ишетелә. Әйтерсең лә, өзми-куймый балалар елаша. Алар мәет исе тоеп, шуны ашап туену шатлыгыннан улыйлар, ахры. Ә күк йөзе кап-кара. Әйтерсең лә, кара хәтфә каплагыч япканнар аңа. Йолдызлар артык якты, артык чекери. Алар асманга тагылган бриллиантлар кебек.

Иске Бохараны икенче сентябрь көнне штурмларга приказ булды. Беренче эшелонның удар группасында һөҗүм итүче безнең полкка Каршы капкасы аша шәһәргә керергә боерылды. Иртәнге тугызда мин үземнең взводым белән беренче буларак Иске Бохара урамнарына барып кердем. Урам сугышлары алып барабыз. Фанатик бирелгәнлек белән, сугышта корбан булудан курыкмыйча, әмир гаскәрләре һәрбер өй, һәрбер йорт саен сугышалар. Баштарак без аларны бу дәрәҗәдә үк

хәйләкәр, кара эчле дип уйламаган идек. Алар безнең мөселман булуыбыздан файдаланалар. Байтак дуслар тозакка төште инде. Онытасым юк, без унлап кеше мәчеткә барып кердек. Күңелебездә шик, ләкин һич аны-моны сизеп булмый. Аксакаллар намаз укый. Без ишек янында карап торабыз, картлар бик бирелеп гыйбадәт кылалар. Михрабтагы мулланың да бездә эше юк. Аның күзләре йомык, ул бары үзенең эшен генә белә. Киттек, егетләр! Ләкин без борылып чыгарга өлгермибез, арттан ату тавышлары ишетелә. Колак очыннан сызгырып инглиз мылтыгы пулялары оча.

Тагы бер вакыйга. Без шул ук көнне шәһәр уртасындагы бер тар тыкрыкта җеназачыларга юлыгабыз. Кешеләр мәет күмәргә баралар. Алар, шәрык гадәтенчә, мәетне кызу-кызу, йөгерә-йөгерә алып баралар. Менә алар безгә якынлаштылар. Без аңгарып та өлгермибез. Кинәт төркем туктала да кабыкны җиргә куя. Ул да булмый, мәеткә куллар сузыла һәм һич уйламаганда алар аннан мылтыклар алып безгә һөҗүм итәләр. Дошманның провокацияләре, хәйләләре безнең өчен шактый кыйммәткә төшә. Ләкин без аның тактикасына тиздән төшенәбез. Нинди генә хәйләләр кылмасын, без инде хәзер үзебезнең максатыбызга ирешербез. Чөнки Бохарадагы хезмәт халкы, юксыллар, кимсетелгәннәр барысы да безнең яклы. Алар безгә төрлечә ярдәм күрсәтәләр. Без баш күтәргән җирле халык белән берлектә уртак дошманны Бохарадан куабыз. Әмир чак кына эләкми, качып котыла. Иртәгесен, ягъни өченче сентябрь көнне, Михаил Васильевич Фрунзе безне, кызыл байрак белән бүләкләнүче полкны, котлады. Менә ул парад кабул итә. Аның нурлы йөзе, дустанә елмаюы минем күз алдымнан гомер буена китмәс».

Хәбибрахман шул җирдә тукталды да урыныннан торды. Кемдер ишек звоногын шалтырата иде.



## XVII

Альфредның урам аркылы чыгыйм дип сул якка борылуы булды — «Волга» машинасы тормозларын шыгырдатып аның янына ук тукталды. Альфред курка төшеп артка чигенде, ләкин машинаның алгы тәрәзәсеннән пыжик бүрекле Латифның башы күренде.

— Бер генә минутка. Исәнмесез,— диде ул. Ибраһимов ачык чырай күрсәтергә теләп сөйләшә иде. Ләкин Альфред аның күңеле төшенке булганлыгын шунда ук абайлады.

— Мин теге чакны сезгә бер әйбер бирергә онытканмын,— диде ул, Альфредның кулын кысып.— Бәлки ул сезнең өчен кирәктер.

— Сүз һаман әтиегез турындамы? — диде Альфред, елмаеп.

— Әйе, әйе, шул инде, минем бар кайгым шул хәзер. Әйтегез әле, ничек, вакытыгыз бармы? Ну, бер ярты сәгать...

Альфред кулындагы сәгатенә карап куйды. Әйе, хәзергә әле профессор барыбер кафедрага килмәгән. Ул шулай икедән кичке бишләргә кадәр өендә ял итә.

— Бар, нәкъ ярты сәгать вакытым бар,— диде ул.

— Алайса машинага кереп утырыгыз әле. Мин сезгә әтинең кайчандыр өйгә язган хатларын күрсәтмәкче булам. Алар минем квартирда...

Альфред, кабалану аркасында, арткы ишекне ача алмыйча азапланды. Нәкъ җиде минуттан соң алар Ибраһимовның квартира ишек төбендә тукталдылар. Латиф шоферга китмәскә, Альфредны көтеп торырга кушты; алар эчкә керделәр.

— Менә алар, әтинең хатлары,— диде Латиф, икесе дә чишенеп эчке бүлмәгә узгач. Альфред игътибар итте. Гаҗәп хәл, бу кеше «әтинең» дигән сүзне ничектер ризасызлык күрсәткәндәй әйтә иде.

— Сез безнең иске шрифтны танышсыздыр инде? — дип сорады Латиф. Бу юлы аның йөзендә ниндидер куркынуга охшаш чалымнар күренде. Тәгаен, ул белми, ахры, дип шомлана иде.

— Гарәп шрифтынмы? — дип сорады Альфред.— Әлбәттә, беләм.

Латиф, өстәл тартмасыннан үзенең хатларын алып, аларны Альфредның алдына салды.

— Укып карагыз, теләсәгез лупа да бирә алам.

— Кирәкми,— диде Альфред,— мин бит ерактан гына начар күрәм.

Ул вакытны чамалау өчен, бу эшкә күпме бирергә була икән дигәндәй, тагы сәгатенә карап алды, аннан игътибар белән укый башлады.

— Я, ничегрәк, файдасы тиярдәйме?

— Кызык бу,— диде Альфред,— ләкин болар мәгълүм нәрсәләр инде.

Ул икенче хатка текәлде. Ләкин бусы артык тузган, аның, дөресен әйткәндә, укырлыгы да калмаган иде. Тик Латифның аптыравына каршы, егетне шушы хат күбрәк кызыксындырды. Ул кайбер урыннарына озак-озак текәлеп карап утырды.

— Менә нәрсә,— диде ул, ниһаять, хаттан аерылып,— бу хатта да минем өчен әллә ни яңалык юк. Ләкин,— диде ул һәм тукталып мәгънәле генә итеп хуҗага карап куйды.

— Нәрсә «ләкин»?

— Монда сезгә кирәкле бер штрих булмагае әле.

— Ничек инде, штрих? — диде Латиф, аңламыйча.

— Менә бу хатта ниндидер Хәмзә турында сүз бара. Менә күрәсезме, нәрсә язылган: «Минем яңа иптәш Хәмзә»,— диелгән.

— Я шуннан?

— Үзегезгә мәгълүм, бездә Хәмзә исеме, әйтик, Габдулла я Әхмәт кебек еш очрый торган исемнәрдән түгел. Әллә, мин әйтәм, сүз шул ук Беренче бригадада булып байтак истәлекләр язып бастырган Хәмзә ага Бакиров турындамы?

Латифның йөзе куанычлы дулкынланудан кинәт яктырып китте.

— Нигә, шундый кеше бармыни?

— Әйе, андый кеше бар.

Альфред Латифка шул кеше янына барып сөйләшеп утырырга киңәш итте.

Латиф, әлбәттә, моңа каршы түгел иде. Альфред блокнот битен ертты да аңа Бакировның адресын яза башлады.

— Ләкин сез аның белән болайрак сөйләшегез инде,— диде ул, язуыннан бүленеп.

Латифның төшенеп җитмәвен сизгәч, «болайрак»ның җаен табыбрак, ипләбрәк икәнлеген, чөнки ул пенсионерның кыркурак табигатьле булуын, мәсәлән, үзен бусагадан уздырмаганлыгын аңлатты.

Икенче көнне кичкырын Латифның машинасы Хәмзәләр подъезды янына барып туктады. Ибраһимов машинасыннан бәрелә-кысыла чыгып, ашыкмыйча гына, тыныч адымнар белән ишеккә таба юнәлде. Ләкин ул тыштан гына шулай күренә. Чөнки аның күңеле олы башын кече итеп кеше бимазалап йөрергә мәҗбүр булганлыктан рәнҗеп сыкрый, өзгәләнә иде.

Латифны Хәмзә шикләнеп, төксе чырай белән каршы алды. Ул беркемне дә көтми һәм беркемнең дә үзенә вакытсыз килүен теләми иде, ахры.

Латиф тешен кысып булса да үзенең ни өчен килүен, кем икәнлеген әйтеп эчкә узгач, Хәмзәнең йөзеннән хәтта шомлану билгеләре узды, ул ут яктысында Латифка бер мәл сынап карап торды.

Латиф эчкә кереп утыргач, әтисенең исем-фамилиясен һәм гражданнар сугышында Татар бригадасында хезмәт итеп сугышта үлеп калуын сөйләргә кереште.

Хәмзә, һаман сынап, ышанычсыз рәвештә Латифны күзләреннән кичерә иде әле.

— Юк, сез аны белергә тиеш,— диде Латиф,— чөнки аның миндә хатлары саклана. Анда сезнең турыда әйтелә.

— Әйе, мин Ибраһим Касыймовны яхшы беләм,— диде, ниһаять, Хәмзә.— Ул минем якын дустым иде. Вәхаләнки мин сезгә бернинди дә рәсми белешмә бирә алмыйм. Мин бары хәтердә калганнарын гына сөйли алам. Сезгә ни өчен кирәк булды ул? Эшегездә берәр... Әйе, бәлки эш линиясе буенчадыр?

Латиф: «Әллә бу сизенәме, әллә бу белә дә үкме?» дип уйланды. Сүз таба алмыйча, йөзен чытып башын түбән иде.

— Була, була. Төрле хәлләр була,— дип куйды Хәмзә.— Нигә соң сез мине баштарак күрергә ашкынмадыгыз? Мин бит Казан кешесе.

— Юк, аның кирәге һич эшемә бәйләнмәгән,— диде Латиф, соңгарыбрак булса да.— Мин сезгә тагы бер кабат әйтәм, Хәмзә ага, мине аның язмышы просто әти булганга күрә генә кызыксындыра. Еллар уза, мин һаман җыенам да җыенам. Әгәр үзең җиң сызганып керешмәсәң, беркайчан да аның язмышы ачыкланмаячак.

Хәмзәнең кара күзләре кысылып калды, ул бөтен гәүдәсе белән алга омтылды.

— Әллә аның турында берәр хәбәр ишеттегезме?

— Хәбәр дип, аның үлү хәбәре әллә кайчан мәгълүм инде, тик минем барлык төгәллегән беләсем килә.

Хәмзә тынычлана төште:

— Мин әллә аның турында берәр уйдырма ишетелдеме дип торам,— дип куйды.

Латиф иелгән башын сүзсез генә селкеде.

— Мин аның белән Казанда унтугызынчы елның язында, әле безнең Татар бригадасы оешкан чакта ук таныштым,— дип сүз башлады Хәмзә.— Безнең язмышлар бер төсле булгандыр, ахры, без бер-беребезне күрү белән үк дигәндәй, дуслашып киттек. Хәер, аның бер кызыклы вакыйгасы да булды. Мин авылдан күп кенә итеп азык-төлек алып килгән идем. Ә ул заманны, беләсез инде, ачлыгы да, ялангачлыгы да житәрлек булды. Вәхаләнки минем өйдә тормыш болай бик әллә ни шәп булмаса да, ярыйсы гына иде. Мин житәрлек ризык алып килдем. Ипие дә, мае, күкәе дә, дигән шикелле. Әни мәрхүмә, ашарсың әле дип, йомырка салмый торган бер тавыкны да суйдырып пешерде. Анда кагы, балы да әз-мәз бар иде. Шулай, без Казанга килеп төштек. Инде казармага урнашып тора башлавыбыз булды, икенче көнне үк минем капчыкны чәлдерделәр! Минем күршедә генә бер кара тутлы, чабаталы егет ята иде. Карыйм мин моңа, сәндерәсенә менеп ята да бу ашарга керешә, менеп ята да ашарга керешә. Ә кулындагы ипиеннән нәкъ минем ипи исе килә, итеннән дә нәкъ минем ит исе... Тукта, мин әйтәм, шулдыр әле йөзе кара угры. Шуышып бардым да тегенең якасыннан эләктердем.

— Син фәлән-фәсмәтән, нигә минем капчыкны урладың, мин әйтәм. Егет усал күзләре белән бер генә акаеп карады миңа, шуннан сәндерәдән үземне атты да бәрде. Мин көчсез егет дип саналмый идем, тик моның алдында бөтенләй зәгыйфь бер нәрсәгә әйләндем. Теге мине кибәк тутырылган капчык урынына гына ыргытты.

Синдә, ди, күз урынына ботак тишеге икән. Әнә, синең капчык идәндә аунап ята, ди. Аны теге очтагы җирән егет бушатты. Шуны бел, ди. Билгеле, бу кара чутыр, уенга катнашмаган булса, мин теге җирәнгә барып бәйләнә алмас идем. Тик күрәм, бу үзе көчле, үзе намуслы,

андый урлашу, алдашу кебек начар эшләрне күтәрә торган егет түгел. Шулай итеп мин күршем белән дуслашып киттем. Соңыннан мин аның Ибраһим атлы, Касыймов фамилияле егет икәнлеген дә белдем. Менә шулай таныштык без сезнең әтиегез белән.

— Шулайдыр, әни мәрхүмә дә аның бик батыр көрәшче булуы, сабан туйларында һәрвакыт батыр калганлыгы турында сөйли иде. Ә теге ризыкларыгызны таптыгызмы соң?

— Хәтерем ялгышмаса, ризыкның очына чыгып булмады. Аның байтагын егетләр бүлешеп ашап бетергәннәр иде инде. Дуслашып китүнең тагы бер сәбәбе шул булды, әтиегез, кызганып, үзенең капчыгыннан миңа да өлеш чыгаргалады.

— Шулай, сөйләүләренә караганда, ул бик юмарт та булган,— диде Латиф, җылынганнан җылына биреп.

— Ул бик көчле, бик шәфкатьле, хискә бик тиз бирелүчән бер кеше иде.

— Шуннан? Сөйләгез, зинһар, минем өчен аның турындагы барлык сүз кадерле.

— Шуннан безне рәткә китереп, хәл кадәренчә өйрәтеп, коралландырып, киендереп, дигәндәй, фронтка озаттылар. Мин шуны әйтергә тиеш, вәхаләнки сезнең әтиегез булмаса, мин харап булачак идем. Без отделениедән сезнең әтиегез белән икәү генә исән калдык, башка барлык иптәшләрне атлы казаклар шашка белән чабып үтерделәр. Бу сугышта әтиегез зур батырлык күрсәтте, дип әйтә алмыйм. Тик шуны әйтәм, без бөтенебез коелып, тетрәнеп төшкән чакларда да ул, нәрсәгәдер ышанып, үлемнән курыкмый иде. Әтиегезнең булдыклылыгы аркасында мин үлемнән котылдым. Бу вакыт инде мин, аллага ышангандай, бары сезнең әтиегезгә генә ышандым. Ул яшерен дисә, яшерендем, ят дисә, яттым, тор дисә, тордым. Шунардан кыюлыкка, батырлыкка өйрәндем. Хәтеремдә, без ниндидер күлдә камыш арасында аклардан яшеренеп яттык әле. Аннан шулай бик күп газаплар кичергәннән соң, үзебезнең исән калган иптәшләргә барып кушылдык. Безне бригадага иптәш Шәйхетдинов алып кайтты. Соңыннан аның үзен полк командиры итеп билгеләделәр. Менә шул.

— Шуннан?

— Шуннан инде без яңадан Самарада бөтәйдек, безгә корал бирелде, полкны тулыландыру булды. Вәхаләнки кораллandыру дигәч тә бүгенге көннәрдәге гаскәрне кораллandыру белән чагыштырмагыз, хәтта Ватан сугышы чорын да күз алдыгызга китермәгез. Ул, мин сиңа әйтим, барабыз Самар урамнарын яңгыратып стройда, Галиябануны җырлыйбыз, ә үзебезнең өс-баш көләрлек тә, еларлык та. Менә дәрт бик көчле булган инде!

— Ә әти белән сез һаман дуслар инде?

— Әтиегез белән болай. Без аның белән Җаек суын кичкәнче бергә, бер пулемет расчетында булдык. Җаекны кичкәндә ул яраланды. Яраланганнан соң аны бригада лазаретына җибәрделәр. Ә аннан кайткач инде ул минем белән бергә булмады. Мине икенче взводка күчерделәр.

Хәмзә, әйтергә микән, юк микән дигәндәй, икеләнеп уйланып торды. Моны Латиф сизенде.

— Барысын да сөйләгез,— диде ул, үтенеп.

— Болай алайса. Әтиегезнең ярасы әйтерлек куркыныч түгел иде. Ул лазареттан бик тиз савыгып чыкты. Савыгып чыкты бу шулай. Без сирәк-мирәк кенә күрешкәлибез. Ләкин алай да мин мондагы ниндидер бер үзгәрешне тоям. Егетнең күз карашлары бөтенләй башка. Вәхаләнки көннәрдән бер көнне бу таки миңа серен чиште бит. Безнең лазаретта бик чибәр, бик акыллы шәфкать туташлары бар иде. Аларның икесе Саиновалар — Мәрьям белән Гайшә — безнең бөтен бригаданың сөек-

ләре иде инде. Менә шул татар кызлары арасында тагы Талия Котдусова дигәне дә бар иде. Әтиегезне шул карап дәвалаган икән.

— Шуннан?

— Шуннан шул, әтиегез аңа, ә ул әтиегезгә гашыйк булган. Шуннан соң мин Ибраһимовның һәрвакыт шул кыз турында сөйләгәнен ишетә идем. Алар чын мәхәббәт белән яндылар.

— Ә ул Талия кем иде соң, нindирәк кеше?

— Ул, минем белүемчә, Алафузов заводында эшләгән бер Казан эшчесенең кызы. Чын мәгънәсендә революция тудырган яңа кеше, комсомолка иде...

— Шуннан соң мин аларны еш күрә башладым,— дип дәвам иттерде Хәмзә.— Ә әйе, шуны әйтим әле, Казалинскида шактый зур бер җанҗал булып алды. Анысы инде Төркстанга барышлый. Ул вакытны сезнең әтиегез нindидер сәбәпләр аркасында икенче полкка барып эләккән иде. Шунда шул җанҗалда әтиегезнең катнашуы булганлыгын сөйләделәр миңа. Ул вакытны ул взвод командиры иде. Шуннан соң бу фетнәчеләрне, аларның башлыча командир булганнарын, икенче полктан алып, башка полкларга тараттылар. Әтиегез янадан безгә кайтты. Ләкин ул хәзер безнең ротада түгел иде. Аны рядовой иттерделәр, ахры. Бер очрашканда мин аннан Талия турында сораштым. Ләкин ул миңа карап кул гына селтәде. Чөнки Талия сезнең әтиегездән йөз чөергән. Әле алай гына да түгел, әнә шул Казалинскида полк комиссарына кияүгә чыккан. Әтиегезнең ул фетнәгә катнашуы да әнә шунын аркасында булырга тиеш.

— Гаҗәп хәлләр! Мин тудырган образдан әти ераклаша бара.

— Юк, әгәр сез әтиегезне начар күңелле кеше итеп күз алдына китерсәгез, бик ялгышасыз. Ул Талияне өзелеп яратты. Соңгы тапкыр мин әтиегезне Иске Бохара урамнарында сугыш барганда күрдем. Ул инде отделение командиры иде. Бу минем аны соңгы тапкыр күрүем булды. Мин, истәлекләремдә язганча, Бохара шәһәренә беренче булып барып кергән кызылармеец. Каршы капкасына туптан атып җибәрүләре белән, без ябырылып эчкә ташландык. Бу иртәнге тугызларда булды. Көндезге уникеләрдә, урам сугышлары бик кызган чакны, мин сезнең әтиегезне урамда очраттым. Ул каты яралы иде. Пуля аның күкрәгенә, нәкъ йөрәк турысына тигән иде. Без аны иптәшләр белән шунда ук санитарларга тапшырдык.

Хәмзә тынып торды. Латиф тирән хәсрәт кичергән хәлдә яралы әтисен күз алдына китерергә тырышты. Ләкин ни өчендер каһарман ата җанланып гәүдәләнми иде.

Латиф сорау бирде:

— Ә ул исән идеме әле? Сез очратканда дип әйтүем...

— Әйе, без күргәндә исән иде. Ләкин аның шул ук төнне үлгәнлеген миңа икенче көнне лазаретта хәбәр иттеләр.

— Аның каберендә булырга туры килмәдеме?

— Мин аның кайсы туганнар каберендә ятканлыгын әйтә алам, күрдем. Ә ул үлгәндә аның янында була алмадым. Беләсез бит, сугыш бара...

Латиф ирексездән кулларын җәеп өнсез калды. Бер секунд эчендә аның башыннан төрле юраулы уйлар өермәсе узды. Тәгаен шулайдыр әле. Канлы сугышта, Совет власте өчен барган сугышта ул батырларча үлгәндер.

— Карагыз әле,— диде Хәмзә, елмая төшеп.— Сезгә минем турыда кем әйтте? Аңлавымча, сез безнең тарихтан бик ерак тора торган кеше.

— Анысы шулай, ерак торам ул фәннән. Ләкин ярдәм кулын сузарга әзер торучы кешеләр юк түгел бу дөньяда. Минем бик шәп, Альфред Хәйретдинов дигән булышчым бар. Бик эшчән егет. Шул сезгә барырга киңәш итте.

Латиф Хәмзәгә рәхмәт әйтеп аның кулын кысты һәм урамга чыкты. Шофер, кабинасына бикләнгән килеш, бирелеп китап укый иде. «Киттек»,— диде Латиф, һәм:— «Управлениегә»,— дип өстәде. Җепшек кар ява иде. Бөтен тирә-юньне соры, авыр билгесезлек каплаган. Нигә һаман күңелсез әле миңа? дип сорады Латиф, хәер, дип уйланды, артык арылган. Юкса бик ачык әйтте бит инде карт. Шофер машинаның алгы пыяласындагы себергечне җибәрде дә стартерга басты.

Латифка хәзер кинәт җиңел булып китте. Ахмаклык түгел диген инде! Шул көннән бирле, оп-олы башы белән, шундый провокациянең корбаны булып йөри ул.

Ул күгелҗем кар белән өртелгән урамга һич кызыксынусыз карап куйды һәм үз алдына ачынып елмайды.

Бүген үк, бүген үк дип уйланды ул, тиешле оешмасына хәбәр итәргә кирәк, тапсыннар, белсеннәр, нинди кабахәте провокацияли икән аны?! Бәлки дошман эшедер? Ләкин хикмәт шунда, ни өчен мин кирәк булганмын аларга?

Латиф уйлап-уйлап очына чыга алмады. Чыннан да, ни өчен Латиф кирәк булган аларга? Юкса аның хезмәт өлкәсе бернинди дә серле урын түгел бит.

Ул, ирексездән, узган тормыш юлын айкарга кереште. Бәлки чыннан да кайчандыр аларны кызыксындырырлык берәр нәрсә булгандыр? Әйтик анда, аңа кайчандыр берәр сер тапшырылгандыр, яки башкача. Юк, юк. Бер нәрсә дә юк. Ул уку йортын бетереп инженер-механик исемен алды һәм җирле промышленность системасындагы заводларның берсендә тырышып эшли башлады. Ул бераздан үзенең киләчәгенә карап фикер йөртергә кереште. Бәлки тегеләр киләчәк перспективаны күздә тотып эш итә торганнардыр? Әйе, Латиф министрлыкның иң булдыклы кешеләреннән санала. Ул күптән шуны тоя: аны бүген булмаса иртәгә, трест управляющие итеп куюлары мөмкин. Ләкин моңа риза булырмы әле Латиф?

Латиф, ни дип уйларга да белмәстән, җилкәләрен җыерып куйды. Күрәсең, уйларына артык бирелеп, ул мимикасын беренче тапкыр гына үзгәртми иде. Кузгалып киткәннән бирле Латифны күзәткәләп барган шофер сорамый түзмәде:

— Сезне бик борчуга салып чыгардылар, ахры, Латиф Ибраһимович?

Латиф кинәт сискәнеп китте:

— Киресенчә,— диде, елмаеп.

## XVIII

Латиф иртәгесен эшне Дәүләт иминлеге комитетына хәбәр итәргә булды. Шуның белән барлык ахмак борчулар эфирдай һавага очып, юкка чыгарга тиеш иде. Бик уйлап хат язарга кирәк иде. Латиф, маңгаена учын куеп, күңеленнән җөмләләр тезә башлады. «Көтелмәгән вакыйга мине сезгә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итә. Мин шушы көннәрдә чит илдән бер хат алдым. Аннан килгән хатның провокация икәнлеге көн кебек ачык. Кемдер миңа әткәм исеменнән хат яза. Кемдер шундый ялган ысуллар кулланып минем белән якын элемтәгә, бәйләнешкә кермәкче була. Хәлбуки минем әтием үлгән, моны мин, кирәк булса, шаһитлар ярдәмендә теләсә кайчак исбат итә алам». Ничегрәк булыр шулай язганда?

Латиф язылачак сүзләрнең тәэсирен күз алдына китерергә тырышты. Менә анда берәр иптәш укып чыга да Латифка: «Гафу итегез, сез әтиегезнең үлгәнлеген анык беләм дисез инде?» ди. «Әлбәттә, шулай. Ул бик күп еллар элек булган вакыйга. Моны барлык кеше белә. Мәсәлән,

минем әнием»... «Туктагыз әле, әнигез аның үлгәнен күргәнме?» «Күрмәгән». «Ә кем күргән?» Шушы урында Латиф борчыла башлый. Әйе, тукта, ничек инде? Теге Бакиров Хәмзә дә үз күзләре белән күрмәгән бит аның үлгәнен, аңа бары кемдер әйткән генә, кемдер аңа менә шушы туганнар каберендә ята диган...

Латиф урынынна торды да әрле-бирле йөренә башлады. Ачык форточкадан кергән һава агымы түшәмнән идәнгәчә төшкән ак ефәк тәрәзә пәрдәсен җиңелчә җилбердәтә иде. Латиф, тәрәзә аша урамны бераз күзәткәннән соң, үз алдына көлеп куйды.

— Җүләр мин,— диде ул.— Кеше әйтеп тора. Ә мин фәлсәфә сатам.

Ул шул ук көнне хатны, үзеннән кыска гына аңлатма өстәп, тиешле оешмага тапшырды.

Өч-дүрт көннән соң авыр кичерешләр артта калды. Барысы да диярлек онытылды. Трест башлыгының урынбасары Латиф Ибраһимов нәкъ элекке халәтенә кайтты.



## XIX

Звонок булырга тиеш иде инде, ләкин ни өчендер Фәйрүзә апаның кыңгырау чыңы ишетелми әле. Альфред укытучылар бүлмәсендә утыра. Ул китап-дәфтәрләрен тәртипләп өеп куйды да, йодрыкларын чигәсенә терәп, звонокны көтә башлады. Каршысында утырган карт укытучы хатын үзе җитәкли торган классның журнал битләрен тикшереп, әледән-әле ачынып башын чайкый иде. Ул, нидер әйтергә теләп, Альфредка карады, ләкин өлгерә алмады, ишек төбендә үк Фәйрүзә апаның кыңгыравы чылтырый башлады. Ансыз да гөрләп торган коридорда тавыш тагы да көчәйде. Бермәл колаклар тонып калды. Бер минуттан соң бөтен тирә-юнь тынлыкка чумды. Альфред та, башка укытучылар да классларга керү өчен кулларына укыту әсбаплары алып, эшлекле бер кыяфәттә ишеккә таба юнәлделәр.

Бүген җиденче класста яңа тема башланырга тиеш иде. Укыту мөдиренең уйлары ул класс ишегеп ачканда да шуның турында булды.

Альфред күренү белән класс кинәт тынып калды. Аннан парта капкачлары шапылдый башлады. Балалар барысы да аякка бастылар. Бу класста да Альфред иләшкән, хәттә яраткан, күп тапкырлар сыналган, таныш укучылар иде. Ул аларның һәрберсен белә. Алар әллә ни матур киенмәгәннәр. Хәтта күпчелеге артык гади киенгән. Кызларның барсыныкы да диярлек чәчләре үреп таралган, малайларның чәче киртәртелгән. Аның каравы балаларның йөзләре аз гена дә шәһәрдәге үз иптәшләренекеннән аерылмый. Шундый ук шук, кызыксынучан җанлы күзләр, беркатлы, тере, хәрәкәтчән йөзләр. Кызыксыну артыграк та түгел микән әле биредә.

Альфред гадәтенчә: «Исәнмесез, укучылар, утырыгыз»,— диде. Парта капкачлары тагы дөбердәшеп куйды.

Альфред үзенә текәлгән йөзләргә карап чыкты.

— Без бүген, укучылар, яңа тема башлыйбыз.

Альфред инде яңа теманы аңлатырга җыена иде. Алгы партада утыручы, йөзен сипкел бизәгән саргылт чәчле малай кул күтәрде.

— Соравың бармы әллә, Өлфәт?

Малай аягүрә басты.

— Минем бер соравым бар иде, Альфред Яхич.

— Я?

Альфред малайның яшькелт күзләренә текәлде.

— Менә шундый сорау,— диде малай.— Элек бит рус дәүләте Новгород һәм Киев кнәзлегендә генә булган. Ә аннан соң үсеп Ерак

Көнчыгышка кадәр барып җиткән. Мин һаман аңламыйм. Ничек булды икән ул?

— Нәрсә димәкче буласың син, Өлфәт, фикереңне ачыграк әйт,— диде Альфред.

— Патшалар баскаклар булганмыни? дип...

Альфред сабыр рәвештә барысын да аңлатырга кереште. Балаларның күз алдына тарих сәхифәләрен китереп бастыру өчен барлык тапкырлыгын җикте. Канлы, кыргый сугышлар, таркау кнәзлекләрдән торган рус иленең көч-куәт алып үсүе, ныгуы, ахыр чиктә төрле чит ил илбасарларына каршы тора алырлык күп милләтле Россия дәүләтенең дөньяга килүе. Бу тарихи зур вакыйганың ахыр чиктә барлык халыклар өчен дә уңайлы булуы, ул илдәге халыкларның бергәләшеп уртак туган илне чит җир дошманнарыннан саклавы, ниһаять, кулга кул тотынышып сыйнфый дошманнарына каршы көрәшүе, ахырда Россия пролетариаты җитәкчелегендә бөтендөнья тарихының иң гүзәл сәхифәсен — Октябрь революциясен ясауларын сөйләде. Альфред бу очракта вакыт кызганып тормады. Бер Өлфәт өчен генә булса да, шундый сорау туган икән, тулы итеп, төрле шикләнүләргә урын калмаслык җавап бирергә кирәк дип уйлады ул. Һәм үзенең максатына бераздан ирешкәнлеген укучыларның күзләренә, йөзләренә карап тойды да ул.

— Башка сораулар юкмы? — диде. Класс бердәм: «Юк»,— дип кычкырды.— Алайса яңа теманы башлыйбыз,— диде Альфред.

Альфред класcның үзен яратуын аңлаган, тойган хәлдә күтәренке күңел, хәтта эчке куаныч, шатлык белән сүзгә кереште. Хәлбуки алай шатланырга кирәкмәс иде. Чөнки директорның шушы класста укый торган улы, өенә кайткач, һичбер явыз нияте булмаса да, әтисенә чәчмитүкми барысын сөйләячәген уйламый иде ул.

Ике көн узгач, Альфредны директор үз бүлмәсенә чакыртып кертте.

— Утыр әле, сүз бар сиңа,— диде.

— Утырдым, Халит абый, тынлыйм,— диде Альфред, һич аны-моны сизмичә, елмаеп.

— Ләкин эш бер дә елмаерлык түгел,— диде директор, ачуыннан кызарына төшеп. Альфредның кашлары тартышып куйды.

— Менә нәрсә,— диде Халит бөтенләй ят, салкын бер тавыш белән,— синең белән районда сөйләшергә телиләр.

— Нинди мәсьәлә буенча?

— Анысын әйтерләр.

Альфред аптырап җилкәләрен җыерды.

— Нинди табышмак ул, Халит абый, нигә әйтмисез?!

— Нигә әйтмимме? Чөнки белмим.

— Ә белмәгәч, нигә кирәк андый төкселек.

— Төкселек...

Альфред тәмам аптырашта калды. Утырган урыныннан торды да директорга карамыйча гына:

— Кайчан барырга? — дип сорады.

— Мөмкин кадәр тизрәк.

Халит сәгатенә карап куйды.

— Бүген барып өлгермисең инде. Иртәгә иртәнге яктан китәрсен.

— Ә дәресләр?

— Бу дәресләрдән мөһимрәк.

Альфред, авыр тойгылар аркасында ишекне ябарга да оныткан хәлдә, чыгып китте. Директор торып үзе бу эшне башкарды. Аның нәрсәдер әйтеп, сукранып калуы ишетелде.

Бу нинди эш тагы! Нәрсә уйлый бу Халит абый?! Шулай ук теге көнне Татар бригадасы командирының истәлекләрен уку шундый тәэсир ясады микәнни, дип уйланды Альфред. Ул укытучылар бүлмәсенә керде, үз өстәле янына барып утырды. Аның ни сәбәптәндер тетрәнгән-

леген, әлбәттә, беренче булып Луиза абайлады. Ул инде иренең директорга чакырылуын ишеткәч тә сагайган иде. Ара-тирә Альфредка карап аны күзәтә башлады. Альфред исә дәшми-тынмый кашларын җыергалап утыруында булды. Ниһаять, ул башын күтәрде дә үзенең уң ягындагы өстәл янында утырган, шома итеп таралган кап-кара чәчле химия укытучысына мөрәҗәгать итте.

— Нәгыймә Сәлимовна, хәзер сезнең дәресегез бит.

Хатын сораулы караш белән башын күтәрде.

— Әйе.

— Мин сезнең дәрескә кереп утырмакчы булам. Сездә күптән булганым юк.

Хатынның ап-ак йөзе алсуланып китте.

— Ихтыярыгыз, Альфред Яхич.

— Шулай шул,— диде укыту бүлеге мөдире, уйланып,— күптән кергәнем юк.

Ул химия укытучысының дәресенә керде. Альфред яшь укытучыны бик хөрмәт итә, аның дәресләрен ярата һәм кергән саен горурлык хисләре һәм күңел тынычлыгы алып чыга иде. Тик бу юлы әллә укытучы юньләп әзерләнмәгән, әллә каефсез, дәрес көтелмәгәнчә начар узды. Һәрхәлдә, Альфредка шулай тоелды. Ул химия дәресеннән, тынычланасы урында, тагы да ярсый төшеп чыкты. Үзен барлык көченә җигеп кулга алды. Укытучының хәтерен калдырмау өчен соңыннан дәресне тикшергәндә барысын да әйтеп бетермәде, ләкин бу әңгәмә шулай да дәресне теткәләп ташлау булып чыкты.

## XX

— Луиза! Мине ни өчендер районга чакыртканнар,— диде Альфред, ишектән керү белән.

Луиза түр якта Шамилне итәгенә утырткан килеш чәй эчә иде. Хатынының дәшмәвенә аптырый төшеп, Альфред киез итекләрен мич башына ташлады да эчке бүлмәгә оекчан гына узды. Ул тәмам якынлашкач, хатынының өстәлгә иелеп тавышсыз гына елавын абайлады.

— Я, нәрсә инде тагы?! Әллә Шамилгә бер-бер хәл булдымы? — диде ул, куркынып.

Луиза яшькә чыланып беткән йөзен иренә таба борды.

— Шамилгә, Шамилгә,— диде ул, борынын еш-еш тартып,— син үзеңне бел. Шамилне кызганган булып кыйлана але! Үзем турында әйтмим дә инде.

Альфредның күңелендә шомлану ускәннән үсте, ләкин ул һаман хатынын күзәтеп торды. Луиза сүзен дәвам иттерде.

— Бераз гына ичмаса замана кешесе булыр идең. Дон-Кихот биг син, кемгә кирәк бу җүләрлекләрең синең! Аны кеше иттеләр, укыттылар, инде үзен укыту мөдире итеп күтәрделәр.

— Тукта, син нәрсә сөйлисең соң, Луиза? — диде Альфред, артык түзә алмыйча.

— Белмәгән булып кыйлана әле! Нинар эшләгәнеңне белмисеңмени? Әллә синең һәр эшеңә риза булып торырлар дип уйлыйсыңмы?

— Син әйтәсеңме, юкмы, наконец? — дип кычкырды Альфред,— нәрсә минем нервыда уйныйсың?!

Луиза яшьле күзләрен тутырып иренә карап торды да шактый тыныч тавыш белән:

— Әнә синең турыда балаларың районга жалоба язып җибәргәннәр,— диде.

— Нәрсә дип?

Луиза тагы ирене карап торды.

— Әнә шул тарих актаруларың турында инде...

Ул артык ни әйтергә дә белмәстән тынып калды.

— Белдем алайса,— диде Альфред,— барысы да Әхмәдиев эше. Әллә нишләде ул кеше!

— Ну, ничек син Халит абый эше дип әйтә аласың! Әйтеп торам ич, укучылар дип.

— Ә син каян беләсең аны?

— Беләм. Миңа Саимә апа әйтте.

Саимә апа дигәне математика укытучысы, җиденче классның җитәкчесе иде.

— Ә ул каян белгән?

Луиза бу кадәресен анықламазын аңлатып, иренен бүлтәйтеп куйды. Аннан:

— Аңа балалар әйткән булса кирәк,— диде, бераз уйлангач.

Альфредның гасабилануыдан йөзе кызарган иде. Ул чынаякка текәлгән килеш уйга калды. Кинәт Луизага ире үтә кызганыч булып тоелды. Хәзер инде хатын гарьлегеннән түгел, ә ирен кызганганга күрә дә еларга әзер иде.

— Кая соң безнең Җәзилә апа, әллә тагы киттеме? — диде Альфред, һич көтелмәгән сорау бирер.

— Юк, монда гына, күршедә генә. Асия апаларда.

Альфред бер сүз дә дәшмичә алдындагы кастрюльдән тәлинкәгә кайнар аш сала башлады. Ул бик ачыккан иде. Парланмасын өчен көзлеген өстәлгә куеп, пешә-пешә ашарга кереште. Ул ашый, ләкин ашаганын тоймый иде, ахры.

— Син борчылма, Люлю,— диде ул, тәлинкәсен читкә этеп,— миңа берни дә булмас, мин РОНОда аңлатырмын. Мин ничек аңласам, намусым ничек кушса, шулай эш итәрмен.

— Син кирәгеннән артыгын да сөйли башларсың әле анда. Мин сизенәм. Чөнки артык ярсыгансың.

Альфред чынаягына термостан су коеп алды һәм банкадагы болгар конфитюрын калак белән каерып-каерып кабып чәй эчәргә тотынды. Алар байтак вакыт ашау-эчү белән генә булаштылар.

— Ай, онытканмын да,— диде кинәт Луиза, урыныннан торып,— мәле баланы.

Альфред улының исен, йомшак тән җылысын тою белән ниндидер бер рәхәт нәрсәгә орынгандай булды. Шамил юеш авызын ачып шатланып елмайды да әтисенең борынынна эләктереп алды. Альфред улының нәни кулын авызына капты.

— Бүген Мәскәү эстрада концерты бирә ич,— диде Луиза, телевизорны тоташтырып.

— Шулаймы? Әйдә бераз тыңлыйк. Тик озакка түгел, минем дөнья кадәр дәфтәрем бар.

— Үземнең дә карыйсы эшләрем муеннан,— диде Луиза, телевизорны көйләп.

Альфред һаман улы белән шаярып утырды, ләкин бераздан шулай да концерт аны үзенә җәлеп итте.

Ишек ачылганы ишетелде.

— Җәзилә апа! — диде Альфред.

— Җәзилә апа, кайда йөрисең инде? — дип кычкырды Луиза,— аш суынып бетте ич!

— Ярар, ярар,— диде Җәзилә апа. Ул йомры гына, елдам гына бер карчык иде.— Мин әле Асияләрдән бик сыйланып кайтып киләм. Кайда, үзебезчә кәнсирт бирмиләрме соң?

Җәзилә апа, бүгенге концертка теше үтмәслеген аңлагач, табынны

җыештырып, алгы якка чыгып китте. Луиза башын картының җилкәсенә салды. Альфред аны биленнән кысып тотты.

— Альмам, иртәгә тәти генә сөйләш инде, бәгырем, яме,— диде Луиза, үтенеп.

## XXI

Иртәгесен аның белән район мәгариф бүлегендә мөдир үзе сөйләште. Альфредка моңарчы аның карашы начар булмады. Мөдир дә вакытында университет бетергән, шактый тирән белемле интеллигент кеше иде. Ул районга Альфред килгәч, алдын-артын уйлап, анык бер максат белән, Альфредны Әхмәдиев мәктәбенә җибәрде. Күңел төбендә бу егетне сынап, аннан үстереп, директор итеп калдыру иде. Чөнки Әхмәдиевнең кимчелекле яклары шактый күп. Аның артык гади кеше булып кыйланганлыгын, ә дәреслектә шуның белән аз белемле икәнен яшерергә тырышуын ачык күрә иде ул. Һәм, әйтергә кирәк, Альфредның завуч булып күтәрелүендә мөдирнең дә роле юк түгел иде.

Альфред исә шулай ук бу кара тутлы, зифа буйлы, һәрвакыт ак яка, кара галстуктан йөрүче Сәгыйдуллинны хөрмәт итә иде. Әле мәгариф бүлегендә үзенә туп-туры мөдиргә керергә кушылгач, ул шактый иркен сулыш алды. Һәрхәлдә, аның белән ачыктан-ачык сөйләшергә, аңлашырга була иде.

— Карагыз әле,— диде мөдир, утырырга урын күрсәтеп һәм кул биреп,— нәрсә булды сезнең анда?

— Мин үзем шуны ачыклау өчен килдем, иптәш Сәгыйдуллин. Ишеткәннәрем дөрес булса, минем өстән кемдер жалоба биргән. Аңлатыгыз, зинһар.

Сәгыйдуллин сүзне ничек башларга белмичә, Альфредка карап торды. Завучның бик гасабилануын чамалау артык авыр түгел иде. Ләкин берни эшләр хәл юк. Вазифа турысын әйтергә мәҗбүр итә.

— Менә болай алайса,— диде ул,— турысын әйткәндә, сезнең өстән жалоба бар. Ә бу нәрсә, үзегез беләсез, уен эш түгел. Сезгә аңлатып торасы юк, без балалар тәрбияләү эшендә интернационализм принципларын күз алмасыдай сакларга тиеш.

Альфред утырган килеш кыбырсып куйды, аның сызылып киткән матур кашлары тагы да катырак кысылдылар. Ул күзлеген салып, һич кирәкмәсә дә, яулыгы белән шуны сөртә башлады.

— Мондый жалобаны кем язган?

Мөдир, якасы кыскандай, башын боргалап куйды.

— Иптәш Әхмәдиевме? — дип сорады Альфред.

— Мин хәзергә анысын әйтмим...

— Мин нәрсә эшләдем икән соң? — диде Альфред, басынкы тавыш белән.

— Язуга караганда, вакыйга җомга көн җиденче класста булган.

— Тулырак итеп сөйләгез, зинһар, иптәш Сәгыйдуллин.

— Шуннан тулырагын сез сөйләгез инде. Мин сезне шуның өчен чакырдым да. Ничек булды соң? Ягез әле хәтерләгез.

— Җомга көн, җиденче класс...— диде Альфред, уйланып.— Ничек булды? Мин дәрескә керү белән, программадан һич читкә чыкмыйча, яңа тема башладым. Тема...

— Ә аннан алда? — диде мөдир, бүлдереп.

— Алда...— Альфред бераз уйланып утырды һәм кинәт яктырып,— әйе, бер бала сорау бирде. Ул рус дәүләтенең киңәюе белән кызыксынды.

— Ә сез ни дип җавап бирдегез?

— Мин Россиянең куәтле бер дәүләткә әйләнүе өчен таркау князьлекләрне берләштерү кирәкле булуын аңлаттым.

— Шуннан тагы нинди сорау бирделәр?

— Шуннан?

Альфред хәтерләргә тырышып азапланды.

Сәгыйдуллин тирән итеп көрсенеп куйды. Күрәсең, аның тагы да нидер ишетәсе килә иде.

— Сез әйтегез әле, кем минем өстән шундый серле әләк яза? — диде Альфред, кинәт кабынып,— әйтегез, Әхмәдиев иптәшме? Әгәр ул икән, ни өчен соң минем белән ачыктан-ачык сөйләшми? Ни өчен ул минем белән ачыктан-ачык бәхәсләшми? Андый мәсьәләләрне бәхәс аша да коллективта да хәл итеп була бит. Әйтегез, зинһар, үз кул астындагы кеше өстеннән жалоба язу бу бит бер дә егетлек түгел. Мин бу юлы да ул үзедер дип уйлыйм. Чөнки жиденче класста аның улы укый. Баладан сөйләткәндер, арттырып-бутап сезгә җиткергәндер...

— Ә ни өчен ул мондый эшкә барсын! Ул бит теләсә нинди очракта да оттыра...

— Мин аңламыйм инде алайса. Димәк, сез, ут төтенсез булмый, аның минем өстән язып бирүе нигезле, димәкче буласызмы?

— Мин, беренчедән, сезгә ул язган дип әйтмәдем шикелле. Икенчедән, сигнал булгач, мин сезнең белән сөйләшергә тиеш идем.

— Сез миннән яшерсәгез дә, мин һаман бу жалобаны иптәш Әхмәдиев язган, я инде ул булмаса, шуның кушуы буенча язганнар, ул оештырган дигән фикердә калам.

— Анысы сезнең эш.

— Әгәр беләсегез килсә, директорның миңа каныгуы сәбәпсез түгел. Менә җайсызрак килеп чыкты. Мин, вакыты җиткәч, үзем сөйләп-киңәшеп утырыр өчен сезнең янга килергә җыенган идем. Алданрак булса да әйтми булмый. Хәлләр мәҗбүр итә.

Никадәр тыныч калырга теләсә дә, Сәгыйдуллинның бу хәбәр белән кызыксынганлыгы Альфредка ачык күренде. Бераз паузадан соң Альфред сүзен дәвам иттерде.

— Эш менә нәрсәдә, иптәш Сәгыйдуллин. Мин бер елдан артык инде профессор Даутов кул астында гыйльми эш башкарам. Һич вакыт җиткерә алмыйм. Ә темам бик күңелле, кызыклы. Эчкәрәк кергән саен тагы да өр-яңа горизонтлар ачыла... Кыскасы, мин профессорның киңәше буенча университетка күчәргә булдым. Әлегә тоткарлык бары вакансия юклыгында гына. Әнә шул расланмаган. Димәк, ул булу белән мин мәктәптән китәргә тиеш булам.

— Без сезне җибәрмибез,— диде Сәгыйдуллин, кискен рәвештә.

— Менә шул ук сүзне миңа Әхмәдиев тә әйтте. Инде мине куркытыр өчен, ахры, ул пычратып ташларга тырыша. Мин аның тактикасын аңлыйм. Ул яңасе мине яман атлы иттерә дә университетка узмаслык хәлдә үзе янында асрый.

Сәгыйдуллин көлеп җибәрде.

— Әгәр сез яман атлы буласыз икән, завуч булып кына түгел, бездә педагог булып та эшли алмаячаксыз.

— Менә, менә, шуны тели дә инде ул, күрәсең.

— Юк, юк,— диде мөдир, кискен рәвештә каршы килеп,— эш, минемчә, бөтенләй сез уйлаганча түгел. Әгәр, әйтик, ул сезне җибәрмәскә теләсә, киресенчә, сезгә яхшы шартлар тудырып, сезне үзенең игътибары белән сүзеннән чыкмаска мәҗбүр итәр иде. Эш башкада.

— Белмим. Сез күңел түрендә ул хаклы дигән фикер сакламыйсыздыр ич?

— Мин ул дип бер сүз дә әйтмәдем сезгә. Ә менә жалоба язучының хаклы булуы да мөмкин. Һәрхәлдә, районо мондыйны ачыкламыйча кала алмый, туган.

Альфред дәшмәде. Сәгыйдуллин аягүрә басты.

— Менә болай. Сезнең дәресләрегездә үзем булырмын, әгәр үзем була алмасам...— Ул тынып торды.— Һәрхәлдә, шушы көннәрдә комиссия көтегез. Мин шуннан соң сезгә үземнең соңгы сүземнә әйтермен...

## XXII

Альфред, тимер юл станциясенә җиткәч, уйга калды. Аның бу минутта һич өенә кайтасы килми иде. Ләкин ул нинди дә булса башка берәр юл да күрми иде.

Альфред, җирле поездлар расписаниесенә текәлгән хәлдә, һаман икеләнеп торды. «Карале, ярты сәгатьтән соң бер поезд Казанга китә икән,— дип уйланды ул.— Ә авылга поезд әле ике сәгатьтән соң гына була. Әллә Казанга барып Рәфкать абый белән киңәшеп кайтыргамы икән?»

Ул Казан поездына утырып китәргә булды. Юлга чыкканчы өендә җүнләп ашамаган иде, вокзал буфетына кереп, тамак ялгап алды; ул арада поезд да килеп җитте.

Казанда ул иң беренче эш итеп университетка барырга, профессорны күрергә булды. Ләкин, уйлана торгач, ул бу фикереннән чигенде. Ничектер зарлану, хәтта әләк кебегрәк бер нәрсә килеп чыга иде. Бары теге мәсьәлә, штат мәсьәләсе, хәл ителмәде микән. Ул бары шул максат белән генә университетка кереп, профессорның кабинет ишеген шакыды.

Профессор аны үз итеп, ләкин, гадәтенчә, бераз таркаурак бер кыяфәттә каршы алды.

— Оныта язганмын,— диде ул, сүз Альфредның эше турында беткәннән соң.— Сезне теге могтәбәр иптәш тагы күрергә тели.

— Нинди «могтәбәр иптәш»?

— Соң теге инде.— Профессор исенә төшерә алмыйча, газап чигеп, бармакларын уып утырды.— соң теге инде... Латиф Ибраһимович.

Альфред яктырып китте.

— Мин аңа Хәмзә Бакиров белән сөйләшергә киңәш биргән идем, нәрсә булып бетте икән?

Профессор ул кадәресен белми иде.

Альфред кесәсеннән телефон номерлары, адреслар язылган куен дәфтәрен чыгарды.

— Сез хәзер үк шалтыратып белешә аласыз,— диде профессор,— бәлки китмәгәндер әле.

Профессорның әһәмиятле эшләре бар, ахры. Ихтимал хәзер аның бик җитди чыгышка әзерләнеп утыруыдыр, бәлки ул лекциягә җыенадыр. Ни булса да ул ялгызлыкта калырга тели иде кебек. Альфред моны аңлау белән урыныннан торды, теге штат турында да сорарга кыймады. Булса үзе әйтер иде. «Гафу итегез», дип урыныннан кузгалды.

Коридорга чыккач, ул үзенең Казанга һич кирәкмәскә вакыт әрәм итеп килгәнлеген тойды. Чыннан да, әйтерсең лә, аның бер дә эше юк, әйтерсең лә, ул ни эшләргә белмичә йөри торган бер сорхантай!

Альфред ашыгып университеттан чыкты да Ленин урамы буйлап Кремльгә таба китте. Ичмаса, архивта кирәкле материаллар әзерләнгән булса иде. Ә бәлки Альфредның йомышын үтәгәннәрдер, узган атнада ук табып бирегез, дигән папкалар бәлки хәзер гадәттә Альфред эшли торган өстәлдә ятадыр? Иң яхшысы эшкә чуму. Ул әле олыгайган кеше булмаса да, үзенең булган тәҗрибәсеннән чыгып та, иң зур юаткыч нәрсәнең хезмәт, сөелеп эшләнә торган хезмәт икәнлеген яхшы белә иде. Альфред, озак уйланмастан, туп-туры дәүләт архивына юнәлде. Чыннан да, анда берничә папка документ табылган, өстәлдә ята иде. Кәгазьләр арасында актарынганда Альфред үтә кызыксыну белән бер

язуны укырга кереште. Ничектер эш кәгазьләре арасына эләккән донесениедә бер рота командиры Бохараны штурмлаганда батырларча үлгән кешеләр турында яза иде. Шәһитләр арасында Ибраһим Касыймовның да исемен күреп Альфред уйга калды. Ул профессорның әле моннан ярты сәгать элек кенә әйткән сүзләрен хәтерләде. Ул бит шул Ибраһим Касыймов улы Латиф Ибраһимов турында әйткән иде.

Чыннан да, менә бит аңа кирәкле документ! Альфред ашыгып киенде дә урам аръягындагы автомат телефон будкасына юнәлде. Поезд китәргә бер сәгать вакыт бар әле. Альфред Латифка үзенең килергә җыенуын әйтеп шалтыратты.

Алты-җиде минут узмагандыр, ул трест управляющие урынбасары кабинетында иде инде. Латифның күңеле күтәренке иде, ул кунагына кәнәфигә урнашырга тәкъдим иткәч, алгы якка чыгып, секретарьга хәзергә кабинетка беркемне дә кертмәскә кушты.

Үзе утыргыч алып килеп Альфред каршысына утырды, өчпочмаклы карсак өстәлгә кыйммәтле папирос ачып салды.

— Эш болай тора, Альфред иптәш,— диде ул, кәфеләнеп папирос суыргач,— мин сезне просто рәхмәт әйтү өчен чакырдым.

Альфред шундук сүзнең ни турыда барачагын чамалап эченнән куанып куйды.

— Алайса теге чактагы безнең юрау дөрескә чыкты, әтиегез турында барысын да ачыкладыгыз? — диде ул.— Миндә дә өстәмә мәгълүмат бар. Әле генә кулга төште.

— Барысы да хәзер ачыкланды,— диде Латиф, Альфредның әйткәннәрен тыңлагач. Бу — үзенең дәрәҗәсен беркайчан да онытмый торган төксерәк олы кешенең йөзендәге куанычы аерата ачык булып күзгә ташлана иде.

— Хәзер барысы да артта калган кысыр хәсрәтләр инде,— диде ул, көлемсерәп.— Сез мине Хәмзә агага җибәреп бик дөрес эшләгәнсез. Әтинең хатындагы «иптәш Хәмзә» дигәне чыннан да шул Хәмзә үзе икән. Ул миңа бик ачык итеп үзенең әти белән бергә фронтта булуын, Бохараны азат итүдә катнашуын, инде килеп шул Бохарада әтинең үлеп калуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Менә шул,— диде ул, шатлыгын һич яшерә алмастан.

Ничек инде, әтисе үлеп калган, ә бу шуңа шатланып утыра, дигән уй узды Альфредның күңеленнән.

— Сезгә аның нинди шартларда үлүен белү шулай бик мөһим идемени? — диде ул.

— Бик, бик,— диде Латиф,— чөнки сәбәбе булды. Хәзер узган кысыр хәсрәт инде ул, барысын да сезгә кызык өчен сөйләргә була.— Ул торып өстәл тартмасын ачты һәм аннан мәгълүм хатны алды.

— Менә барысы да шуның аркасында,— диде ул, яңадан утыргычка урнашып. Ул, кулындагы конвертны селкеп, бераз вакыт әйтергә сүз эзләп торды.— Нindидер бер бәндә, минем әллә кайчан үлгән әтием исеменнән миңа Мюнхеннан хат язып җибәргән. Хәзер аңлашыламы инде?

Альфредның кызыксынудан күзләре зур булып ачылды.

— Мюнхен шәһәреннән, ФРГданмы? — диде ул, аптырап.— Нинди кеше микән соң ул? Үзе татарча язганмы?

— Татарчаның да нинди генәсе әле,— диде Латиф.

— Алайса узган сугышта плен төшеп, Дахау концлагерыннан исән калган берәр кешедер инде.

— Дахау? Нигә алай дисез?

— Чөнки Дахау бит ул Мюнхеннан егерме километр арада гына.

— Юк, юк, алай түгел. Монда ниндидер башка әйбер... Хәер, белмәссең.

Латиф конверттан хатны алды да Альфредка сузды:

— Сез аны укып карагыз әле, авторның бик борынгы заман кешесе икәнлеген үзегез дә аңларсыз.

Альфред игътибар белән хатка текәлде. Ул аны бер тапкыр укып чыкты, тагы әйләндереп караштыргалый башлады. Аның нидер әйтергә теләве, нидер сизенүе йөзенә чыккан иде. Альфред тынычсызланып, кашларын җыергалап беравык утырганнан соң әйтми булдыра алмады.

— Мөмкин булса, сез бер көн миңа күрсәткән хатларны бирегез әле.

— Рәхим итегез,— диде Латиф, көлемсерәп.

Ул хатларны алдына салды да кызыксынып тикшерә башлады. Гаҗәп хәл, Альфредча, ике хат та бер үк кул белән язылган иде. Әлбәттә, соңгысы күзләре начар күрә башлаган һәм кулы йомшарган карт тарафыннан, ә баштагысы язу тануы чамалырак булса да нык куллы яшь кеше тарафыннан язылган. Тик шулай да бер үк кул. Альфред уйга калды. Кызык бит бу, ә бәлкем чыннан да Мюнхенда яшәүче карт Латифның этиседер? Бәлки ул чыннан да шанлы бригада тарихына бәләкәй генә булса да яңа бер штрих өстәргә сәләтле шаһиттер? Алай дисәң, ә бу документлар, шаһитләр?..

— Мөмкин булса, сез миңа ул картның адресын бирегезче,— диде Альфред.— Мин аңа хат язып җибәрергә телим. Юри, кызык итеп. Нинди кеше икән ул. Нинди сәбәпләр аркасында ул сезгә хат язарга булган.

— Ул сезгә бернинди дә җавап бирмәс дип уйлыйм.

— Нигә алай дип уйлыйсыз?

— Чөнки бу эш, минем ышануымча, кемнәрдер тарафыннан оештырылган.

Альфред блокнотына адресны күчерде дә сәгатенә карады. Карасана! Кузгалырга вакыт икән ләбаса!

Ул ашык-пошык саубуллашып ишеккә таба китте. Өенә кайтып кергәндә көн караңгыланган иде инде. Альфред яңа яуган кырпак кар тапларны калдырып алгы бүлмәгә узды.

— Я, ничек булды,— диде куркынган Луиза,— нигә шул кадәр озак тоттылар?

— Кем тотсын мине,— диде Альфред,— мин аннан соң Казанга барып кайттым әле.

— Ә синең турыда тагы бер сүз йөри әле,— диде Луиза, серле һәм шомлы бер тавыш белән.— Халит абыйга ниндидер бер кеше Казаннан шалтыраткан да синең турыда нәрсәдер әйткән.

Альфред соң дәрәҗәдә ярсып:

— Кем нәрсә әйтсен минем турыда!? — диде.

— Кычкырма, пожалысты! Фәйрүзә апа Халит абыйның шул кеше белән сөйләшкәнен үзе ишеткән. Кичен мәктәптә башка берәү дә булмаган.

Альфред мондый уйдырманың булу мөмкинлегенә ышанмыйча шаркылдап көлеп җибәрде.

— И син шул уйдырмага ышандыңмы инде?

## XXIII

Бүген почтальон Хәбибрахман абзыйга бер пакет китереп тапшырды. Хәбибрахманның аптыравына каршы, әманәт бик салмак иде. Конверт эченә калын дәфтәр салынган булып чыкты.

Дәфтәрне күрү белән Хәбибрахман кинәт ниндидер бик якын, бик таныш, ләкин күп еллар узу аркасында онытыла башлаган кадерле бер нәрсәгә орынгандай булды. Бу Хәбибрахманның югалган көндәлеге иде. Бу көндәлекне ул унтугызынчы елның җәендә Беренче укчы полк

атлы казакларга каршы сугышканда сызгалаган иде. Полк тар-мар ителгәннән соң көч-куәт туплау өчен яңадан Самарага кайткач, Хәбибрахман көндәлеген күчереп тулыландырды.

Хәбибрахман куанычыннан һәм аптыравыннан тәмам югалып, йөзеннән елмаюын җуя алмас булып өнсез утырды. Кара инде син аны! Нинди мәрхәмәтлесе табып җибәргән моны! Карт, сак кына хәрәкәтләр белән, ак клеенка тышлы дәфтәрнең саргайган битләрен ачып карый башлады. Ул кулларының җиңелчә дерелдәвен үзе дә тойды. Хатирәләр аны кинәт бик еракта калган, узган давыллы көннәргә алып киттеләр. Әйе, алар кан коеп, дары сөреме һәм тузан йотып, барлык җан-тәннәре белән ирек, бәхет яулап йөрделәр. Бүген безнең нинди дә булса уңышларыбыз бар икән, алар Хәбибрахман ишләренең тырышлыклары һәм фидакарьлекләре аша ирешелде. Ничек табылган диген син бу дәфтәрне! Кемнең башына килгән бу эш? Кайдан белгәннәр Хәбибрахманның аны эзләвен. Карт дәфтәр битләрен ашыкмыйча гына ачып кулы белән сыпырып иркәләп, сөеп торды. Ул укый алмый иде әле. Аның күзләре яшьләнгән иде. Юкса һич еларга исәбе дә юк иде алай. Ул укымыйча гына, күзсез кешедәй, капшанып бу эшнең чынлыгына ышанырга теләгәндәй иде. Дәфтәрнең уртасыннан ярты битлек кенә бер язу чыкты. Карт сискәнеп үк китте. Монысы тәгаен бандероль җибәрүчедән иде. Хәбибрахман тиз генә яулыгы белән күзләрен сөртте, күзлеген табып киде. Хатны ниндидер укучы бала язган иде. Әле ныгып җитмәгән, ләкин пөхтә кул шуның турында сөйли.

«Хәбибрахман бабай,— дип язылган иде анда,— без сезгә бер дәфтәр җибәрәбез. Әнием ул сезнеке ди. Аны әниемә әбием биргән, дәфтәр сезнең йортны сүткәндә сайгактан килеп чыккан. Гарәп хәрефләре белән язылганны укый алмыйбыз без. Әбием үлгәнче безгә укып күрсәтә иде. Тик ул үлгәнгә дә бишенче ел китте. Хәбибрахман бабай! Әгәр мөмкин булса, син аны хәзергечә иттереп язып җибәр. Кечкенә чагымда укыган булсалар да хәтеремдә, сез гражданнар сугышы турында язгансыз анда. Без аны мәктәптә бергәләп укыр идек. Мин үзем звено башлыгы. Безгә шундый төрле чаралар уздырырга туры килә. Без хәзер үзебезнең авыл кешеләренең истәлекле вакыйгаларын язабыз. Безнең альбомда хәзер истәлекләр бик күп инде. Без музей оештырабыз. Синең язуларыңны да без саклап, кадерләп кенә торыр идек. Әти белән әнидән, абый белән ападан бик күп сәлам. Бабай, нигә безгә кунакка кайтмыйсың? Хәзер юл йөрүе читен түгел. Казаннан һәр көн самолет очып килә. Ә инде районнан һәр көн кырыкмаса кырык машина йөреп тора. Колхоз правлениесенә телефоннан әйтсәң, председатель Гата абый сиңа җиңел машинасын да җибәрер әле. Кайт, бабай, яме! Сезгә миннән күп сәлам. Җиденче «А» классы укучысы Әлфия Сафиуллина».

Хәбибрахман хатны укып чыкты да урыныннан кузгала алмыйча уйланып, башын чайкап утырды. Яңа, яшь буынның бер вәкиле яза иде аңа. Кинәт Хәбибрахманның кемгә булса да үзенең шатлыгын әйтәсе килде. Ләкин теге бүлмәдә кәефсезләнебрәк торуы аркасында әле бүген дә бакчасына бармый калган Ләйлә генә. Ишекне ачуга ул чүгәләгән урыныннан торып бабасы янына килде. Кыз Хәбибрахманның тезенә кулларын салды:

— Бабам, нәрсә ул, ә? Нәрсә ул, ә?

— Көндәлек дәфтәре, кызым,— диде Хәбибрахман Ләйләнең башыннан сыйпап.

— Нәрсә бу, ә? — диде Ләйлә, тагы күзләрен тутырып ачып.

— Бу мин язган язулар, кызым. Мин аны моннан кырык биш ел элек яздым. Кырык биш ел! Аңлыйсыңмы? Сиңа менә дүрт яшь, ә бу язуларга кырык биш яшь.

Кыз аңларга тырышып һаман күзләрен тутырып каравында иде әле.

— Ай сине,— диде Хәбибрахман, оныгының башын тагын сыйпап.— Уйна, күгәрченем, бераздан синең белән ботка пешерербез. Син бит хәзер зур үстең инде. Кичәге кебек, бүген дә миңа булышырсың. Ярыймы?

Хат килүе, Әлфиянең хатка язган сүзләре Хәбибрахманга барлык күңел кылларын тибрәтерлек тирән тәэсир ясады. Ул рәхәт минутлар кичерә башлады. Эчендәге әлеге дәртле ялкын тагы дөрләргә кереште.

Ул әле һаман кулларын ышаныч белән бабасының ботына куеп торучы Ләйләгә көндәлеген кычкырып укырга тотынды. Ара-тирә тукталып, узган көннәрнең барлык вак-төякләрен күз алдына китереп, елмая, я көрсенә иде ул. Башта Ләйлә бик игътибар белән, аңларга тырышып, тынлады. Аннан бабасының хәрәкәтләре, иреннәренең ничек селкенүе белән генә кызыксына башлады. Ниһаять, уенчыклары янына, икенче бүлмәгә чыгып, тагы чүгәләде. Хәбибрахман моны бераздан соң гына тоеп, көндәлеген үзе өчен генә, авыз эченнән генә укый башлады. Бик күңелле иде аңа, коточкыч авыр көннәрне, газаплы, ләкин героик минутларны күз алдыннан кичерү әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә иде. Узган юлның дәрәҗәсе, кадере кеше олыгайган саен арта бара икән!

Көндәлектә менә нәрсәләр язылган иде. Хәбибрахман кайбер битләрен тулысынча, кайберәүләреннән өзеп-өзеп кенә укыды.

«1919 нчы ел, 16 нчы май числосы. Без бүген иртәнчәк вагоннарга төялеп фронтка киттек. Вагон ишеге төбенәчә ачык иде. Анда бастырык тактага сөялеп бардык. Ә тышта көн искиткеч матур иде. Уҗымнар яшел хәтфә келәмдәй бик ераклардан ялтырап күренәләр. Кояш нурлары кайчак безгә төшеп, күзләрне чагылдыралар. Тургайлар үзләренең җырларын җир өстенә сибәләр иде. Чәчү бетеп килә икән инде. Ә безнең газиз башлар әллә кайларга китте дип уйлап бардым.Ниләр генә булыр, ниләр генә күрербез. Ишек янына өелгән егетләр моңлы гына итеп җырлап бардылар. Эх, йөрәкләргә төшә шул туган як җырлары! Авыл көенә, моңлы, бер дә туйдырмый торган авыл көенә җырладылар. Ә безнең поезд бик озак алга барды. Келтер-келтер бара бирде. Бармыйча да ярамый шул. Анда Колчак илне басып алырга, элекке патша тәртипләрен урнаштырырга тели ди бит. Аны себереп түкмичә дә булмый бит. Ни язган булса, шуны күрербез инде дип тынычландым».

«1919 нчы ел, 17 нче май числосы. Без бүген иртәнге биштә Сорочинский атлы станциягә килеп җиттек. Барысы да — Казан да, Самар да артта калдылар. Безнең юл Оренбург каласына таба дип сөйләнәләр. Безне шушы Сорочинскийда поездда төшерделәр. Я булса да була бит! Көн бик аяз, бик матур иде. Станция янындагы куаклыкта чут-чут итеп сандугачлар сайрый. Шунда яшел чирәмгә сузылып чалкан ятасым килде, барысын онытып бер ял итәсем килде. Тик ул була торган эш түгел шул дип уйладым. Поездан төшеп, кагынып-сугынып, үзебезне тәртипкә китерергә өлгермәдек, тезелергә команда бирделәр. Гөж килеп торган бушлык кинәт тынып калды. Һәркем үз отделениесен, үз взводын эзли китте. Эх, егетләр, егетләр, якташларым минем! Ниләр генә көтә микән инде безнең башларны! Кайсыбызга ни язган икән инде! Егетләр бик батырланып үрә катканнар иде. Түшләре киерелгән. Берсеннән берсе матур, яшь үзләре. Кара инде мондагы бөркелеп торган яшьлекне, гайрәтне! Тик кием-салым гына ах дип әйтерлек түгел. Әйдә, була бирсен, шулай да егетләр сынатмыйлар әле, гренадерлардай, борынны күккә чөеп, смирно торалар. Бераздан батальон алдына комбат, батальон комиссары вә полк командиры ярдәмчесе иптәш Сабитов чыгып бастылар. Безгә унбишенче майдан бирле үк иптәш Фрунзеның алдыбызга куйган бурычлары мәгълүм инде. Без фронтның уң канатын

саклап, атлы казакларга каршы сугышырга тиеш, диделәр. Сул канатта Чапай дигән комдив икән, шуның дивизиясенә юл ачылсын өчен без дошманны тоткарлап торырга тиешлеген аңлаттылар. Әйе, безнең эшләр алда күп күренә, бу яклардагы авылларның барысында да диярлек атлы казаклар яши икән. Алар Совет властена каршы икән, җае чыгу белән баш күтәрергә торалар икән. Алар белән дә әле безгә мәшәкатьләнергә туры килмәгәе, диделәр. Аңлаткан сүзләренең тел төбе шуңарга кайтып кала. Менә иптәш Сабитов комбат вә комротлар белән нидер сөйләшкәннән соң, рота командиры взводныйларны чакырып нидер аңлата башладылар. Аңлашыла инде, безне кайсы урынга билгеләү турындадыр сүз...» «Ап-ак өйләр, алтынга манган гомбәзле чиркәүнең түбәсе кояшта җылык-җылык итә иде. Авылда рәхәттер инде, дип уйладым. Сөтле чәй эчеп утыралардыр. Эх, туган авыл искә төшеп китте шул чак. Йөрәкләр кузгалып куйды, күңелләр тулып китте шулчак. Кая ул минем туган илем? Кая ул минем көлгә тәгәрәткән бәрәңгеләр ашап ат көткән чакларым, кая ул йөгерүдән кызышкан битләрне саба җилләреннән иркәләтеп, кызарып чыккан кояшларны каршылауларым, дип моңайдым.

Аннан соң без бер авылга урнаштык...»

«1919 нчы ел, 18 нче май числосы. Без бүген таң атканчы ук торып отделениебез белән разведкага чыгып киттек, читтә генә торган бер фәкыйрь алачыкка сугылып, өй хуҗасыннан сораштык. Гидай казак икән. Безнең турыда атлы казакларга без килеп төшү белән билгеле булганлыгын, хәзер инде аларның безгә каршы һөҗүмгә әзерләнүләрен хәбәр итте безгә...

Алар иярле атларга атланганнар, кулларында үткен кылыч, сөңге икән. Ә өсләрендә менә дигән өр-яңа кием икән. Мыеклар бөтеренке, чәчләр бөдрә икән. Шуларын да әйтте. Ә безнең егетләрдә нәрсә соң? Ичмаса мылтыгы да җитәрлек түгел бит, дип пошындык».

«1919 нчы ел, 19 нчы май числосы. Ни сәбәптәндер таң алдыннан ук безнең бер батальон позицияне ташлап киткән дип хәбәр салдылар. Әйтүләренә караганда, ул без урнашкан Замчаловкадан чигенгән...»

«Беренче батальонның китү хәбәрен ишетеп хәсрәтләнергә өлгермәдек, кинәт авылның уң ягындагы куаклыктан нәрсәдер сызгырып безгә таба оча башлады. Ул да булмады, нәкъ безнең алдыбызга төшеп, дөньяның астын-өскә китереп, җир тетрәтеп, шартлады. Снаряд шулай очып, шулай шартлый икән...»

«...Бераздан куаклыклар артыннан атлы казаклар эскадроны күренде. Алар таралышып, алдыбыздагы бөген бушлыкны тутырып, әле яна күтәрелеп килә торган кояш нурларында кылычларын ялтыратып килделәр. Тынлыкны ярсып чапкан атларның ухылдавы, тояк тупырдавы, казакларның кыргый сызгыру-кычкырулары басып китте ул чак. Безнең мылтыклар күптән корулы иде, без брустверларга сыенып дошманның якынлашуын көттек. Ләкин бу ни тагы? Шулчак арттан артиллериябезнең гөрселди башлавын ишеттек. Берничә минут эчендә безне изеп китәргә җыенган атлы казаклар арасында буталыш башланганын күрдек. Тик бу озакка сузылмады. Казаклар тагы өннәрен җыйдылар вә тагы кояшта кылычлар ялтырый башлады. Ходаем, ник тынды соң инде безнең туплар дип борчылдык».

«...Миннән өч кеше аша гына сул якта торган күрше авыл егете әйләнеп төште. Пуля аның нәкъ маңгай уртасына тигән иде, кызыл кан эзе күңелемә дәһшәт салды. Тирә-юнемдәге иптәшләрдән берәү дә исән калмады бүген. Ә минем ник берәр җирем сыдырылсынчы! Без отделениедән икәү генә калдык. Командирыбыз һәлак булды. Туплар тавышы тынып өлгермәде, казаклар флангларга төшеп, безне камыйлар дигән хәбәр цепь буенча таралды. Димәк, баш бетте дип куркындык. Яралыларны окоплардан чыгардык. Сөрем вә тузанга буялып беткән шәфкать

туташлары аларга ярдәм күрсәттеләр. Санитарлар яралыларны носилкаларда авылга ташый башладылар. Анда лазарет урнашкан икән. Хәзер ул тулы дип сөйләделәр. Ә мәхшәр вакытында без берәм-берәм окоплардан чыктык та берәм-берәм взводный артыннан йөгердек. Көн бик кызу тоелды, аркаларны утта кыздырдылармыни, тир күзләрне әчеттереп бетерде». «...Без баш яшерерлек урын әзерләргә өлгермәдек, казаклар тагы һөҗүмгә ташландылар. Әле дә ат тояклары тупырдавы ишетелгәндәй, күз алдында кыннарыннан алынган кылычларның кояшта ялтыравы тора...» «...борынга дары исе һәм түкелгән кан исе кергәне гомер онытылмас кебек...» «Бераздан дошманның чигенгәнен күрдек. Чәнчелә башладыгызмы аналарыгызны эт талагыры буржуй артын ялаучы тәре баганалары! дип шатландык. Ә-ә, менә шулай ул! Даешь, даешь! дип кычкырдык. Тегеләр, пуля яңгырына түзә алмыйча, туктап калдылар. Ә атлар бик тә кызганыч иде. Бичара малкайлар гаепле түгел бит инде. Алар бөтен тирә-юньне яңгыратып кешни башладылар. Кешнәү генә түгел иде бу, ниндидер үзләренә бер төрле елау, ат елавы иде бу. Валлаһи менә. Ах, атлар кызганыч иде..»

«Без атаканы кире кайтардык. Дошман җиңелде. Әмма без дә тәмам тетелгән-йолкынган идек инде. Безнең патрон бетте шул чак. Әгәр безгә яңадан бер тотынсалар, без, әлбәттә, өнсез егылачакбыз дип куркындык. Шулай булды да...

Без Медведовка авылына таба чигендек».

«1919, 20 нче май числосы. Без Медведовка авылында хәзер. Кояшны сөрем, тузан каплаган. Ул кан кебек кып-кызыл. Безне монда икенче батальон каршы алды. Я хода, ниләр генә әйтим икән! Ике-өч көн эчендә башлар ни күрмәде! Нинди асыл егетләребез шәһит китмәде. Тамырларымда каннарым кайный, йөрәгем яна. Мең ләгънәт сезгә минем ватандашларымны, якташларымны, авылдашларымны, кордашларымны үтерүчеләр!»

«Медведовкага җитеп, бер өйгә кергәч тә, аска бер кочак салам түшәп, сигез сәгать үледәй йоклаган идем, иртә торсам — ходаның җәннәте! Бөтен тирә-юнь тып-тын. Ул, мин сиңа әйтим, инеш буендагы тал-тирәкләрдә сандугачлар сайрый. Ирексездән көлдем дә, җылап та җибәрдем. Авылым, туган авылым исемә төште. Өйдә безнекеләр нишләп яталар икән дип моңайдым. Эшләр беткәндер инде. Сабан туе вакытлары якынлаша бит. Их, минем Мәчтүрәм нишләп йөри микән?»

«Безнең батальонга резервтан егетләр килә башлады. Без әле ял итәбез. Тамак туйдырабыз. Очраган рус кызларына күз кысабыз. Русча сукалый белгәне хәйран күңелле итеп тәкелдәшә. Кием-салым ямыйбыз. Итек-ботинка җүнәтәбез, сакал-мыек кырабыз. Тәмәке хәлләре авыррак инде. Тик өченче көн авылдан суырсаң күзләреңнән яшь чәчрәп чыгарлык каты махра табып кинәндек. Бер юанрагын төтәтсәң, күзләр тона, йөрәкләр уйнаклый башлый.

Ә иртәгә тагы сугыш».

«1919 ел, 21 май числосы. Безне таң беленгәнче үк алып чыгып киттеләр. Май төне озын булмаса да, караңгы иде. Бары күк йөзендәге йолдызлар гына чекерәеп безне күзәтәләр. Тавышланмаска, тәмәке көйрәтмәскә куштылар. Шулай да адым тавышлары гөрес-гөрес итеп торды...» «...Я алда, я артта атлар пошкырганы ишетелеп китә иде. Алда кавалерия, артта туплар барды. Ә без һаман алга бардык. Безгә Белогорка дигән авылда төпләнеп калган казакларны куып чыгарырга кирәк иде».

«...Казаклар безнең авылга якынлашуыбызны сизеп өлгерделәр. Ләкин сонга калганнар иде...» «Җиңү куанычына берни дә җитмәгәнлеген мин менә бүген белдем. Бик кыйбатка төшкән бер җиңү булды инде булуын, бәлки шуңа күрәдер әле, аның тәме дә әйтеп бетермәслек иде. Без кергән өй ярыйсы гына, бай сымак иде. Хәер, монда барлык

өйдә диярлек байлык, муллык күзгә ташлана. Идәннәр сап-сары итеп буятылган, алгы якның яртысын мич алып тора. Мич башы каршында гына иркен сәндерә. Кышкы чиллә суыкларында урманнан катып-туңып кайтсаң, мен дә ят инде. Әйбәтләп тәрәзәләрне ачып җибәрдек, каты сугыштан соң тынып калган авылның тынлыгын дип әйтимме, моңын дип әйтимме, тыңлап утырдык. Ә хуҗаларның берсе дә өйдә юк иде. Бары бер карчык кына сукранып йөри шунда.

Командирлар безгә бик әйбәтләп аңлатканнар иде инде. Җирле халыкка сүз әйтәсе булмагыз, хәтерләрен калдырмагыз, милләте кем булуына карамастан, әйбәт мөгамәләдә булыгыз диделәр. Бу безнең бәйнәлмиләл бурычыбыз диделәр. Сорамый берни алмыйбыз, кычкырынмыйбыз, җикеренмибез. Күрәсең менә шулар барысы да халыкка тәэсир иткәндер инде. Төштән соң авылда кешеләр күренә башлады. Безнең өйгә дә кыйгач кашлы, нечкә билле бер казачка килеп керде. Ул безгә күз кырые белән генә дә карамады ичмаса, керү белән бик эшем кешеседәй мич янында кайнашкан булып, теге карчыкка булыша башлады. Тик безнең күзләр аннан аерылмый иде инде. Кызык икән бу армия дигән нәрсә! Шулай Самарада чакны урамнан узганда юлыбызда берәр чибәррәк кыз очраса, бөтен ротабыз белән башларны шуңа таба бора идек. Соңыннан командирлар каршыга шундый «чикерткә» килеп чыккан саен үзләре үк «Равнение на девушку» дип көлеп команда бирә башладылар. Әле дә шулайрак килеп чыкты. Күзне таки кыздан алмыйча утырдык бит! Сүз дә бетте, өн дә бетте, күз карашларыбыз кыз белән бергә хәрәкәтләнә. Арабызда бер Казан егете бар. Хәйран гына русча сукалый шул. Без әйтәбез, яле сораш әле, кем икән, кайдан килеп чыккан икән бу каракаш, дибез. Тегеләр үзара такылдашырга тотындылар. Без дә бераз аңлыйбыз. Аңламаганын теге Казан егете шәрехләп бирә башлады. Кыз әйтә икән, сез бит денсезләр, ди икән, безгә сезнең турыда сөйләделәр инде, бөтен кешене суярга җыенасыз икән сез, кеше суеп канын эчәсез икән сез, безгә шулай дип аңлаттылар аклар, ди икән. Без егылып көлә башладык. Менә нәгаләт җаннар, безнең турыда ниләр сөйләгәннәр бит. Безнең көлү кызны тынычландырды, ахры. Кызый ипле генә сөйләшә башлады, бер заман минем якка карап елмаеп та куйды. Синең милләтеңне сорый ул, дип аңлатты теге Казан егете. Мин әйтәм: «Татар, Казан ягыннан». Ә-ә, дигән була чибәркәй, бер дә имеш безнең казаклардан аергысыз икәнсең. Әгәр, мин әйтәм, беләсең килсә, минем кызым да синнән ким түгел. Кызыңны сагынасыңмы? диде. Ә мин әйттем, сагынып нишлисең, менә сезнең ак казакларны акылга утыртып, өебезгә кайтыйк әле, типтереп туй ясарбыз. Матур чукынган кыз, тел генә белмим, юкса кинәнер идем үзе белән әҗе-гөҗе сөйләшеп».

«1919 ел, 22 май числосы. Без бүген иртәнге якта авылдан чыгып, авыл алдындагы бер үрдә урнаштык. Окоплар ярым-йорты казылган иде инде. Безгә аларны тирәнәйтергә, бераз киңәйтергә генә туры килде. Бераздан команда пунктлары да, пулемет оялары да, артиллерия дә урнашты. Позициянең бик шәп икәнлеген, хәрби кеше булмасам да, беләм. Алдагы киңлекләр уч төбендәгедәй ап-ачык булып күренеп тора. Артта гына авыл. Килеп карасыннар казаклар! Үкчәләрен тиз күтәртербез.

Көннәр җылы җылысын да, шулай да кичләрен салкынча. Егетләр өйләрдә уздырган көннәрен сагыналар. Бу авылда бер төн генә кундык, шул арада нинди генә хикмәтләр булмаган, егетләр әллә ничә кыз белән танышып, гыйшык тота башларга өлгергәннәр. Ха-а, һич аптырап йоклап тормый шул безнең егетләр. Ә мин Мәчтүрә турында уйлыйм. Аратирә авылдагы казачка Нина да искә төшеп куя. Әйбәт шул каһәр. Без китәбез, хуш инде дигәч, шундый батырып бер карады. Әллә инде хода-вәндә... Әйттем, әйттем исә кайттым, минем Мәчтүрәм исән бул-

сын. Әйе, ул исән булсын да, мин дә, явыз дошманның муенын сындырып, туган илгә кайтыйм. Ә кайтып булмаса?»

«1919 ел, 23 май числосы. Безне бүген сәгать бердә уятып, взводыбыз белән дошман ягына таба алып киттеләр. Взводыбыз белән охранениегә бардык...»

«1919 нчы ел, 24 нче май числосы. Без исән-сау гына боевой охранениедән кайттык...» «Бик каты йокланган. Төшемме дип торам, уянып китсәм, колагыма бик матур музыка тавышы ишетелә. Карасана, үзебезчә уйныйлар бит, җитмәсә әллә кая түгел, якында гына. Күзләремне ачарга куркып, рәхәтләнеп тыңлап яттым. Янәсе, төш булса, күз ачылу белән моңлы көй юкка чыга. Бераздан моның төшемдә түгеллегенә ышандым, ячейкамнан чыгып, музыка уйнаган кешене эзли башладым. Кубызда уйныйлар лабаса! Тик ятмыйлар егетләр. Нинчек башлары җиткән диген әле син! Без авылда кунып чыккан арада, кубыз ясап та өлгергәннәр... Күз алдыма тагы туган-үскән яклар килеп басты. Әнине, этине, Мәчтүрәне искә төшердем. Ул ара да булмый, көтмәгәндә теге казачка Нина күз алдына килеп басты. Әстәгафирулла тәүбә! Каян керә бу башка шул чукынган кыз! Ни телен белмим, ни фигылен дигән шикелле, дене дә үзебезнеке түгел. Тик чыкмады бит баштан шул. Әллә инде командирдан сорап авыл тирәсеннән бер әйләнеп кайтырга микән дип уйлыйм. Күреп булмасмы шайтан кызыйны, янәсе. Теге озаткан көнне бик тә күзләрен мөлдерәтеп карады, югыйсә дидем.

Кичкырын күрше авыл егете Гайнулла Мостафин белән икебезне командир авылга җибәрде. Киттек. Күңелләр бик күтәренке иде. Тик үзебезне алда нәрсә көтәсен генә белмибез икән. Ә безне менә нәрсә көтә икән. Үзебез торган фатирның тәрәзәсеннән баш тыгып карасак, теге минем күз төшкән марҗа кызы бер бөдрә чәчле казак белән үбешеп тора. Ул ара да булмады, абзардан ат кешнәгәне дә ишетелеп китте. Беребез тәрәзә янында калды, икенчебез абзарга ташланды. Эшләр безнең менә шулайга әйләнеп китте бит. Бу эш кызлар күрергә бару урынына, казак ауларга бару булып чыкты инде».

Хәбибрахман абзый шушы урында көндәлегеннән аерылырга мәҗбүр булды. Чөнки кемдер телефон шалтырата иде.

# XXIV

Район мәгариф бүлегенә чакырылган көнне Сәгыйдуллинның үзе белән сөйләшкәннән соң Альфред ни өчендер, күрәсең, мөдиргә һәм гаделлеккә ышаныптыр, шактый тынычланды. Ләкин бәхетсезлеккә каршы, ул икенче көнне үк Латиф биргән адреслы блокнотын югалтты. Ул гына җитмәгән, онытылып өстәлдә калган блокнотның өч көннән соң директорда икәнлеге беленде. Әхмәдиев, әлбәттә, блокнотның битләрен берәм-берәм ачып укып чыгудан тыела алмаган һәм үзенчә тиешле нәтиҗәләр ясап өлгергән булса кирәк.

Альфредны көтмәгәндә Әхмәдиев тагын үз бүлмәсенә чакыртты. Кабинетка керү белән үк завуч нидер сизенде. Чөнки директор артык җитди иде.

Альфред бүлмәгә керде.

— Нинди йомыш, нинди мәсьәлә? — дип сорады.

— Бик катлаулы эш,— диде Әхмәдиев.

— Сүз минем турыда бармаячактыр бит?

— Кызганычка каршы, нәкъ синең турыда, егет.

Альфред Әхмәдиев каршысына барып утырды.

— Мин сезне тыңлыйм.

— Әйт әле, Альфред Яхич,— диде Әхмәдиев.— Син ни өчен һаман коллективтан яшерен эшләр башкарып йөрисең?.. Без монда, Альфред

Яхич, мәсьәләгә конкрет килик. Мине, конкрет әйткәндә, синең чит ил белән хат алышуың бик борчый.

— Хат алышуым? — диде Альфред, хәйран калып, аннан барысын да аңлап, кинәт көлеп җибәрде.— Юк, мин әле берәүдән дә хат алырга өлгермәдем. Минем блокнот сездәме?

— Анысы икенче мәсьәлә, сүз блокнот турында бармый, ә сезнең Мюнхендагы ниндидер эмигрантлар белән хат алышуыгыз турында бара,— диде Әхмәдиев, ни өчендер «сез»гә күчеп.

Альфредның ачуы кабара башлады.

— Әйтегез,— диде ул,— минем блокнотым сездәме? Миңа бик кирәк ул. Чөнки анда китаплар исемлеге, аннан архивтагы опись номерлары...

— Блокнотыгыз миндә түгел, блокнотыгыз тиешле җирендә. Ләкин сез шулай да безгә аңлатырга тиеш. Шундый хәл килеп чыккан икән, сез безгә барысын да сөйләп бирергә тиеш. Нинди адрес ул?

— Ул адрес буенча мин, хат язып, Татар бригадасы турында материал...

Әхмәдиев пырхылдап көлеп җибәрде.

— Ичмаса алдый белеп алдагыз, энекәш,— диде ул.— Мюнхенга хат язып диссертациясенә материал җыя, имеш...— Ул җитдиләнеп уйланып утырды.

— Юк, чыннан да,— диде,— ул берәр тарихчымы? Кем соң ул?

— Ул бернинди тарихчы түгел. Ул заманында Татар бригадасында хезмәт иткән кеше булырга тиеш.

— Ә адресны кем бирде соң сезгә?

— Адреснымы? — Альфред ирексездән икеләнеп торды. Әйтергәме, әйтмәскәме? Теге управляющий урынбасарын җайсыз бер хәлгә кую булмасмы?

— Адресны әнә шул кешедән хат алган иптәш бирде миңа,— диде ул, ниһаять.

— Нинди кеше ул? — диде Әхмәдиев, кулына автомат каләмен алып.

— Нинди кеше? Кеше инде. Нәкъ сезнең кебек, минем кебек. Ул карт аны үзенең улы дип уйлаган, хат язган, бәлки ялгышкандыр, бәлки юктыр. Минем шуны беләсем килде. Ну, нигә бәйләнәсез сез шундый вак нәрсәләргә?

— Ә шулай да сезнең аңлатуыгыз мине канәгатьләндерми. Беләсеңме, Альфред Яхич, мине нинди авыр хәлгә калдырасың син,— диде Әхмәдиев,— мин сине коллективка керттем. Сиңа аерата игътибарлы булдым. Синең күтәрелүеңә ярдәм күрсәттем. Инде шуның өчен рәхмәт диясе урында син мине кыен бер хәлгә калдырасың. Чит илдәге ниндидер адәм актыгы белән хат язышa башлагансың. Ә иртәгә, менә шул әйткән иде диярсең, синең үзеңне шпионлыкка вербовать итеп, иленне сатарга кушачаклар.

Альфред, утка пешкәндәй, урыныннан сикереп торды.

— Мин сезнең белән артык сөйләшмим дә, нитмим дә,— диде ул.— Хакыгыз бар икән, теләсәгез нишләтегез.

Ул кискен рәвештә борылды да ишекне ябып коридорга чыкты.

Әлбәттә, Альфред шуның белән барысы да бетте дип уйламады, киресенчә, ул алда мәгънәсез, тиешсез борчулар туачагын тоя иде.

Юк, нәрсәдер бар, Халит абый ул дәрәҗәдә үк хәлне белмәс кеше түгел бит инде,— дип уйлады ул.— Иртәгә үк райкомга җиткерергә кирәк, юкса эш тирәнгә китәр. Тизрәк хәл итсеннәр. Әллә бәлкем Асия Фәхриевна белән сөйләшергәдер? Ул ярдәм итми калмас. Ул партия оешмасы секретаре. Эшнең серен белә торгандыр. Альфред ачынып кулын селкеп куйды. Асия ханым кичә генә партия конференциясенә китте бит. Шул исенә төште.

Луиза укытучылар бүлмәсенә килеп кергән Альфредны сагышлы

бер караш белән күзләреннән кичерде. Альфредның аңлавынча, хатынының күз карашында шелтә һәм рәнҗү дә юк түгел иде.

Альфред дәрескә керергә әзерләнә башлады... Юк, юк, чигенүгә юл куймаска тиеш ул!

Альфред бөтен көчен туплап үзен тынычланырга мәҗбүр итте, дәфтәр-китапларын күтәреп ишеккә таба юнәлде.

Ә тәнәфескә чыкканда аның өстәлендәге телефон хәтәр чылтырый иде. Район мәгариф бүлегеннән иртәгә мәктәпкә комиссия членнары киләчәген хәбәр иттеләр.



## XXV

— Нишләвең инде бу синең, нишләвең?! — диде Луиза.

Альфред Шамилгә манный ботка ашатып утыра, ул үзе дә әле генә мәктәптән кайтып кергән иде. Хатынының болай кычкырып ярсып эндәшүенә аптырап, хәтта куркына төшеп, Луизага текәлде.

— Нәрсә булды соң? — диде Луиза, һаман тавышланып,— нинди адрес турында сөйлиләр, нинди яшерен хатлар тагы?

Альфред боткадан туеп тәлинкәгә кулы белән үрелә башлаган бәбинең авызын сөртте дә, аны сандык өстендә оек бәйләп утырган Җәзилә апага сузды.

— Кил әле, Люлю,— диде ул,— мин сиңа хәзер барысын да сөйләп бирәм.

— Син дә ир аталасың инде,— диде Луиза. Аның бит алмалары тыштагы суыктан кызарынган һәм ачудан ут булып көйрәгән каракоңгырт күзләре үзе никадәр җенләнмәсен, әйтеп бетергесез матур иде.

— Туктале, утыр әле,— диде Альфред.

— Нишләп утырыйм ди мин. Әгәр син мине яратсаң, миннән ниндидер серләр яшереп торыр идеңме!?

Ул, кискен рәвештә борылып, Шамилгә таба китте.

— Ой, минем нәни чыпчыгым. Минем балдан татлы мармеладым. Ой, ала алмыйм шул, ала алмыйм шул, нәнием, минем кулларым би-и-к салкын.

— Аш суынмаган әле. Мичтә,— диде Җәзилә апа.

Гадәттә мондый чакны Луиза өстәлгә ике тәлинкә-кашык куеп, чуендагы ашны икегә бүлә иде. Ләкин бу юлы ул юри уч итеп ашны бер тәлинкәгә генә салды һәм Альфредны бөтенләй ашарга чакырмады да.

Альфред, артык тыела алмыйча, урыныннан торды.

— Син мине тыңлыйсыңмы, юкмы, наконец?!

Ул хатыны янына утырды.

— Җикеренмә, пожалысты, мин синең мондый кеше икәнеңне белгән булсам...

— Син тыңлале, Луиза, тыңлале башта. Хөкемеңне соңыннан чыгарырсың. Минем бит беркемгә дә ярамас хат язганым юк. Минем бернинди яшерен эшем юк.

Луиза өрә-өрә берничә кашык аш капты, коры гына:

— Нинди чит ил эмигрантлары турында сөйлиләр иптәшләр? — дип сорады.

— Ул игътибарга лаеклы нәрсә түгел. Безнең Казанда яшәүче бер кешенең этисе булырга тиеш ул.

Альфред адрес вакыйгасын сөйләп бирде.

Луиза тәлинкәсен бөтенләй читкә этеп куйды, маңгаен учына терәде.

— Я, хода, син ичмаса безнең турыда бераз уйлар идең. Бераз гына синдә сизгерлек дигән әйбер бармы, юкмы? Син бит безне...

Ул, Альфредны тәмам дәһшәткә салып, кычкырып елый башлады.

— Туктале, туктале, Луиза! Нигә елыйсың? Ул адрестан берни дә булмый бит. Мин бит...

— Кит, кит,— диде Луиза, башын күтәрмичә, кулларын чәбәләндереп.— Әгәр син мине тырнак очы кадәр генә яратсаң да миннән әллә ниләр яшереп йөрмәс идең.

— Син бит...— Альфред хатынына нидер әйтмәкче булды, ләкин Луиза тагы кул гына селтәде. Тәмам гаҗиз булган Альфред ялварулы тавыш белән Җәзилә апага әйтте:

— Ичмаса, сез әйтер идегез. Соң бит инде болай булмый. Мин бит берниндн начарлык ясамадым, Җәзилә апа!

— Кызым, кирәкмәс иде, Әлфәритең әйтеп тора бит, берниндн хәтәр эш юк дип әйтә бит.

Ләкин Луиза елавын дәвам иттерде.

— Китегез әле, Җәзилә апа, безнең арага кысылмагыз,— диде ул.

Җәзилә апа, шактый хәтере калган хәлдә, ләкин шулай да берни дә сиздермәскә тырышып, яңадан олы якка чыккач, Луиза Альфредка ачулы караш ташлады.

— Беләсеңме, син Дон-Кихот! Сине мин эгоист дип тә әйтә алмыйм, әгәр акыллы кеше эгоист булса, беркайчан да үзенә үзе начарлык эшләми.

Альфредның моңача булган гаҗизлек тойгылары ачу белән алмашына башлады.

— Рәхмәт,— диде ул,— рәхмәт комплиментларың өчен, Люлю.

— Сиңа чыкканнан бирле бер тынычлык, бер рәхәт күргәнем юк. Миңа андый тормыш нигә кирәк, я, әйт?!

— Мондый сүзләр әйткәнче, чын дус булсаң, хет авыр чакта ярдәм итәр идең...

— Подумаешь! Ул семьяга борчу артыннан борчу китерсен дә, мин аны юатып торыйм ди тагы!

— Син аңларга тиеш, мин кирәкле, файдалы эш эшлим.

Луиза, күз яшьләрен сөртеп алды да:

— Менә иртәгә комиссия була. Син бит аның кемне тикшерергә тиешлеген яхшы беләсең. Синең дәресләреңнән генә түгел, ул комиссия минем дәресләремнән дә кимчелек табарга тырышачак. Җитмәсә менә синең яңа «бүләгең»...— Альфредның борын төбендә кулын селки-селки дәвам итте Луиза.— Нindидер эмигрант белән кызыксыну...

— Ташла әле, Луиза, зинһар, саруны кайнатма!

— Акырма! Син күбрәк үзеңнең баткакка эләгүең турында уйлан. Иртәгә сине завучлыктан очырачаклар, ә берсекөнгә мәктәптән үк куачаклар. Коммунист булып йөргән була тагын!..

Альфред, үзен-үзе тота алмас хәлгә җитеп, урыныннан торды. Аның йөзе кызарынды, ә матур кара кашлары җыерылган иде.

— Йа-а, Луиза,— дип куйды ул, тешләрен каты кысып.— Дус авыр чакта сынала, диләр иде, син үзеңнең кем икәнлегеңне күрсәттең!

Ул борылды да эчке, олы бүлмәгә кереп китте.

— Син ул үзеңнең кем икәнлегеңне күрсәттең, мин түгел! — дип кычкырып калды Луиза.

Альфредның эше күп. Иртәгә аның дәресенә керәчәкләр, аңа аерата тырышып әзерләнергә һәм дәресне үрнәк булырлык итеп уздырырга кирәк. Ләкин ул үзен өстәл янына тиз генә утырта алмады. Почмактагы телевизорны кабызды һәм хәлсезләнеп табуреткага чүкте. Бераздан экран яктыра башлады. Альфред, күзләрен шуннан алмыйча, хәзер калкып чыгарга тиешле җыр һәм бию ансамбле артистларын көтте.

Бераздан һич көтелмәгән хәл булды. Луиза, Альфредның янына ук килеп, аның чәчләрен сыйпарга тотынды.

— Гафу ит мине, Альфред,— диде ул, елау аркасында тынкышлана төшеп,— мин синең хәлеңне аңлыймын. Гафу ит.

Альфредның беренче тойгысы аны этеп җибәрү иде. Ләкин бу тойгы тернәкләнергә өлгермәде, икенче бер тойгы — рәхәтлеккә омтылу, иркәләнүгә сусау тойгысы күнелен били башлады. Яраткан кешеннең иркәләп дәшүе, аның җылы йомшак кулы артык татлы шул! Альфред. Луизага бер сүз дә дәшмәстән, тик кенә утыра бирде. Луиза икенче утыргыч китереп карты белән янәшә утырды. Бераздан Альфред чиксез аптыравына каршы, үзенен билендә Луизаның кул җылысын тойды.

— Нигә аш ашап алмыйсың?

— Рәхмәт,— диде Альфред,— тамагымнан үтми.

Луиза иренең җилкәсенә күперенке йомшак чәчле башын салды. Алар шул килеш хәрәкәтсез калып, телевизорга текәлеп утырдылар.

— Нинди кеше иде соң ул, Альма? — дип сорады Луиза, сак кына.

— Нәрсә, нинди кеше иде?

— Теге сиңа адрес биреп хат язарга кушкан кеше. Нинди кеше иде.

— Нинди кеше булсын, бик әйбәт кеше.

— Ә кайда тора ул?

## XXVI

Латифның өстәлендәге кызыл пластмассадан ясалган телефон шалтырады. Аның өстәлендә ике телефон: кызылы туп-туры үзенә, ә икенчесе, агы — секретарь аша.

Ул трубканы алды.

— Исәнмесез, иптәш Ибраһимов, сезнең белән Хәбибрахман Зәйнуллин дигән пенсионер сөйләшә,— дип дәште бер карт тавыш.

Тукта, кем соң ул Зәйнуллин? Латиф тиз генә хәтерли алмыйча азапланды.

— Гафу итегез, мин сезне белмим,— диде ул, ахырда.

— Ничек инде белмәскә, иптәш Ибраһимов! Сез миңа әтиегезнең язмышы турында сорашып мөрәҗәгать иткән идегез. Хәтерлисезме? Хәбибрахман, Хәбибрахман.

— Ә-ә,— дип куйды Латиф, тиз генә хәтерли алмавына гарьләнеп,— Хәбибрахман абыймы? Исәнмесез! Я, ниxәлләр соң? Тормышлар ничек, эшләр ничек бара? Апа ниxәл?

— Барысы да әйбәт, Латиф туган! Менә нәрсә. Минем кияүдән сезнең өчен бик кызыклы хат килде бит әле!

— Нинди хат тагы? Кемнән дисез?

— Соң инде кызымның иреннән. Теге сезнең танышыгыз инженер киявемнән, Салихтан, Ул бит, әйткән идем, чит ил командировкасында хәзер. Шуннан хат килде.

Латиф иреексездән күзләрен йомып торды, аның күкрәк астына суык эз калдырып җылан үрмәләгәндәй булды. Аннан ул кинәт әтисе турында Хәмзәнең әйткәннәрен хәтерләде дә тынычланып үзен кулга алды.

— Соң шуннан? — диде.

— Шул менә! Чит илдә Ибраһим Касыймов дигән бер кешене күрүе турында яза.

Латиф көлемсерәп:

— Мондый эшнең булуы мөмкин түгел,— дип куйды.

— Мөмкин икән шул, Латиф иптәш. Хатта бик ачык язылган. И ул кешенең сезнең әтиегез булуы да бик мөмкин.

«Чепуха» дип уйланды Латиф. Ләкин:

— Ярый, рәхмәт. Мин аны тикшерермен,— диде, карттан тизрәк котылу өчен. Ул ашыгып, «хушыгыз» диде, телефон трубкасын аппаратка куйды.

Ләкин, телефон трубкасын аппаратка куйганнан соң, Латиф калын авыр кашларын кинәт җыерып пошаманга калды. Бу нәрсә инде тагы? Латиф бит барысын да хәл иткәнгә саный иде. Димәк, нәрсә килеп чыга соң? Миңа хат язган кеше минем әти булу өчен тырышамы? Бу инде

провокациянең дә иң оятсызы. Бу инде... Ә ни өчен тырыша ул кеше? Ләкин шулай да кызык, бик кызык. Һич әйтеп бетергесез кызык. Нинди кеше икән соң ул?

Латифны котылгысыз рәвештә кызыксыну, гади, кешегә хас кызыксыну тойгысы били башлады. Ул Хәбибрахманга шалтырату өчен ирексездән телефонга үрелде. Управлениедә эш муеннан иде. Күп отчетлар әле каралмаган, аларга анализ ясалмаган, тиешле чаралар күрелмәгән иде. Ләкин шулай булуын белгән хәлдә дә, ул берни эшли алмады. Ниндидер эчке боерыкка колларча буйсынып, ул кулына телефон трубкасын алды, Хәбибрахман абзыйга шалтыратты. Картның килегез, мин сезне көтәм дип әйтүе булды, Латиф шоферга машина әзерләргә кушты һәм ашыгып ишек алдына чыкты. Ун минут узар-узмас, ул Хәбибрахман абзыйларның ишек төбендә иде инде. Теге вакыттагыча кунакны карт үзе һәм әлеге кызчык икәүләшеп каршыладылар.

— Эчкә узыгыз,— диде Хәбибрахман абзый,— бик әйбәт булды, әле яңа гына Альфред та килеп керде.

Чыннан да, Латиф өске киемен салып, эчкә керүе белән, түр бүлмәдә күзлек пыялаларын ялтыратып утыручы Альфредны күрде. Моннысы шәп түгел иде. Шул ук арада Латифның Альфредка хат укуы да, адрес бирүе дә, узган юлы исә Хәбибрахманга әтисеннән хат килүен яшереп калуы да исенә төште. Әйе, бусы әйбәт килеп чыкмады. Турысын гына әйткәндә, Латиф адәм көлкесенә калды дигән сүз инде бу.

Ләкин берниндн дә чара юк иде. Латиф өйгә кереп Альфред белән коры гына исәнләште дә, егетнең нидер әйтергә теләвенә игътибар итмәстән, картка текәлде.

— Хәбибрахман ага! Мин сезнең белән икәүдән икәү генә калып сөйләшергә теләр идем.

— Нигә? Кирәкми,— диде Хәбибрахман, һич исе китмичә.— Мин үзем дә әле Альфред иптәшкә кияүдән килгән хат турында сөйләп утыра идем.

— Шулаймы? — диде Латиф, күңелсезләнә төшеп,— алайса сез мине дә ул хат белән, зинһар, таныштырыгыз инде.

— Хәзер,— диде карт.

Альфред, гадәтенчә, кашларын җыергалап, ләкин үзе елмайган хәлдә, Латифка:

— Мин бүген сезгә кирәчәк идем,— диде,— монда очрашуыбыз бигрәк тә шәп булды.

— Менә нинди хат,— диде Хәбибрахман, икенче бүлмәдән конверт алып чыгып.— Минем кияүнең чит ил командировкасында икәнлеген сезгә, Латиф иптәш, теге юлы әйткән идем.

— Шулай, әйткән идегез. Ул хәзер кайда соң?

— Ул хәзер Мюнхен шәһәрендә. Теге Көнбатыш Германиядә инде.

— Мюнхенның кайда икәнен беләм.

Латиф ихтыярсыздан Альфредка карап куйды. Егетнең йөзенә серле елмаю йөгерде һәм ул хәзер үк нидер әйтергә ашкынып тора иде, ахры. Ләкин Хәбибрахман үзе сүз башлады.

— Менә шул Мюнхенда безнең кияү белән бер татар кешесе сөйләшкән. Шул кешенең исеме-фамилиясе сезнең әтиегезнеке кебек бит. Мин аны, билгеле, сезгә хәбәр итеп тормас идем... Туктагыз, без аны укып чыгыйк әле. Бәлки сез ул кыска юллардан тагы да күбрәк мәгънә аңларсыз.

Кунаклар икесе дә түземсезлек белән хатка үрелделәр. Хәбибрахман күзлеген киеп алды, калтыранган бармакларын картларча сабырлык белән конверт эченә кертеп җибәрде.

— Менә ниләр яза безнең кияү,— диде ул, хатны кулына алып,— мин инде сезгә барысын да укый алмыйм. Ул хат минем кызыма язылган. Мин сезгә шул кирәген генә укыйм.

Хәбибрахман, калганын үзең бел дигәндәй, күзлек өстеннән генә Латифка күз ташлап, елмаеп куйды.

— Укып күрсәтегез, зинһар,— диде Латиф, түземсезләнеп.

— Мин сезгә кирәкле җирләрен астына сызган идем,— диде Хәбибрахман. Ул зәгыйфь бер тавыш белән кычкырып укый башлады. Латиф кинәт йөрәгенең авыртып кысылганын тойды.

— Ягез, тизрәк,— дип куйды ул, ирексездән уң кулын йөрәгенә таба сузып.

— Ә-э... командировкага чыкканнан бирле бер татар белән дә очрашып сөйләшкәнем юк иде. Юкса, бу якларга адашып килеп чыккан безнең халык вәкилләре барлыгын ишетеп белә идем. Әле өченче көн генә бер абзыйны Мюнхен шәһәрендә очраттым. Мине үзе эзләп табып таныште. Исеме Ибраһим, фамилиясе Касыймов. Сөйләвенә караганда, гражданнар сугышында булган. Безнең эти хезмәт иткән Татар бригадасында да сугышып йөргән. Ә тулырагын кайткач сөйләрмен, Кадрия. Ну, аннан семья хәлләре китә инде...

— Шул гынамы? — диде Латиф, үзен кулга алып.

— Шул гына,— диде Хәбибрахман.— Нәрсә, азмы? Минемчә, бу бик тә кызыклы очрашу. Сезнең этиегез дә Касыймов фамилиясендә йөргән кеше бит... Менә син, әй! Туры килүен кара!

— Әйе, шулай.— Латиф ни әйтергә дә белмичә җилкәләрен күтәреп куйды. Ниһаять, сорады: — Кайчан кайтырга тиеш соң киявегез?

— Мин аны өзеп кенә әйтә алмыйм. Анысы турында кызым белән сөйләшергә кирәк.

— Шулай, үзен күреп сөйләшергә кирәк. Юкса, бу хаттан берни дә аңлашылмый әле,— диде Латиф, катгый бер карарга килеп.

Латиф Альфредка тагын күз атты. Ләкин укытучы хәзер үз алдына карап ни турындадыр җитди рәвештә уйлана иде.

— Булмаса киявгә бергәләп хат языйк,— диде кинәт Хәбибрахман, җанланып.— Шундый-шундый шик бар, син аны үзең җүнләп бел әле дип, ә? Ничек уйлыйсыз сез? Чөнки, мин әйтәм, мәсьәләнең торышын белмәгәч, барысын да сорашмас ул.

Латиф тагы бер тапкыр Альфредка карап алды.

— Минемчә, кирәкмәс,— диде, йөзен чытып,— киявегез сезнең эш кешесе, аның болай да вакыты чамалыдыр. Без аны кирәксез эшләр белән борчымыйк,— Ул тагы Альфредка карап алды.— Аннан соң мин әле моны гади бер очраклылык, исем-фамилияләр охшау факты дип уйлыйм. Гомумән ул чит илдәге кешеләр белән, үзегез беләсез, саграк кыйланырга кирәк.

— Нишлибез соң алайса? — диде Хәбибрахман, тагы дустанә елмаеп.

— Нишлибез? Көтәбез. Киявегез кайтсын, сөйләшербез. Калганын кайткач, дигән бит. Димәк, аның ул кеше турында әйтер сүзе бар. Ләкин... ай-һай! — Ул тагы Альфредка карап куйды,— минем бер дә күзем җитми. Ничек инде ул алай? Аның үлгәнлеген күреп беләләр. Менә, мәсәлән, шул ук Хәмзә абый, сезнең дустыгыз. Аннан әле, күптән түгел генә Альфред иптәш тә бер документ тапты.

Хәбибрахман кашларын җыерып аска карады. Альфред исә ничектер сәер генә елмаеп куйды. Латиф, моның серен аңламастан, сүзен дәвам иттерде:

— Әйтәм ич, Хәмзә абый бер көн үзе дә сөйләп утырды. Минем эти Иске Бохарада өченче полк шәһәргә керү белән үтерелгән. Аннан тагы Альфред иптәш тапкан донесение дә... Әйтәм ич...

Аңа каршы берсе дә җавап кайтармады. Латиф урыныннан торды.

— Сез мине гафу итегез, мин артык утыра алмыйм, вакытым юк. Рәхмәт сезгә.

Аның китәргә җыенуын сизгәч, Альфред та аякка басты.

— Минем сезгә әйтәсе сүзем бар иде,— диде ул, караңгы коридорга чыккач.

Хәбибрахман утны яндырып җибәрде. Латиф әрнүле елмаю белән Альфредка карады да:

— Шулаймы? Минем дә сезгә әйтәсе сүзләрем бар. Мин ашыгам, бәлки сез минс бераз озата барырсыз?

Алар икесе дә киенә башладылар.

— Син, Альфред, кайтырсың бит әле?— диде Хәбибрахман, ишек бигенә үрелеп.

— Әйе, күп булса бер ун минуттан.

Алар чыгып киттеләр. Хәбибрахман киез башмакларын чыштырдатып кухня якка чыкты һәм анда, сөт ашап утырган Ләйләнең башыннан сыйпап, газ плитәсенә чәйнек белән су куйды.

— Кызым, кайнап чыккач әйтерсең!

— Ә син нишлисең, бабакаем?

— Ә без менә теге күзлекле абый белән язу язабыз.

— Ә күзлекле абый китте бит.

— Ул хәзер килә, нәнием. Син чәйнекне күзәтә тор, ярыймы? Юкса, беләсең бит...

— Н-ю,— диде Ләйлә, борынын җыерып,— минем дә сезнең белән язу язасым килә.

Хәбибрахман җавап кайтармады, тагы аның аяк чыштырдатуы ишетелде.

Ничектер сәер килеп чыкты. Латиф, шатланасы урында, нигәдер көтелмәгән сагаючанлык күрсәтте.

Шулай шул, бик сәер, бик сәер, сагаерлык та.

Карт, барына кул селтәп, алдындагы язуларга чумды. Өстәлдә яткан калын күн портфельдән соңгы көннәрдә үзенә бригадада бергә хезмәт иткән кордашларыннан килгән хатлар пачкасын тартып чыгарды. Бу хатларны озак көтте Хәбибрахман. Инде язмаслар, ахры, дигәндә генә килә башлады алар.

Хатларны һич көтелмәгән, югалган, беткән дип уйланган кешеләр яза иде. Татар бригадасында кайчандыр сугышып йөргән егетләр хәзер илнең төрле почмакларына таралганнар. Барсының да шатлыклары шул, күп гомерләр узуына, тормыш сикәлтәләре бик күпләрне шактый хәтәр тетрәтүенә карамастан, полкташлар кызыл әләм ялкыннары белән нурланган гражданнар сугышы елларын онытмаганнар, алай гына да түгел, үзләренең яшьлекләре узган шул шаулы көннәрне күңелләрендә якты истәлек итеп саклыйлар. Хәбибрахман хатларны конвертлардан бер-бер артлы чыгарды.

Бер хат Төркмәнстаннан килгән иде.

«Хәбибрахман иптәш, бәлки сезнең мактаулы эшегездә ярдәмем тияр дип, мин хәтердә калган иптәшләрнең портретларын сурәтләргә тырышып карыйм әле. Менә минем күз алдымда бригада командиры Йосыф Ибраһимов басып тора. Ул уртадан түбән буйлы, чем кара күзле, кара кашлы, елдам-җитез һәм бик сөйкемле кеше. Ул революциягә кадәр үк белемле интеллигент булып җитлеккән кеше. Нәзакәтле, ләкин нык, батыр, ихтыяр көченә бай кеше. Аның өстендә күн кием, биләндә агач кабуралы маузер.

...Менә минем күз алдымда башта штаб начальнигы булып хезмәт иткән, соңыннан бригада командиры булган Литва татары Александр Тальковский...»

Кинәт ишек звоногы шалтырады. Хәбибрахман, хатларны портфеленә тыкты да, ашыгып коридорга чыкты. Ишек янында Альфред басып тора иде.

— Минем вакытым бик чикле,— диде ул,— әле бик мөһим йомышыгыз булгач кына...

Ул кыска мех киемен салып чөйгә элде дә эчкә кереп китте.
— Вакытыгыз да чикле булгач, алайса, Альфред, сүзне озынга сузмыйча гына, кереш сүзсез дигәндәй, бәшлыйк. Менә нәрсә.
Хәбибрахман зиһенен туплап Альфред каршысына барып утырды.
— Мин сезгә әйттем микән, юк микән. Казанда бер кулләгәм яши...
— Бераз гына төшенәм. Сез теге Бакировны әйтәсезме? Ә кулыгызда нинди дә булса аргументлар бармы соң?
— Сабыр итегез, башта тыңлап бетерегез,— диде карт, ризасызлык белдереп.
— Тыңлыйм.
— Менә шулай. Хикмәт шунда, Альфред, мин күптән түгел генә, уйламаганда-көтмәгәндә үзем туып үскән авылдан бер көндәлек дәфтәре алдым.
— Көндәлек дәфтәре,— дип сорады Альфред. Аның йөзенә куаныч билгеләре чыкты.
— Әйе, көндәлек дәфтәре,— диде карт, бераз аптырап.
— Дәвам итегез,— диде Альфред, серле генә елмаеп.
— Менә шул көндәлек дәфтәрендә минем тиешле аргументларым теркәлгән инде. Мин сезгә ул көндәлек турында әйтмәгәнмендер бит?
Альфред, тыела алмыйча, тавышланып көлеп җибәрде.
— Мин сезнең көндәлегегезнең табылуына бик-бик шат, Хәбибрахман абзый,— диде ул,— сез белмисез, ләкин бу эшкә минем дә бераз катнашым бар.
— Ничек?— диде Хәбибрахман, тәмам аптырап,— нинди катнашыгыз, мин сезгә аның турында сөйләгән идеммени?
— Сез аның турында миңа бик борчылып сөйләгән идегез. Бәхеткә каршы, сезнең туган авылыгыздагы бер укытучы минем дус булып чыкты. Мин аңа шул көндәлекне эзләүне оештыр әле, дип хат җибәрдем. Мин бик шат. Бүген үк мин ул дуска сезнең исемнән дә рәхмәт әйтеп хат язачакмын.
Хәбибрахман, күңеленнән картлыгын, хәтерсезлеген әрләп һәм шул ук вакытны Альфредка ничек рәхмәт әйтергә дә белмичә, сәер генә елмайган хәлдә сүзсез утыра бирде.

## XXVII

Латифның җитмеш эше бар, утәләсе йомышлары хәттин ашкан. Ләкин, шулай булуына да карамастан, алардан әзгә генә аерылган арада да әтисе турындагы хәсрәте яңадан дөрләп кабына иде. Серле һәм куркыныч иде. Юк, аңа бернинди дә куркыныч яналмый, әлбәттә. Бу ниндидер исемен табуы читен булган бер курку. Һәркем үз якынының яхшы булуын тели. Атаның баласы белән горурланасы килә. Хатын иренең абруйлы булуын тели. Юк, бала атасы өчен һич җавап бирмәсә дә, аның өчен, әтисе өчен, ут йотмый булдыра алмый икән шул. Бигрәк тә хәзерге сыйныфлар якалашкан, бөтен планетаны шаулаткан тиңсез көрәш барган бер чорда. Гаҗәп хәл, дип уйланды Латиф, кеше хәлен кеше белми икән шул, үз башына төшмәсә. Ул, мәсьәләгә айнык карап, үзен тынычландырырга тырышты. Ләкин шомлы уйлар аның саен арттан һич калмыйча дәһшәтле билгесезлек рәвешендә күңелне сыкратып, йөрәкне авырттырып торалар иде.
Латиф, торып, көзгегә карады. Әле менә яңа хәбәр ишетелгәч, кинәт яңаклары суырылып калган, күз төпләрендәге каплары салынып төшкән иде аның. Кыйшайган галстугын төзәтеп куйды һәм:
— Кирәгез әле,— диде секретарьга.
— Нәрсә, Латиф Ибраһимович?

— Әйтегезче, миңа килгән хатларның барысы да үземә генә тапшырыламы?

Секретарь кызның бизәнгән матур йөзенә җете кызыл төс керде.

— Ничек инде, мин аңламыйм, Латиф Ибраһимович, әлбәттә, сезгә генә тапшырыла!

Латиф үзенең ахмак бер эш эшләп ташлавын тойды һәм хәлне йомшарту өчен:

— Миңа бер хат булырга тиеш иде,— дип куйды.— Ләкин ни өчендер ул һаман килми. Әллә, мин әйтәм, сез ялгышып башка берәр кешегә бирдегезме?

— Юк, андый эшнең булуы мөмкин түгел,— диде секретарь, катгый тон белән. Латиф кызыйның үпкәләгәнлеген анык аңлады.

— Ярар, хәтерегез калмасын, Наталья Герасимовна,— диде ул, үзен елмаерга мәҗбүр итеп.

Ул шунда ук үзенең гамәленә анализ ясарга да өлгерде.

Әгәр теге Мюнхендагы кеше һаман аның әтисе булып кыйланса, әлбәттә, аңардан тагы бер хат килергә тиеш кебек иде. Чөнки инженер аңа Латиф турында әйтми калмагандыр. Кыз борылып чыгып китәр алдыннан Латиф, үзе дә тоймастан:

— Зинһар, сез миңа дигән корреспонденция булса, башка беркемгә дә бирмәгез,— дип калды.

Ул хәзер Министрлар Советына барырга тиеш иде. Тиешле белешмәләрен барлады да, киенеп, молнияле портфелен бер почмагыннан тоткан хәлдә чыгып китте.

Гадәттәгечә, ул бүген дә эшендә тоткарланды, бу юлы кичен үзе утырыш уздырды. Ниһаять, арып-талып, кабынырга торган дарыдай ярсып, өенә кайтып керде.

Өйдә аны улы ялгызы гына каршылады. Ул ишекне һич теләмәгәндәй генә ачты.

— Әниең кая китте, улым?— диде Латиф, киемнәрен чөйгә элеп.

— Әллә! Мунчага китте бугай.

— Нигә, әйтмәдемени?

— Ә нигә миңа әйтсен ул,— диде егет һәм бүлмәсенең ишеген ябып куйды.

Латиф, күңеленең тагы да катырак сыкрана башлавын тоеп, кухняга якка чыкты. Ачуы кабарганнан кабара һәм озакламый ул, һичшиксез, нинди дә булса сылтау табып, улына бәйләнәчәк иде. Ләкин ул шулай да үзен вакытында тыеп кала алды. Кухняга кереп, хатыны әзерләп киткән ашны җылытып алды.

Аннары, кухня шкафындагы коньяк шешәсен кулына алгач, уйланып карап торды. Карасана, эчемлек болай гына түгел иде ләбаса! Кемнең эчүе мөмкин моны? Шундук аның суына башлаган ачуы дөрләп яңадан кабынды һәм ул коньякны Марат эчкәндер дигән фикергә килде. Әлбәттә, шулай, юкса ничек инде ул, гомердә булмаганча, әтисенә шундый тупаслык күрсәтсен. Латиф шешәне өстәлгә куйды да ашыгып коридорга чыкты.

— Улым, кил әле!

— Ну, нәрсә инде?— диде егет, ризасызлык белән.

— Кил әле, кил.

Марат, һич теләмичә генә, эленке-салынкы хәрәкәтләр белән бүлмәсеннән коридорга чыкты.

— Әйдәле,— диде Латиф.

Алар кухняга керделәр.

— Әйт. Син эчтеңме?— диде Латиф, шешәгә бармак белән төртеп. Ул улының хәзер үк яшермичә, әйе, әтием, мин кызыксынып кына, нинди нәрсә икән ул, дип кенә эчеп караган идем, диюен көтте. Хәлбуки,

малай ачуыннан агарынып ук китте. Аның нәкъ этисенекенә охшаган яшькелт күзләре хәзер ут чәчәләр иде.

— Нәрсә син,— диде ул,— котыра башладыңмы әллә?!

Латиф артык түзеп тора алмады, улын эләктерде дә җилгерәтеп каршысына ук китереп бастырды. Улының йөзендә хәзер дәһшәт чагыла иде. Ул тайпылып читкә китәргә өлгермәде, Латиф ике куллап улының яңакларыннан кысты:

— Сула,— диде, тыны кысылып. Бала, әмер үтәү теләгеннән битәр куркуыннан, тирән итеп көрсенеп куйды. Шайтан белсен, эчкәнме, эчмәгәнме, юньсез малай! Латиф аныклап белә алмады, ләкин коньяк исе сизелмәсә дә, ул эчкәндер дигән фикер аңа карап үзгәрмәде.

— Нишләтергә инде сине, малай актыгы,— диде ул, сукранып,— уналты яшьтән бозыла башладың, сукин сын. Мин синең яшьтә...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, кинәт ишек звоногы чылтырады.

— Бар ач, нәрсә карап каттың! — дип кычкырды Латиф. Әйтерсең лә, егетнең түземен җимерү өчен бары шул гына кирәк иде, Марат күз яшьләрен агызып шундук елап җибәрде. Латифның күңел төбендә нидер дерт итеп куйды. Әйе, улы бит аның йөрәк парәсе, төпчеге... Ләкин ул шулай да:

— Җен малай, дип сукранып ишек ачарга үзе чыкты.

Гөлбикә, кәефе бик күтәренке кыяфәттә, алсуланып мунчадан кайтып керде. Өйләрендә ванна булса да, ул шулай айга бер-ике тапкыр Болак буендагы мунчага бармый калмый иде.

— И-и, син дә кайткансың икән,— диде ул, ирен күрү белән яктырып. Латиф сүзсез генә аңа чишенергә ярдәм итте. Хатыныннан җылы мунча арулыгы бөркелеп тора иде. Ул тыгыз итеп бәйләнгән яулыгын чишмичә генә кухня якка узды һәм улының өстәл янында мышык-мышык елап утырганын күргәч, хәйран калып, кашларын күтәрде.

— Әбә-әү, ни булды сиңа, улым?!

Улы отыры ныграк, хәзер инде тавышланып ук елый башлады. Латиф чыраен бозып:

— Ул мәгънәсезгә миннән эләкте әле,— диде.

— Нишләгән,— диде Гөлбикә, куркынып.

— Әнә нишләгән,— диде Латиф, шешәгә күрсәтеп. Хатыны аңламаганлыгын белгәч, ул «эчкән» дип өстәде.

— Эчкән ди менә! Үзе эчкән, э мин гаепле. Больно мне нужно синең аракыларың!

— Әтигә алай әйтмиләр. Тор, улым, бар, бүлмәңә кер,— диде Гөлбикә, үзе иренә рәнҗүле караш ташлады. Тәгаен Латиф белмәгән бербер хәл булган иде. Тәгаен ул егетне юкка гына рәнҗеткән иде. Ләкин улын үз бүлмәсенә озатып Гөлбикә кире кухняга кергәч, Латиф бик җитди кыланган булып:

— Юкка син, Гөлбикә, Маратны үзындырасың. Син, әни буларак, аның бу эше өчен рәнҗергә тиеш идең,— диде.

— Карале, картым, ул бит эчмәгән. Нигә син шулай үз улыңны...— диде Гөлбикә.

— Эчмәгән, эчмәгән! Мин сиңа әйтәм икән, значит, юкка гына сөйләнмим инде. Син бит белмисең, мин аның...

Латиф «авызын исәнә карадым» димәкче иде. Ләкин кинәт, үзенең артык ваклануын тоеп, тукталып калды. Хатыны аңа тагы баягы кебек итеп күзләрен тутырып рәнҗү белән карап алды.

— Әллә нишли башладың син, Латиф!? Шулкадәр дуамалланырга ярыймы соң инде! Белмисең-нитмисең, хөкем чыгара башлыйсың.

— Ничек белмисең, ничек белмисең?— диде Латиф, әтәчләнеп.

— Белмисең шул.

— Белмәсәм, коньяк нишләп кимегән?

— Гаяз абый килгән иде. Шуна бер чынаяк салып бирдем.

— Ә-ә, алай булса,— дип мыгырданды Латиф. Хатыны үзен ничектер өтек итеп күрсәткән яулыгын чиште дә башын селкеп әле кибеп җитмәгән чәчләрен дуылдатып куйды. Шул чак аңа элекке горур матурлыгы кире кайтты. Ахмак бер хәлдә калды бит Латиф. Гөлбикәнең, җиңү тантанасын сиздергәндәй, иренә һич карамыйча эре бер кыяфәттә күзге каршында чәч тарап торуы аны тәмам аяктан екты диярлек.

Латиф коньяк эчеп җибәрде. Чәнечке алып бераз ит кисәкләре капкалады, ләкин тамагыннан аш үтмәде. Ниһаять, ул уянырга теләгәндәй каты итеп маңгаен сыпыра башлады һәм, хатынының көзге алдында чәче белән булашуына һич карамыйча, үз бүлмәсенә керде. Юк, аның мондый халәттә хатынына яңалыкны ачасы килми иде.

## XXVIII

— Карале, Латиф, син нигә тормыйсың инде, сәгать ун бит,— дигән сүзләргә ул чәчрәп уянып китте. Каршысында Гөлбикә басып тора иде.

— Бүген соңрак барасыңмыни?— дип сорады ул.

Латиф, кабаланып, урыныннан торды да киенә башлады:

— Соң барасы түгел, киресенчә,— диде.

Ул сәгать бишне суккач кына йоклап китүе турында бер сүз дә әйтмәде. Хәтта алай гына да түгел, уянып киткәч тә әле уйлары үзеннән үзе һаман, өзми-куймый бер ук нәрсә тирәсендә чуалдылар. Ни пычагыма соң әле ул, тирәнтен фикер йөртмичә генә, теге авыл укытучысына эч серләрен ачып салды?

Латиф, батырчылык итеп, Хәбибрахманның кияүеннән килгән хат турында хатынына сөйләде... Ниһаять, бераз җиңеллек тоеп эшенә китте.

Трестта аны гадәттәгечә якты чырай белән каршы алдылар. Бераздан эш турындагы уйлары Латифны тагы да тынычландыра төште. Учреждение бусагасын атлап керү белән ул үзен борчыган нәрсәләргә шактый тыныч карый башлады, хәтта аңарга үзенә булган элекке ышанычы яңадан әйләнеп кайтты. Ләкин, кызганычка каршы, бу да озакка бармады. Ул, үзе дә сизмәстән эшеннән аерылып, тагы кичәге хәбәр тудырган газаплар белән булаша башлады.

Ул, кәгазьләреннән аерылып, тәрәзәдән күренгән өй түбәләренә текәлде һәм хәрәкәтсез калды. Юк, аның зиһене бернәрсә дә теркәми иде. Латиф үзенең эчке дөньясына чумган иде. Ниһаять, ул ныклы бер карарга килде. Тик ятарга ярамый. Әгәр аңа каршы козырь ташланган икән, ул тагы да зуррагын каршы якка ачып куярга тиеш. Бары шулай гына. Чөнки башкача аңа җан тынычлыгы насыйп булмаячак.

Ул, Хәмзә Бакиров сөйләвеннән, этисенең фронттагы мәхәббәт маҗарасын хәтерләде. Тукта, кем әле ул? Ул — Талия Котдусова, Алафузов заводыннан. Әтисе шуңа гашыйк булып шашынып йөргән.

Латиф шунда ук телефон трубкасына үрелде. Житен комбинатында андый кызны белергә тиешләр иде, аныңча. Чөнки гражданнар сугышы елларында фронтларда татар кызлары әллә ни күп булмаган. Ләкин башта уйлаганча Латиф ансат кына ул Талиянең эзенә төшә алмады. Машинасына утырып чыгып китәргә туры килде аңа. Белсәләр, шул елларда заводта эшләүчеләр, хәзерге пенсионерлар белер аны, диделәр. Латиф завод идарәсе тарафыннан бирелгән барлык адреслар буенча йөрергә кереште. Соңгы адрес буенча табылган карчык аңа өметләнерлек хәбәр сөйләде. Чыннан да, шундый кеше булган икән. Гражданнар сугышы беткәч Талия ире белән Казанга кайткан, ләкин Бөек Ватан сугышы алдыннан ул машина астында калып һәлак булган, ә ире армиягә китеп, сугышта югалган.

— Аларның бала-чагалары юк идемени?— диде Латиф. Әби бик озак уйланганнан соң аларның кызлары булырга тиешлеген әйтте. Карчыкның белүенчә, кыз хәзер кияүдә, үзәк урамнарның берсендә, Казанда яшәргә тиеш иде.

Төн житкән иде инде. Талиянең кызын эзләүне иртәгә көнгә калдырып, Латиф өенә кайтырга мәжбүр булды.

Бу вакытта да аның хәле шулкадәр сәер иде ки, барлык уй-теләкләре бары тизрәк шул соңгы өмет йолдызы җемелдәгән очрашуга кайтып калды. Иртәгесен ул, эшкә барганчы, Талиянең кызын эзләп тапты. Баксаң-күрсәң Латифлардан ерак та тормый икән үзе!

Ап-ак йөзле бер чибәр генә блондин ханым каршы алды аны. Ул, өйдәге тәртипсезлек өчен гафу үтенеп, Латифны эчке бүлмәгә узарга чакырды. Латиф исә, мәрхүмә Талия Котдусовадан истәлекләр, хатлар калмадымы? дигәч, хатын шаркылдап көлеп үк җибәрде.

— Сез дә тарихчымы әллә? — диде ул.— Менә сез әниbudнең истәлекләре белән кызыксынып килүче икенче кеше инде.

— Шулай укмыни, килүче булдымыни?

— Булды шул,— диде ачык чырайлы хатын,— әнинең барлык язуларын, хатларын Бакиров дигән бер агай тикшереп китте.

Латиф уңайсызланып җилкәләрен җыерды.

— Мин тарихчы түгел шул. Хикмәт бары шунда: сезнең әниегез белән минем бер бик якын кешем гражданнар сугышы чорында дус булганнар һәм мин...

Латиф тукталып калды.

— Ах, сез әллә минем әниемә гашыйк булган Ибраһим Касыймовның туганымы?

— Әйе,— диде Латиф, балалар кебек кызарынып. Хатын ашыгып күрше бүлмәдән бер төргәк кәгазь алып чыкты.

— Рәхим итегез, әнидән калган кәгазьләр менә шунда.— Ул, елмаеп, Латифка күз атты.— Сезнең абзагызның әниемә гашыйк булып йөрүен, ул әтиемә кияүгә чыгарга булгач, көндәшенә кул күтәрүен әтиләрнең көлешеп искә алганнары әле дә хәтеремдә.

Латиф җавап бирмәде, үзен никадәр тыярга теләсә дә, булдыра алмыйча, ашыгып, өстәлдә яткан кәгазьләргә үрелде.

Хат, хат кирәк иде аңа! Тәгаен, Латифның әтисе Талиягә бер генә хат язмагандыр. Шуларның бәлки берәрсе саклангандыр әле. Шул хат табылса, аңа башка берни дә кирәкми, берни дә кирәкми. Ул озак эзләнде. Ниһаять, артык җитдиләнеп тынып калды. Тукта, бу шул үзе түгелме соң? Латиф, чәй кәгазенә гарәп хәрефләре белән язылган хат кисәген кулына алды. Әйе, тузып беткән хатның азагына «Ибраһим Касыймов» дип кул куелган иде. Ләкин... Латиф бермәл хәл алып күзләрен йомган килеш утырды да, хатынны аптырашта калдырып, аягүрә басты.

— Барсы да аңлашылды,— диде ул ничектер карлыккан, зәгыйфь бер тавыш белән.— Хушыгыз.

Аның тизрәк кешеләрдән еракkарак, читкәрәк китеп үзенең яна ачышын сеңдерәсе, үзенең яңа бер гаҗәп халәтенә лаеклы күңел тигезлеге табасы килә иде.

## XXIX

Кайчандыр Альфред белән беренче тапкыр очрашкандагы кебек, Хәбибрахман абзый үзенең көндәлек дәфтәрен укып, баштан кичкән утлы-давыллы көннәрне хәтерләгәч тә, канатланып, дәртләнеп китте. Юк, аңа һич тә кире чигенергә, ниндидер бер намуссыз кешенең оста дәлилләүләренә карап икеләнергә ярамый. Дөреслек ул һәрвакыт бөек. Бәлки, Хәбибрахманның һәм аның дусларының гайре табигый батыр-

лыклар ясаганы да юктыр. Лэкин алар вакытында булдыра алганнын барын да эшлэделэр. Нигэ моны барлык кешегэ, хэтта тарихка житкермэскэ?! Нигэ менэ шул нэни Лэйлэ, үскэч, аңлы бер кеше булгач, үзенең бабасы турында белми йөрергэ тиеш? Дөрес, картлыкның да начар яклары бар! Буыннар сызлый, көч-хэл кими. Лэкин бу экланырга сэбэп түгел эле. Һай, Хэбибрахман, кайда синең типсэ тимер өзэрдэй чакларың?! Кайда синең баскан саен очкыннар очырткан ир-егет вакытларың!? Бирешмэ, бирешмэ, карт! Яле, күтэрел. Үзеңне кулга ал. Без эле алай тиз генэ төшеп калмыйк. Күрсэтик эле барысына да карт гвардиянең кем икэнлеген!

Хэбибрахман абзый, квартир ишеген биклэп, ачкычны күршесенэ бирде дэ таягына янтаеп баса-баса музейга таба китте.

Анда аны таныйлар иде, җылы каршыладылар. Лэкин, эшнең асылын аңлагач, мондый хэтэр мэсьэлэне иң элек профессор Даутовка җиткерергэ кирэклеген эйттелэр. Беренчедэн, ул тарихчы, авторитет, икенчедэн, ул нэкъ менэ шул Хэбибрахман үз башыннан кичергэн чор белэн кызыксына. Хэбибрахман абзый күңелен төшермэде, таягына тагы да ныграк янтая төшеп, университетка таба юнэлде. Ул барып җиткэнче берничэ тапкыр ял итте, баскычтан менгэн арада тэмам ухылдап чыкты, мэгэр телэгенэ иреште, профессор кабинетына барып җитте һэм, артык тэкэллефлэнмичэ, шакылдатып та тормастан, ишекне ачты.

Профессор аны, лупа тотып, ниндидер борынгы карта тикшергэн хэлдэ каршы алды.

Ишек ачылып ят бер кеше күрүен ул абайламады да, күрэсең, кафедра кешесе дип уйлады булса кирэк.

— Килегез эле, мин сезгэ нэрсэ күрсэтэм,— диде.

— Исэнмесез, профессор,— диде Хэбибрахман, галимнең янына ук барып. Профессор аны бермэл танымыйча торды. Таныгач, елмаеп җибэрде. Куанычына каршы, Даутов Хэбибрахманның исем-фамилиясен дэ хэтерли иде.

— Утырыгыз рэхим итеп,— диде ул, урын күрсэтеп.

— Мин сезнең белэн бик җитди эңгэмэ корырга килдем,— диде Хэбибрахман абзый, сүз башлап.

Карт куен кесэсеннэн көндэлек дэфтэрен алып өстэлгэ салды, профессор сабыр гына көтте, бер Хэбибрахманга, бер дэфтэргэ карап куйды. Сүзне ничегрэк башларга белмэгэндэй, кашларын җыергалап, тамак кыргалап утырган картның җитди сүз башларга телэве ачык иде. Ниһаять, Хэбибрахман, зиһенен җыеп, сүзгэ керешге. Профессор, комачауламасын дигэндэй, ике арадагы китаплар өемен дэ читкэрэк этте. Хэбибрахман барысын да сөйлэде. Күңеле бушап, үзе җиңелэеп калгандай иде хэзер.

— Эйтэм җирле, теге музейдагы инциденттан соң күңелдэ ниндидер төен калган иде,— диде профессор.— Мин сезнең олы, җитди кеше буларак, алдашу юлына басмаячагыгызны тойган идем, хэлбуки сез иптэш Бакировка каршы ул чакны нигезлэп берни дэ эйтмэдегез.

— Мин ул чакны коралсыз идем,— диде Хэбибрахман, тэмам җанланып.— Минем бер дэлилем дэ, хаклы икэнлегемне исбат итэрлек бернинди мөмкинлегем дэ юк иде.— Ул, кабаланып, калтыранган бармаклары белэн көндэлек битлэрен актара башлады.

— Менэ,— диде ул, яшьлэнгэн күзлэрен профессорга төбэп,— мин сезнең вакытыгызны күп алмам, тик шулай да берничэ юлын укып күрсэтим эле.

Көндэлектэге укылган урында 1919 елның унтугызынчы июнь көне тасвир ителгэн иде. Таң ату белэн безнең гаскэрлэргэ каршы атлы казаклар һөҗүм башлый. Таякның иң юан башы тугызынчы ротага төшэ. Дошман көчле, ул сан ягыннан да, корал җэһэтеннэн дэ күп өстен. Лэкин, шуңа да карамастан, кызылармеецлар каһарманнарча су-

гышалар, дошманның котырынган атакасын берничә тапкыр кире кайтаралар. Хәл штык сугышына кадәр барып житә. Ләкин көндезге унберләрдә өченче батальон полкның төп көчләреннән аерылып камалышта кала. Күп тә үтми, икенче батальонның язмышы да кыл өстендә икәнлеге мәгълүм була. Ниһаять, ул күп югалтуларга дучар ителсә дә, беренче батальонның ярдәме белән үзенең төп көчләрен саклап, ут боҗрасыннан чыга башлый.

Полк башта Воробьевка дигән авылга таба чигенә. Ләкин тиздән бу авылның дошман кулында икәнлеге беленә. Полк белән командир ярдәмчесе Сабитов житәкчелек итә. Ул оста маневрлар ясап, полкны дошман уты астыннан алып чыга, ләкин үзе батырларча һәлак була. Хәзер бердәнбер чара Гамалеевка станциясенә барып, андагы полк штабын дошманнан саклап калу. Тик, кызганычка каршы, казаклар монда да килеп өлгергәннәр инде. Комендантский взвод барлык көченә тырышып, кан коеп, үзеннән күп тапкыр көчлерәк дошман белән сугыш алып бара. Яраланып беткән, ач, ялангач кызылармеецлар соңгы патроннары белән мылтыкларын корып, тагы сугышка ташланалар. Ләкин бу — вакытны бераз гына булса да кичектерү өчен генә ярый. Рәхимсез дошман барыбер безнең гаскәрләрне изеп, сытып китәчәк. Бары бер бурыч: дошманның тоткарлануыннан файдаланып, станциядәге тупикка кертелгән тугыз вагонны коткарып калып булмасмы? Чөнки анда штаб, анда документлар. Бу эш Хәбибрахманга йөкләтелә. Ул, котырынган ут өермәсе арасыннан чыгып, сигез егет белән бергә станциягә йөгерә. Ярый әле вагоннар үз урынында икән. Ләкин аларны алып китәр өчен берәр паровоз, я декапот кисәге булсынчы! Егетләр шундый җаваплы бер минутта зур тапкырлык һәм батырлык күрсәтәләр. Колгалар ярдәмендә вагоннарны берәмләп кузгаталар һәм составны урыныннан алып китәләр. Дошман утыннан котылганчы тугыз километр араны этеп баралар...

Хәбибрахман абзый шул җирдә тукталды да сорау белән профессорга текәлде. Аның карашы, күрәсезме, менә ничек булды бит ул, без мең михнәт чигеп үз җилкәбездә советны дошманнан сакладык, ә кемнәрдер, берни эшләмәгән хәлдә, шуннан үз даннары өчен файдаланалар, дия иде.

Профессор, Хәбибрахманның көндәлеген алып, үзе укый башлады.

— Ул нәкъ менә шушы эшләрне, беренче полкның штабын коткаруны мин үзем башкардым дип сөйли,— дип куйды Даутов, берничә бит укыганнан соң.

— Шулай,— диде Хәбибрахман.

— Искитмәле оятсызлык!— диде профессор.

— Әйтеп бетергесез.

— Һичсүзсез фаш итәргә, фаш итәргә! Тарихның бер генә тамчысын бозып күрсәтү дә зур җинаять ул. Мин шундый карашта. Фальсификаторлар белән көрәш бик нык көчәергә тиеш.

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде Хәбибрахман,— ләкин нидән башларга?

Даутов бераз вакыт уйланып утырды.

— Хәбибрахман ага, бу көннәрдә сезгә Альфред Хәйретдинов килеп чыкмадымы?

— Булды ул миндә.

— Бик әйбәт,— дип куйды профессор,— минемчә, сезгә иң элек көндәлегегезне матбугатта бастырып чыгарырга кирәк. Менә шуны оештыруда ул сезгә ярдәм итәр.

— Ул дигәнегез Альфредмы инде?

— Әйе, Альфред Яхич. Ул яшь, энергияле, акыллы кеше, аннан иренчәк тә түгел. Мин шефлык итүне үз өстемә алам.

Ул, елмая төшеп, мөһим сер чишкәндәй:

— Шушы көннәрдә хәл итеәә. Без аны кафедрага ассистент итеп алабыз,— диде.
— Адресын калдырган иде булса кирәк ул егет,— дип куйды Хәбибрахман, чигәсен кашып.
— Менә аның адресы,— диде профессор, Альфредтан килгән хатның конвертын суҙып.— Ҡиңәш шул: сез, озакка сузмыйча, аны чакыртыгыз да эшкә керешегез.
— Ләкин эш аның белән генә бетмәячәк бит әле. Мин сезгә тегенен кайбер башка мәсьәләләрдә дә караклыгын әйтә алам. Теләсәгез, тагы укыйм.
— Мин сезгә ышанам. Без иркенләп бер утырырбыз әле. Ә хәзер сезгә йомгакны сүтә башларга кирәк. Аннан күз күрер. Мондый хәлдә дәшми тору ул инде... беләсезме, ни дигән сүз?
— Беләм.
— Тик тагы менә шул, бу дәфтәрегезне югалтмагыз, саклагыз.

## XXX

Луиза, Альфредка ярдәм итү теләге белән, кием тектерергә кирәклеген сылтау итеп, якшәмбе көнне Казанга китте. Комиссия тикшерүләре, бәхеткә каршы, шома гына үтте. Луизаның исәбенчә, әгәр ул үзе эшкә керешеп, Альфредка ярдәм кулын сузса, һичшиксез, аның ире Әхмәдиев яласыннан да котылачак иде.
Луиза, Казанга килеп төшү белән танышларына кереп, Латифларга телефоннан шалтыратты.
— Латиф абый өйдәме? Латиф абый кирәк иде миңа, апа,— диде ул Гөлбикәгә.
Телефондагы кешенең Латифның хатыны икәнлеген тою өчен, әлбәттә, хатын-кыз һәм Луиза булырга кирәк иде.
— Сез кем буласыз соң?— дип сорады Гөлбикә.
— Мин эш буенча, апа,— диде Луиза, бик җитди тон белән.
— Хәзер әйтәм,— диде Гөлбикә,— ул әле ванна керә.
— Мин, әгәр рөхсәт итсәгез, сезгә барып чыгар идем, апа,— диде Луиза,— Минем Латиф абыйның үзен күреп сөйләшәсем килә.
— Яхшы, әйтермен, ул сезне көтәр.
Луиза иптәш кызының кулын кысты да, теге никадәр кыстамасын, артык тоткарланмыйча, Латифларга чапты.
Ул зәвык белән җыештырылган бай, җитеш квартирага барып кергәндә, хуҗа ваннадан чыккан, хәзер чаңгы каешларын көйләп маташкан улына булыша иде.
Ул, аптыравын яшерергә тырышып, Луизаны төксе йөз белән каршы алды. Луизаның тавышын ишетеп коридорга чыккан Гөлбикәнең йөзендә исә ниндидер салкын елмаю һәм сынаучан бер караш билгеләре чагылып китте.
— Минем сезгә бик зур йомышым бар, Латиф абый. Мөмкинме?— дип сорады Луиза. Бу яшь хатынның йөзендә ярарга тырышып елмаю һәм үз дигәнен итәргә әзер тору күрде Латиф.
Тәмам тәшвишкә калган хәлдә, ул, ни әйтергә дә белмичә, тамак кырып куйды.
— Рәхим итегез. Нинди йомыш?
Луиза, Латиф ишарә ясау белән үк, күз ачып йомганчы дигәндәй, мех эчле итекләрен салды да, авыл гадәте буенча, оекчан гына, мантодан, хәтфә келәм җәелгән эчке бүлмәгә узды.
— Утырыгыз,— диде Латиф. Луиза җыйнак кәнәфигә чумды һәм хатын-кызга хас кызыгу тойгысы аша бүлмәдәге стильле мебельне күзеннән кичерде. Менә шундый булсын иде ул өең, дигән уй аның йөзен-

дә ачык чагыла иде. Ләкин алда шулай да житди сөйләшү тора иде әле. Ниндидер кырыс кыяфәтле, олы гәүдәле агай, бик зур кешедер инде, әлбәттә. Луизаның әрсезлеген өнәми, ләкин нишләмәк кирәк соң?! Альфред өчен барысын да эшләргә әзер Луиза.

— Сөйләп жибәрегез,— диде Латиф. Луиза каршысына утырып. Хужа ничек дип тә юрарга белми иде. Күңел төбендә сызып ниндидер төер ята. Ул исә хәтәр бер нәрсәгә, дәһшәткә әйләнергә тора. Чыннан да, нәрсә кирәк бу чибәр хатынга? Латиф, шундый уйлар кичереп, Луизаның тизрәк сүз башлавын көтте.

— Мин Альфредның хатыны,— диде Луиза.— Сез аны беләсез бит? Альфред Хәйретдиновны.

Латиф отыры сагаеп, Луизага текәлде.

— Әйе. Беләм мин аны.

Хатынның йөзен башта матур елмаю балкытты. Аннары ул житдиләнеп:

— Бер күңелсез нәрсә килеп чыкты, Латиф абый,— диде.— Альфред ничектер сез биргән адресны онытып калдырган. Сез ана ФРГда яшәүче әтиегезнең адресын биргән идегезме?

Яшен яшьнәп киткәндәй булды. Латиф ирексездән куркынып ишеккә карап алды. Җавап бирү урынына, «әйе» дигәнне аңлатып, бары ияк кенә какты.

— Чит илдә минем бернинди дә әтием юк. Шуннан, шуннан,— диде ул, ниһаять, тынычлана төшеп.— Кайда оныткан соң ул аны? Адресны дигәнем...

— Ләкин эшнең хәтәрлеге шунда: ул адресны бер иптәш тапкан. И нигәдер хәзер Альфредка тузга язмаган гаепләр тагарга йөри. Ул соңгы вакытларда Альфредка гел каныга. Шул!

— Ничек инде, ни өчен алай? Әллә адресның иясе...

— Янәсе, ул чит ил шпионнары белән бәйләнеш тота.

— Ничек инде?— диде Латиф, бөтенләй агарынып.— Фамилиясе ничек аның?

— Фамилиясе — Әхмәдиев.

Латиф, ни әйтергә дә белмичә, бер мәл өнсез утырды.

— Хәзер сез минем ни өчен килгәнемне аңлыйсыздыр инде,— диде Луиза, сүзен дәвам иттереп.— Мин сезгә үтенеч белән килдем. Әгәр сез Альфредка ярдәм итмәсәгез, аның пычратылуы мөмкин. Минемчә, моңа бернинди дә нигез юк.

Луиза, озын керфекләрен сирпә-сирпә, җавап көтеп Латифка текәлде.

Кинәт Латифның күңелендә ниндидер яна тойгы туды. Тукта, ни өчен бу шундый сорау бирә әле аңа? Ә дөреслектә ул Альфред хатынымы соң? Ни өчен минем өемә әрсезләнеп килеп кергән ул? Кем адрес биргән аңа?

— Менә нәрсә, сеңелем,— диде ул,— безнең эш чисто мужской, ирләр эше. Әгәр сезнең ирегезгә нинди дә булса ярдәм кирәк икән, әйтегез, ул үзе килеп чыксын...

Луизаның матур күзләре зур булып ачылдылар.

— Ә нигә алай? Мин бит монда килүемне аңа бөтенләй әйтмәдем дә. Ул бит бик... нәрсә дип әйтим инде, эчтән генә көеп йөри торган кеше. Аның хәтта профессор Даутовка да хәсрәтен чишкәне юк. Ә бит аңа сез биргән адрес өчен генә бәйләнми Әхмәдиев абый. Ул аңа бүтән гаепләр дә тагып бетерде инде.

Латифның бу сүзләрдән соң шикләнүе чигенә житте. Күңелендә бер-бер артлы тагын тәшвишле сораулар туа башлады.

— Менә хәл болай, сеңелем,— диде ул, күңелсезләнеп,— мин сезгә барын да сөйләп бирим инде алайса. Сез үзегез хөкем итәрсез, тиешле нәтиҗәләр ясарсыз. Ләкин мин башта шул кадәресен әйтим: мин менә

инә очы кадәр генә дә курыкмыйм. Мин барына да риза. Эш бары шунда: мин атамның үзебезнең кеше булуын телим. Мин бары аның андый булмавыннан куркам. Газаплануның төп сәбәбе бары шунда. Сездән мин яшермим. Чөнки бу урынсыз.— Ул этисеннән килгән хат турында һәм этисенә карата булган юрауларын сөйли башлады. Ләкин Луизаны Ибраһимовнының кичерешләре, уйлары бөтенләй кызыксындырмый иде, ахры. Ул сүзне озынга китә башлагач бүлдерде:

— Ә нигә сез ул адресны Альфредка бирдегез?— диде.

Латиф әрнү аша көлемсерәп куйды.

— Ул үзе сорап алды аны.

Луиза, ни әйтергә дә белмичә, матур кашларын өскә күтәрде.

— Мин сезнең шулай да Альфредка ярдәм итүегезне үтенәм.

— Ә аңа ярдәм мәсьәләсендә без сөйләштек инде,— диде Латиф, үкенечле рәвештә елмаеп.— Әгәр ярдәм кирәк икән, ул үзе килсен. Адресны белә. Һич булмаса, эшләгән урынга шалтыратсын.

Луиза, ни әйтергә дә базмыйча, җәһәт кенә торды да саубуллаша башлады.

Латиф, бүлмәсендә яңа килгән газеталарны караштырганнан соң, түзмичә, хатыны янына, кухня якка чыкты.

— Әбәү, син трестка барып кайтам дигән идең ич?

Чыннан да, Латиф, ял көне булса да, берәр сәгатькә барып, тәгәлләнмәгән эшләрен бетереп кайтырга җыенган иде. Ләкин теге шикле хатын аркасында барлык план челпәрәмә килде...

— Юк инде,— диде Латиф, меланхолик рәвештә,— гомердә бер булса да мин дә кешечә ял итим әле.

Латиф, кухнядагы буфетның капкачын ачып, нидер эзләнә башлады.

— Нинди хатын соң ул, үз өенә кайтып кергәндәй?..— дип сорады Гөлбикә.

— Нигә, син минем әйткәннәрне ишетмәдеңмени?

Гөлбикә, аптырап, иңбашларын селкетеп куйды.

— Слушай, кая, минем монда коньяк бар иде,— диде Латиф.

— Тагы шул коньягына тотынды инде,— диде Гөлбикә, сукрана төшеп.— Бар, эшеңне бетереп кайт башта. Син кайтуга аш әзерлим. Менә шунда...

— Бармыйм, дип әйттем бит инде мин сиңа! Ичмаса, гомеремдә бер тапкыр, кешечә, үзем теләгәнчә, ял итәргә хаклыдыр бит мин, наконец!?

— Әллә нишләдең син, Латиф...

Латиф үзен бу минутта бәхетсез итеп тойды. Аңа коньяк хәмере дә ярдәм итмәде. Ул әлеге хат уңае белән үзе кичергән мәгънәсез газаплардан котылу турында тагын уйлана башлады:

— Мин бит этиемә иң изге, иң мөкатдәс кешегә карагандай ышанып, инанып карадым. Ә бәлки минем фәлсәфәм ялгыштыр? Юк, җаным, үзеңне юатма. Кирәкми. Барысы да нәкъ сызылган юл буенча, дөп-дөрес юл буенча бара. Ә бәлки этием минем бер дә андый куркырлык кеше түгелдер, ә? Бәлки, ул безнең кешедер? Ха-ха. Юатма үзеңне әллә нинди иллюзияләр белән! Этиең синең, тәгаен, бер адәм актыгыдыр әле...

Ниһаять, ул урынынннан сак кына торды да, «ашың пешәме әле?» дип сорау өчен хатыны янына, кухняга таба юнәлде.

## XXXI

Хәбибрахман абзый Альфредка профессорның бергәләп эш итәргә киңәш биргәнлеген әйтте. Күренеп тора, укытучының күңеле боек, үзе борчулы иде. Әлбәттә, Хәбибрахман бу эшнең сәбәбен анык белми иде һәм шуңа күрә моңа җитәрлек игътибар да итмәде.

— Миңа бу эштә ярдәм итәрсез дип ышанам,— диде ул сүзен тәгәлләп.

— Нindирәк ярдәм кирәк булыр соң сезгә?— диде Альфред.

— Миңа сезнең профессорыгыз тегене фаш итеп вакытлы матбугатта чыгыш ясарга киңәш итә.

— Ә судка мөрәҗәгать итсәк?— диде Альфред, авызын каплап иснәнгән хәлдә.

— Суд, минемчә... юк, бармый! Чөнки ул кешене бөтен халык алдында фаш итәргә кирәк. Берьюлы акылга утыртырга.

Альфред елмаеп куйды. Хәбибрахман абзый исә үзенең көрәшкә һич чигенүсез әзер икәнлеген сиздерергә тырыша иде.

Ул тагы сүзгә кереште.

— Кулъязма өстендә эшләү авырлашты, Альфред. Зиһен бик таркау. Җөмләләр ничектер чатлы-ботлы чыга. Мәкалә язганда сез миңа нәни генә ярдәм итеп җибәрсәгез, бик тә әйбәт булыр иде.

Альфред, ни рәвештә дигәндәй, тагы аңа сорау белән текәлде.

— Юк, язарга түгел,— диде карт, ашыгып.— Язганны төзәтеп, редакцияләп кенә чыгарга. Бераз тәртипкә китерергә.

— Андый эшне генә башкара алырмын дип уйлыйм,— диде Альфред, уйланып.— Мин барысын да үз өстемә алыр идем. Әйтик, анда редакцияләргә йөрүне дә, тиешле оешмаларның ишеген шакуны да. Чөнки бу бит бик изге эш, тик...

Ул шунда сүзеннән тукталып калды.

— Вакыт тармы?— диде Хәбибрахман, ярарга тырышкандай елмаеп.

— Һи, вакыт! Вакыт юк та юк инде. Ләкин монда мәсьәлә башкачарак тора. Дөресен әйткәндә...

— Нәрсә?— дип сорады Хәбибрахман, нидер сизенеп.

Альфред тирән итеп көрсенде дә Хәбибрахманга барысында сөйләп бирде. Директорның каныгулары да, хатынының бу хәлне артык авыр кичерүе дә, өйдә шуңа күрә соңгы көннәрдә тынычлык югалуы да сөйләнде.

— Шулай икә-эн,— дип, башын аска иеп озак кына уйланып утырды Хәбибрахман. Аннары серле рәвештә шыпырт кына бу эшләрне оештырып йөрүче кеше теге Хәмзә Бакиров түгел микән?— дип сорады.

Альфред ирексездән көлеп җибәрде. Булса да була бит! Кеше, берәүне сөймәсә, бөтен гөнаһларны шуңа өя башлый.

— Юк, безнең мәктәп директоры үзе шундыйрак кеше инде,— диде ул Хәбибрахманга.— Ләкин мин шулай да, сезгә ярдәм итми калмам.

— Миңа ярдәм дип, ул кадәр... шул минем язганымны карап чыгып, төзәткәләсәгез, башка әллә ни кирәкми. Минем башка кешегә сиздерәсем килми. Юкса, мин кеше табар идем.

— Юк, карап чыгарга авырсынудан түгел, Хәбибрахман абзый. Мин бит Казанда яшәмим. Ә авылдан чыгып китү минем өчен хәзер бик авыр проблемага әйләнде. Бары шуңа күрә генә...

— Соң аны...— дип куйды Хәбибрахман,— мин аны язган да идем инде. Менә, карап чыгыйк алайса. Калганын үзем дә эшләрмен.

Карт үзенең кадерле язулары саклаңган әлеге саргылт иске портфеленә үрелде. Аның бәләкәй кесәсеннән дәфтәр битенә язылган язу алып, байтак вакыт тикшереп утырды. Ниһаять, Альфредка сузды.

— Менә ул! Карап чыгыйк әле. Шулай ярар микән? Мин моны гәзиткә дип яздым.

Альфред шунда ук укып чыкты.

— Болай бармый, Хәбибрахман абый.

— Шулаймыни? Нигә?

— Сез бик артык ярсыгансыз, күрәсең. Сез ике сүзнең берендә аны

хурлыйсыз. Дәлилләп, фактлар белән нигезләп, тынычрак тонда язарга кирәк. Нигә алай чәпчергә!?

— Шулаймыни? Шулай тоеламыни? Ә бит андыйларга бәреп әйтергә вакыт җиткәндер инде!

— Әйтергә кирәк, ләкин мәсхәрә итү рәвешендә түгел. Минемчә, тыныч кына, деликатно гына, ләкин нигезләп. Ахыр чиктә, минемчә, бурыч үзегезнең хисләрегезне күрсәтү түгел, ә шундый тойгыларны башкаларда тудыру. Шулай түгелмени?

Хәбибрахман, башын кырын салып, көлемсерәп куйды:

— Алайса, Альфред, минә шуны төзәтеп, киртәсенә кертеп, дигәндәй, язийк әле.

Альфред тиз генә сәгатенә карап алды.

— Әгәр унбиш минуттан мин сездән чыгып китмәсәм...

— Һем-м, алай икән,— диде Хәбибрахман, күңелсезләнеп,— унбиш минут дисең. Ул арада чәй эчәргә дә өлгермәбез шул. Ай, чәй дигәннән, онытканмын да ич...

Ул, кабаланып, урыныннан торды, аксый-туксый кухняга чыгып китте.

Анда чәйнек күптән инде дөбер-шатыр килеп кайный иде. Ләйлә исә идәнне һәм өстәлне генә батырып калмыйча, үзе дә чәчләренә кадәр онга буялып беткән, бөтен кухняга хуҗа булып, камырдан нindидер калачлар ясап утыра иде.

Хәбибрахманның күзләре шар булды.

— Кы-зы-ым, нишләвең бу?! Әниең кайтып керсә, ничек җавап бирербез!

Ләйлә, һич исе китмичә, гамьсез генә камыр әвәләвендә булды, аннан соң көтелмәгән тынычлык белән:

— Бабакаем, духовканы яндырып бир әле, әнием кайтуына мәмәй песереп куйыйм,— диде.

Хәбибрахман тиз генә Ләйлә ясаган камырларны тәлинкәгә җыеп сала башлады. Мондый хәлгә тәмам шаккаткан Ләйлә, бераздан эшнең нинди юнәлеш алганлыгын аңлап, кычкырып еларга, бабасы белән тарткалашырга тотынды. Картның артык озаклавына һәм коридордан килгән тавышка аптырап, Альфред кухня якка чыкканда аларны шундый хәлдә күрде.

— Менә бит син аны, кара инде, билләһи,— диде Хәбибрахман кунакны күргәч, акланырга теләгәндәй.— Һич ялгызын калдырырга ярамый. Нинди булса да берәр хикмәт ясамый калмый.

Ул Ләйләне аяк арасыннан ычкындырды. Хәзер инде көйсез кызчык, үкереп, нәни йодрыклары белән бабасының ботын барлык көченә тукмаклый иде.

— Ай-яй,— диде Альфред, шелтә белән,— бабайны шулай кыйнарга ярыймыни?

Ләйлә, бу сүзләрне ишеткәч, кинәт туктады, яшьле күзләрен тутырып, нәфрәт белән Альфредка карап торды, аннары, күрәсең, артык түзә алмаудандыр, нәни кызыл иреннәрен очландырып завучка таба төкеренә башлады. Хәбибрахман кызын ботына кысты.

— Без болай итик,— диде Альфред картка,— сез миңа үзегезнең теге көндәлегегезне бирегез. Миндә Бакировның мәкаләләре бар, мин, көндәлегегезгә нигезләнеп, мәкаләне сезнең исемнән язармын. Киләсе атнада минем барыбер Казанга киләсем бар, без шунда аны карап, тиешле рәвешенә кертербез. Сез каршы түгелме?

Үзсүзле үҗәт кызчык аркасында шактый тетрәнгән һәм каушап калган Хәбибрахман башта аңламыйча торды. Ниһаять, төшенгәч, кызын ычкындырды да Альфред артыннан эчке бүлмәгә узды. Шул вакыт картның хәтеренә профессор Даутов әйткән сүзләр төште. Көндәлегезне нык саклагыз, дигән иде ул. Ә бу егеткә ышанып буламы соң?

— Менә, Альфред, мин сезгә язуны бирәм. Тик, үпкәләштән булмасын, көндәлекне хәзергә...

— Хәерле булсын,— диде Альфред.— Язуыгызны бирегез.

— Шулай итик,— диде карт,— булмаса шулай итик. Сез минем язуны әйбәтләп төзәтеп күчерсәгез, хәзергә шул җиткән.

— Борчылмагыз,— диде Альфред, язуны алып.

Карт, Альфредны озата чыкканда кухня турысына җиткәч:

— Вәт бәла! Ай-яй-яй,— диде, һаман елап торган кызына күз атып.

Альфред чыгып киткәч, Хәбибрахман көндәлекне егеткә бирмәвенә үкенеп куйды. Хәер, язуда әйтелгәннәре дә җиткән, дип уйланды ул бераздан, тынычланып.

# XXXII

Хәбибрахман Альфредны өч көн көтте, шуннан соң картның сабырлыгы тәмам бетте. Ул, завучны чакырып, тагы хат салды. Картның уенча, Альфред өч көннән дә калмый Казанга килеп чыгарга тиеш иде. Бу юлы хәтерем ялгышмыймы икән дигән уй аның һич башына да кермәде. Теге ыгы-зыгы аркасында, күрәсең, ул барын да онытып бутап бетергән иде.

Һәрхәлдә, үз башында туган юрауларны чынбарлык белән бутау аркасында, ул, өч көн узса да Альфред һаман күренмәгәч, бөтенләй борчыла калды. Ни булды егеткә? Я булмаса, онытгымы? Ах, әгәр Хәбибрахман сәламәт, я яшьрәк кеше булса, аптырап торыр идеменI Альфредны җиде җәһәннәм артыннан эзләп табар иде!

Шулай тагы ике көн узды. Өченче көн киткәндә Альфредтан хат килеп төште. Анда бары ике генә җөмлә язылган. Егетнең бик ашыгып каләм тибрәткәне күренеп тора иде: «Хәбибрахман абзый, борчылмагыз. Мин әйткән вакытымда сездә булырмын, сәлам белән: Альфред».

Карт, хатны алгач, озак вакыт башын чайкап күңелсезләнеп утырды. «Менә шул инде ул хәзерге яшьләр,— дия иде ул эченнән,— вакытында булырмын, имеш. Ә бит вакыты күптән узды инде. Ничек күрәләтә шулай итәргә була». Ләкин ул һич югында хат килүенә дә шат иде. Димәк, үзе дә килми калмас.

Хәбибрахман, әле ул кайчан килә, килсә, аның язганы минекеннән яхшырак буламы, юкмы әле, дип уйланды. Иң яхшысы — үзенә ышану. Ул, шундый караштан чыгып, хәзер үк, бүген үк эшкә керешергә булды. Нигә сузарга, иң әһәмиятлесе факт бит, ә инде матур итеп язуын гына анысын редакция кешеләре белән бергәләп тә эшләргә булыр.

Ул, газета өчен әзерләнгән мәкаләнең үзендә калган караламасын бик озак төзәткәннән соң, зур тырышлык белән акка күчереп алды. Аннары Ләйләне иярте дә, ишекне бикләп, газета редакциясенә китте. Матбугат йортының озын коридорларында байтак эзләнеп йөргәннән соң, алар кирәкле бүлекнең кирәкле сотруднигын таптылар. Бабай белән кызчыкны каршы алган редакция кешесе тәбәнәк кенә буйлы, житү чәчле бер егет иде. Хәбибрахманның: «Сездер инде ул мин эзләгән кеше?» — диюенә каршы ул:

— Әйтеп багыгыз, ниндирәк йомыштыр бит,— диде. Хәбибрахманның сулышы капкан, тез буыннары калтырана башлаган иде инде. Моңа, әлбәттә, газета сотруднигы да игътибар итми кала алмады.

— Әнә урындык, башта утырып торыгыз, бабай,— диде ул. Шул ук минутта зур кара күзләрен тутырып үзенә текәлгән Ләйләгә дә игътибар итте. Күз кысып:

— Айт сине, нигә иртә торгач күзеңне юмадың?— диде,— Сезнең юлдаш шәп икән, бабай.

— Шәп ул минем кызым,— диде Хәбибрахман, утырып,— ул минем беренче булышчым.

Сотрудник кулындагы каләмне өстәлгә куйды да:

— Я, ничек соң, бераэр хәбәр китергәнсездер, ахры?— диде.

Хәбибрахман тагы бер тапкыр тирән итеп сулады һәм редакциягә язган хатын ашыкмыйча гына кесәсеннән чыгарды.

— Хәбәр дип әйтмәс идем мин. Менә нәрсә ул!

Сотрудник язуны алды да, өстән-өстән генә карап чыккач:

— Ярар, калдырыгыз,— диде,— танышкач, сезгә җавабын җиткерербез.

— Туктагыз, сабыр итегез,— диде Хәбибрахман,— мин әле ял итеп тә өлгермәдем ич.

— Ә утырыгыз, утырыгыз, бабай,— диде егет,— ашыкмагыз. Менә минем эш...

— Шулайдыр, сезнең эш күптер,— диде карт, егеткә үзенең кәгазьләренә кереп батарга ирек бирмичә.— Тик шулай да сез мине тыңлагыз әле. Мин гражданнар сугышында Беренче татар бригадасы белән берлектә Казаннан Бохарага кадәр булган араны сугышып узган кеше. Аннары килеп шул кадәресен дә әйтим: мин партия райкомы секретаре да булдым.

— Менә бик әйбәт булган. Безгә хатлар-хәбәрләр язарга да вакыт табасыз икән. Бик әйбәт. Без озак көттермәбез. Сезгә менә шушы атнада ук хәбәрен җиткерербез.

— Юк, алай булмый. Шушы атнаны көтә торган эш түгел бу. Сез менә хәзер үк укып чыгыгыз әле шушы язуны.

Сотрудник укый башлады. Карт аның йөзенә карап кичерешләрен аңларга тели иде. Менә ул калын иреннәрен җәһәтрәк селкетергә тотынды. Менә аның кечкенә генә күзләре беткәнче ачылдылар. Кашлары күтәрелде. Хәбибрахман, үз алдына кәефләнеп, таяк тоткасы өстендә яткан бармакларын сикертеп куйды. Бу вакытта Ләйлә исә теге абыйны күзәтеп туйган, хәзер бабасының тезенә корсагы белән ятып тирбәлә иде.

Ниһаять, сотрудник хатны укып чыкты да бер мәл картка карап торды.

— Карагыз әле,— диде ул, кырысланып,— сез боларның барысын да уйлап яздыгызмы?

— Минем моңарчы уйламый берни дә эшләгәнем булмады.

— Менә монда язылганнарны документально исбат итәргә дә кирәк бит әле!

— Борчылмагыз, энем, минем документларым бар. Тарихны бозуларга юл куймаска кирәк.

Егет йомшый төште.

— Шулай, анысы дөрес. Тик, мин әйтәм, капылт кына, нигезләминитми тотынып үзегезгә уңайсыз булмасын.

— Мәсьәләне кабыргасы белән куйыйк. Мәкалә шушы рәвештә барамы?

— Анысында эш тормый, абый. Бәлки бераз каләм төртеп төзәтергә дә туры килер. Монда бит принципта хәл итәсе әйберләр бар. Сез моңарчы бик абруйлы, безнең газетка да күп язышкан бер кешегә каршы киләсез. Әгәр сез язганнар дөрескә чыкса, ул кеше, әйтик, үзе дә уңайсыз хәлгә кала бит.

— Аның ялганы тотылырга тиеш. Бу эш бик кирәк. Башкаларга сабак булсын. Сүз тарих дигән әйбергә кагыла икән, бераү дә берни үзгәртмичә, дөреслекне бозмыйча эш итсен. Бу принципиально! Сез ничек уйлыйсыз?

— Соң анысы шулай инде,— диде егет, җилкәләрен җыерып.

— Туктагыз әле,— диде кинәт Хәбибрахман,— әллә сез мине бо-

лай язгач, бары үземнең хәтер калудан гына шулай эшли дип уйлыйсызмы? Әгәр дә бу эш хосуси бер мәсьәлә булса, мин, дөресен әйтим, тәгаен, кул селтәгән дә булыр идем. Тарихта бернинди ялган булырга тиеш түгел! Менә шул! Мәрхүм дусларымның рухы өнди мине бу эшкә!

Ул кәкре бармагын өскә күтәреп, кемгәдер янагандай итте.

Егет уйланып карап утырды. Аннары:

— Шулай,— диде,— мин сезнең фикерләрегезгә кушылам, Хәбибрахман ага. Сүз сезнең ни дәрәҗәдә исбатлый алуыгыз турында гына бара.

— Соң бит анда мин көндәлек дәфтәремә ишарәлим. Күрмәдегезмени?

— Көндәлек? Нинди нәрсә ул?— диде егет.

— Ничек «нинди нәрсә»?! — диде Хәбибрахман, ачу аралаш аптырап.

— Шулай. Башта сез аны миңа күрсәтегез әле. Карыйк.

— Мин аны алып килмәдем. Ләкин, кирәге чыгу белән, редакциягә китерә алам.

— Китерергә кирәк иде.

— Менә мин сезгә аның нинди дәфтәр икәнен сөйләп бирәм. Ул үзе калын, клеенка тышлы, шакмаклы кәгазьле дәфтәр. Мин аны 1919 нчы елны Самарада сатып алдым. Талчоктан. Менә шул.

— Ярый, монысы көндәлек булсын ди. Сезнең хатка тагын кире кайтыйк әле. Бит болай. Сез бу хатыгызда иптәш Бакировны ялганчылыкта, фальсификаторлыкта гаеплисез. Димәк, исбат иткәндә дә конкрет материаллар белән эш итәргә кирәк. Әллә, бәлкем, ул көндәлегегезне сез кичә генә язгансыздыр.

— Туктагыз әле,— диде Хәбибрахман.— Сез бит теге Бакировның мәкаләләренә бернинди дәлилсез дә ышангансыз. Ни өчен миңа дә ышанмаска?

Егет аптырап калды. Ләкин каушамады, шундук җавабын да бирде:

— Без бит аны күптән беләбез.

— Менә ул башта үзенең хаклылыгын исбат итсен әле. Мин шул вакыт көндәлегем белән аның авызын шап итеп каплармын.

— Юк, ачуланмагыз, бер басылган әйберне без алай дәлилсез-нисез генә юкка чыгара алмыйбыз.

Ул кинәт урыныннан калыкты да Хәбибрахманга язуларын сузды.

## XXXIII

Альфред партия оешмасы секретаре Асия Фәхриевнаның конференциядән кайтуын дүрт күз белән көтте. Директорның үзенә булган мөнәсәбәте турында мәсьәләне ачыктан-ачык партия телендә сөйләшеп хәл итәргә вакыт җиткән иде. Чөнки ике җитәкче арасындагы мондый килбәтсез киеренкелекнең ахыры барыбер хәерле булып бетмәячәк, өлгерешкә, тәрбия эшенә һәм укытучылар коллективына авыр, белмәссең, бәлки әле төзәтелмәслек үк җәрәхәт-зыяннар китерүе мөмкин иде.

Альфред белән Луиза бик бирелеп дәрескә әзерләнеп утырганда, әле генә Шамил белән биләмнән кайтып кергән Җәзилә апа Асия Фәхриевнаның кичке җиде поезды белән авылга кайтуын хәбәр итте. Ир белән хатын ирексездән эшләрен бүлеп бер-берсенә карашып алдылар. Ниһаять, Альфред түзмәде:

— Бәлки миңа хәзер үк барып килергәдер?— диде.

— Ничектер уңайсыз бит, Альфред, кеше әле генә поездан төшкән, ганләсе бар...

— Шулай шул,— диде Альфред, килешеп. Ләкин ул күңеле белән Асия ханым янында иде инде. Никадәр үзен мәҗбүр итәргә теләмәсен,

ул, әледән-әле эшеннән аерылып, партия оешмасы секретаре белән әңгәмә башлый иде. Барысын да әйтергә кирәк, барысын да. Аның мине аңламавы мөмкин түгел. Мин белеп торам, минем бернинди гаебем юк. Мин барысын да намусым кушканча эшлим. Ә намусым минем, һичшиксез, саф, чөнки мин бары яхшылык кына телим, бары яхшылык эшлим.

Альфред шулай әледән-әле төп эшеннән аерылып байтак азап чиккәннән соң, аягүрә басты да, кулларын тирә-якка җибәреп, берничә тапкыр физкультура хәрәкәтләре ясап алды. Аннан Җәзилә апа итәгендә күгәрчен кебек гөрләп үзенчә нидер сөйләп утырган улы янына килде. Тик Шамил белән дә ни өчендер бу юлы әңгәмә куермады.

Альфред алгы якка чыкты, өстенә киенде. Мин бераз һавада йөреп керәм әле, диде хатынына.

Ул урамга чыкты, ләкин ял итеп йөрү аның башыннан шул секундта ук очып чыкты. Альфред ашкынып, эшлекле бер кыяфәттә Асия Фәхриевналар квартирасына таба юл тотты.

Башта ул артык тәвәккәл рәвештә, хәзер үк Асия ханым белән иркенләп сөйләшергә кирәк, башкача мөмкин түгел, дигән бер фикердә иде. Ләкин чүлмәк түбәле таныш өйгә якынлашкан саен аның дәрте сүнә барды. Ул, хатыны әйткән сүзләрне хәтерләп, чыннан да бүген яраксыз, яхшы түгел, иртәге көнгә калдырыйк дип уйлана башлады. Асия ханымның өе чатлыктан өченче булып тора иде. Альфред тыкрыкка житте дә кире борылды, шул вакыт кинәт Асия Фәхриевналарның кечкенә капкалары ачылып китте. Аннан ниндидер хатын-кыз күренде. Альфред ачыграк күрү өчен күзлек пыялаларын сөртә башлады. Тик ул танып алганчы аның үзен таныды теге хатын. Асия ханым иде ул.

Хәл-әхвәлләр сорашылганнан соң Асия Фәхриевна көлә төшеп сорау бирде:

— Сез, гадәттә, Альфред Яхич, үзегезнең урамнан йөри идегез, безнең урамга адашып килеп чыкмагансыздыр бит?

— Адашмадым,— диде Альфред,— минем бары сезне күреп бик сөйләшәсем килгән иде.

Хатын сагая төште.

— Әйе? Бер-бер көтелмәгән ашыгыч эш килеп чыктымы әллә мәктәптә?

— Әйе шул. Сезнең капкагыз турысына җиткәч икеләнә калдым. Мин әйтәм, картын, балаларын сагынып кайткандыр, әҗе-гөҗе килеп рәхәтләнеп чәй эчеп утыралардыр...

Асия көлеп җибәрде.

— Булмаганны! Исхак та өйдә юк әле. Совхозга нәселле бозаулар алырга киткән дә әле һаман кайтмаган. Үзем өйгә аяк басу белән керләр уарга тотындым. Әле балаларны йоклаткач, ичмаса бер һава алыйм дип чыгуым иде.

— Эш бик җитди,— диде Альфред, сүзне бөтенләй башка юнәлешкә җибәреп,— минем сезнең белән бер мәсьәлә турында сөйләшәсем килгән иде. Сез аны якынча төшенәсездер дип уйлыйм.

— Сезнең Халит абый белән мөнәсәбәтегез турындамы?— диде Асия, елмая төшеп.

— Әйе. Мөнәсәбәт сез киткәч тагы да катлаулана төште.

— Әйдә соң сөйләшик. Дөресен генә әйткәндә, минем үземнең дә сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшәсем килеп йөри иде, тик менә Казанга китүем генә эшне сузды. Әйдәгез, өйгә кереп сөйләшик.

Алар, күрәсең, балаларга дәрес әзерләп утырырга тыныч булсын диптер инде, вак-вак бүлмәләргә бүленгән җылы өй эченә керделәр.

— Утырыгыз, Альфред Яхич,— диде Асия, чишенеп эчкә узгач.

Алар тын аулак бүлмәдә өстәл аша бер-берсенә кара-каршы утырган хәлдә башта бераз вакыт өннәрен җыю өчен тынып калдылар. Ан-

нары Альфред эчендәге барлык борчуларын Асиягә сөйләргә кереште. Альфредны аңлаган хәлдә дә Асия ханымга директор белән бәхәскә керү өчен зур батырлык кирәк иде. Моны завуч төшенә. Шуңа күрә ул аның ярдәм итүен түгел, ә бары объектив фикер тудыру өчен бәхәсне партия җыелышына куюны үтенергә булды. Ләкин Альфред үзенең дәлилләрен бер-бер артлы ачкан саен парторгның йөзенә ниндидер якты, әйбәт тәвәккәллек чалымнары чыга торды.

— Минемчә, Альфред Яхич, җыелышка куеп торуның һич хаҗәте юк,— диде Асия.— Чөнки мәсьәлә көн кебек ачык. Без сезнең кем икәнлегегезне һәм нәрсә эшләвегезне беләбез. Монда бәлки башка чара кирәктер...

Альфред сорау белән Асиягә текәлде.

— Монда, минемчә, безгә райком белән сөйләшергә кирәк,— диде Асия ханым.— Райком секретареның аңлатуы Халит абыйга ныграк тәэсир итәр. Аннан соң, ни әйтсән дә, директорның коллектив каршында абруен саклап калуны да мин кирәкле дип саныйм. Халит абыйга райкомда болай ярамаганлыгын аңлатсалар, ул сезгә булган карашын үзгәртми калмас. Мәнә Асия Фәхриевна әйткән иде диярсез!

— Ярый алайса, мин риза,— диде Альфред, урыныннан торып.

## XXXIV

Альфредның уйлары әле бер, әле икенче вакыйга тирәсендә чуалдылар. Ул кайберәүләрнең күп очракта бер-берсе белән нигезсез бәхәс алып баруларын, ахмак рәвештә дошманлашуларын һәм моны принципиаль каршылык дип, хәтта горурланып ук йөрүләрен белә иде. Ә тирәнтенрәк карасаң, объективрак булсаң, барысы да ачык, дип уйлый иде. Мондый хәлләрнең нигезендә бары эгоистик шәхси интерес кына ята. Гаҗәп, бик гаҗәп хәл иде бу!

Альфред Латиф Ибраһимов белән соңгы тапкыр үзенең сөйләшүен хәтерләде. Ул көнне алар ачык аланда шоссе юлында һич көтмәгәндә очраштылар. Альфред район үзәгенә бару өчен юлаучы машина булмасмы дип, олы юлга чыккан иде. Латиф бер авылдан кайтып килә икән. Альфред машинага утырды. Ул беренче караудa ук Латифның артык төкселеген, борчулы икәнен тойды. Күрәсең, управляющий урынбасарының кемгәдер хәтере калган иде.

Латиф ачыктан-ачык:

— Мәнә нәрсә,— дип сүз башлады,— мин теге көнне карт белән сөйләшкәндә борчылып утырдым. Сез бабайга минем серләрне әйтмәдегезме?

— Юк, әйтмәдем. Ләкин сезнең борчылып йөрүегезне, яшерен газаплануыгызны шулай да аңламыйм.

— Ә сез минем урында булсагыз нишләр идегез?

— Мин аңа бик җылы бер хат язар идем. Чөнки ул иң әлек сезнең әтиегез бит әле.

Латиф утырган урынында сискәнеп баш калкытты:

— Ә сез ни өчен шулай дип уйлыйсыз?

Альфред дәшмичә җилкәләрен генә җыерды. Тынлык булып торды. Ниһаять, Латиф басынкы бер тавыш белән:

— Ә ул, «сезнең әтиегез», халыклар икегә бүленеп көрәш алып барганда, чыннан да, теге якта булса, ничек соң?— дип сорады.

— Ә сез аны анык беләсезме?

— Һем... анык беләсезме...

— Юк, сез анык беләсезме?

— Анык белмим, ләкин...

— Анык белмисез икән, минемчә, һәрвакыт яхшыга юрарга кирәк. Мин шулай итәм.

— Ләкин сез яшьлегегез аркасында кайбер нәрсәләрне аңлап җиткермисез.

— Нәрсәләрне икән соң ул?

— Тормыш сабаклары сизгерлек дигән нәрсәнең кирәклеге турында әйтә. Моны без бер генә минутка да онытырга тиеш түгел.

— Ләкин ул сизгерлек дигән сыйфат шикләнү белән алыштырылса, бик начар инде.

— Ахыр чиктә алар икесе дә бер әйбер бит. Кеше шикләнмәсә, тикшерми.

Әле Альфред шундый сөйләшүне хәтерләде. Машинада барганда ул көнне сүз күп нәрсәләр турында булды. Кабат кайтып Латифның әтисе турында сөйләштеләр. Ләкин Альфредның тапкырлыгы җитмәдеме, җитәрлек дәлилле алмадымы, Ибраһимов элекке карашында калды. Соңыннан Альфред аңа үз хәлен аңлата башлады. Ул Латифтан бөтенләй ярдәм эстәмәде, бары әлеге адрес аркасында килеп чыккан мәгънәсезлек тарихын гына сөйләде.

— Карагыз әле,— диде кинәт Латиф,— менә күкрәгегезгә кулыгызны куеп, чын коммунистларча, саф күңел белән әйтегез әле. Теге көнне миңа килгән яшь ханым сезнең хатынагыз идеме ул?

— Әйе, ул минем законный хатыным,— диде Альфред, елмаеп.— Ләкин, дөресен әйтим, белгән булсам, мин аны сезгә җибәрмәгән булыр идем. Әле сездән кайткач та ул кичкә кадәр миннән сездә булуын яшереп йөрде. Мин аның өчен сездән гафу үтенергә тиеш. Чөнки килеп чыккан аңлашылмау ул уйлаганча ук куркыныч күренми. Мин аны үзем генә дә ерып чыга алам. Нигә алай дип сорадыгыз? Сезгә ул кем икәнлеген әйтмәдемени?

Латиф җавап кайтармады, бары авыр итеп көрсенеп кенә куйды. Монысы да гаҗәбрәк иде! Ничек инде, кеше үзенең кем икәнлеген әйткән, ә ул ышанмаган! Ә бәлки Луиза шикләнергә урын калдырырлык итеп сөйләшкәндер?..

Альфредның уйлары хәзер үзенең Хәбибрахман абзый белән әлеге Бакиров турындагы әңгәмәсенә күчте. Менә монысы инде бигрәк тә хәтәр! Альфред Хәбибрахманның бары чын дөреслекне сөйләвенә ышана иде. Ул аны беренче тапкыр күргәндә үк яратты. Була бит шундый мәхәббәтле бабайлар. Алар үзләренең гадилекләрен һәм әчкерсезлекләрен балкытып, матур итеп күрсәтә беләләр һәм яшьләр андыйларга яктылыкка омтылган күбәләк кебек ашкыналар. Менә Хәбибрахман абзый да Альфредка шундый кеше булып күренде. Ә бәхәс ничек булып бетә соң? Юк, бәхәс кенә түгел, бу — сукыр дошманлыкка әйләнгән ызгыш. Әйтеп бетергесез сәер, сәер, сәер!

...Альфред райком секретаре ишеге төбендә шундый уйлар белән булашып, үзен чакырганнарын көтте. Стена буендагы утыргычта — мәктәп партия оешмасы секретаре Асия Фәхриевна. Халит исә, урталыктагы зур өстәл янында Альфредка арты белән басып, чибәр генә секретарь кыз белән сөйләшеп тора.

Көрән дерматин белән тышланган биек ишек ачылып китте дә бүлмәдән бер төркем кеше чыкты. Әлеге чибәр секретарь кыз, звонок шалтыравына торып, кабинетка кереп чыкты һәм көтеп торучыларга: «Керегез»,— диде.

Иң алдан, иелә төшеп, Әхмәдиев, аның артыннан Асия Фәхриевна, иң арттан Альфред кабинетка керделәр.

Бүлмә иркен, якты һәм җылы иде. Секретарь — агара башлаган куе коңгырт чәчле, чандыр буйлы, урта яшьләрдәге кеше — алдындагы язудан баш күтәреп, керүчеләрне күздән кичерде дә яңадан укуын дәвам иттерде. Исәнләшүгә баш иеп җавап кайтарды, утырышырга ишарәләде.

Ниһаять, ул укыйсы кәгазьләрен укып чыкты булса кирәк, өстәл тирәсендә утыручыларга эшлекле бер кыяфәт белән текәлде.

— Ягез, иптәшләр! Сезнең нәрсә анда, нинди бәхәс килеп чыкты?

Әхмәдиев теләр-теләмәс кенә елмаеп куйды, Альфред исә стенадагы Ленин портретына карап утыра бирде.

— Ягез, сөйләгез, сездән башлыйк, партия оешмасы секретаре,— диде секретарь.— Кем сезнең анда Иминлек Комитетына ниндидер блокнотлар җибәреп,ниләрдер исбат итәргә тырыша?

Кинәт Халитның йөзе чытылып китте. Ул кулын чак кына өскә күтәрде дә:

— Рөхсәт итегез әле, Афанасий Петрович,— диде.— Эшне кыскача гына үзем аңлатыйм әле.

— Сез сөйләгез алайса, иптәш Әхмәдиев,— диде секретарь.

Әхмәдиев, беркемгә дә карамыйча, сүзгә керешге. Аның тавышы тоныкь, ләкин тигез иде.

— Мин сезгә баштан ук аңлатыйм,— дип сүз башлады Халит.— Иптәш Хәйретдинов, бездә завуч булып эшли башлаганнан соң, ниндидер кирәкмәс эшләр белән шөгыльләнергә тотынды. Мәсәлән, тел һәм әдәбият укытучысына нигәдер бик каныкты. Ахырда без ул укытучыны, завуч сүзләренә ышанып, эштән алырга мәҗбүр булдык. Әйтергә кирәк, мин әле ул чакны Альфред Яхичка ышандым.

— Шуннан? — диде секретарь.

— Шуннан болай булды,— диде Әхмәдиев,— көннәрдән бер көнне мин иптәш Хәйретдиновның Казанга барып, бер профессор белән дуслашып, Татар бригадасы тарихы турында гыйльми эшкә алынуын ишетәм. Игътибар итегез, гомумән халыкларның гражданнар сугышындагы фидакарьлеге турында түгел, ә бер бригада турында!

— Ә булса ни? Бу начармыни? Мин дә, рәхәтләнеп, бу атаклы бригаданың юлын тикшерер идем.— Секретарь елмаеп куйды.— Тик миңа вакыт кына юк.

Әхмәдиев тәмам аптыраашта иде, ул тирән итеп көрсенде дә:

— Инде соңгы фактка килик,— диде, күңелсезләнеп.— Әле моннан атна-ун көн элек миңа аның блокноты белән танышырга туры килде. Анда бик күп адреслар язылган. Кайдадыр төрле якта, чит республикаларда яшәүче кешеләрнеке... Аннан... — Халит тукталып калды. Кыюланып Альфредка карады һәм сүзен тагы дәвам иттерде.—...аннан чит капиталистик илдә яшәүче кешенеке дә...

Халит кабаланып күкрәк кесәләрен актара башлады. Бераздан кәгазь кисәге чыгарып, аны секретарьга сузды. Ләкин Афанасий Петрович язуны алмады.

— Миндә бар ул,— диде.— Әйтергә кирәк, Хәйретдиновның ул хат буенча аңлатмалары мине, иптәш Әхмәдиев, канәгатьләндерә. Ә сез тагын нәрсә әйтерсез?..

Әйе, нәкъ ике көн элек Альфред райком секретаре белән бу адрес турында сөйләшеп утырган иде инде.

Әхмәдиев, мондый хәлгә тәмам аптырап, бер мәл тотлыгып торды.

— Мин башкача булдыра алмадым,— диде ул, шактый каушаган бер кыяфәттә.— Минем намусым аны тиешле оешмалардан яшереп калырга рөхсәт итмәде.

— Мин берни дә әйтмим,— диде секретарь.— Мин шуларны тикшерү өчен бирегә чакырдым да сезне.

Ул кинәт Альфредка таба борылды да:

— Ягез, сезне тыңлап карыйк инде,— диде,— директорыгызга ни дип җавап кайтармакчы буласыз?

Альфред барлык көчен җигеп тыныч булырга тырышты. Әкрен генә урыныннан торды, сөйләргә керешге. Барысы да, барысы да, аныңча,

Әхмәдиевнең тырнак астыннан кер эзләргә теләвеннән килеп чыккан уйдырмалар иде.

Секретарьга эшнең торышы аңлашыла иде инде, күрәсең. Сүзнең артык озынга китүен кисәтергә теләгәндәй, ул беләгендәге сәгатенә карап куйды. Аның хәл ителергә тиешле җитдирәк мәсьәләләре бар иде әле, ахры.

— Мин сезне тыңлаганнан соң шундый нәтиҗәгә киләм,— диде ул,— бәхәсегез сезнең, егетләр, шулкадәр нигезсез, аның турында авыз күтәреп сөйләп торырлык та түгел. Мин аңламыйм сезне, иптәш Әхмәдиев, ничек итеп инде үзеңнең беренче ярдәмчеңне бернинди конкрет факт булмаган хәлдә гаепләргә мөмкин?! Сез бит аны үз халкын яратуда гаеплисез. Ә халыкны ярату — илеңне ярату дигән сүз түгелмени? Милли һәм милли-колониаль мәсьәлә турында Ильичның җыентыгын укыганыгыз бардыр бит?

— Бар,— дип куйды Халит.

— Шулай булгач! Альфред Яхичнын Татбригада тарихы белән кызыксынуы — яхшы тырышлык. Мин бая шаярып әйтмәдем. Мин үзем дә, вакытым булса, шундый эшләр белән шөгыльләнер идем. Молодец! Безнең урта мәктәп укытучылары күбрәк шулай фән белән кызыксынсыннар иде әле! Сез, ана ярдәм итәсе урында...— Ул тукталып калды. Халитка карап торды һәм тәнбиһ белән баш чайкап.— Ярамый болай,— диде. Ул Асия Фәхриевнага күз ташлады: — Мин сезгә дә әйтергә тиеш. Директорыгызны шундый чакны дөрес юлга бастырасы булган.

Ул тагы Халитка карап алды:

— Ә инде теге чит ил адресы турында без Альфред Яхич белән аңлаштык. Хат алышырга мөмкин. Менә шул!

Альфред бөтен җаны-тәне белән шатлык-тантана кичерә иде. Ул, һич тыела алмастан, елмая төшеп, Халитка күз атты. Тик гаҗәп хәл, директор, райком секретаре сүзен бетерү белән, урыныннан сикереп торды да:

— Гафу итегез, Афанасий Петрович,— диде,— минем сезгә әйтәсе тагын берничә сүзем бар иде.

— Я, әйтегез.

Халит Альфредка карап куйды. Аларның икесен генә калдырып, парторг белән завуч кабинеттан чыгып киттеләр.

## XXXV

Альфред белән Луиза, мәктәптәге эшләрен тәмамлап, өйләренә кайтып киләләр иде. Алар бик шат. Район партия комитетының Әхмәдиев әләкләренә ышанмавы, чебеннән фил ясарга теләмәве яшьләрнең үзләренә булган ышанычларын арттырды, күңелләрен күтәреп җибәрде.

Башта алар иркен урамның ат юлыннан бер-беренә сыенган хәлдә бардылар. Ярты юлны үткәч, ике яктан ике трактор килеп чыкты. Альфред белән Луизага өйләргә ышыкланып, тар сукмактан атларга кирәк булды. Ләкин өй араларындагы бушлыкларда кар күрәлмәгән, анда бары биек көртләр һәм тар сукмаклар гына иде. Альфред, Луизаны алдан җибәреп, инде үзе аның артыннан барырга тиеш. Алар бер-бер артлы кар таулары арасына менә-төшә бардылар.

— Люлю,— диде Альфред,— бәлки әле безгә көндезге поезд белән кунаклар да килеп төшкәндер.

— Аллам сакласын,— диде Луиза, башын бора төшеп. Альфред аның уенчак, елмайган матур йөзен күреп алды.— Ә сиең кая?..

— Һи, табылыр әле, исең киткән!

— Табылыр сиңа! Синең кебек акыллы башлар кыш кергәч тә, бер-ике сарык суйдырып, түшкәсен элеп куялар да рәхәтләнеп ашап яталар. Кешечә бер яши белмибез инде без, Альфред, э-эме? Авылда торган булабыз, шәһәрдәгечә яшибез. Акчаны сберкассада яткырып ни файда?

— Нәрсә мине тагы Дон-Кихот дип атамакчы буласыңмы?

— Юк, әйдә, без үткән-сүткәннәр турында сөйләшеп вакыт уздырмыйк. Карале, Альфред, чыннан да, берәр кеше-кара килсә, уңайсыз булуы бар бит.

— Әйдә, тумаган бала егылып төшмәгәе, дип хафаланмыйк әле, Люлю. Килсәләр, килә бирсеннәр. Син сыебыз юк дип борчыласың. Ә мин эшем калудан да курыкмыйм әле.

Алар өйгә якынлашкан саен үзләре дә сизмәстән кызурак атлый башладылар. Гаҗәп хәл, моның төп сәбәбе Альфредның «бала» дигән сүзне телгә алуы булды. Шул сүздән соң икесе дә Шамил турында уйлана башладылар. Бала газиз иде, яшьләрнең күңелләрен ләззәт, куаныч тойгысы белән бизәп, үзе янына чакыра, кызу-кызу атларга мәҗбүр итә иде.

Менә ул бәләкәй генә, тузып барган өй. Өченче ел инде Альфредлар хуҗасы Казанга күчеп киткән шушы ояда гомер сөрәләр. Җил капка, кар басып киткән ишек алды. Киез итеккә ябышкан карларны себереп, тар, караңгы өйалдына шатлыклы авазлар иялтеп өйгә керделәр. Берниңди кунак килмәгән иде. Шамилгә суык тидермәс өчен, икесе дә, чишенү белән мич авызы янына килеп, учак уты җылысына сыендылар. Ләкин малай, әти-әнисенең тавышын ишетүгә, шундук күзләрен шарландырып караватында очына башлады. Ахырда көтелгән рәхәтлек артык зарыктырды булса кирәк, Шамил үзенең кабырчык шалтыравыгын идәнгә атып бәрде дә акырып еларга тотынды.

Ә, менә күптән шулай кирәк икән! Әти-әнисе генә түгел, кайтучыларга алгы якта аш әзерләп йөргән Җәзилә апа да атылып олы якка чыкты.

— Абаудыр ла, абаудыр ла! Кемнең күгәрчене шулай разбой сала икән?!

Әтисе дә, әнисе дә: «Кил-кил, үземә кил!» — дип, икәүләшеп кулларын суздылар. Шамил башта әнисенә барды, ләкин аның кулында бераз юанганнан соң, күзлек пыялаларын ялтыратып каршысында торган әтисенә үрелә башлады.

— Ах, минем герой космонавтым, ах, минем Шамилем! — дип, Альфред баланы әнисеннән тартып алды да югары чөя башлады.

Луизаның мондый очракларда коты алына иде. Ул Альфредка әз генә дә ышанмый. Әйтерсең лә, нәникәч бары аның үзе өчен генә бик кадерле. Малай, тешсез авызын ерып, бәхетнең җиденче кат күгенә ирешә, ә әти кешенең улын тотарлык кына көче бар иде.

Ул Шамилне түшәмгә кадәр бер-ике тапкыр чөеп алды да, күкрәгенә кысып, яңагын баласының йомшак, җылы битенә тидерде. Луиза шунда гына тынычланып икенче бүлмәгә чыгып китте. Аның артыннан Альфред та баласының нәни кулларын ирennәре белән генә тешли-тешли алгы якка чыкты. Алар бераздан дүртәүләшеп өстәл тирәсенә утырыштылар. Малайны Җәзилә апага тоттырдылар, үзләре токмачлы кайнар ашны тәмләп ашарга керештеләр.

— Их, менә бу аш янында тозлы кәбестә дә булсын иде,— диде кинәт Альфред.

— Күңелең әче теләп куйдымыни? — диде Җәзилә апа, елмаеп.

Альфред аңа җавап бирергә өлгермәде, Луиза чәнечтереп әйтеп куйды:

— Мин сиңа көзен ничә тапкыр әйттем. Беләсең бит, мин дә синең кебек эшлим. Бергәләп тотынсак, әллә бәлкем кышлык кәбестәсен дә,

кыярын да тозлаган булыр идек. Беркөнне кердем Гайникамал апаларга. О-о, җаным! Аларда тозлы кәбестәнең әллә нинди хикмәтләләре бар.

— Безнең Әлфәритнең хуҗалык җәһәтеннән бер дә ыктыматы юк шул.

Альфред сәерсенеп башын борды.

— Ыктымат? Нәрсә дигән сүз ул ыктымат?

— Әллә тагы,— диде карчык, елмаеп,— мин сезнеңчә аңлата белмим. Ыктыматы юк диләр инде, синдәйләргә.

— Һем,— дип куйды Альфред, көрсенеп, аннан Луизага таба борылды: — Ә син миңа Гайникамал апа, Гайникамал апа дип сөйләнмә, Луиза! Әле генә кәбестә ашыйсым килә иде, хәзер аны күрәсем дә килми башлады.

— Юләр, соң бит анда витамин күп! Гайникамал ападамыни эш! Көн дә шул токмачлы ашны ашап кына тору да шәп түгел инде ул.

— Әйдә, бу темага сөйләшмик, Люлю, менә мин сиңа аш ашап бетергәч тә Хәбибрахман абзыйның көндәлеген укыйм. Син үзең дә кызыксындың бит. Шулаймы? Шулай диген, Люлю!

Луиза, йөзендә матур елмаюын балкытып, Альфредка карап куйды. Бу елмаюда ризалык та, бераз гына кызгану һәм үзенең өстенлегеп тою да чагыла иде.

— Рәхмәт, хатларының кайберсен миңа биреп тора бабай,— диде Альфред, Хәбибрахманны хәтерләп.— Барып кердем. Сузылып яткан. Йөзе ап-ак кар кебек. Мәкаләсен кире кайтарып биргәннәр. Карт шул. Картлыктан да бигрәк авыру. Йөрәге аның бернигә дә яраксыз. Гомумән аңа һич-һич дулкынланырга ярамый икән. Бер тапкыр инфаркт уздырган, икенчесе үлем китерәчәк дигәннәр. Узган юлы ышанмаган иде, бу юлы көндәлеген дә биреп торды. Мине көрәшергә өнди.

Луиза сискәнеп китте.

— Көрәшергә? Кем белән тагы? Ну, нигә инде андый эш?

— Ничек инде, нигә? — диде Альфред, тәлинкәсен читкә этеп.— Кеше миннән үтенә. Мин аңа теге чакны ук ярдәм күрсәтергә вәгъдә биргән идем. Тик ул минем атна азагында дигәнемне ялгыш аңлаган, өч көн үткәч, инде бу килмәде, ахры, дип, үзе редакциягә киткән. Шулай итеп язганымның файдасы булмады.

— Шул житкән инде. Син аңа сүз биргәнсең и эшләгәнсең.

— Ничек җиңел карыйсың син, Луиза... Каһарманнар узган юл! Шуларның гомере! Аннан эш моның белән генә дә бетми бит әле...

— Һа, синең һәрвакыт шул инде. Тотынырсың инде тегермәннәр белән сугышырга!

— Бер дә тегермәннәр түгел болар. Бу реаль чынбарлык. Җитәр!

— Әйтер идем инде!

— Берни дә әйтәсең юк. Нәрсә, синең тагы бәхәсләшәсең киләме?

Луиза дәшмәде. Ләкин аның әле генә ягымлы балкыган коңгыркара зур күзләре сүрәнләнде.

Альфред, калай юынгычта шалтыр-шылтыр юынып, авызын чайкады да хатыны янына килде. Аны кочаклап башын күкрәгенә кысты.

Луиза дәшмәде, бары башын иренең күкрәгенә катырак төртә төште.

— Әйдә, Люлю, син кашык-аяк юган арада, мин тегене укып чыгам,— диде Альфред.— Аннан икебез дә бераз телевизор карарбыз да дәресләребезгә тотынырбыз.

Ул кулына Хәбибрахманның көндәлек дәфтәрен алды.

— Кай турысында тукталган идем әле мин? — дип сорады Альфред.

— Теге, Нина янына барып, анда бер атлы казакны очрата да, аны кулга төшереп, полк штабына озаталар. Шунда булса кирәк.

— Әйе, әйе, шулай, искә төште,— диде Альфред,— менә алайса, шушы тирәдә инде.

Альфред, авыз эченнән генә бераз укыганнан соң бер урында яктырып:

— Менә шушы җиреннән башлыйм,— диде,— тыңла.

Ул укый башлады:

«1919 нчы ел, 27 нче май числосы. Иптәшләр йоклый, ә мин бакчадагы сандугачлар тавышына уянып киттем. Башта эти-әнине, аннан Мәчтүрәне искә төшердем, тик, ята торгач, башка тагы теге казак кызы Нина килеп керде. Менә ул дөнья нинди әйбер! Сөйгән егете ат менеп караңгы төндә кызын күрергә килгән. Ике яшь йәрәк гыйшык утында яна. Алар кочаклашканнар, авызны авызга куеп мәхәббәт серләрен уртаклашалар, вәгъдә бирешәләр. Ә без аларның бәхетләрен кисәбез, мәсхәрәле рәвештә егетне кызыннан аерып алып китәбез! Теге казак кызының бездән елый-елый үтенгәннәре, мин сезгә барлык яхшылыкларны эшләргә дә әзер, тик егетемне җибәрегез, дигәне минем күз алдымнан уза. Әйе, берчак мин аңа ышана да язган идем, булмаса атын, коралларын гына алыйк та әйдә китә бирсен, дигән идем. Тик Мостафин миңа бер генә акырды, мин аның сүзен үтәргә мәҗбүр булдым. Ә бит бик рәхимсез тоелды ул Мостафин миңа шул чакта! Тик дөрес эшләгән икән. Соңыннан барысы да аңлашылды, егет казак есаулының ординарецы икән, бик күп кирәкле мәгълүматлар алганнар үзеннән. Полк комиссары строй каршында безгә рәхмәт әйтте, әгәр бу кошны ычкындырган булсагыз, егетләр, бер батальон иртәгә үк кырылып бетәчәк иде, диде.

Мин шулай уйланып яттым. Ләкин ул казак кызын барыбер күрәсем килә. Бүген, ничек булса да буш вакыт табып, барып кайтырга кирәк. Бераздан гадәттәге көн башланды. Ашап-эчкәч, чиратлашып авыл башындагы окопларда сакта ятабыз. Кичкырын безне башка взвод алыштырды. Шунда мин взводныйдан күрше авылга барып кайтырга рәхсәт сорадым.

— Карале, Хәбибрахман,— диде бу,— мин бит, малай, синең ни өчен анда баруыңны беләм. Син теге кара кашлы казачкага гашыйк булгансың.

— Гашыйк булганым юк, бары кызганам гына.

— Ничек син дошманыңның сөяркәсен кызгана аласың?! — диде бу.

— Ул бит үзе миңа каршы корал тотып көрәшми, аннан ул да кеше бит,— дидем мин.— Аны бер күрсәм, шул җитә. Әгәр ул үзе сүз дәшмәсә, аның белән сөйләшмәскә дә риза,— дип өстәдем мин.

Комвзвод: «Кара аны!» — диде. Ләкин шулай да җибәрде. Менә мин авылда, Ниналар өе янында. Тәвәккәлләдем дә бер заман аларның ишекләрен ачтырып, эчкә кердем. Керсәм, ни күрәм! Өйдә беркем дә юк, бары почмакта Нина гына бөгелеп елап утыра. Аның чәчләре биленә кадәр тузгып төшкән, үзе эчке күлмәктән. Хода-вәндә! Су анасы димме, урман кызымы! Карадым да катып калдым. Башта ул мине күрмәде. Ахырда абайлап өлгерде булса кирәк, елаудан кызарып беткән күзләрен миңа текәде. Мин аның йөзеннән, күз карашыннан ниндидер сәер рәнҗү, ялвару кебек бер нәрсә күрдем. Әмма бу озакка бармады. Исәнләшергә өлгермәдем, Нинам яшендәй тиз хәрәкәтләр белән мич астыннан мылтык тартып чыгарды да миңа таба атып җибәрде. Бәхетем юк түгел икән әле, кыз артык каударлангандыр, күрәсең, ара якын гына булса да, миңа тидерә алмады, пуля сызгырып колак турысыннан узды. Мин исә Нинага ташланганымны, ничек итеп аннан мылтыкны тартып алганымны белмим, өнемә килгәндә ул идәндә ята, мин исә аңа үзенең мылтыгын төзәгән идем. Русчаны юньләп белмәү шәп түгел. Күп сүзләрен мин аның аңлый алмадым, тик шулай да кайберсе аңлашылды. Нина миңа: мин сезнең дошманыгыз түгел идем,

диде, мин сезгә яхшылык теләп яши идем, диде, ә хәзер мин сезнең кан дошманыгыз, чөнки сез минем сөйгәнемне тартып алдыгыз, диде.

Ул үзе үк дошман икәнлеген икърар итте, тик шулай да мин аңа тимәдем, мылтыгын алдым да, үзен каты сүгеп, кайтып киттем. Кем белә, әгәр башына тай типмәгән булса, уйланыр-уйланыр да тагы безнең хак эшкә кул куяр. Менә шулай үтте минем бүгенге көнем. Өйгә хат язарга утырдым».

«28 май, 1919 ел. Без бүген дошман белән бәрелешеп алдык. Безнең өскә бераз шрапнель сиптерделәр. Без дә җавапсыз калмадык. Разведкага дип килгән атлы казакларның көлләрен күккә очырдык».

«1919 нчы ел, 5 нче июнь. Бүген күрше хуторга Нина янына бардым. Бик арыган идем, шулай да рөхсәт бирелгәч бармый кала алмадым. Шулай, ишек алларына кердем. Ни күрим! Нина керләр элеп йөри. Ялан аяк, ялан баш, үзе керләр элә, үзе әкрен генә, моңаеп кына нидер җырлый. Башта арттан гына карап тордым, аннан янына барып тамак кырдым. Менә без бер-беребезгә карашкан килеш сүзсез басып торабыз. Аның күзләрендәге ачу йомшаргандай кебек. Мине ул гомерендә беренче тапкыр күргән кешедәй сәерсенеп күзәтте.

— Нигә син теге көнне мине кулга алып аттырмадың, татарин? — диде ул, ахыр чиктә. «Белмим,— дидем мин,— ничек итеп шундый матур нәрсәне юк иттерим...» Бу миңа тагы карап торды да елмаеп ук куйды. «Әйдә, өйгә керик, мин сине сөт белән сыйлыйм»,— ди. «Ә син сөткә агу салмассыңмы соң?» — дип сорадым. «Юк,— ди,— минем инде сине үтерергә кулым күтәрелми, чөнки син дә бит яшь, син дә бит матур, аның өстенә, мин синең арыслан кебек батыр, өстәвенә шәфкатьле кеше икәнлегенне дә белдем. Әйдә кер»,— диде. Мин аның артыннан кердем. Әнисе белән исәнләштем. Карчык, мине күргәч, чукынып-төртенеп алды.

Менә без гүзәл кыз белән кара-каршы шулай утырдык. Мин аның матурлыгына хәйран калып, йөзеннән күзләремне аера алмый утырдым. Ап-ак йөз, сызылып киткән кыйгач кашлар. Ул борынның, авызның килешле матурлыклары! Бирсә дә бирә бит бер иш адәм баласына матурлыкны!

«Аша, аша, егет,— ди бу,— анда сезгә сөт бирмиләрдер, аша»,— ди. Хода-вәндә! Сөтме соң инде минем күңелемдә хәзер. Мин песи баласы түгел лә ул кадәр. Вакытны сузу өчен, ватып-сындырып сүз башлыйм. Янәсе, синең ахириләрең юкмы тагы? Безнең егетләр бит бик шәп, аларга кызлар кирәк. Минем дус кызларым сезнекеләр белән танышмаслар дип уйлыйм, ди. Язгы ни тора, ди. Мин әйтәм, барыбер адәм баласы бит, менә үзең күрдең ич инде, без дә синең кебек, бер дә ким җиребез дә, артык җиребез дә юк, дим. Юк, ди, андый эшнең гомер буласы юк, ди. Ә менә без бит, егетләр, сезнең янга килүгә каршы түгел. Белмәссең, мәхәббәт тә куерып китүе бар, дим, эш бездән тормый, дим. «Сезгә нәрсә ул, ди, сез, мәхәббәт дигән булып, алдашасыз да юкка чыгасыз. Сез ир-атның хәле шәп, ди. Мәхәббәтнең бәясен бары хатын-кыз гына белә», ди бу.

Без байтак вакыт шулай гәпләшеп утырдык. Ләкин нә мин, нә ул теге кулга алынган егет турында сүз катмады. Ә бит мин аның язмышы турында ишеткән идем. Ул безнең бер иптәшне үгереп качмакчы булган, тик икенче сакчы аны атып еккан. Тәгаен, кыз аны белә иде. Миңа, һәрхәлдә, шулай тоелды. Ләкин мин аңа бер сүз дә әйтмәдем».

Альфред тагы дәфтәр битләрен берәм-берәм ачып караштыргаларга тотынды. Ниһаять, теге Нина турында язылганнарга тагы тап булып, янадан укый башлады.

«1919 нчы ел, 8 нче июнь. Мин җиңелчә яраландым. Казак пулясы сул як беләкне сыдырып узды. Лазаретка барышлый, кыек юлны туры санап, мин тагы Ниналар хуторы аша киттем. Миңа берни дә кирәкми.

Әнә теге көндәге кебек ишек алдына кереп, керләр элеп йөргәнен күрсәм, шул җиткән. Мин тагы аларның бусагасында. Ләкин мине каршыларга аның карт әбисе чыга. Аның йөзендә кара нәфрәт вә авызында кабахәт сүз. Әйдә, такылдый бир, өр, әйдә, өр, тик кызыңны гына бер күреп китим. Шуннан гына мине мәхрүм итмә! «Кая Нинка?» — дим. «Ул үләргә җыена»,— ди. «Алдыйсың, карчык, кызыл гаскәр белән шаярма, карап тормам»,— дим. «Әнә, ышанмасаң, теге якка чык, ди. Ул егетнең үтерелүен белгәч, серкә эчеп агуланды»,— ди. Ходa-вәндә! Мин атылып олы якка чыктым. Анда әбинең үзе ише бер кортка утыра. Караватта Нина. «Кит, күземә күренмә, ди, мин сине бөтенләй кеше дип тә санамыйм, син минем егетемне үтергәнсең»,— ди. «Ул качарга теләгән, аңлыйсыңмы? — дидем мин.— Әгәр качмаса, безнең якка чыкса, инде, һич булмаганда, синең өчен, синең мәхәббәтең өчен, безнең якка чыкса, без аңа берни дә эшләмәгән булыр идек, дим. Ул безнең бик матур дустыбызны суеп үтергән, ә егетнең өендә хатыны, ике баласы калган, андый кансыз дошманны ник без атмаска тиеш, сугыш бара, канлы, рәхимсез сугыш, кем-кемне җиңә, шул баш була»,— дим. «Менә мин шуның аркасында үләм, ди. Үлемнән курыкмыйча, рәхәтләнеп, шатланып үләм мин егетем өчен»,— ди. «Юк, дидем мин,— андый начар кеше өчен шундый гүзәл кыз үләргә тиеш түгел. Мин сиңа барыбер үләргә бирмим»,— дидем. Мин шунда ук лазаретка йөгердем, үземнең яра кайгысы баштан китте. Мин кызга ашыгыч ярдәм күрсәтүләрен үтендем. Рәхмәт шәфкать туташларына, алар, шунда ук ат җигеп, хуторга киттеләр, тиздән Нина больницага озатылды. Хуш, Нина, бәлки, син исән-сау калырсың. Бәлки, еллар узгач, үзеңнең матурлыгыңа сокланып хәйран калган, сине һәр даим күрергә ашкынып торган татар егетен хәтерләрсең».

Альфред дәфтәрне япты да тынып калды.

— Шуннан башка ул Нина турында көндәлектә берни дә язылмаган,— диде.

— Терелгән булса ярар иде,— дип куйды Луиза, уфтанып.

— Белмим шул,— диде Альфред.

— Ичмаса сорашыр идең. Узган юлы барганда нигә сорамадың?

— Оныткаңмын,— диде Альфред, гаепле сыман елмаеп.— Кеше авырып ята. Ничектер уңайсыз да.

Кинәт ишек ачылды да Асия Фәхриевна килеп керде. Бердәм икесе дә сикереп тордылар.

Альфред белән Луиза, якты чырай күрсәтеп, кунакны каршылау өчен алгы якка чыктылар.

— Мин бер генә минутка,— диде Асия,— өстемне дә салып тормыйм, гафу итегез.

Луиза, кулындагы баласын, көйсезләнмәсен өчен, җәһәт-җәһәт селки башлады.

— Абау, гомердә бер килеп, анда да шулай ут алырга кергәндәй кыланмыйлар инде, Асия апа.

— Юк, юк, рәхмәт, өйдә Исхак болай да борчыла торгандыр. Минем бит әле иртәдән бирле өемә кайтып кергәнем юк. Мин бары бер хәбәр әйтү өчен генә.

Альфред та, Луиза да сорау белән укытучы хатынга текәлделәр.

— Сез чыгып китүгә, Альфред Яхич, Казаннан шалтыраттылар.

— Кем?

— Университеттан. Профессор Даутов дигән кеше.

Альфредның күзләре нурланып китте.

— Ә нәрсә диде соң?

— Ул ниндидер вакансия мәсьәләсе хәл ителде, диде. Сезгә, кирәкле документлар белән, аннан характеристика белән, әйе, тагы үтенеч язып, Казанга килергә кушты.

Альфредның йөзенә шатлык билгеләре чыкты. Ләкин хатын-кызда бу хәл аптырау гына тудырды.

— Бу ни дигән сүз? — дип сорады Луиза Альфредтан.

— Хәзер әйтсәм дә була инде. Юкса...— диде Альфред. Ул туктадып уйланып торды. Күрәсең, әңгәмәне ниндирәк сүзләр белән башларга кирәклеген исенә төшерә иде.

— Луиза! — диде ул, яктырып.— Профессор үзе шулай дип әйткән икән, димәк, мин эш урынымны озакламый алыштырырга тиеш булам.

Луиза аптырап китте. Асия да хәйран калды.

— Ничек? Сез, Альфред Яхич, безнең мәктәпне, коллективны ташлап китәргә җыенасызмы?

— Нихәл итәсең,— диде Альфред,— тарих — минем призванием. Мин хәзер аңсыз яши алмыйм. Мин университетта ассистент булып эшләячәкмен. Әлбәттә, минем өчен барыннан да мөһимрәге — тикшеренү. Мин бөтен вакытымны тарихыбызны өйрәнүгә бирәчәкмен...

Ул кинәт тынып калды. Артык һавалы бер тоннан башлады ул һәм, моңа үзе дә унайсызлана төшеп, ачуланмый микән дигәндәй, Луизага карады.

Луиза исә ачулы гына түгел иде, аның мондый көтелмәгән хәлдән башта зиһене чуалды, соңыннан күңелендә дөрләп нәфрәт уты кабынды. Ул бит моңарчы һаман иркен, әйбәт тормышта, ләкин авылда яшәргә теләде. Ул шулай да Асия алдында тойгыларын сиздермәде, бары еш-еш сулап, иреннән чәйни төшеп, баласы белән тавышсыз-тынсыз гына булашты. Аның кул буыннары кинәт йомшарып киткәндәй булды, ул, төшереп җибәрүдән куркып, Шамилен каты итеп күкрәгенә кысты.

— Юк, сезне үзебездән җибәрмибез без, Альфред Яхич,— диде Асия, катгый тон белән.— Бу эш бөтенләй мөмкин дә түгел, уку елы башлангач...

— Мин бит әле бүген китәм дип әйтмим,— диде Альфред,— китсәм,— икенче чирек беткәч. Сез мәктәптән минем китүемне бөтенләй тоймассыз да, Асия Фәхриевна.

— Тик бит сезгә документларны хәзердән үк бирергә кушты ул.

— Анысы икенче мәсьәлә.

— Ул характеристика да сорады...

Альфредның йөзе кинәт житдиләнеп китте. Асия Фәхриевнаның күз карашы артык мәгънәле иде шул. Альфред әле үзенә кинә саклап яшәгән директордан унай характеристика алуына, әлбәттә, ышана алмый иде.

Асия Фәхриевна чыгып киткәч, Альфред та, Луиза да тур якка чыктылар. Хатын, баласын күкрәгенә кыскан килеш, бераз вакыт иренә карап торды. Аның агарынган йөзеннән, ачу аралаш ялтыраган күзләреннән нинди хәлдә булуы, хәзер исә бераз айнып, һич югында, сүз башларлык дәрәҗәгә җитеп, зиһенен җыярга тырышуы ачык иде.

Альфред, борчылуын әледән-әле җыерылган кашлары белән сиздереп, хатынының сүз башлавын көтте.

Менә ул өнен җыеп сүзгә кереште. Анын йөзендә әз генә дә Альфред белгән гүзәллек һәм дуслык юк иде.

— Син миннән яшереп кенә Казанга күчеп китмәкче булдыңмыни?— диде ул, сулышына буылып.— Әле заочно укып йөргәндә «кинәндергәннәрең» житмәгән, инде мине бөтенләй кайгыга батырмакчы буласыңмыни? Син бит минем авылда гына яшәргә хыялланганымны беләсең!

— Луиза, Люлю,— диде Альфред, ялварып. Ләкин хатын тукталмады.

— Шуны бел, Альфред Яхич, әгәр женләнеп йөрүләреңне туктатмасаң, мин Шамилемне күтәрәм дә бу өйдән чыгып китәм. Туйдым мин...

# XXXVI

Хәбибрахман абзый өч көннән бирле үзенең караватында хәрәкәтсез ята иде инде. Врачның дарулары, укол кадаулары аны барыбер аякка бастыра алмады. «Менә шушы икән ул үлем,— дип уйланды Хәбибрахман.— Ул һич көтмәгәндә килә дә икән, ай-ваеңа карамастан, синне җилтерәтеп алып та китә».

Юк, никадәр юмор катыштырып фәлсәфә кормасын ул, картның үләсе килми иде. Яшисен яшәде, ашыйсын ашагандыр, тик бит әле төгәлләнмәгән эшләр күп. Әлбәттә, дөреслек ул бер тантана итмичә калмас, Хәбибрахманнар турында кайчан да булса дөреслекне әйтерләр, аларны җылы сүз белән искә алырлар. Ләкин дөреслекнең тантанасына ышанып, кул кушырып утырудан үзеңнең шул тантана өчен даулашып яшәвең әйбәтрәк түгелмени?! Ахыр чиктә, шул бит инде ул бәхет дигән нәрсә! Шулай икән. Картая барган саен кешене рәхәтлекләр берәм-берәм ташлап китә икән. Ләкин хезмәт һәм дөреслек өчен көрәш ләззәте — кешенең иң ышанычлы юлдашы, алар кешене мавыктырып, юатып яшәтә. Яшьлектә менә шуны аңламый икән кеше, ул кулында шул ике нәрсә калачагын, әгәр инде аларны да югалтса, гомумән япа-ялгыз каласын уйламый икән. Юк, юк, әгәр әнә шул ышаныч — терәк булмаса, кешегә беркем дә ярдәм итә алмый. Әйдә, бик әйбәт кешеләр арасында булсын ди ул, ул чагында да кеше үзен үги баладай ят итеп сизәчәк. Менә нәрсә икән ул яшәү серләренең берсе!

Хәбибрахман, чалкан яткан килеш, күзләрен ярым йомып уйлануында булды. Аның йөзе ябык, эчкә баткан яңакларын ак төк баскан иде. Ләкин игътибар белән карап торсаң, картның әледән-әле тамак төере хәрәкәтләнеп алуын һәм агара башлаган керфекләренең сирпелүен абайларга мөмкин. Ә инде кешенең эчке халәтен тикшерә торган нинди дә прибор булса, бу хәлсез картның кайнар йөрәге, бик якты, бик матур уйлары барлыгын да күрер идек. Әнә ул, үлем турындагы шомлануларын җиңеп, яшәү, тормыш турында уйланырга тотынды. Бераздан ул янында торган үз сүзле, иркә, ләкин бик кадерле бәләкәй кызчыгы, балдан татлысы, Ләйләсен шәйләде. Нәни кызны әле бүгенгәчә дәү әтисе янына кертми тоттылар. Ниһаять, алар бүген менә кавышу бәхетенә ирешкәннәр иде. Ләйлә, авыруның янына ук килеп, хәйран калып, кызганып, яратып һәм шунда ук шүрли төшеп, бер мәл сүзсез басып торды. Хәбибрахман аны сулышыннан тойды һәм елмаеп аңа таба борылды.

— Синең басың авырта, име, бабакаем? — дип сорады Ләйлә.

— Башым авыртып тора шул, кызым.

Ләйлә бабасының әле сөйләшә алуына, әле нәкъ шул Ләйлә белгән бабасы булып калуына шатланып китте. Аның өчен хәзер картның битендәге ап-ак төкләре бик сәер булып күренә иде. Ул, һич тыела алмыйча, кызыксынып, шул төкләргә нәни бармагын да тидереп карады.

— Нәрсә, нәнием, үскәнме? — дип сорады Хәбибрахман.

Ләйлә, кашларын күтәргән хәлдә, ияк кагып кына куйды.

— Син, кызым, кайчан бакчага йөри башлыйсың соң инде?

— Әнием әйтә, иртәгә, ди. Тик син авыргач минем анда барасым килми. Үләрсең дип куркам.

Хәбибрахман күзләрен йомган килеш хәлсез рәвештә елмаеп куйды.

— Үлмим, кызым, үлмим мин! Әле безнең бит синең белән циркка барасы бар.

— Сулай сул,— диде Ләйлә. Ләкин нәкъ шул вакыт ишектән Хәбибрахманның кызы Кадрия күренде.

— Әйдәле,— диде ул, Ләйләне кулыннан әләктереп,— бабакайны борчымыйлар алай.

Ул баланы, теләмәвенә һәм еламсырый башлавына карамастан, рәхимсез рәвештә, җилтерәтеп, бүлмәдән алып чыгып китте.

— Кирәкмәс иде, Кадрия, ул бит миңа бернинди дә комачау ясамый,— диде Хәбибрахман. Ләкин аның зәгыйфь тавышын Кадрия ишетмәде, ишек чыелдап ябылды. Җавап урынына Ләйләнең кычкырып елавы гына ишетелде.

Менә бит ул нәрсә! Без кайчак, яхшылык эшлибез дип, начарлык ясап куябыз. Бала минем өчен әле комачау түгел, юаныч иде, ә хәзер аның елавы йөрәкне авырттыра башлады. Хәбибрахман кулын сузып, утыргыч өстен капшарга керешә. Валидол алды.

Тиз генә тынычланмады ул. Аны әкренләп юаткан нәрсә бары үзенең яшьлек чоры һәм менә шул яшьлегендә иң көчле хатирә булып калган гражданнар сугышы көннәре булды. Әйе, алар бит кабатланмас эш башкардылар. Алар, чиксез дәрт һәм ышаныч белән утлар-сулар кичеп, совет власте дошманнарын тар-мар иттеләр, Урта Азия халыкларына Ленин сәламен алып бардылар...

Хәбибрахман бик күп вакыйгалар тезмәсен берәм-берәм күз алдына китерә башлады. Ниләр генә булмады анда! Тукта, тукта, Фәрганә үзәнлегендәге бер кызык вакыйга искә төште. Шулай, шулай, гүзәл Фәрганә үзәнлегендә басмачылар белән сугышып йөргәндә, егерменче елны булды бу эш. Хәбибрахман ул чак атлылар эскадронында иде. Таң атар-атмас шулай тревога белән дивизионны уяттылар да, күрше кышлакларның берсенә Халхоҗа басмачылары һөҗүм итә, ярдәмгә ашыгыгыз, диделәр. Хәбибрахман егерме егетне ияртеп шундук чыгып китте. Чыннан да, алар барып җиткәндә басмачылар тәмам котырынып кышлакны талап, өйләрне яндырып, мал-туарны куып алып китә башлаганнар иде. Кызыл гаскәрнең көтмәгәндә килеп чыгуын күргәч, басмачылар качарга тотындылар. Нәкъ шул вакыт, кышлакка килеп кергәч, бер карт үзбәк Хәбибрахман атының тезгененә килеп асылынды. Бу нинди дошман иярчене дип, Хәбибрахман кылыч сабына тотынды. Ләкин картның күзләрендә яшь, тавышында кызганыч ялвару тоеп, аптырап калды.

— Мәрхәмәтле кеше,— диде үзбәк,— инде ярдәм кулыгызны сузгансыз икән, тагы бер яхшылык эшләгез. Әле генә бер явыз басмачы карап торган бердәнбер кызымны алып качты. Коткарыгыз шуны.

Хәбибрахман аларның кайсы юл белән китү мөмкинлеген сорашты, картка читкә тайпылырга ымлады һәм тезгенне кага төшеп, тулпарын торган урыныннан ук чаптырып алып китте. Көн инде яктырган, шактый ерак араны да Хәбибрахманның яшь күзләре җентекләп күрә ала иде. Иптәшләр арта калды. Берсенең дә аты Хәбибрахманныкыдай йөгерек түгел иде. Бераздан бик еракта бер атлы кеше күренде. Ул ияр алдына нидер салган. Тәгаен, шул басмачы алып киткән теге әкәнең кызыдыр! Хәбибрахман шпорларын атының тәненә батыра төште. Хәзер колакларда җил сызгырганы һәм ат тояклары тупырдаганы гына ишетелә иде. Ара күзгә күренеп кимеде. Хәбибрахман, иңеннән драгун мылтыгын алып, басмачы ягына атып җибәрде. Күрәсең, пуля шактый якыннан узды — басмачы йомылып ук китте. Артына астыртын гына борылып карады һәм үзе дә атты.

— Яле, тулпаркаем, Кызыл Армиягә хезмәт итеп күрсәт әле,— диде Хәбибрахман. Ат монача, гомер буена дигәндәй, басмачылар шайкасының атаманын өстендә йөрткән иде. Әле аның беренче тапкыр гына Хәбибрахманга буйсынуы. Күрәсең, аңлады ул. Барлык җитезлегенә чаба башлады. Юк, ул чапмый, ул оча. Мондый атны Хәбибрахманның күргәне юк иде. Бу ахалтекин токымындагы төркмән аты табигать иҗат иткән гаҗәп бер затлы җан иясе иде.

Күп тә узмады, ара бөтенләй якынлашты. Хәбибрахманның тагы бер атып җибәрүе булды, басмачы ияр өстендәге кызны юл читенә ташлап та калдырды. Хәбибрахман тагы бер атты, аттан ук бәреп төшерерлек булмаса да, тәгаен, яралады ул теге йөзе кара басмачыны. Мәгәр артык куа барырга аның мөмкинлеге юк иде. Аның кызны күрәсе килде. Исәнме ул, юкмы, бәлки, аңа ашыгыч ярдәм кирәктер?

Ул, кыз турысына җитү белән атын туктатып, сикереп төште. Тузан эчендә аунап яткан кыз һушсыз иде. Хәбибрахман кара пәрәнҗәнең кыл каплавычын тиз генә ачып җибәрде. Ходаем! Гүзәл яшь кыз иде бу. Күп булса унбиш яшьләрдер бичарага. Кинәт Хәбибрахманның күңеленә шик килде: теге хаин үтереп үк ташламаганмы бу фәрештә валчыгын? Ул кызның шул ук минутта күлмәген ертып тәненә күз салды. Әйе, аның әле яңа гына тулыланып килә торган яшь күкрәкләре канлы иде. Мәлгунь басмачы кызга ханҗәр кадаган һәм шуннан соң гына аны җиргә ташлаган. Хәбибрахман нишләргә дә белмичә хәрәкәтсез торганда, кинәт кызның ыңгырашканын ишетте. Ул тетрәнеп уянгандай булды, кызның исән булуына балаларча куанды. Кызның ярасын тиз генә бәйләде дә атына алып шундук кышлакка таба чапты ул. Бала гына иде әле кыз. Аның йөзеннән сабыйлар садәлеге дә китмәгән иде. Кыз үлмәгәе дип, Хәбибрахман барлык көченә чапты. Бәхеткә каршы, басмачы пычакны кызның йөрәгенә туры китерә алмаган икән.

Сәгадәт тиз арада савыкты. Инде Хәбибрахманның әле исенә төшкәне тагы шул иде: савыгу белән кызның әти-әнисе аны Хәбибрахманга димли башладылар. Минем Мәчтүрәм бар дигәч, алар аңысына да аптырамады, зарар юк, икенче хатының булыр, диделәр. Әйе, әйе, тагы искә алырлык кызыгы шунда әле, ул бит узган ел гына шул Сәгадәтне Ташкентта очратты. Башта алар бер-берсен танымадылар. Ләкин шундый бер хәлгә тардылар ки, ничектер, сүздән сүз чыгып, бер-берен табыштылар. Һәм әллә кайда да түгел, гади троллейбус тукталышында. Булса да була бит! Сәгадәт хәзер авызыннан сөт исе китмәгән сабый бала түгел, ул инде җитди һәм үзбәк халкының күренекле бер кешесе икән. Хәбибрахманны ул кунакка чакырды, ләкин, үкенечкә каршы, нәкъ икенче көнне үк Хәбибрахманның кәеф китеп барды. Нишли икән хәзер ул хатын? Чыннан да, нигә аңа мөрәҗәгать итмәскә! Ул бит безнең бригаданың тарихы белән бик кызыксына торгандыр. Ничек диде әле ул? Халыкларыбызның күптәнге дуслыгын, туганлыгын онытырга ярамый. Безнең эшләр, безнең узган утлы юллар алар онытылыр өчен башкарылдылармыни?!

Хәбибрахманның уйлары шунда житкәч, ишек тагы ачылды. Авыру, Ләйләдер дип куанган иде, тик тавышсыз сак адымнар белән аңа таба килүче кеше Кадрия булып чыкты.

— Әти, нинди дер кеше сине сорый. Керергә рөхсәт итмәс микән, ди.

— Нинди кеше микән соң ул, кызым?

— Мин аның боевой соратнигы, дусты, мин аның өчен яхшылыктан башка берни дә теләмим,— ди.

— Соң, керсен,— диде Хәбибрахман, сәерсенеп.

## XXXVII

Хәбибрахман керәсе кешене кызыксынып көтте. Әнә ул нидер сөйләнә-сөйләнә өс киемнәрен сала әле. Ләкин аның тавышы артык тоныкишетелә, бары Кадриянең генә кайбер сүзләре колакка җитә. Менә бүлмә ишеге ачылды һәм Хәбибрахман янына әлеге кеше килеп тә керде. Ул — Бакиров Хәмзә булып чыкты. Хәбибрахманның сырхау йөзе кинәт чытылып китте. Ул, Хәмзәне тану белән, стенага таба борылды.

Юк, юк, аның бу кеше белән һич сөйләшәсе, көрәшәсе килми. Ул, Хәмзәгә карамаса да, аның һәр хәрәкәтен, бөтен барлыгын тоеп, сыкранып ятты. Кунак исә, йөзендәге елмаюын һич үзгәртмәстән, Хәбибрахманның баш очындагы утыргычка барып урнашты.

— Нихәл, кордаш?

Бу сорауның тонын Хәбибрахман сау кешенең авырудан өстенлеген сиздерергә тырышуы итеп кабул итте. Җавап кайтармады, бары йотлыгып, очлы, зур тамак төерен генә хәрәкәтләндерде.

— Хәлеңне белергә килдем,— диде Хәмзә.— Ни генә әйтмә, без бит синең белән үзебезнең яшьлектә бер лаеш суларын эчкән кешеләр.

Хәбибрахман: «Кит, чыгып кит, зинһар»,— дияргә теләде, ләкин шунда ук, әгәр шулай әйтсәм, теге дә җавапсыз калмас дип уйлады. Хәмзәнең сүзләре йөрәгенә хәнҗәрдәй кадалачагын исәпләп алды ул. Әйдә, өрер-өрер дә чыгып китәр әле,— шуның өчен үлем белән шаярып хәлем юк.

Ә ул кеше исә, һаман тыныч кала биреп, сүзен дәвам иттерде.

— Минемчә, сина спецклиникага кереп ятарга кирәк,— диде ул,— теләсәң, мин бу эшне оештырам. Анда әйбәт карыйлар, анда сине иң яңа дарулар белән дарулаячаклар, Хәбибрахман дус.

Авыру артык түзмәде, «кирәкми», дигәнне аңлатып, башын селкеп куйды. Бераз тын гына утырганнан соң, Хәмзә: «Ихтыяр үзеңдә»,— диде.

Хәмзәнең әрсезлеген, талымсызлыгын Хәбибрахман бөтен тән күзәнәкләре белән тоеп ятты. Юк, юк, ул һич авыруның хәлен белер өчен кермәгән, моның төбендә нindидер мәкерле эш ята. Хәбибрахман аның хәзер үк чыгып китүен, үзен тынычлыкта калдыруын тели иде.

Ул, ахыр чиктә кулын изәп, «кит, чыгып кит» дигән сүзләрне аңлата башлады. Хәмзә исә боларның барысын да күрә, ләкин һич кымшанмыйча урынында утыра бирә иде. Ниһаять, ул ниндидер бер сер сөйләгәндәй ярым шыпырт тавыш белән:

— Син, Хәбибрахман туган, минем өстән язып редакциягә баргансың, икән,— диде.— Кузгалма, кузгалма, сиңа ярамый. Тыңла.

Ул бераз тынып торды. Хәбибрахман исә йөрәгенең һәм аркасының тагы да катырак авырта башлавын тойды.

— Менә нәрсә, кордаш,— диде Хәмзә,— без инде синең белән ачыктан-ачык сөйләшик. Без синең белән карт гвардия вәкилләре. Без синең белән, теге кем әйтмешли, нәзберек байбәтчәләр түгел. Менә шулай. Безнең өчен иң кадерлесе — принцип. Син минем теге чакны дусларча аңлатуыма колак салмадың. Ә бит мин үзем өчен генә беркайчан да андый хәтәр юлга аяк басмас идем. Син халык өчен эшләвемне хөрмәт итү йөзеннән генә булса да миңа аяк чалмаска тиеш идең...

Хәмзә, Хәбибрахманның гасабиланып боргалануын күргәч, бераз вакыт тынып торды. Аннары тагы аның сүзләре ишетелде.

— Тынычлан, кордаш, бу дөньяда кем яшәмәгән дә, кем бу якты дөньяны куймаган. Без дә синең белән мәңгегә килгән кешеләр түгел. Тик принциплар һәм халык кына мәңгелек. Без бөтен эш-гамәлебезне шуңа багышларга, шуның өчен фида итәргә тиеш. Моны бездән заман сорый.

Хәбибрахманның артык түзәрлеге калмады, ул, йөрәгенең каты авыртуына карамастан, барлык көчен җыеп, терсәкләренә таянган килеш башын калкытты.

— Син нәрсә, мине үтерергә килдеңме? — дип сорады ул, карынкы тавыш белән.

— Юк, мин аның өчен килмәдем, кордаш, мин сиңа бөек дөреслекне аңлатып бирү өчен килдем.

— Нәрсә соң ул синең «бөек дөреслегең», кеше хезмәтен үзләштерүме? Ялганны файдалы эшкә җигеп ахмаклануmы? Барып чыкмас!

Берни дә барып чыкмас. Ялган сине бервакытта да дәреслеккә алып чыга алмас. Минә минем әле кәеф юк. Терелим генә. Терелим генә. Мин сине фаш итәчәкмен. Күр дә тор!

— Ай-һай, белмим шул, синең сүзләреңә колак салучы булыр микән,— диде Хәмзә, көлемсерәп.

— Мин сине судка бирәм. Минем дәлилләрем бар.

— Барысы да юкка гына тырышу, юкка гына көчәнү. Киңәш итмим. Кирәкми, кордаш, тынычлыгыңны бозма, минем белән булашма. Минем абруем бар, мине беләләр. Сүзем дә үтә...

Хәбибрахман тагы хәлсезләнеп кире ятты. Аның аркасы таштай каткан һәм нәрсәгәдер бик каты бәрелгәндәй авырта иде. Ләкин шулай да ул хәзер әз генә дә үлемнән курыкмый иде. Аның күңелендә моңарчы һич булмаганча яшәүгә ашкыну һәм менә шушы Хәмзәне фаш итеп, төрле ялган юллар белән күтәрелгән дәрәҗәсеннән бәреп төшерү теләге йөри иде. Ул Хәмзәнең күзләренә, симез йөзенә текәлгән килеш хәрәкәтсез ятуында булды.

— Без, иң яхшысы, синең белән дус булып яшик. Инде аерылышырга язган икән, дуслар булып аерылышыйк. Менә шул,— диде Бакиров, сүзен дәвам иттереп.— Мин сиңа, дөресен генә әйткәндә, бер тәкъдим ясау өчен килдем, Хәбибрахман дус. Ишетүемчә, син күптән инде безнең бригада турында материал җыясың. Вәхаләнки андый эш белән мин дә шөгыльләнә башладым. Тик күпләр теге дөньяга китеп өлгергән, шуңа күрә, бер үзем генә очлап чыга алмам кебек. Инде бу яктан караганда синең хәл яхшырак, материалга син миннән баерак. Тик бит, кордаш, минем дә уңай яклар юк түгел. Беренчедән, мин яза беләм, инде үзем булдыра алмыйм икән, менә дигән ярдәмчене любой вакыт таба алам, икенчедән, минем имза булган кулъязманы уздыру авыр түгел. Менә шулай, туган, без бер-беребезгә кирәк. Синдә житешмәгән як мин дә бар, миндә житешмәгәне — синдә.

— Инде шуннан ни әйтмәк буласың? — дип сорады Хәбибрахман.

Хәмзә күгелҗем-кызыл зур авызын ерып елмайды да:

— Аңлашыла булса кирәк,— диде,— син миңа материалларыңны бирәсең, ә мин, синең дә имзаны куеп, китап язам, басылып чыгуын тәэмин итәм.

— Ул китап нәрсә турында була инде?

— Ул китап безнең үткән данлыклы юлыбыз турында була. Идел буе аерым беренче татар укчы бригадасы турында була. Аның исемен мин якынча «Безнең шанлы юл» дип куярга уйлыйм.

— Беләсеңме нәрсә, Хәмзә,— диде Хәбибрахман,— син ялганчы гына түгел, син бик юләр дә икән!

Хәмзәнең йөзе каралып киткәндәй булды. Шешенке күз кабаклары тагы да салынып төште, ә күзләрендә нәфрәт чаткылары кабынды.

— Нидән чыгып әйтәсез мондый мыскыл сүзләрен? — дип сорады ул.

— Соң син үзең уйлап кара! Синдәй кешегә кем тарих язарга рөхсәт итсен!

— Сиңа ул рөхсәт итмәячәкләр! Ә минем турыда борчылма, мин үземнең бу эшкә хаклы икәнлегемне исбат итә алам.

— Бәлки син язарсың да, тик бит әле монда без дә бар. Тарихның тере шаһитләре. Аларны кая куясың?

— Борчылма.— Ул бераз вакыт тынып торды.— Димәк, синең бу сүзләреңне баш тарту дип аңларга кирәк?

— Кара инде, үзең чамала!

— Ә бит син бу эшең өчен үкенәчәксең!

— Юк, үкенмәм. Мин тере чакны син миннән материал ала алмассың, Хәмзә. Аннан, исеңдә тот, менә әз генә савыга төшим, мин сине фаш итәчәкмен! Күр дә тор!

— Булды, булды, анысын әйттең. Күрдек ич, бик алай өркетә алмадың!

— Ярар, бик әйбәт, мин хаста чакта бик батыр кылана аласың икән. Инде мине тынычлыкта калдыра күр. Адресыңны беләм...

Хәбибрахманның йөрәге тагы да катырак авырта башлады. Ләкин аның һич сер сынатасы килми иде. Ул тешләрен кысып түзде, тыныч ятарга тырышты.

— Үкенәчәксең,— диде Хәмзә, урыныннан торып. Хәбибрахман бер сүз дә дәшмәде, аның күзләрендә бары сәер ялтырау гына чагылып китте.

Хәмзә, ишеккә якынлашкач тагы тукталып, артына борылды.

— Бәлки, синең тарихка әйбәт, уңай кеше булып керәсең киләдер. Аны бел, бу яхшылык белән генә эшләнә ала. Әгәр начарлыкка китә икән...

— Тарих ул дәреслек дигән сүз, ахмак сүзләр сөйләмә, әйдә, юлыңда бул!

— Шунда да, кордаш, артын-алдын уйлап сөйләш. Сәламәтлегең ташка үлчим.

Хәбибрахман аңа бер сүз дә дәшмәде. Хәмзә, үзе дә аңламастан, тирән итеп көрсенде дә, «Бәхил бул» дип, ишекне этте.

— Ай-һай кеше! — дип калды Хәбибрахман.

Хәмзә чыгып киткәч, ул үз йөрәген тыңлап ятты. Йөрәк авырта иде, ара-тирә туктап куя иде, ләкин шулай да бирешмәде бит әле ул! Менә син, нигә башта шулкадәр шүрләгәндер ул! Хәбибрахман сәгатькә карап алды. Иртәрәк әле иртәсен, шулай да дару эчеп алганда зыян итмәс.

Бүлмәгә ашыгып, җилләнеп Кадрия килеп керде.

— Бигрәк озак утырды дустың,— диде ул, этисенең юрганын төзәткәләп.— Бик арымадыңмы?

— Юк, кызым.

— Нигә килгән соң? Бик кызып сөйләштегез, мөгаен, хәл белергә генә түгелдер.

— Ул турыда сөйләшмик,— диде Хәбибрахман,— икенче тапкыр килсә, кертмә син аны, Кадрия.

Кадрия куркынып этисенә карады.

— Борчылма, берни дә булмады,— диде Хәбибрахман, кызын тынычландырып.

# XXXVIII

Латиф хәзер үк кузгалырга торган җирле поездга утырды. Халык аз иде. Латиф тәрәзә янындагы җайлы бер урынга урнашып, креслоның аркасын аска төшерде. Хәзер аның өчен поездның кузгалып китүе генә кирәк иде. Әйдә, барысы да артта, Казанда, калсын әле, бәлки, үзенә җан тынычлыгы алып кайтыр.

Чыннан да, дизель поезд озак көттермәде, йомшак кына кузгалып китеп тә барды.

Поезд әкрен генә хәрәкәтләнеп берәм-берәм шәһәр йортларын артта калдыра башлагач, Латифка да күңелле булып китте. Күптән аны шулай итәсе калган. Бер җилләнеп кайтуның шифалы нәрсә икәнен ул бик яхшы белә бит!

Латиф кесәсеннән әле генә сатып алынган «Экономическая газета»-ны чыгарды да укый башлады. Бераздан арыды, тагы тәрәзәгә күз салды. Поезд хәзер куе нарат урманы эченнән бара иде. Биек-биек карт наратлар тыгыз койма хасил итеп юл кырыена тезелгәннәр. Латиф, әгәр мөмкин булса, хәзер үк төшәр иде дә чаңгыда шул урманны бер айкап

чыгар иде. Аннан ул поездга утырып тагы арырак китәр иде. Тагы төшәр иде, тагы урман юлларыннан чаңгы белән узар иде. Урман эченнән килеп чыккан бер төркем чаңгычы яшьләрне кызыгып һәм көнләшеп күзәтте ул. Алар барысы да поход өчен тегелгән махсус киемнәрдән, барысы да зифа, яшь һәм матур иде. Менә алар яннарыннан ашыгып узган поездга кул болгап торалар. Күрәсең, бик ерактан киләләрдер. Аркаларындагы рюкзаклары, өс-башлары бәс белән капланган. Әйтерең бармы! Нинди гүзәл ул яшьлек, әгәр тумас борын картайган кеше булмасаң!

Әйбәт иде Латифның кәеф хәзер. Ул бер мәл күнел сыкравын да тоймый барды, кышкы урман гүзәллеге белән мавыкты.

«Менә бит, бөтенләй беркая да тукталмыйча, бары поездда утырып йөреп кайтсаң да, үзенә бер хозурлык. Юләр инде мин! Күптән, күптән шулай итәргә кирәк булган икән».

Ул иртәгә ук үзенә дә чаңгы сатып алачак. Шуннан алар улы белән икәүләп шушы поездга утырып барырлар да якындагы станциядә төшеп калырлар һәм рәхәтләнеп чаңгы шуып йөрерләр. Ә бәлки, Гөлбикә дә барырга теләр. Чыннан да, нинди гаҗәп күңелле узачак ул көн. Вакыт юк сылтавы белән бик зур мөмкинлекләрдән файдаланмыйбыз бит. Ә дөреслектә барысы да иренчәклек һәм сафсатачылык аркасында!

Ул үзләренең өчәүләшеп чаңгыда баруларын күз алдына китерде. Көмештән коелып ясалгандай матур урман ешлыгы. Саф һава. Күнел көрлеге. Латиф үз-үзенә: «Чаңгы алмый калырга ярамый»,— дип куйды.

Урман поезд юлыннан читкәрәк китте. Хәзер ул алдагы уйсу урынны әйләндереп алган сөзәк таулар өстенә күчте. Латиф яхшы белә, бу урман шулай вакытлыча гына читкә китеп тора да бер заман тагы поезд юлына ук килеп теріләә. Ләкин урман ерактан да матур. Ул, тау башларына менеп китсә дә, һаман үзенә чакырып, кызыклы, серле маҗаралар вәгъдә итеп тора.

Латиф бераз карап барганнан соң, кулына тагы газета алды. Укый башлаган мәкаләсенә чумды. Яңадан бер күтәрелеп карагач, ул инде тәрәзәдән артык аерыла алмады. Искиткеч гүзәл урыннан бара иде поезд. Мондагы наратлар аерата мәһабәт, таралып, җәелеп, тармакланып үскәннәр. Алар, кәүсәләрен биек күкләргә ашырган төз каеннар белән аралашып, поезд юлы буенда тыгыз койма булып торалар.

Бәләкәй генә тимер юл будкасы яныннан уздылар. Шлагбаум, тимер юл аша кечү урыны, урман эченә туп-туры булып сузылган юл чагылып калды.

Латифның артык түзәрлек тәкате калмады, ул күршесендә утырган күзлекле олы кешедән:

— Әйтегез әле, якында берәр разъезд юкмы? — дип сорады.

— Менә хәзер санаторий платформасы,— диде әлеге кеше.

— Мин төшеп калыйм әле шунда,— диде Латиф, ни өчендер уңайсызланган хәлдә елмаеп,— гаҗәп матур урыннар!

Ул урыныннан торды.

— Беренче тапкыр килүмени бу якларга? — дип төпчендә теге кеше.

— Беренче тапкыр түгел дә, ничектер эш турында гына уйланып игътибар да итәлмәгән.

Латиф урталыктан тамбурга таба узды, һәм, чыннан да, ул тышкы ишек янына барып җитәр-җитмәс, поезд йөрешен дә әкренәйтә башлады.

Латиф төшкән платформа янында да кара куе урманлык иде. Башка төшүче пассажирлар күренми. Якында гына торган тимер юл эшчесенең өен, очлы кибәннәр күренгән ишек алдын Латиф читләтеп узды да уйчан гигант агачлар арасыннан сузылган олы юлга килеп чыкты. Менә кайда иде ул дөнья рәхәте! Зәңгәрсу ап-ачык күк гөмбәзе, тын-

лык һәм бәллүр яктылык. Әле узган төндә генә кар явып киткән, ахры. Кар ап-ак, йоп-йомшак. Ул юлны да каплаган, ылыс тәлгәшләрен дә сыгып аска таба игән. Латиф, иркен киң юл буйлап бара торгач, олы юлны кисеп узган таррак юлга килеп чыкты. Монда отыры аулак кебек иде. Ләкин сул якта, бер-ике йөз метрлар арырак, агачлар арасыннан һавага туп-туры булып төтен күтәрелгәне күренде. Димәк, санаторий шунда. Юк, кирәкми, анда бармыйм, диде Латиф. Ул ашыкмыйча гына, тирә-юнен сокланып күзәткән хәлдә, уң якка таба китте. Аяк астында кар җиңелчә генә шыгырдый иде. Тукта, бу нәрсә бу? Латифның колагына тонык кына булып ниндидер куыш әйбергә бәрелүдән туган авазлар ишетелде. Ул башта гаҗәпләнеп тыңлап торды, аннан көлеп җибәрде. Карасана, бу тукран бит, Латиф шундук, бар дөньясын онытып, тукран кунган агачны эзли китте. Ләкин ул шактый эчтә, тирән карлы җирдә иде. Читтән генә карап торырга калды. Шулай да күрде ул бу тырыш, хезмәт сөючән кошны. Елмаеп карап торды, тагы ашыкмыйча гына юл буйлап китте. Аның берни турында да уйлыйсы килми иде бу минутта. Җитмәсә, күзәтүчән кеше өчен урман үзе бер кызыклы, мавыктыргыч дөнья булып чыкты. Латиф шактый ерак китеп тагы да эчкәрәк кергәч, куян эзләренә тап булды. Яңа яуган карда озын колакның чуалып беткән эзләре ярылып ята иде. Латиф зур эшлеклелек белән шуны тикшерә башлады. Әнә ул юл уртасыннан чапкан-чапкан да элмәк ясап сулга тайпылган. Ә аннан соң тагы юлдан бара ул. Кара син аны, хәйләкәрне, ничәмә элмәк ясап эзен чуалткан!

Латифка ерактан гына булса да поши да күрергә туры килде. Ул башын горур рәвештә югары тотып, зур тояклы аякларын шактый биек күтәрә-күтәрә юртып, Латиф барган юлны аркылап узды. Бу урман патшасының хәрәкәтләрендә тынычлык һәм солтанатлылык кына күрде Латиф.

Ул хәзер үзен бөтенләй башка дөньяга эләккәндәй хис итә башлады. Бу куе урманда ул тагы бик күп, бик күп хикмәтләр очратты әле. Мондагы кошлар дөньясы тукраннар белән генә чикләнми иде. Латиф, әйтерсең лә, беренче тапкыр күргәндәй, кызыл түшләрнең чыр-чу килеп, песнәкләрнең һәм тагы әллә нинди кошларның фырылдашып өерләре белән очканын күзәтеп барды. Каядыр шунда агач башында саесканның кырык-кырык килеп тавышланганын сәерсенеп тыңлап торды. Кайчак кычкырып өскә ала каргалар күтәрелә иде.

Латиф, ниһаять, яшь наратларны басып киткән кар элпәләре белән кызыксынып йөри башлады. Бусы да бик кызык. Ылыс тәлгәшләренә утырып калган кар юрганы әллә нинди җанварларга охшый. Берсен аның нәкъ төлкегә охшатты Латиф. Әйе, әйе, ап-ак калын койрыклы төлке. Ә менә монысы аю. Ак аю. Латиф кардан ясалган нинди генә җанварлар күрмәде! Бер җирдә ул биш-алты метрга сузылган гигант еланга хәйран калып карап торды. Бу кар елан борылып-сырылып үзенең корбанына таба якынлашкан кебек иде.

Латиф тагы юлын дәвам иттерде. Рәхәт иде аңа. Ул, бөтен күкрәген тутырып, күңелгә дәрман-тереклек бирә торган салкын урман һавасы сулады. Һәм үзе дә тоймастан үз-үзеннән сорап куйды. «Эх, син, юләр, шул дөньяның кадерен белмәскә мөмкинме соң!» Латифның йөрәгеп кинәт нидер авырттырып тырнагандай булды. Ул барысын да берьюлы хәтеренә төшерде. Урман һавасы, мондагы ирек һәм ялгызлык аңа, күрәсең, бик аек уйларга, барын да тыныч кына бизмәнгә салырга мөмкинлекләр тудыра иде. Ул куркусыз-нисез барын да өр-яңадан тикшерә, бәяли башлады. Узган гомер эчендә хәтер киштәләрендә үзенә урын тапкан вакыйга-хәлләр барысы да хәрәкәткә килде. Авыр иде Латифка. Әйе, тагы авыр булып китте. Ләкин ул аның саен түземлелек белән үзенең җәмгыятьтәге яңа бер сыйфатына урын-бәя табарга тырышты. Шулай да сәер иде аның хәле. Талия атлы кызга язылган хатны күреп,

анын сөйгәне үз этисе түгеллеген анык аңлады бит ул. Димәк, этисе аның чит илдә. Димәк, Латиф кичә генә эле граждаинар сугышы каһарманы улы иде, ә бүген ул куркак, качак бер кешенең улы. Сәер, бик сәер. Ә соң Латифка нинди дә булса үзгәреш кертәчәкме бу? Латиф тагы авыр уйларга чумды. Кинәт өстән, наратлар очыннан, кар тузаны коела башлады. Күрәсең, җил исеп куйгандыр. Латиф бер генә секундка тукталып уйларыннан аерылды да бераз агач башларын күзәтеп торганнан соң гына элекке фикеренә әйләнеп кайтты. Ә хәтер киштәләрендә шулай да бер вакыйга ачык сакланган икән. Менә ул. Сугыш бетү белән армиядән ирләр кайта башлады. Латиф ул вакытны цех начальнигы булып эшли иде. Аның цехында да яшүсмерләрне, хатын-кызны таза ирләр алыштыра башлады. Шулар арасында Латифның игътибарын җәлеп иткән, армиядән әле генә кайткан бер кеше булды. Ул коммунист иде. Кырык икенче елны партиягә кергән икән. Күкрәгендә Алтын Йолдыз һәм Ленин ордены иде. Латиф шул кешенең анкетасы һәм тәрҗемәи хәле белән танышкач, аптырап калды. Утызынчы елларда сыйнфый дошман буларак сөрелгән кулак малае булган икән ул кеше. Хәзер исә Латиф шуны хәтерләде, һәм ул кешенең үзен хәтерләүдән дә бигрәк аңа булган мөнәсәбәтне исенә төшерергә тырышты.

Латиф тагы тукран тавышын ишетеп тукталып торды. Ул башын күтәреп агач башыннан кошчыкны эзләде, ләкин тапмады һәм шунда ук онытты да аны. Чөнки теге элеге уйлары аның бөтен барлыгын били башладылар. Әйе, ничек булды соң әле ул? Бер нәрсә истә калган: Латиф ул кешегә ничектер шикләнеп караган иде. Ул кеше башкалар арасында бер ак карга кебек иде Латиф өчен. Ничек инде, сөрелгән кеше малае, ә үзе герой? Башка кешеләрнең моңа бик табигый бер нәрсә итеп карауларына аның бераз ачуы да килгән иде ул чак. Ниһаять, ул түзмәде. Ничектер бер җаен туры китереп, теге техниктан сорады (техник иде герой). «Үпкәләштән булмасын,— диде,— ничек соң, сезнең күңел төбегездә безгә карата рәнҗү, үпкә хисләре ятмыймы?» Менә шундый сорауга теге ничек дип җавап бирде әле? «Минем кылган эшләрем моңа җитәрлек һәм ышандырырлык җавап түгелмени?» — диде. Аннан әле ул үзе сорау бирде: «Ә сез соң минем урында булсагыз, нишләр идегез?»

Латиф ул чакны бу сөйләшүгә әллә ни игътибар итмәгән иде. Хәзер исә теге кешенең җавабы һәм соравы бөтен төгәллеге белән аның колагында яңгырап ишетелгәндәй булды. «Чыннан да,— дип уйланды ул,— кеше безнең өчен кәрәштә гомерен кызганмаган. Гомерен! Кеше өчен иң кадерле нәрсәне! Ә мин аңа шундый сорау биргәнмен. Мин аны рәнҗетмимме дип ничек уйламадым икән? Ә бит ул чын мәгънәсендә икеләтә батыр. Ул, беренчедән, үзенең ата-анасы кайчандыр кичергән сыйнфый интереслардан югарырак булып үскәнгә батыр, ә, икенчедән, сугыш каһарманы булганга күрә батыр».

Латиф тукталып калды. Читтән күзәтеп торучы берәр кеше булса, бәлки аның акылына бераз зәгыйфьлек килгән дип тә уйлар иде. Тик урманда песнәкләр генә чутылдаша иде. Латиф имән бармагын борынына тидерде дә: «Тукта, нәрсә дип әйттең син? — дип сорады.— Ул, беренчедән, үзенең кайчангыдыр сыйнфый интересларыннан югарырак күтәрелә алганы өчен батыр, диденме?»

Аңа ни өчендер җиңел булып китте. Чөнки этисеннән хат килгән көннән соң авыр хисләр кичерде һәм кичерә иде ул. Газаплы уйланулар, эзләнүләр юлы узган иде Латиф һәм көтелмәгәндә үзенә бик кирәкле, үзен башка миллионнардай тояргa хокук бирә торган хикмәтле, җан азыгы булырдай җавап хәзинәсенә юлыккан иде.

Латиф салмак кына адымнар белән баруын дәвам иттерде. Инде хәзер барысы да аның өчен хәл ителгән кебек булды.

«Ә хат? — дип сорады ул үз-үзеннән.— Әтиеңә хат язарсыңмы соң син, Латиф? Әлбәттә, язармын, чын дөреслекне белер өчен, хакыйкатьне ачыклау өчен...» — диде ул.

# XXXIX

Альфредның иң авыр кичергән нәрсәсе хәзер Луизасын югалту куркынычы иде. Әмма нинди генә хәлләрдә дә ул аннан аерылмас! Ул барысын эшләр, мәгәр, Луиза, ак йөзле, коңгыр-кара күзле Луиза, аныкы, бары аныкы гына булып калыр.

Алар моңа кадәр дә еш-еш бәхәскә керәләр һәм кайчак бер-берсен шактый ямьсез сүзләр белән рәнҗетәләр иде. Ләкин әле Луизаның беркайчан да иренә: «Мин китәм!» дип әйткәне булмады.

Ни өчен, бу ни дигән сүз? Бер-береңне яратып кушыл да көннәрдән бер көнне гомерлек союзны җимереп ташла. Һәм ни өчен? Ни өчен? Сәбәп бит һич тә җитәрлек түгел. Моннан да зуррак гаделсезлекнең булуы мөмкинме дөньяда! Ә бит үзе аңламый да түгел. Иплэп сөйләшкәндә барысы белән дә килешә, бер генә нәрсәгә дә каршы килми. Гаҗәп бу кеше дигәнең, эш сүз белән генә чикләнгәндә барысына да риза, ә инде сүз гамәлгә әйләнә башласа, барысы да зир-зөбәр килә, барлык аңлашу, сөйләшүләрнең көле күккә оча. Бу нәрсә бу?

Альфред хатынының ультиматумын ишеткән көнне шулай уйланды. Барлык дәрт-ашкынулар берьюлы, сыпырып төшерелгәндәй, очып юкка чыктылар.

Альфред мәҗбүрән үзен эшкә утыртты. Хатынына артык бер сүз дә әйтмәде, мәсьәләне куертырга батырчылык итмәде һәм, бүген үзе белән караватка ятмыйча, сандык өстендә йоклаган Луизага карамаска тырышып, булдыра алганча тизрәк эшен тәгәлләде дә ятагына чумды. Вакыт соң иде инде. Башка вакыт башы мендәргә тияр-тимәс үк, гырлап йокыга китә иде. Тик бүген ул бары үзенең күңел сызлавын ишетеп йоклый алмыйча ятарга дучар, ахры. Барысын да башыннан кичерде. Үзенең студент чакны шушы Луизага гашыйк булып йөргәнен дә, мәхәббәттән тәмам тилереп, күп тапкырлар юләрлекләр, мәгънәсезлекләр эшләгәнен дә, хәтта шул сөю аркасында иптәшләре алдында көлкегә калган чакларын да — барын да хәтерләде. Әйе, ул аны, Луизаны, үлеп яратты. Ул күңеле белән борчылып, хәсрәтләнеп, бу кыз мине сөймәс, мине тиң күрмәс дип янып-көеп йөрде. Ахыр чиктә Луизаның үзенә игътибар итүен, алай гына да түгел, көннән-көн үзенә якынаюын тойгач, ул җиденче кат күккә ашты. Җир шарында хәзер Альфредтан да бәхетлерәк кеше юк иде кебек. Ләкин шулай булса да аның күңелендә һаман әле ниндидер куркыну, бу зур бәхетне югалту мөмкинлегеннән куркыну яши иде.

Алар бит Луиза белән күптән түгел генә бергә тора башладылар. Әле һаман бер-берсенә иярләшү, аңлашу һәм шуның нәтиҗәсендә еш-еш карашлар, фикерләр бәхәсе чорын кичерәләр иде. Альфред үзенең тәҗрибәсезлеге аркасында мондый хәл гомер буена дәвам итәргә тиеш дип уйлый иде. Ләкин Луизага булган мәхәббәте аны бу газапларга да әзер торырга күндерде. Әйдә, Альфред гомере буена Луизасы белән бәхәсләшеп, чәкәшеп торырга да әзер, әйдә, нервлар тетелә бирсен, тик алар аерылышмасыннар гына! Чөнки бит ул сүз көрәштерүләр була да бетә. Аның каравы, соңыннан туган тынычлык минутлары отыры татлы һәм отыры рәхәт.

Әйе, шулай ул. Ләкин Альфредның Луиза авызыннан бу кадәр авыр сүзләр ишеткәне булмады. Китәм, имеш. Бик-бик авыр иде аңа. Альфред әле бер, әле икенче ягына әйләнеп, авыр сулап, уфтанып ятуында булды.

«Нинди гаделсезлек, нинди гаделсезлек! — дип кабатлады ул эченнән.— Миндә бернинди дә гаеп юклыгын белә бит инде, ә шулай да миңа каршы күтәрелә. Чыннан да, әгәр ул башлык булса, нәкъ шул ук Әхмәдиев кебек кыланыр иде микәнни?»

Ул ай яктысында тоник кына булып күренгән матчага карап, Луизаны директор ролендә күз алдына китерергә тырышты. Ниһаять, ул күренеш бөтен тулылыгы белән килеп басты һәм Альфред ирексездән елмаеп куйды. Елмаюы аның әрнү аша, ирониялe иде башта, ләкин тора-бара Альфред хатынының үзе уйлап чыгарган кыланышларыннан һич эчкерсез көлә башлады. Бик сөйкемле иде шул каһәр Луиза. Ул тискәре рольне башкарганда да иренең күңелендә соклану тойгылары тудыра иде. Альфред артык йомшак булып тоелган мендәрен селкеп мамыкларын бер почмакка төшерде дә җайлабрак ятты. Бераздан аның тәкатьсез рәвештә хатынына күз төшерәсе килә башлады.

Луиза мич буендагы сандык өстендә башын Альфредның аяк турысына куеп йоклый. Альфред башта аның тигез генә, тын гына сулавын тыңлап ятты. Ахырда түзмәде, башын калкытып, аның йөзен күрергә тырышты. Луиза мичкә йөз биргән, аның бары тузгыган чәчләре генә каралып күренә иде. Альфред башын мендәргә салды, бераз яткач тагы күтәрелеп карады. Хатыны һаман шул ук бер кыяфәттә йоклый иде. Кинәт кулын күтәреп, ни өчендер, чәчен сыпырып куйды ул. Альфредның хәзер барлык сизгерлеге уянган, игътибары-дикъкате иң югары ноктага күтәрелгән иде. Ул өстәлдән күзлеген алып киде дә хатынын күзәтә бирде. Менә Луиза ап-ак беләкләрен янә юрган эченә яшерде һәм тагы җиңелчә генә мышнап йокыга китте.

Альфред түзмәде, пышылдап:

— Люлю,— диде. Җавап булмады.

— Лю-лю!

Ләкин Луиза әллә йоклый, әллә йоклаган булып юри кылана иде шунда, бер сүз дә дәшмәде.

Альфред урыныннан сак кына төште дә, аяк очларына гына басып, хатыны янына килде. Кинәт Луиза бөтенләй тынып калгандай булды. Тәгаен йокламый иде шайтан. Альфред, үз алдына елмаеп, аның колагына пышылдады:

— Лю-лю.

Кинәт Луиза кискен хәрәкәт ясап, юрганын өскә тартты. Хәзер Луизаның колагы капланган, бары муены һәм чак кына аркасы ачылып киткән иде.

Тоник ай яктысында Альфредка күптән таныш кара миңле арка һәм ап-ак матур муен күренә иде. Хәтта аркадагы нәни миңгә кадәр бик якын, үз иде шул болар!

Альфред бераз вакыт икеләнеп торды. Аннары, батырчылык итеп, иелде дә хатынының миңле аркасын үбеп алды. Чак чигенеп өлгерде. Луиза яшен тизлегендә юрганны тагы да өскәрәк тартты. Хәзер инде ул башыннан ук бөркәнеп ята иде. Альфред, каушый төшеп, Луизаның барлык гәүдәсен күзеннән кичерде. Хатын йомарланып яткан, шулай да баштан ук бөркәнгәнгә күрә, аның бер аягы тышта калган иде. Әнә ул Луизаның кечкенә генә матур тәпие. Үзе ап-ак, килешле, ә яртылаш ачылган балтыры тыгыз, шулай ук бик матур иде. Альфред, оныты-лып, шуларга карап тора башлады. Бер мәл аның башына әллә шул тәпине кытыклап карарга микән дигән уй да килеп китте.

Әйе, әйе, аның шулай шаярып кети-кети иттергәне бар. Ләкин хәзер ярамый. Бусы артыграк, бу инде тозсызлык булачак. Ә бит Луизаның дуламавы, күңелне рәнҗетеп берәр авыр сүз әйтмәве өметне өзмәскә куша кебек!

Альфред, ишлим икән дип бераз торганнан соң, өченче тапкыр иелде дә Луизаның колагына пышылдады:

— Люлю әйдәле, әйбәтләп сөйләшик әле. Люлю дим, син бит акыллы, син бит барысын да аңлыйсың, әйдәле, әйбәтләп сөйләшик әле.

Кинәт Луиза юрганны ачып иренә текәлде. Альфред сискәнеп китте, чөнки хатынның күз карашында өметләнерлек бернәрсә дә күренми иде.

— Беләсеңме нәрсә,— диде Луиза,— мине төнлә дә борчыма. Синнән үтенәм, калдыр мине!

— Син бит теге сүзләрне миңа чынлап әйтмәдең, шулай бит, Люлю? Шунысын гына әйт.

— Чынлап әйттем. Кит янымнан,— диде Луиза һәм хәзер, бөтенләй йомарланып, юрган астына йөзен һәм аякларын да яшерде.

Хатын-кыздан да рәхимсезрәк җан иясе юк иде җир йөзендә Альфредча. Ул кискен рәвештә борылды да караватына таба китте. Бераздан ул тирән уйлар, икеләнүләр һәм күңел сыкрануы белән булашып ята башлады.

«Бәлки, чыннан да, Луиза хаклыдыр,— дип уйланды ул,— бәлки, минем тырышлыкларым барысы да юләрлек аркасында гынадыр. Кемгә кирәк ул синең эшләрең?»

Ул шулай дип уйланды да эчтән тынып калды. Альфред күңелендә икегә әверелә белә иде. Берсе үзе, ә икенчесе — үзен хөкем итеп торучы. Ул бу юлы да шулай итте. «Әйе, менә шулай туа торгандыр инде ул обыватель,— дип уйланды ул, үзенең гамәлен үлчәүгә салып.— Авыр, курыктың, кинәт үзеңнең тирә-юнеңдәге кайберәүләрнең башкача эш итүен, башкача фикер йөртүен тойдың, һәм кинәт синең кемгәдер ышанычың какшый башлады. Ләкин... ләкин, чыннан да, беркем дә бит синең кебек янып көеп йөрми, кысыр хәсрәт түгелме соң бу? Юкка тына син азап чикмисеңме, юкка гына син Луизаңны хәсрәт утларына ташламыйсыңмы? Луизаңның да бит кешечә яшисе килә, ул үзе өчен, баласы өчен, киләчәге өчен борчыла һәм шуңа күрә аның протест белдерүе бик табигый. Димәк, нәрсә булып чыга инде? Димәк, синең өстеңә кемдер пычрак ата, кемдер сиңа каршы күтәрелгән һәм син дә, хатының да шуннан шүрләдегез. Туктале син, тотасың да ул эгоистлык, шәхси интереслар аркасында килеп чыккан хәл, дисең, ә бәлки, син ялгышасыңдыр?»

Ул артык озак уйлана алмады. Тиздән оеп йокыга талды.

Иртәгесен Альфред эшенә соңгара язды. Ләкин шулай да ул уянганда Луиза мәктәпкә китмәгән иде әле. Сикереп торды, ашык-пошык кулын-битен юды, пожарникларча тиз өс-башын киенеп алды һәм хатыны белән бергә үк диярлек өйдән чыгып китте.

Тышта салкын, шулай да рәхәт иде. Альфред, хатыны белән янәшә атлап урам уртасына кадәр сүзсез барды да аулаграк урында тәвәккәл рәвештә:

— Син мине ташлап китәргә теләсәң, ихтыярың,— диде,— мин сине көчләп тота алмыйм, Луиза!

Луиза каерылып конгыр-кара күзләрен иренә текәде. Бу күзләрдә аптырау, куркыну һәм ачыну билгеләре бар иде.

— Әйе, мин шаярып әйтмим. Әгәр мине яратмыйсың икән, мин сине көчләп тота алмыйм, — диде Альфред, кабатлап.

## XL

— Әнә, үзе дә килде,— дип куйды физика укытучысы Сәлимҗан ага.

— Эш нидә соң? — дип сорады Альфред, укытучылар бүлмәсенә керер-кермәс.

— Сезне Казан телефонга чакыра,— диде карт укытучы.

Луиза иренә куркынып күз атты, Альфред исә сер сынатмаска тырышты, телефонга дип директор бүлмәсенә таба китте.

Әхмәдиев, трубканы кулына тоткан килеш завучны сүрән генә каршылады. Альфредның исәнләшүенә җавап итеп ул:

— Әнә Казан сине сагынган,— диде. Альфредның күзләренә ирексездән Халитның мәсхәрәләү һәм җиңү тантанасы белән тулы йөзе чагылып китте.

— Бирегез әле,— дип, Альфред телефонны үзенә таба тартты.

— Кем бу? Телефонда Альфред Хәйретдинов. Сезне тыңлыйм.

Бераз вакыт трубкадан бары җил сызгырган тавыш кына ишетелеп торды. Альфред Әхмәдиевның, тын да алмыйча, телефоннан ишетеләчәк сүзләрне ниндидер өмет белән көтүен тагы абайлады.

— Миңа Альфред... Альфред, Альфред Яхич Хәйретдинов кирәк иде,— диде, ниһаять, телефоннан хатын-кыз тавышы. Аппаратка чакыручы кеше Альфредка таныш түгел иде. Шалтыратучы аның исемен кәгазьгә карап әйтә иде, ахры.

— Әйе, сезне Хәйретдинов үзе тыңлый,— диде Альфред.

— Ә, исәнмесез,— диде хатын тавышы.— Әтиемнең үтенечен тыңлагыз әле, зинһар өчен.

— Гафу итегез, кем соң сезнең әтиегез? — диде Альфред, кинәт тынычлана төшеп. Күңелен рәхәт бер җылылык сыйпап узды.

— Мин Хәбибрахман абзагызның кызы, сезгә таныш бабайның кызы, Кадрия. Әти миңа хәзер үк шалтыратып сезне чакырырга кушты.

— Хәзер үк дисезме?

— Әйе, хәзер үк, чөнки аның хәле бик начарланды, ул бик каты авырый бит.

Альфред бүген эшлисе эшләрен тиз генә исәпли башлады. Шунда ук, алай бик кирәк булмаса, Хәбибрахман абзый аны чакыртмас иде инде дип тә уйларга өлгерде.

— Яхшы,— диде, — мин көндезге икедән дә калмый сездә булырмын. Шулай дип әйтегез.

Ул Хәбибрахман абзыйның хәле турында тәфсилләбрәк сорашмакчы иде, ләкин телефонистканың, вакытыгыз бетте, дип арага керүе тыелырга мәҗбүр итте. Кадрия трубканы элде.

— Менә нәрсә, иптәш Хәйретдинов,— диде Халит,— бүгеннән дә калмый теге Равил белән синең үзеңә шөгыльләнергә туры килер. Бүген үк барып белеш. Ни өчен ул малай өч көннән бирле мәктәпкә йөрми?

— Соң бит Нажия Ахметовна белеп кайтты.

— Бер нәрсә дә белмәгән ул. Синең үзеңә барырга кирәк булыр. Бүген бар, миңа кичкырын әйтерсең!

— Яхшы,— диде Альфред. Ул директорның барысын да ишетеп торганлыгын һәм өметләре өзелеп, җене кузгалганын яхшы аңлый иде.

«Педсовет, ата-аналар җыелышы һәм бу һич укырга теләмәүче ялкау малай...— дип уйланды ул,— ни булса шул, дәресләремне уздырам да Казанга китәм. Белмәссең, авыру, олы яшьтәге кеше, бәлки, әҗәл түшәгендә ятадыр инде».

Альфредның юравы дөрескә чыкты. Ул барлык эшләрен калдырып Хәбибрахманнарга килеп кергәндә, карт хәл эчендә түшәктә ята иде.

Альфредның күзләренә Кадрия, ак халат кигән врач белән сестра чагылдылар. Аларның йөзләренә каушау, сагаю һәм тирән борчылу билгеләре чыккан иде. Альфред, Кадрия белән ияк кагып кына исәнләшкәч, авыру янына килде.

— Нәрсә, Хәбибрахман абзый, кәеф начарланып торамы? — диде ул. Бу сорауның бик мәгънәсез икәнлеген уйлап, шундук эченнән үзүзен каһәрләп ташлады. Карт, исәнләшү өчен, хәлсез, ябык кулын Альфредка сузарга теләде. Ләкин кул күтәрелмәде.

— Начарланып кына тора түгел, бик начар. Болай булганы юк иде

әле, — диде Хәбибрахман калтыранган, хәлсез бер тавыш белән,— менә мине больницага алып китәргә килгәннәр, ярый әле килеп җиттегез. Ул больница...

Хәбибрахман артык сөйләшә алмады, тынып бераз хәл җыйды.

Альфред картның салкын кулын учына алып җылытырга теләде.

— Менә нәрсә ни...— диде Хәбибрахман, тагы сүзгә керешеп.— Минем синә бик зур гозерем бар.

— Әйтегез, Хәбибрахман абзый,— диде Альфред.

— Әйбәт булды әле килеп житүең, юкса...

Карт тагы тынып калды һәм ничектер сәер итеп Альфредка карап алды. Хәбибрахман абзыйның зәңгәрсу-ак күз алмасын ничектер сәер ялтыратып куюы Альфредның йөрәгенә кинәт дәһшәт салды. Тәгаен, аның күзләрен шулай йөртүе артык хәлсезлектән генә иде.

Доктор Альфредка якын ук килде дә шыпырт кына:

— Сез аны озак борчымагыз, зинһар,— диде.

— Юк, доктор, сез үзегез мине борчымагыз. Мин әйтәсе сүзләремне әйтми торып больницага китмим,— диде Хәбибрахман, Альфред учыннан кулын чыгарып.

— Сез үзегезнең хәлегезне белергә тиеш, сезгә бернинди артык хәрәкәт һәм борчылу ярамый,— диде врач...

— Менә нәрсә, Альфред,— диде Хәбибрахман, докторның сүзләрен җавапсыз калдырып,— әнә теге өстәл тартмасында бер папка бар. Анда истәлекләр. Шул ук папкада минем өлкә органнарына язган үтенечем бар. Үзең күрерсең анда. Син менә шуларны хәзер үк ал әле, зинһар.

Альфред торды да өстәлгә таба атлады.

— Ачкычы биредә,— диде Кадрия.

Хатын өстәл тартмасын ачты.

Папка шактый салмак иде. Альфред аның тасмасын чиште: иң өстә әлеге үтенеч ята иде.

Альфред яңадан караватъ янындагы буш утыргычка барып утырды.

— Инде болай,— диде Хәбибрахман, сүзләрен бүлә-бүлә,— безнең хәлләр шундыйрак инде, ни... Альфред. Табигать законнары үзенекен итә. Ләкин дөреслек, без яулап алган дөреслек, сафта калырга тиеш. Менә монысы сезгә, яшьләргә, тапшырыла. Үтенечне син ал да... шунда барып, үзеңә мәгълүм мәсьәләне кузгат. Бәлки, сиңа кемнәргәдер нәрсәләрдер исбат итәргә туры килер. Минемчә, син анысын булдырырсың.

Ул тагы байтак вакыт тынып, хәл алып ятты.

— Менә тагы нәрсә,— диде сүз башлап,— безнең Бригаданың тарихын өйрәнүгә керешеп бик әйбәт иттең. Син аны очлап чыгарсың дип уйлыйм. Менә нәрсә...— Ул тагы тынып хәл җыйды, аннары сүз башлаганчы, ничектер баягыча тагы күз акларын күрсәтеп өстәлгә карады.— Менә шул өстәл өстендәге сары портфельне күрәсеңме?

— Күрәм Хәбибрахман абзый.

— Ал син аны. Үзеңә булсын. Анда бик күп, бик кызыклы истәлекләр бар. Син алардан файдалан.

Альфред өстәл янына барды да портфельне алып килде. Аның бу минутта: «Рәхмәт сезгә, Хәбибрахман абзый, ышанычыгыз өчен рәхмәт, кайгырмагыз, сезнең бу язуларыгыз әрәм булмас», димәкче иде. Ләкин әйтә алмады, ничектер карт артык гади сөйләшә иде һәм шундый вакытта Альфредка болай әйтү артык театрча, килешсез дә, мәгънәсез дә булып тоелды. Ул яңадан утырды, портфелен кочаклаган хәлдә хәрәкәтсез калды.

Хәбибрахман бу юлы авыр сулап, байтак вакыт сүзсез ятты. Ләкин аның бик бирелеп нидер уйлаганлыгы ачык күренә иде. Ниһаять, ул, китә аласың дигәнне аңлатып, уң кулының бармакларын гына хәрәкәтләндереп куйды.

Альфред аягүрә басты һәм Хәбибрахманның салкын кулын янадан учына алды.

— Савыгыгыз, Хәбибрахман абзый, мин чын күнелемнән сезнең терелүегезне телим,— диде ул. Кинәт ул күзләрен яшь элпәсе каплаганын тойды. Ничектер болай мәлҗерәп төшү оят иде. Альфред шуны сиздермәс өчен, күзләрен йомып алды, тик яшерә алмады, ике күзеннән дә яшь агып, Хәбибрахманның ак җәймәсенә тамды.

Альфред кисәк кенә борылды да ишеккә таба юнәлде. Ул өстенә йөнтәс кыска тунын кигәч кенә бераз тынычлангандай булды. Үзен озата чыккан Кадриядән, аңа бик текәлмичә генә, Хәбибрахман абзыйның кайсы больницада дәваланачагын сорады.

Урамга чыккач, уйланып барды. Альфредка кыйммәтле истәлекләр генә тапшырылмаган иде...

## XLI

Альфред, Хәбибрахман абзый биргән әйберләрне өстәлгә куйды да, дәфтәр тикшереп утыручы Луиза янына килде.

— Берничә минутка эшеннән аерылчы, зинһар,— диде ул хатынына.

Хатыны каләмен кара приборына куйды. «Бәлки, сүз кузгатуның хаҗәте дә юктыр,— дип уйланды Альфред, бераз икеләнә төшеп,— бәлки, аның өянәге узгандыр инде». Чыннан да, Луизаның матур күзләрендә кичәге рәнҗү дә, үпкә дә күренми иде хәзер. Альфред бераз тынып торды. Аннан: «Юк, әйтергә, аңлашырга кирәк, ахыргы тапкыр аңлашырга, һич югында кабатлану мөмкинлеген кисәтергә кирәк», дигән катгый фикергә килде.

— Люлю,— диде ул,— мин синең белән барысын да алга салып сөйләшергә телим. Син миңе тыңла, аннан үзеңнең карарыңны чыгар. Менә нәрсә,— Альфред читкә караган хәлдә, бераз вакыт уйланып торды. — Менә нәрсә! — диде ул, ниһаять.— Мин һаман шул: син белгән Альфред булып калачакмын! Тукта, тукта, әйтеп бетерим, Люлю! Мин моны эгоистлыктан эшләмим, миңа моны намусым куша. Әгәр беләсең килсә, безнең әтиләребезнең, бабаларыбызның васыяте куша. Тукта, кашларыңны җыерма, әйтеп бетерим, без аңлашырга тиеш.

Луиза рәнҗеп елмайды да:

— Син нәрсә, әллә мине үзең белән бергә тилереп йөрергә өндисеңме? — диде.

Альфред бүленгән сүзен дәвам иттерде:

— Мин шулай ук Әхмәдиев кебекләргә каршы да көрәшәчәкмен, мин бу мәктәптән китмим. Юк, синең өчен генә түгел. Мин үземнең хаклы икәнлегемне исбат итү өчен китмим. Менә шул. Инде әйт, әгәр син шундый Альфредны яратсаң...

Альфред сүзен әйтеп бетермәде, Луиза, күрәсең, үзенең кичерешләрен яшерергә теләптер:

— Китәле, пожалысты, теленә салынма, зинһар,— дип сүзне башкага борды.— Дөнья кадәр карыйсы дәфтәрем бар, баш катырып утырасын шунда!

Альфред хатынының күзләренә сынап карап утырды. Барысы да хәзер аңлашыла иде. Хатыны никадәр генә ачулы булып кыланмасын, ул Альфредны аңлый һәм, алай гына да түгел, ул үзенең әлеге авыр сүзләре өчен үкенә дә иде.

— Люлю, карале, Хәбибрахман абзый миңа нәрсәләр бирде,— диде Альфред бераздан. Ул сак кына хәрәкәтләр белән портфельдән хатлар, язулар чыгара башлады.— Хәле бик начар, бик, бик...

Луиза аңа күзәтеп тора иде... Альфред бераз кәгазь кыштырдатканнан соң бер кызыклы язуга очрап, аерыла алмыйча, бөтенләй тынып калды.

Ниһаять, портфельне өстәл тартмасына салды һәм Җәзилә ападан Шамилне алып, тагы хатынына мөрәҗәгать итте:

— Я, нинди сүз булды соң мәктәптә?

— Нинди сүз? Сине ачуланалар.

— Барысы дамы?

— Кем икәне билгеле инде.

— Мин бит аңа язу калдырган идем. Ул аны укымадымыни иптәшләргә?

— Укыр ул!

— Ә син соң ник әйтмәдең?

— Соңыннан аңлаттым мин,— дип куйды Луиза. «Ләкин эш узган иде инде»,— дип өстәлергә тиешлеген Альфред үзе аңлады.

— Соң?

— Шул. «Без генә бөтен йөкне тартып йөрергә тиешмени?» диләр...

Альфредның йөзе чытылып китте. Аның артык борчылуын күреп, Луиза тукталырга мәҗбүр булды.

— Минемчә, син иптәшләргә тиешенчә аңлатмагансың. Мин анда барысыннан да мөһимрәк эш дип саныйм,— диде Альфред,— мин бит бармый кала алмый идем.

— Нечкәлекләрен үзең сөйләп бирерсең инде,— диде Луиза. Ул, сүзнең шунда беткәнлеген аңлатып, үзенең дәфтәрләрен карый башлады.

— Ә син нигә йокламыйсың әле? — диде Альфред улына, — әйт сине, тишек борын!

Шамилнең йокысы туйган, күңеле көр иде, ул, гадәтенчә, әтисенең күзлегенә үрелә башлады.

— Карале, Люлю, карале, моның тагы ике теше калыккан бит! — диде Альфред, шатланып.

— Әле яңа гына күрдеңмени? — диде Җәзилә апа,— күптән инде...

— Зинһар өчен шауламагыз әле. Менә зинһар дип үтенәм,— диде Луиза, колакларын каплап.

— Бәтте, бәтте,— диде Альфред һәм улына хәйләкәр генә итеп күз кысып куйды.— Шаулама, улым, юкса сиңа да, миңа да эләгер.

Ул бераз улы белән уйнады да, аны әбигә тапшырып, дәресләренә керешә. Альфред эшне бирелеп, бөтен көчен туплап эшли белә иде. Шуңа күрә, гадәттә, бер үк арада Луизадан күбрәк эш кыйратып ташлый ала. Бүгенге төндә дә ул үзенең бу сыйфатын күрсәтте. Дәфтәрләр карап билгеләр кую өстенә ул планнарын язды, укытылачак дәресен әзерләде, ниһаять, иң татлы хезмәтенә, тагы үзенең тарихи язмалары эченә кереп чумды.

Алар икесе бер бүлмәдә шулай тыныч кына эшләргә күнеккәннәр иде инде. Икесе ике өстәлдә онытылып укыйлар, язалар, әйтерсең лә, өйдә башка беркем дә юк. Бу шулай бик озак дәвам итә. Ләкин кайчак бу кагыйдә бозылып та куя, моңа гадәттә берәр укучы баланың кинәт искә төшкән әкәмәт сүзләре, я керделе-чыктылы язган җөмләсе сәбәп була. Андый чакта бу көлке хәлгә юлыкканы һич тыела алмастан пырхылдап көлә башлый.

Альфред әле үзенең кәгазьләреннән аерыла алмыйча, тын гына утырды. Ул ятканда Луиза караватта йокыга киткән иде инде.

Иртәгесен алар мәктәпкә, кичәгедән үзгә буларак, култыклашып һәм алай гына да түгел, бер-берсенә шактый нык сыенган хәлдә киттеләр. Авыл халкының мондый эшне бик өнәмәвен дә яхшы беләләр алар. Тик теләсә ни әйтсеннәр! Шулай рәхәт. Алар юл буенча сөйләшеп бардылар, ләкин сүз бары мәктәп һәм мәктәптәге эш турында гына булды.

Мәктәпкә барып кергәндә, Альфредны күңелсез хәбәр көткәнлеген аларның берсе дә сизенми иде әле. Буп-буш укытучылар бүлмәсенә

уздылар, киемнәрен салып чөйгә эләргә өлгермәделәр, үзенең бүлмәсеннән Әхмәдиев килеп чыкты.

— Альфред Яхич, ниндидер якын кешең үлгән синең,— диде ул,— ә син, понимаешь, бәйрәмдәгечә авызыңны ерып йөрисең!

— Үлгән? Кем үлгән? — диде Альфред, куркынып.

— Исемен хәтерләмәдем, ниндидер якының инде, килгән шәпкә шалтыраттылар. Бер хатын-кыз сөйләште, ул беләә, кичә больницага озаткан идек, ди.

— Хәбибрахман абзый! — диде Альфред, агарынып. Барысы да сагаеп тордылар. Ниһаять, Халит:

— Вәт шул инде алайса,— диде дә үз бүлмәсенә кереп китте. Альфред әле һаман ни әйтергә белмичә тора иде. Хатыны, аның коелып төшүен һәм кулларының дерелдәвен тоеп, янына барды, юатырга теләп күзләренә карады.

— Кичә күргәндә бу аның соңгы сүзләре, васыятыдыр дип һич уйламадым,— диде Альфред,— башыма да кереп чыкмады...

Ул хатынын сак кына читкә этте дә, каударланып, директор бүлмәсенә таба атлады.

— Җеназасы кайчан соң, кайчан күмәчәкләр? — дип сорады ул, ничектер тиешеннән артык тавышланып.

Газеталар карап утырган Халит күзлек өстеннән генә Альфредка күз ташлады.

— Анысын шалтыратып белерсез инде!

Директорның шундый минутта да кинә саклап салкынлык сиздерергә тырышуы Альфредны тәмам чыгырыннан чыгарды, ул, үзен кулга алырга теләп, бер мәл дәшмичә торды.

— Аның нинди кеше икәнлеген беләсегез иде ичмаса,— дип куйды ул, әрнеп.— Ул гражданнар сугышы каһарманы, ул безнең өчен, Совет власте өчен кан койган кеше.

— Бик әйбәт.

— Нәрсә, аның үлүе әйбәтме?

— Юк, нәрсә сез? Аның кан койган кеше булуы әйбәт.

Альфред ишекне япты да үзенең өстәле янына китте. Бу арада укытучылар килеп беткәннәр һәм бүлмәдә Луиза белән алар Хәбибрахман абзый турында сөйләшәләр иде.

## XLII

— Я, ничек? — дип каршылады Луиза.

— Нәрсәсе ничек? Күмдек, җирләдек,— диде Альфред, күңелсезләнеп. Хатынының шундый тыныч бер тонда сорау бирүе аның ачуын китерде, ахры. Хәлбуки, Луизаның яхшылыктан башка бернинди теләге юк иде. Әле бары ире белән сүз башлавы һәм Альфредның көче-сәләте көтелмәгән күңелсезлеккә каршы торырлык микән дип капшап каравы гына иде.

Өйдә эч пошыргыч тынлык иде. Шамил, курәсең, төш күрә, аратирә үзе генә аңлый торган авазлар чыгарып куя, ә Җәзилә апа оек бәйли иде. Альфред, терсәкләре белән өстәлгә таянып, башын аска игән хәлдә, байтак вакыт утырып торды. «Барыбер, хәзер булмаса, иртәгә беләчәк ул. Барыбер билгеле булачак, бүген үк әйтергә кирәктер»,— дип уйланды Луиза.

— Тагы бер яналык бар,— диде ул, әкрен генә.— Сина Мюнхеннан хат килгән.

— Мюнхеннан? — Альфред бермәл аңламыйча аптырап карап торды. Аннан кинәт барысын берьюлы хәтерләде. Үзенең теге вакытны

Ибраһимов белән сөйләшүен дә, шул ук көнне аның әтисенә хат язып җибәрүен дә — барысын да берьюлы исенә төшерде.

— Бир. Кайда ул хат? — диде, урыныннан кубып.

— Ул хатны миңа күрсәттеләр генә,— диде Луиза.

— Ничек инде ул алай?

— Шулай, аны почтальон ни өчендер мәктәпкә калдырып киткән, Халит абый күргән дә...

— Я, я, күргән дә... шуннан нәрсә булган?

— Беләсең ич инде аны. Беләсең ич синә каныгып йөргәнлеген. Шул, шау-шу куптарып, без бу хатны аннан бөтен коллектив алдында ачтырырбыз, калганын күз күрер, бик туарылмасын әле, фәлән-фәсмәтән дигән була.

Альфред сикереп урыныннан торды.

— Хат андамы?

— Анда дип торам ич,— диде Луиза, куркына төшеп.

Альфред киемнәр элгеченә ташланды.

— Нишлисең син, Альфред, нигә? Кирәкми! — диде Луиза. Ләкин ул ирен тотып кала алмады, Альфред гасабиланудан, ашыгудан бүреген алдын артка кигән хәлдә, пальто чабуларын җилферәтеп, урамга чыгып китте. Луиза, Җәзилә апа сырмасын бөркәнеп, капка төбенә чыкканда, ул, икегә сынып, каударлана-каударлана Әхмәдиевләр өенә таба атлый иде. Луиза күкрәкләренә суык үтсә дә, ирен күзәтеп торды, ул күздән югалгач, кире өйгә йөгереп керде.

Альфред исә бу вакытны мәктәп директорының капкасына якынлаша иде инде. Ул кече капканы каерып ачты да, чылбырдагы зур овчарканың котыруына һич игътибар итмәстән, өйгә кереп китте.

— Халит абый өйдәме?

Беренче сүзе аның шул булды. Алгы якта нидер эшләп маташкан, ире кебек тәбәнәк, юан гына Гайникамал, хәйран калып, бермәл өнсез торды.

— Өйдә. Нигә ул?

— Чыксын! Әйтегез! — диде Альфред әмер тоны белән.

— Әллә бер-бер күңелсезлек булдымы? — диде Гайникамал, күзләрен тасрайтып.

— Чыксын! — дип кабатлады Альфред. Ул арада түр бүлмәдән эчке күлмәк өстеннән пиджагын кия-кия Халит үзе дә килеп чыкты. Ул Альфредны күреп имәнеп китте. Ләкин тиздән тынычлана төште һәм, нидер сизенгәндәй, төксе бер кыяфәт белән:

— Ни йомыш? — диде.

— Хат сездәме? — диде Альфред.— Хат сездәме, дип сорыйм мин сездән?

— Нинди хат?

— Миңа килгән хат. Сезнең кеше хатын алырга нинди хакыгыз бар?! Мин моның өчен сезне җавапка тарттырам!

— Чәпчемә, туган, тынычлыгымны җуеп, хулиганлык кылып, төн уртасында килеп йөрүең турында уйлан, аннан кем кемне җавапка тарта алуын аңларсың! Бәлки, әле миңа синең чын йөзеңне ачкан өчен рәхмәт укырлар.

— Сез кеше түгел, сез цемент, белдегезме? Сезне бер чылатып катырганнар һәм сез шул көенчә мәңгегә...

— Син мине мыскыл итмә. Синең әле авызыңнан ана сөте кипмәгән!

— Бирегез хатны!

— Хатыңны иртәгә коллектив каршында, шаһитләр алдында укырсың. Яшь булсаң да эшне бик астыртын йөртәсең үзең. Тамырларыңны җирән җибәрмәкче...

Альфред директорның юлына атылып каршы төште. Хәзер завучның

бөтен йөзен тимгел-тимгел кызыллык баскан, гәүдәсе ачудан дерелди иде.

— Бирәсезме хатны, юкмы? — диде ул ят бер тавыш белән. Халит күзгә күренеп каушый башлады. Ул, бу какча, ләкин хәзер тәмам усалланган егеттән, чыннан да курка калды. Сүз дәшмәстән, тынып, тиз-тиз алдын-артын уйлап алды.

Әхмәдиев хатны, язу өстәле тартмасыннан алып, Альфредка сузгач та, алар бер мизгел хәрәкәтсез бер-берсенә карашып тордылар.

— Мә,— диде ачу белән Халит.— Телисең икән ал, минем башка юлым юк.

Альфред үзләрен хәйран калып күзәтеп торган Гайникамалга карап алды.

— Гайникамал апа, шаһит булыгыз!

— Ә нигә ул? — диде кинәт Халит, үз чиратында нидер сизенеп.

— Ачыгыз хатны, хәзер үк,— диде Альфред,— ачыгыз дим!

— Ач инде, ач дип үтенгәч,— диде хатыны.

— Синнән сорамыйлар, катышма безнең эшкә! — диде Халит.

— Юк, катышсын,— диде Альфред,— катышыгыз, Гайникамал апа, катышыгыз!

Әхмәдиев конвертны ачты да язу юллары буенча күз йөгертә башлады.

— Кычкырып укыгыз,— диде Альфред,— сез гарәп шрифты белән язылганны миннән яхшырак укыйсыз бит.

Халит укылып беткәнче күзләрен хаттан алмады. Ниһаять, укып чыккач, күңелсезләнеп, сорау белән Альфредка текәлде.

— Дөресен әйт, шифрлы хатмы?

— Укыгыз! — диде Альфред.

— Ах, сафсата! Мин дә юләр,— дип куйды Халит,— тотарсың мондыйларны тиз генә!

— Укыгыз! Ә сез тыңлап торыгыз, Гайникамал апа,— диде Альфред.

Халит төртелә-төртелә укый башлады. «Хөрмәтле вә мәрхәмәтле Альфред әфәнде! Сезнең хатыгызны алып, үземә карата булган игътибарыгызга бик куанганнан соң, сезгә күптин-күп сәламләремне күндереп калам. Мин бичара үз иленнән, үз жиреннән аерылып, чит мәмләкәттә, жиде ят арасында каңгырып йөрүче бер фәкыйрь мөселманмын.

Әгәр баштан кичкәннәрне яза калсаң, ул зур китап булыр иде.Ниләр генә күрмәдем мин үз гомеремдә. Тик үз жиреннән аерылган кешегә аллаһы тәгаләә михнәттән башка берни дә бирми икән. Барысы да ходай иркендә, иллә мәгәр әллә бәлкем минем юлымда явыз адәмнәр очрамаса, мин бу көннәргә калмаган да булыр идем дип уйлыйм. Сез миннән Беренче укчы татар бригадасы турында сорыйсыз. Сез, ихтимал, мине үз илемнән киткәнгә күрә эшәке кешегә саныйсыздыр. Тик, алла шаһит, хәзер инде миңа, әҗәлен көтеп йөргән бер карт кешегә, ялганлап торуның хаҗәте юк. Язган сүзләремнең хак сүз икәнлеген исбатлау өчен корьән тотып ант итә алам. Әле сездән, баштан кичкәннәрне язып җибәрә алмассызмы, дип язылган үтенечле хат килгәч, үземнең фәкыйрь куышымда бик озак уйланып, кызыл гаскәрдәге хезмәтемне искә төшерергә тырышып яттым. Бик күп сулар акты шул ул көннәрдән бирле, инде җитмәсә аннан соңгылары да җиңел булмады, киресенчә, күңел бәгырьләренә үтәрлек, хәтерләргә тирән сырлар ясарлык булды. Инде килеп, миңа озак вакытлар үземнең узган юлымны оныту кулай иде. Шуңа күрә бик күбесе истән чыккан.

Хәтеремдә, без Буа шәһәреннән язын чыгып киттек. Аннан безне поездга утыртып Казанга алып бардылар. Аннан хәтеремдә калганы тагы Самарада балык шулпасы белән генә туенып торган чаклар. Җаек суы аркылы чыгуы бик тә күңелгә сеңеп калган. Бик авыр, каты сугышлар булды шунда. Инде килеп, бик ачык хәтердә сакланганы

Бохарага баруыбыз. Бик кызу көннәр иде. Без ул сәфәрдә михнәтне аз чикмәдек. Ләкин алла саклады. Бохараи-шәрифкә исән-сау барып җиттек. Менә шунда инде минем бәхетемә балта чабылды. Әлбәттә, бу эштә мин үзем дә гаепле. Ләкин бер адәм минем янымда булмаса, минем күңелемә вәсвәсә салмаса, мин, мөгаен, мондый тинтәклекне эшләмәгән булыр идем. Башта барлык вакыйгалар томан аркылы гына күренсә дә, менә монысы, Альфред әфәнде, һәр даим минем күз алдымда.

Минем Казанда ук танышкан бер дустым бар ие. Без Бохарада да, анарчы да һәр даим бергә булдык. Менә шул кеше аркасында булды минем бәхетсезлегем. Гөнаһ шомлыгына каршы, без аның белән Бохарага үзебезнең полк барып кергәч, сугышның иң кызган бер вакытында казна байлыгы саклана торган Бохара әмиренең зиннәтле сараена эләктек. Андагы алтын, андагы кыйммәтле ташлар, йөзек, беләзекләр кинәт безнең күз явын алдылар, зиһенебезне таркаттылар. Иллә мәгәр шулай булган хәлдә дә, әгәр минем дустым күңелгә вәсвәсә салмаса, мин бер генә нәрсәгә дә кул сузмас идем. Без аның белән башта, авызыбызны ачып, бүлмәдән-бүлмәгә кереп карап йөрдек. Шуннан бер бүлмәдә капчык-капчык алтын тәңкәләр, бриллиант йөзек кашлары күренгәч, минем дустым телгә килде. «Әйдә, Ибраһим, ганимәт малыннан файдалана белик»,— диде. Ул миңа, кеше-кара килгәнче, бу байлыклар советка күчкәнче дип, шуларның бер өлешен үзебез күтәрерлек итеп алырга киңәш бирде. Мин курка калдым, ә аннан нишләрбез, без бит барыбер бер тотылмый калмабыз, Кызыл Армиядә бу эш өчен каты җәза бирелә бит, дидем. Дустым бу сүзгә дә аптырап калмады. Шаулама, без хәзергә бу байлыкны капчыкларыбызда йөртик тә, бер җае чыккач, яшерербез. Беләсеңме, никадәр алтын биредә, ул безнен гомеребезгә җитәр, диде. Ул менә шулай итеп күңелемә шайтан вәсвәсәсе салды. Мин юләр, аның сүзләренә ышанып, ул әйткәнчә эшләдем. Бохараны алып, ул якта әмир гаскәре бетерелгәч, безнең полкны Пешпәктән алтмыш километр ераклыктагы Токмак исемле бер авылга урнаштырдылар. Без шунда алтыннарыбызны уңайлы вакыткача яшереп саклыдык. Тәрлечә янап һәм куркытулар ясап, шул ук алтын өчен тоттырам дип ул мине полктан качарга котыртты. Инде март аенын унсигезендә, киемнәребезне алыштырып, качтык та. Минем дустым мине таулар аша Кытай чигенә алып китте. Юлда күп газаплар чиктек, күп авырлыклар күрдек. Иллә мәгәр урланган малның әҗерен күрә алмадык. Инде морадыбызга ирештек дигәндә генә басмачы юлбасарларга очрап, бик күп алтын исәбенә генә җаныбызны саклап кала алдык. Без Кытайдагы мөселман халкы яшәгән Кашгар дигән шәһәргә җиткәндә, тәмам хәлсезлектән бетерешкән идек. Шул Кашгарда мин, патапач авыруы йоктырып, хасталанып егылдым. Рәхмәт андагы кешеләргә, безгә урын бирделәр, ризыктан мәхрүм итмәделәр. Иллә мәгәр минем дустым бәдбәхет кеше булып чыкты. Мин чир аркасында саташып ятканда икебез өчен дә күз алмасыдай кадерле булган тәңкәләрнең миңа тигән өлешен дә урлап качты. Рәхмәт мәрхәмәтле адәмнәргә, мине савыктырдылар, иллә мәгәр миңа алардан китәргә туры килде, чөнки минем Кызыл Армия сафында булганлыгым, хәзер аннан качкан булсам да, миңа карата түрәләрдә шик кузгатты. Мин шулай илдән илгә күчеп йөри башладым. Сезгә, әлбәттә, минем бары Кызыл Армиядә күргәннәрем генә кызыклы булыр. Инде, теләсәгез, мин киләсе хатымда сезгә үземнең бәхетсез тормышымның дәвамын да яза алам. Хатыгыз аша хәбәр кылыгыз. Менә шулай, Альфред әфәнде. Минем тормышым тоташ газаплардан торган бер яман юл булды. Ходай мин күргәннәрне дуска түгел, дошманга да язмасын.

Мин үзем дә гаепле. Ләкин, кабат-кабат уйлыйм да, гаепнең күбрәк өлеше миңа хыянәт ясап качкан кешедә бит, дип бераз юаныч алам.

Ул да дөнья куйгандыр инде, аның турында берни дә ишеткәнем юк. Ул Хәмзә Бакиров дигән бик чая бер егет иде.

Инде сезгә, мәрхәмәтле Альфред әфәнде, үтенечем шул, сезнең ярдәмегез илә туган-үскән якларга кайтырга мөмкин булмас микән? Мин бу теләгемне үземнең улым Латифҗанга да язган идем. Мәгәр аннан бернинди хәбәр булмады. Мин аны гаепләмим. Ихтимал, ул мине башка бер кеше белән бутыйдыр. Ник дип сорасагыз, мина мәгълүм тагы бер Ибраһим Касыймов бар иде. Ул кеше Бохараны алганда үлде. Минем улымның үзен шул кеше баласымындыр дип уйлап йөрүе мөмкин. Аллага тапшырдык. Шушы мәктүбемә каршы хат язарсыз дигән өмет белән көннәремне хәер догада үткәрәчәкмен.

Ибраһим».

Альфред хатны барлык дикъкатен җигеп, бирелеп тыңлады. Инде Халит соңгы җөмләләргә җиткәч, Альфредның тынычлыгы качты. Ул, колакларына ышанмастан, хатны директорның кулыннан тартып алды. Әйе, барысы да нәкъ ишетелгәнчә, акка кара белән язган иде. Альфред хатны тагы укыды, аптыраудан әле генә җен ачуларын кузгаткан Халитны да онытты ул. Ниһаять, бер сүз дә әйтмәстән, хатны кесәсенә тыкты да, кискен рәвештә борылып өйдән чыгып китте.

Дөрес микән хаттагы сүзләр? Әмма дөрес булмаска нигез бармы соң? Булган, булган! Заманында шундый хәлләр тәгаен булган. Язмышлар бер төрле түгел.

Альфред урам уртасыннан бер үзе бара иде. Авыл тын, тик тәрәзәләрдән төшкән яктылык кына күңелгә тынычлык бирә, кешенең ялгызлыкта калмаганлыгын сиздерә.

Альфред әле бүген генә күмелгән Хәбибрахман абзый турында уйлана башлады. Иртәгә үк ничек тә Казанга барып кайтырга кирәк, дигән фикергә килде ул. Казанга барырга, тиешле урыннарга керергә, мәрхүмнең соңгы теләген үтәргә. Менә шул.

Кинәт аның башына яна бер уй килде. Ул бит Хәбибрахман абзыйның үтенечена менә әле генә укылган хатны да терки ала. Әйдә, тикшерсеннәр, белсеннәр!

Альфред, ярты юл узгач тукталып, галошларын берәм-берәм салып кардан арчыды. Шулай да иртәгәдән дә калмый районга барып та сөйләшергә кирәк дигән фикергә килде. Бу эшне дә артык сузарга ярамый. Әлбәттә, Альфред боларның барысы да нииндидер аңлашылмау кесәфәте икәнлеген белә. Ләкин, ни әйтсәң дә, аңа каныккан Әхмәдиев кулындагы соңгы корал бит бу.

Альфред иртәгә эшләнәчәк эшләре турында уйланып бара башлады. Ул директорның котын алып, төрле оешмалар исеменнән әледән-әле телефон шалтыраткан, яшерен язулар җибәргән һәм яшь завуч турында төрле уйдырмалар чыгарып, директорга житкергән кеше Хәмзә Бакировтыр дип тә уйламады. Инде тозакка эләгәчәк Хәмзәнең начар юллар белән үз абруен сакларга тырышуын тоймый иде ул. Шундый кеше иде инде Альфред. Ул, анык белмичә торып, беркайчан да кеше турында начар фикер йөртми иде.

*1969.*

## Нәби Дәүли

# Көндәшләр

Резеданы, роза чәчәген
Бер вазага өзеп куйдылар.
Ике чибәр йөзгә-йөз карашып
Бары бер төн бергә кундылар.

Аллы-гөлле иде ул чәчәкләр,
Янып торган утлар шикелле.
Күрештеләр алар, үбештеләр,
Бик сагынган дуслар шикелле.

Телгә килде шунда роза гөле,
Резедага әйтте сүзләрен:
— Синең белән минә очрашырга
Язмышыбыз куша, гүзәлем.

Син борчылма, сиңа рәхәт булыр,
Син бәхетле минем янымда.
Уяныр сың йоклап таң атканда
Матуррак булып тагын да.

Яз исләре миндә, кояш төсе.
Яшәрерсең шушы ис белән.
Минем йөзгә иртән бер карасаң
Нур чәчәрсең үзең кич белән.

Мин җанымны ачам синең өчен,
Каршыңда мин синең тезләнәм.
Кемнәр генә сиңа гашыйк түгел...
Башка дусны ләкин эзләмәм.

Ә резеда башын түбән иде
Дустының бу татлы сүзеннән.
Әкрен генә тынды сулышлары,
Бер тамчы яшь тамды күзеннән.

Роза көлде, чөнки белә иде,
Резедалар түзми хуш искә.
Көндәшенең соңгы минутларын
Соңгы кабат күрде шул кичтә.

Ә икенче көнне иртә белән
Килделәр дә кешеләр күрделәр:

Ике чибәр бергә кочаклашып,
Кара янып шиңгән иделәр.

Шатланырга роза өлгермәде,
Сизми калды үлеп киткәнен.
Белми калды матур резеданың
Күз яшьләре агу икәнен.

*1969*

## Минем бүләгем

*1969 нчы елның январь аенда Бакуда берничә көн буена кар яуды.*

Яшел, зәңгәр, кызыл утлар.
Аэропорт учак яга.
Мин Бакуга килеп төштем,
Ә Бакуда кар ява.

Кар ява, ап-ак чәчәкләр
Тулып ята урамда.
Кемгә салкын, миңа рәхәт
Бакуда кыш булганда.

Мин телим шушы сәгатьтә
Дусларыма дәшәргә:
Гөлстанда кар белән дә
Мөмкин матур яшәргә.

Мин самолет канатында
Алып килдем болытлар.
Бу сезгә минем бүләгем,
Бу бит безнең жылы кар.

Кар ява, гаҗәп, егетләр,
Мәңге җәй булган якта.
Сергей Киров тауга менеп
Баскан да мәрмәр ташка,

Кулын сузып, тотып алып,
Мактый Вятка карларын.
Сагынып искә төшерә булыр,
Туган-үскән якларын...

Кар ява, ә мин шатланам,
Булсын җирдә кар гына.
Кар киткәндә таудан агып
Кешегә җыр калдыра.

Тундырмый да, өшетми дә,
Үз карымны мин беләм.
Ул йомшак та, ул матур да
Ялтырый энже белән.

Кар астында беркайчан да,
Үлми җир, шиңми иген.
Исемдә, карны ябынып
Окопта яткан көнем.

Әйтмәгез лә бер авыр сүз
Безнең кар исеменә.
Сезнең җирнең гөлләреннән
Шушы кар исе килә.

Алмада да, йөземдә дә
Шушы карның тәме бар.
Дөньяда кар яуса гына
Бу тормышның яме бар.

Мин самолет канатында
Алып килдем болытлар.
Бу сезгә минем бүләгем,
Бу бит безнең җылы кар.

# Кое

Бу шигырьне язып бирәм кулларына,
Бер мисал бу — укырга да, уйланырга...
Бер авылда булган икән бер зур кое,
Шуннан халык сулар эчкән гомер буе.
— Һай суы да суы,— диеп мактаганнар,—
Су түгел лә — ширбәт,— диеп шатланганнар.

Хәтта кояш шушы коега төшкән диләр,
Эссе көндә салкын суын эчкән диләр.
Хәтта ай да шунда килеп чумган диләр,
Суларында көмеш йөзен юган диләр.
— Һай, суы да суы,— диеп мактаганнар,—
Су түгел лә — ширбәт,— диеп шатланганнар.

Еллар узган, картлар үлгән, яшьләр туган,
Җәен, кышын кое һаман тулып торган.
Юлчылар да шунда туктап ял иткәннәр,
Атлары да, үзләре дә су эчкәннәр.
— Һай, суы да суы,— диеп мактаганнар,—
Су түгел лә — ширбәт,— диеп шатланганнар.

Ләкин коены кем казыган бу урында?
Оныталар уйлашырга шул турыда.
Иртә белән таң атканын көтәләр дә,
Сулар эчеп, юлга чыгып китәләр дә:
— Һай, суы да суы,— диеп мактаналар,—
Су түгел лә — ширбәт,— диеп шатланалар.

Мин кычкырам сезгә, дуслар, туктагыз, дип,
Түләмичә бер тамчы су йотмагыз, дип.
Юк, теләмим акча белән түләтергә,
— Онытмагыз рәхмәт диган сүз әйтергә.
— Һай, суы да суы,— диеп мактаныгыз,—
Су түгел лә — ширбәт,— диеп шатланыгыз.

*1969*

## Камил Мостафин

### Ачкыч

Табып алдым беркөн иске ачкыч,
ашыгып барган чакта юл буйлап.
Туктап калдым һәм кесәгә салдым,
ятмасын, дип, аунап...

Өйгә кайткач аны элеп куйдым
стенага каккан кадакка...
Эленеп тора хәзер иске ачкыч
түр якта.

Серле бакыр ачкыч... Бәлки, элек
ул ачкандыр бояр сандыгын,
һәм яткандыр, бәлки, шул сандыкта
җәүһәр белән алтын...

Я ачкандыр ачкыч гүзәл кызның
ялгыз өен, җыйнак бүлмәсен...
Ләкин байлык яки зур мәхәббәт
сезне, кешс, иске ачкыч тотып,
табам, диеп йөри күрмәсен!

Миңа калса, әгәр ачкыч чынлап
серле һәм сихерле булса,
барып ачар идем мин бүген
нигезе дә инде сакланмаган
туган өенең иске ишеген...

### Инженерлар

Адашмасак иде буранда.
Югалмасак иде томанда.
Онытылмасак иде.

Төннәр буе
башны башка терәп
утырабыз чертеж өстендә...
Тышта буран, дөнья иксез-чиксез,
безнең бүлмә генә кечкенә.

Үз итептер безне, алдыбызга
бик күп сорау куйган замана.

Җавап кайда?
Һәм без, ватман җәеп,
тагын иеләбез аңа...

Тышта буран безнең эзне каплый
һәм көрт өя безнең сукмакка.
Шулай булгач,
бездән соң чыкканнар
ничек юлны табар бу якка?

Юлны табар алар...
Яшь егетләр
буран аша безне табачак,
чөнки таңга кадәр бүлмәбездә
без кабызган лампа яначак.

Утырабыз башны башка терәп,
язга кадәр янар утыбыз...
Табылырмы җавап? Бу турыда
шомырт чәчәк аткан чакта, дуслар,
газетлардан үзегез укыгыз...

Шомырт чәчәгенең буранында
адашсак та ярый,
гүзәл вакыйгалар томанында
югалсак та ярый,—
онытылмасак иде...

●

Безнең исем әле ташка язылмаган,
ташлар безгә һәйкәл түгел,—
сукмак бүген...
Без йокласак, таш та йоклый,
без торганда,
иптәш кебек, ул да гүя ача күзен.

Таштан ташка, таштан ташка,
атлый аяк,—
табаннары ташка җылы биреп килә.
Без еласак, ташлар елый, таулар елый,
без кычкырып көлсәк, кыя-ташлар көлә.

Ә сукмакка, җылы ташка егылганда,
безнең тәннәр суынса да, суынмас таш,
безнең аяк табаннарын искә алыр
һәр таш — иптәш, һәр таш — чордаш,
һәр таш — юлдаш.

Һәм язмагыз, дуслар, ташка исемебезне,
елатмагыз гаҗәп, гүзәл юллар ташын...
Ташлар һаман тойсын аяк табаннарын,
алар һаман
горур сукмак булып калсын.

●

Без серләрне югалтабыз,—
югалтабыз,
кыен җавапларны тапкан чакта,
төннең битен ачып, учак яккан чакта.
Без серләрне югалтабыз...

Серне саклап йөртә күңел.
Серле күңел,— нинди бай ул, өмет кебек,
ә ачылса сере, күңел — укылган хат,
иске китап... Нигә серләр мәңге түгел?

Без серләрне югалтабыз,
уйланабыз,
нигә артык таныш, диеп, сөйгән ярлар,
кайсы таңда соңгы серен ача алар,—
безнең ярлар?

Һәм карыйбыз аларга без, ә аларның
кулы — камыр, өсләрендә — ситсы халат...
һәм яңадан сокландыра таныш китап,
сискәндерә укылган хат...

Уйландыра су буенда янган учак,—
ялкын теле төнне ерта...
...Без серләрне югалтабыз,
ә сер төшеп калган җирдә,
ахры, безнең уйлар шыта...

●

Китапларны язалар да, аталар да.
Поэмалар туалар да, яналар да.
Кайда илһам хөкем сөрә, кайда — мәкер...
Күрсәтегез икесен дә балаларга!

Без атылган китапларны бастык тагын,
утта янган җырларны без яздык тагын.
Ләкин дөнья ничек итеп кеше итсен
фашист булган, җәллад булган балаларын?

Кайда илһам хөкем сөрә, кайда — мәкер,—
күңел сизсен, күзләр күрсен, акыл белсен...
Явызлыкка каршы чыккан минутында
бу дөньяның баласына илһам килсен!

## Болгар кызы

*Баллада*

Батый ханга ялчылары китергәннәр
кара күзле, озын чәчле болгар кызын.
— Кәләшем бул, җанашым бул,— дигән Батый,
сыйпый-сыйпый зур корсагын, кысып күзен.

Гүзәл кызчык ап-ак булган, эндәшмәгән,
ә хан моны кызык күргән, ә хан көлгән:
— Бик курыксаң, әйдә башта эчеп җибәр,—
җамаякка татлы шәрап салып биргән.

— Юк,— дигән кыз,— мин кәләшең булмам
синең...

Әгәр мине гүзәл күрсәң, бик ошатсаң,
шушы татлы эчемлеккә агу куш син,
ишетәсеңме, и мәшһүр хан, и бөек хан!

Усал Батый уйга калган... һәм шәрапка
агу салган, аны гүзәл кызга сузган...
Таңга кадәр ул утырган күзен алмый
хәрәкәтсез яткан озын чәчле кыздан...

...Татар халкы, туган халкым, газиз халкым,
дусларың күп, байрагың ал, юлың озын.
Исемеңне синең Батый ханнар бирсә,
горурлыкны, кыюлыкны — болгар кызы!

## Эмигрант

*Баллада*

Күптән киткән кеше Ватаныннан,
кеше күптән эмигрант булган,
француз телен инде яхшы белгән,
французча елмайган һәм көлгән.

Балалары французлар кебек —
ике мадемуазель һәм бер мусье-егет...

Париж, Париж,— урамнары гаҗәп,
Париж, Париж,— мәйданнары гүзәл,
ләкин шушы гаҗәп шәһәрдә дә
яши икән әҗәл.

Эмигрант үлем түшәгендә,
аны борчый әллә нинди уйлар,
ә янында — ике кыз һәм егет,
французча кайгыралар алар.

Елый алар бик әдәпле итеп,
папа́ күрмәсен дип,
һәм елмая аңа өчесе дә,
«үлмәссең» дип...

Эмигрант исә улын чакыра
һәм бер төргәк суза аңа,
«каберемә» ди ул французча
һәм күзләрен йома.

Париж, Париж,— гажәп гүзәл шәһәр,
әмма анда күпме гомер сулган.
ә төргәкнең саргылт кагәзенә
«Идел туфрагы бу» дип язылган.

Сүзләр французча язылса да,
никтер бүтән телдә яңгырый кебек,
һәм елыйлар, бөтен милләт елагандай,
ике мадемуазель һәм бер мусье-егет...

## Фантаст Хуҗалар

*Баллада*

Көтә-көтә көтек булып беттек...
Җәй артыннан көзне көтәбез,
ә көз килгәч,
урамнарга чыгып китәбез
һәм эзлибез җәйне...
Без көтәбез
төнлә кояш нурын, көндез — айны,
һәм һәр көнне —
кичә көтеп ала алмаганны...
Без көтәбез,
шуңа
маякларда
корабларны чакырып ут яна.
Шуңа күрә Хуҗа Насретдиннар
яши безнең фани дөньяда.
Хуҗа Насретдиннар хикмәт көтә,
әмма аны эшли үзләре!
Без көләбез ботны чаба-чаба
Хуҗаларның тыңлап сүзләрен.
Без көләбез юкны бар итүдән,
шаян хыяллардан көләбез...
һәм, кул биреп фантаст Хуҗаларга,
тагын юлга чыгып китәбез дә,
тагын яңа көнгә керәбез.
Без көтәбез, һаман көтәбез без!
Без күрәбез: җирдә яз туа,
кайдан килә ул яз?
Умырзая
ничек куна карлар астында?
Без сизәбез:
гажәп чәчәк кебек,
шатлык шыта безнең йөрәктә.
Безнең күңелләрне
шатланырга,
я әйтегез, кемнәр өйрәткән?
һәм мәхәббәт,
кинәт пәйда булып,
сөйгәненә таба талпына...
...Сез көлмәгез фантаст Хуҗалардан:
көтә белсәң, юктан бар туа!

— *Чиләбе — Уралның уртасы...*

Урал бик зур,
төньягында Туфан торган,
көньягында Тукай булган, Җәлил туган.
Без уртада,
ай-һай кыен юлчы булу,
зур-зур таулар чорнаганда уңнан, сулдан.

Ләкин монда,
биеклекләр арасында,
хыяллар да, теләкләр дә үтәләләр.
Һаман өскә җилкенгәндә, җилпенгәндә,
абынсаң да, биеклекләр күтәрәләр.

Биеклекләр юлчыларны күтәрәләр,
без дә, дуслар, һәркөн таңда
юлда булыйк...
...Без уртада. Уңда — таулар, сулда —
таулар.
Без уртада,
ләкин, дуслар, урта булмыйк!

Габдулла Шәрәфетдинов

# СУСЫЗ ДӘРЬЯ

*Солдат язмаларыннан өзекләр*

### АВТОРДАН

*Бу язманы мин үзем белән бергә монгол далаларын, Гоби чүлен, Зур Хинган тауларын кичкән дусларыма багышлыйм.*

*Монда сурәтләнгән вакыйгалардан соң чирек гасырга якын вакыт узды. Японияга каршы 1945 елгы сугышка катнашкан кешеләр инде шактый олыгаеп баралар, ул чагындагы унтугыз-егерме яшьлек егетләрнең хәзер үз уллары-кызлары җитеп килә. Бөек Ватан сугышы тарихы, аталары узган юл алар өчен кызыклы булыр дип уйлыйм.*

*Әлеге язмада телгә алынган кешеләрдән күбесенең исем-фамилияләре үзгәртүсез бирелде. Вакытлар узу белән онытылганнарының гына исемнәре үзгәртелде. Моның өчен иптәшләр мине гафу итәрләр, фамилияләре аталмаса да, үзләрен, һичшиксез, танырлар дип өметләнәм.*

## Бер йотым су

Күк йөзе чалт аяз. Иксез-чиксез дала. Тирә-юньдә ник бер агач, ник бер куак булсын. Чәч бөртеген селкетерлек тә җил исми. Кояш нурлары гүя бихисап инәләргә әверелгәннәр дә солдатларның арыган гәүдәләрен, талчыккан йөзләрен рәхимсез чәнчиләр. Маңгайларда, җилкәләрдә — тоз. Һәркемдә бер уй: туйганчы эчәсе иде. Әмма гасырлар буе үзе дә шундый уй белән яшәгән чүлле даладан нәрсә көтәргә?!

Офицерлар дала картасын барган саен ешрак ачалар, йотлыгып карыйлар. Бу тирәдә су булырга тиеш, кайда ул?.. Кипкән... Колонна салмак адымнар белән алга баруын дәвам итә. Тагын карталар ачыла... Кайда кое?.. Кипкән!.. Ә кояш, бернәрсәгә исе китмичә, торган саен катырак кыздыра. Ниһаять, алҗыган колоннага дәрт биреп, сафтан сафка, солдаттан солдатка шатлыклы хәбәр йөгерә: «Алда зур күл булачак!» Башлар югарырак күтәрелә. Тупларга, хәрби арбаларга җигелгән кыска торыклы монгол атлары да җәһәтрәк атлыйлар.

Белмим, бу вакытта хуҗалык ротасындагы чуваш егете Василий Максимовтан да күбрәк куанучы булды микән. Иртәдән бирле полкта аннан да сүрәнрәк кеше юк иде. Чөнки частьның аш-суга хаҗәтен шулар ротасы үти. Ә су юк та юк. Ә хәзер ул, ротадан ротага күчеп.

тиздән суга барып җитәчәгебез турында җылы хәбәр салып йөри. Аның авызы колакка җиткән:

— Әйттем ич, су пула дип, менә пула!

Күлгә якынлашкан саен, адымнар җиңеләя бара. Җилкәгә аскан винтовка каешлары да, капчык һәм противогаз тасмалары да иңбашларны хәзер ул хәтле кисмиләр кебек. Әнә колоннаның башы күлгә барып та җиткән. Чакрымга сузылган ул колонна торган саен җыерыла, кыскара бара һәм, ниһаять, күлгә таба бүлтәеп яр буена тарала. Ләкин... Ләкин күлнең суы кипкән булып чыга. Бөтен киңлегенә җәелеп юка гына тоз катлавы утырган. Уртасында дөя үләксәсе. Аның күләгәсендә кипмичә аз гына су калган. Ул, сусаган кешеләрне үчекләгәндәй, тын гына ялтырый...

Күл янында бераз хәл җыйгач, полк тагын кузгалды. Поход йөргәндә шул кыска ялдан соң кабат кузгалып китүдән дә авыррак нәрсә бар микән! Аяклана алмыйча алҗып бетәсең. Табан асларының чәнчүе һәр адымыңны җәзага әйләндерә. Җитмәсә тын алгысыз бөркү. Әнә бер солдат егылган. Эх, су булсачы, бер генә йотым су! Кемдер күлгә йөгерә.

— Кая чабасың, кортлы су ич анда!

Бу — Максимов тавышы. Флягасын тоткан килеш, егылучы янына ашыга. Менә ул аны солдатның кипшегән иреннәренә тидереп, зур саклык белән күтәрә башлый. Фляга инде иреннәр өстендә авызы белән капланып үк тора диярлек, ә суы һаман килми. Ниһаять, солдатның бугаз төене кузгалып, кашлары селкенеп куя. Тузан кунган иягенә нечкә генә ак юл сызып су ага. Башка солдатларның да бугаз төеннәре тамак төпләрен еш-еш капшыйлар. Ләкин бу сусаудан гына түгел. Анда йота алмаслык төер. Күзләр дымланып Максимовка төбәлгән. Рәхмәт сиңа, чандыр дус, диләр иде алар.

Әнә шулай үрчемсез чакрымнар белән тартыша-тартыша Гоби чүленә якынлашканда, алгы сафтан кемдер: «Болыт килә!» дип кычкырды. Кайчандыр су булган җирдә утырып калган тозның яисә кызган һаваның кояш нурында ерактан чып-чын су кебек ялтырап күренүе безне инде күп тапкырлар алдаган иде. Шуңа күрә монысы да мираж түгелме икән дип, яңа күренешкә артык игътибар итүче булмады. Тик бер кавымнан соң, болыт дигәннәреннән җиргә таба кара-кучкыл толымнар сузылып, сизелер-сизелмәс җил дә искәли башлагач, моның чыннан да болыт икәнлегенә берәүдә дә шик калмады. Болыт колонна өстенә җитәрәк, скаткаларны сүтеп, плащ-палаткаларны чыгардык. Әмма бу яңгырдан саклану өчен түгел, һич югында тамак чылатырлык кына булса да су җыелмасмы дип талпыну иде.

Палаткаларны почмакларыннан тоткан килеш зур өмет белән көтә башладык. Менә болыт колонна турысына килеп житте. Ләкин ни гаҗәп: баш өстендә коеп яңгыр ява, ә безнең палаткаларга ник бер тамчы су төшсен! Һава шул кадәр кызган, яңгыр тамчылары җиргә төшеп җиткәнче үк парга әверелеп бетәләр.

Бу шулай байтак дәвам итте. Тик соңыннан гына, капчык төбен селкегәндәй, берәм-сәрәм тамчыларын калдырды да, үзенә төбәлгән меңнәрчә күзләрне омсындырып, болыт китеп барды...

## Армиянең интеллигенциясе

Радистларны армиянең интеллигенциясе диләр. Бәлки, моны аларның уку, өйрәнү, һәртөрле күнегү программалары бик катлаулы булганлыктан, күп вакытларын класста уздырулары өчен шулай чыгарганнардыр. Ләкин бу — өйрәнү чорында, тыныч вакытта гына. Ә походта, сугыш шартларында? Арыганмы син, алҗыганмы,— бер нәрсәгә

карамыйча, элемтәңне булдыр. Артиллеристмы ул, танкист яисә пехота солдатымы — барасы җиренә барып җиткәч, эшлисе эшен эшләгәч, башын төртеп кенә булса да черем итәргә, азмы-күпме көч җыеп алырга җаен таба. Ә радистның хәле башкачарак. Ул юлда да эштә, кеше ял иткәндә дә эштә. Чөнки штаб бер генә минутка да туктамый, штаб һәрвакыт уяу. Димәк, радист та уяу, радист та эштә.

Менә бүген дә без ике радист — карел егете Соколов һәм мин — башкалар кебек үк юл газапларын кичереп, туктаусыз элемтә тотып килүебезгә карамастан, полк штабы белән янәшә үзебезнең ике кешелек кенә палаткабызны тиз-тиз әмәлләп куйдык та тагын эшкә тотындык.

Ләкин әле күптән түгел генә колак төбендә сөйләгән күк бик әйбәт ишетелеп торган дивизия штабы, авызына су капкандай, тынып калды. Кайта-кайта дәшеп тә җавап бирмәгәч, шактый ук борчуга төшеп, күрше полк штабларын чакырып карадык. Алар безне дә, дивизия штабын да бик яхшы ишетәләр булып чыкты. Нәрсәдер эшләргә, элемтәне ничек тә ялгарга кирәк иде. Башта радиостанциянең куәтен арттырып карыйсы иттек. Беребез станция янында китмичә дежур тора, икенчебез тышкы, җәелмә антеннаны куя. Ниһаять, бар да әзер. Микрофон белән дә, телеграф белән дә чакырып карыйбыз, әмма дивизия штабы элеккечә үк ләм-мим. Ул арада радиограмма тотып, полк штабы начальнигы килеп җитте, кайда урнашуыбызны әйтеп дивизиягә хәбәр итәргә куша.

— Элемтә өзелде, иптәш капитан,— дибез.

— Ничек алай... Беләсезме, бу ни дигән сүз?!

— Беләбез, иптәш капитан.

— Белсәгез, менә шул, элемтә булсын!..

Микрофон эченә керердәй булып, дивизия штабын чакыруымны бераз карап торды да:

— Элемтә булгач ук тапшырырсыз,— дип, капитан китеп барды.

Моңарчы җае чыккан саен безне мактап, эшебездән канәгать булып килгән штаб начальнигы алдында бик нык кызардык. Ләкин ни чара, элемтә юк. Инде бер генә юл калды: дивизияне башка полклар аркылы чакырырга. Иң яхшы ишетелгәне 43 нче полк. Анда — Федотов белән Кошкин, шуларны чакырдык.

Дежурда Федотов иде. Без, радистлар, бер-беребезгә шулкадәр күнеккән, микрофон аркылы сөйләшсәк — тавыштан, телеграф белән эшләсәк — почерктан иптәшләрне һич тә ялгышмыйча таныйбыз. Ләкин Федотовның тавышы калтырабрак чыга. Димәк, 43 нче полк әле ялга туктамаган, радист барган килеш сөйләшә.

Безнең хәл шундый инде: радиостанция ике көпчәкле арбага беркетелгән, ә үзең, чегән арбасына тагылган аю кебек, башыңа телефон колакчыннары кигән хәлдә арттан тәпилисең. Ат чапса — чабабыз, туктаса — туктыйбыз. Радиограммаларны да күп очракта барган көе кабул итәбез, үзебез дә тапшырабыз. Ә бу, ай-һай, җиңел түгел. Бигрәк тә кич белән, тычкан утыдай кечкенә генә күчмә электр лампасы яктысында — мең бәла. Шуңа күрә аптырабрак калдым: тапшырыргамы радиограмманы, әллә бераз сабыр итәргәме? Ләкин вакыты шундый иде, кичектерергә һич ярамый. Тагын Федотовны дәштем.

Федотов безнең радиограмманы алып, дивизия штабына тапшыруын хәбәр иткәч, тынычланыбрак калдык. Инде беребез ятса да була.

— Бар, йокла — дим Николайга.

— Йокларгамы? Хәзер, хәзер,— дип, ул урын әмәлләргә керешә. Элек бер шинельне бөкләп баш астына салды, икенчесен аска җәйде дә сузылып торып чалкан ятты. Ләкин шунда ук уң ягына әйләнде, аннары сул ягына ятып карады һәм бераздан торып ук утырды.

— Нишлисең? — дим моңа.

— Нишлим, дежур торам, бар ят,— ди бу.

Ләкин башта аның үзен яткырырга туры килде. Әнә ул изрәп йокыга да киткән. Ара-тирә ыңгырашуы гына ишетелә. Шулай утырам мин. Телефон колакчыннарында, әйтерсең лә, кошлар базары. Һәр радиостанциянең үз тавышы. Кайсы йомыркадан әле яңа гына чыккан каз бәбкәләренеке кебек зәгыйфь кенә, нәзек кенә, кайсы бака, кайсы үрдәк һәм каз тавышы чыгара. Болары үтә куәтле радиостанцияләрнеке. Ул да булмый, трансмиттерны эшләтә башлыйлар. Баш өстендә тургайлар сайрыймыни! Барысы да бер дулкында, барысы да бер урынга өелгән. Ә приемник шкаласына карасаң — ул энә юанлыгы гына бер сызык. Әнә шунда нихәтле станция! Ручканы чак кына бордыңмы, күршедә — тагын шундый ук кош базары. Радист шулар арасыннан үз «кошын», үзе элемтә тота торган станцияләрне таный, аера белергә тиеш. Әле ул гынамы, һәркайсы сукыр чебеннәр кебек колагына керергә торганда, минутлар буе син үз адресатыңны бутамыйча аннан радиограмма кабул итәргә тиешсең. Һәм итәсең.

Инде төн уртасы авышкан иде. Күрше полк радистлары безнең өчен дивизия штабыннан алынган радиограмманы тапшырдылар. Кое казу өчен кирәк-яракларны алып, фәлән-фәлән районга егерме кеше җибәрергә кушканнар. Әлбәттә, болар барысы да яшерен код белән бирелгән иде.

## Ком дәрьясы

Изрәп йоклаганмын. Бары тик Соколовның:

— Әйдә, калганын сугыштан соң йоклап бетерерсең,— дип аягымнан тартуына гына күземне ачтым. Баш өстендә бер нәрсә юк. Николай палатканы инде күптән җыеп куйган. Штабныкын да сүтеп маташалар.

Радиостанцияне арбага беркетеп, тагын кузгалдык.

Әллә ничек шунда, дала кичәге дала кебек түгел. Без барасы яктагы офык та бүген әллә нинди. Кояш чыгышы бит инде, югыйсә. Ә үзе башка тарафларга караганда никтер сәеррәк күренә, томанлырак та, күгелҗемрәк тә кебек. Белмәссең бу даланың хикмәтләрен. Күрәсең, һәркем шулай уйлагандыр, бу хакта сүз озайтучы булмады. Юлның көндәгечә газабы барын да оныттырды. Фляжкалар кичәгедән бирле буш. Тамак төпләре кипкән. Телне әйләндереп сүз дә әйтәсе килми. Шулай атлыйбыз. Менә бер заманны, җир тетрәтеп, безнең яннан танклар колоннасы уза башлады. Алар артыннан бастырып ук пушкалар тагылган автомашиналар, «Катюша»лар килеп җитте. Иге дә, чиге дә булмас кебек. Тирә-якны тузан каплады. Тын алыр да, ни дә булса күрер хәл дә юк. Янында килгән иптәшеңне дә танымаслык кыяфәткә кердек. Бару мөмкин түгел. Җилнең әсәре дә сизелми. Тузан ничек күтәрелгән, шул килеш һавада асылынып тора бирә.

Без, радистлар, полкның башында атлыйбыз. Алда тик байрак йөртүчеләр дә штаб кешеләре генә. Шуңа күрә юлда ни булуын элегрәк күрәбез. Әнә колонна каршына йөгерә-атлый бер солдат килә. Ике кулында элмәкләреннән асып күтәргән ике каска. Менә якынлаштык. Максимов икән. Каскаларында туп-тулы су! Үзенең киемнәренә, хәтта битенә, чәчләренә кадәр пычрак ябышып каткан. Танырлык та түгел. Шешенкеле төшкән күз кабаклары арасында тычкан балалары кебек йөгерешкән ягымлы көрән күзләре генә «Мин — Максимов» диләр.

[1] Трансмиттер — морзе сигналларын автоматик тапшыра торган аппарат.

Каскаларның берсен байрак йөртүчеләргә калдырып, икенчесен безгә китерде. Каскалар шундук, кулдан кулга күчеп, колонна буйлап киттеләр. Һәркем бер генә йота да иптәшенә бирә. Ул да түгел, кемдер: «Качать Максимова!» дип кычкырды. Шул кадәр алҗыган халыкка кайдан көч кергәндер, колоннадан ун-унбиш солдат чыгып, Василийны эләктереп тә алдылар. Бичараны чөепме чөяләр. Тегермән канатлары кебек чайкалган чандыр аяклары гына күренеп кала...

Чөючеләр кулыннан ычкынгач:

— Нихәл, якташ, пик арыдыңмы? Хәзер парып җитәпес, әнә генә калды. Саперларга пулыштык, су пулды,— дип сөйләнә-сөйләнә, Максимов безнең яннан атлый башлады. Аның шулай минем хәлгә кереп, беркадәр бозып булса да татарча сөйләшеп килүе күңелле дә, рәхәт тә иде.

Василийның «әнә генә»се өч-дүрт чакрым булып чыкты. Менә соңгы комлык та артта калды. Алда такыр юл. Ул сизелер-сизелмәс кенә сөзәкләнеп түбәнгә алып төшә. Озак та үтмәде, хәтсез киң бер үзәнлеккә килеп кердек. Өч җирдә өч кое казылган. Һәркайсын солдатлар, су ташу өчен резинлап эшләнгән дүрт кырлы зур-зур капчык резервуарлар яки цистерналар куелган машиналар сырып алган.

Ниһаять, су! Җан асрар өчен генә түгел, ә туйганчы!.. Шуңа кушып тагын бер шатлык өстәлде: дивизия белән инде юлда барганда ук турыдан-туры элемтә урнашкан иде, хәзер менә радиограмма тапшырдылар, приказ булмыйча кабат кузгалмаска, ял итәргә кушканнар...

Әле кояш чыкмаган. Кыздырмаса да юл бик авыр. Кичәгедәй такыррак урыннар бүген бөтенләй очрамый. Чүлгә кердек. Кая гына карама — иксез-чиксез ком дәрьясы. Бассаң, таралып ишелергә тора. Атлап кына китеп булмый. Аяклар, арба көпчәкләре баталар...

Бара торгач, кояш та чыкты. Һәм каршыбызда гаҗәеп бер күреиеш ачылды. Үтә күренмәле сыек зәңгәр томан артында караланып, офыкны буйдан-буйга иңләп, кырыйлары күккә тиярдәй булып тоташ койма калыккан. Бу — Зур Хинган таулары. Шундый якын кебек күренә: бер-ике талпыну белән барып җитәрбез төсле. Инде кичәдән бирле ул якның ни өчен шулай сәеррәк күренүен менә хәзер генә аңладык. Халык җанлана төште. Барып җитәсе иде дә, бу җәһәннәмнән тизрәк котыласы иде. Ләкин тиз генә түгел икән шул. Аңа кадәр әле җитмешсиксән чакрым, диләр.

Алай да ашыгырга кирәк. Чөнки вакыты, мондагы сугышның үзенчәлеге шуны таләп итә. Елның бу чорында Гоби аша узарга моңарчы әле беркемнең дә батырлыгы җитмәгән. Сусыз далалар, Гоби чүле, Төньяк Манчжуриядән алып көньякка таба 250—300 километр араны иңләп Сары диңгезгә хәтле сузылган, исәпсез-хисапсыз тау сыртларыннан торган Зур Хинган борынгы заманнардан бирле дошман көчләре арасында табигый киртә булып килгән. Моннан совет гаскәрләре уза алыр дип японнар башларына да китермәгәннәр. Шуңа күрә бу тирәне хәрби корылмалар белән ныгытуны, анда артык ишле армия тотуны кирәк дип санамаганнар. Алар Хинган тавы итәгенең Хайлар, Халун-Аршан, Солунь кебек үзу өчен чагыштырмача җиңелрәк районнарын ныгыту ягын караганнар. Ләкин дошманның бик тиз айнуы, без үзасы урында да көч туплап, кичүләрне ныгытуы, хәзергедәй техника белән бернинди армия дә үтә алмаслык дип саналган барлы-юклы тар гына юлларны да бикләве мөмкин. Безнең дәүләт чигеннән дә, Квантун армиясенең төп көчләре урнашкан районнан да Хинганга чаклы булган араның ераклыгы бер үк диярлек. Шуңа күрә японнар килеп җиткәнче тауны узып Үзәк Манчжурия тигезлегенә чыгарга, бәрелешне үзебез өчен уңайлырак шартларда башлап җибәрергә кирәк.

һичнинди авырлыклар белән исәпләшмичә ашыгуыбызның сәбәбе шунда иде.

## Иске таныш

Өстән кояш, астан олтан аша аякларны пешерерлек итеп ком кыздыра. Эсселек илле градуска житкән. Анда-санда көпчәкләре батып туктап калган автомашиналар, аларны сөйрәп интегүче артиллеристлар, минометчылар очрый. Радиаторларыннан бөркелеп пар чыга. Ә өстәргә сулары юк. Аны әле кайчан китереп житкерерләр. Су ташучы машиналар еш кына үзләре дә барханнар арасында батып калалар.

Шулай бара торгач, безне монгол атлылары куып житте. Тупларына дөяләр жигелгән. Хәйран гына киләләр. Алай да бик талчыкканнар. Атларның башлары салынган. Бары тик дөяләр генә бик һавалы күренәләр, «без кемнәр» дигән шикелле башларын югары тотып, комына да, кызуына да исләре китмичә, жайга салынган бер адым белән атлауларын беләләр.

Якында гына «Сайн байну, СССР цэриг!» [1] дигән тавышка әйләнеп:

— Сайн байну, туган, сайн байну! — дидем дә тагын алдыма карап атлый бирдем. Сәлам бирүче монгол солдаты да, атын бераз тыя төшеп, безнең яннан бара. Башта мин аны радиостанция белән кызыксынып шулай киләдер дип уйлаган идем. Юньләбрәк карасам... Муса!!!

— Ден-саулыгың калай, жолдас. Танымайсынба?

— Кем уйлаган бит тагын очрашырбыз дип.

— Дала киң булса да, жолдары тар гой.

— Үзеңдә соң ничек?

— Аман-сау, жолдас, жапондарды кыйратуга бара жатырмыз гой...

Муса белән моннан ике ай элек танышкан идек. Сугыш башланыр алдыннан безнең занятиеләр тагын да көчәеп, катлауланып киткән иде. Көнне дә, төнне дә белмәдек. Гарнизоннан машина белән егермешәр-утызар чакрымга илтеп куялар да шуннан торып элемтә тотарга өйрәнәбез. Бервакыт шулай окоп казып маташканда, безнең янга ике монгол солдаты килде. Радиостанциябез дә булгач, сагаебрак калдык. Алар да бик якынлашырга кыеп бетермиләр. Читтән торып кына нәрсәдер әйтәләр. Ләкин аңламыйбыз. Берсе ике бармагын иреннәренә тидереп.

— Тамих... Тамих байну? — дигәч кенә төшенеп алдык. «Тәмәкегез юкмы?» — диюләре икән. Күптән түгел генә безгә ныграк итеп бер суырсаң сыныңны катырырлык «вергун» дигән махорка биргәннәр иде. Яннарына барып тәмәке төрә башладык.

Кунакларның берәр генә суырулары булды, күзләреннән атылып яшь чыкты. Аннары бер-берсенә карап яшь аралаш көлешергә тотындылар.

— Уа жаксы, кайдан сондай жаман зат таптыңдар!

Монгол теле татар теленә якын да килми. Ә боларның сөйләшүен мин яхшы ук аңлап торам. Кызыксынып сораштыра башладым.

— Сез кемнәр? — дим.

— Монгол цэриглары, оенга шыгып эдек, ана бездең адамдар,— дип, күршедәге сопка ягына күрсәтәләр.

— Цэриг икәнегезне күрәбез... Мин менә татар малае,— дим үземә төртеп,— ә сез кем?

---

[1] Монголча — СССР солдатына сәлам!

Мине аңлауларына алар да гаҗәпсенәләр иде. Шулай да әле нәрсә соравыма төшенеп җитмиләр. Аннары тагын кабатладым:

— Менә бу рус,— дим, гәрчә карел булса да Николайга күрсәтеп,— мин татар, ә сез кем?

Шуннан соң көлеп җибәрделәр.

— Казакъмыз гой без, казакъмыз... Монау — Муса, монау — Токтыбай болады.

Монгол казакълары икән. Шулай хәйран гына сөйләшеп киттек. Тора торгач Муса исемлесе көтмәгәндә генә:

— Галымҗан туыскан аманбы? — дип сорап куйды.

Мин аптырап калдым. Нинди Галимҗанны соравы икән?

— Белмим, мин әйтәм, кем соң ул?

— Галымҗанба? Ибраһимов Галымҗан... «Казакъ кызы» кетабын җазган ше!..

...Бу олы язучының әсәрләре әнә кайларга, дөньяның икенче читендәге монгол далаларына ук барып җиткәннәр икән ләбаса.

...Хәзер менә Гоби чүлендә тагын очраштык.

— Ой-бай, көндең ыстыгын айтсаңше. Суың җокпа? — дип Муса флягасына үрелде.

— Анысы инде хәзер кемдә дә юк.

— Мәнде бар, менеки авызыңды шайка,— дип Муса миңа флягасын сузды.

— Болай да беткән ич, ярамас,— дим моңа, төбендә генә суы калган фляганы айкап.

— Мән җаяу емес, сән эч,— дип кыстагач, бер йотым суын эчтем.

Ниһаять, Гоби чүле дә артта калды. Алда — Зур Хинган. Ул тагын нәрсә күрсәтер.



## Менә нинди икән ул Хинган!

Текә кыяны уеп салынган тар гына юлдан үргә менәбез. Юл шулкадәр тар, җигүле атлар белән артка борылу яисә чак кына булса да читкә тайпылу турында хәтта уйларга да ярамый. Сул якта — төпсез упкын, ә уңда — таш кыя. Тик бер генә якка — алга таба гына хәрәкәт итәргә мөмкин. Дивизия штабыннан алынган һәрбер радиограмма хәзер дә бары шуны гына кабатлый: алга, алга, мөмкин кадәр тизрәк алга! Дошман мәкерле. Койрыгына бассаң, елан каты чага. Әгәр бу тирәдә чакса, шеше яман булачак. Шуңа күрә дә ашыгырга, ул ис җыйганчы бугазына басарга кирәк. Ә юл текә, хәвефле. Тупларга һәм фургоннарга җигелгән атлар адым саен туктыйлар. Солдатлар, шабыр тиргә батып, аларга булышалар. Юл борылмалы булганга, алда нәрсә бары күренми. Менә бу борылманы гына үтик тә, бәлки, таугa менеп җитәрбез дисең. Әмма борылма артыннан борылма, тау артыннан тау туктаусыз дәвам итә. Кайвакытта көне буе тауга менеп, таудан төшеп, аның тирәли әлмәк ясап, иртән үк узган урынга барып чыгасың.

Ниһаять, бүгенгә соңгы тау артта калды. Алда үзәнлек. Тигез юл. Юл буенда ярым ялангач халык төркеме. Ирләр, хатыннар. Балалар анадан тума. Ябыклар. Колоннага кыяр-кыймас якынлашалар. Гаҗәпсенеп безне күзәтәләр, сыныйлар. Җәбер булмаслыгын сизеп, төркем бераз җанлана төшә.

— Японнар кайда? — дибез. Аптырап бер-берсенә карашалар. Аннары, япон дигәнне аңлап булса кирәк, «ә, ә, ә, япониза... Япониза пфулә, япониза маюлә», ягъни «японнар явызлар, японнар юк», дип, көньякка ишарәләп, аларның качуларын аңлаталар.

— Ник качырдыгыз соң? — дигәч, тагын аптырашалар. Без көлә башлагач, алар да шаулашып көләләр. Кытайлар белән беренче

тапкыр энә шулай очраштык. «Теттереп» сөйләшәбез. Куллар, бармаклар хутка китте, кем нәрсәгә маһир. Кыскасы, бик тиз дуслаштык. Булган кадәр кием-салым өләштек. Алар аны шундук киеп, ирләрне хатыннардан, хатыннарны ирләрдән аера алмаслык кыяфәткә керделәр. Барысында да солдат киеме — ак күлмәк белән ак ыштан. Житмәсә күп ирләрнең хатыннарныкы кебек итеп үргән толымнары да бар.

Һәммәсе киенде. Тик читтәрәк, күкрәгенә имчәк баласын кыскан бер яшь хатын гына киемсез калган. Оялган, күрәсең, якын килергә базмаган. Ә безнең кайсыбызның гына капчыгында запас күлмәк-ыштан калды икән. Шулай да җае чыкты, аңа бер санитар ак халат китереп бирде. Шуннан соң чал кытай карты алгарак чыгып, полк каршына тезләнде дә, маңгаен берничә тапкыр җиргә тидереп, акрын гына басты һәм, без ни дип уйларга да өлгергәнче, юл биреп ике якка тайпылган кытайлар арасыннан, беркемгә дә карамыйча, башын иеп китеп барды.

Кытайлар таралыштылар. Без дә, иске дөньяның әле генә күреп уздырган шәрә чынбарлыгы тәэсиреннән авыр тойгыларга бирелеп, дәшми-тынмый гына, төн уздыру өчен палаткалар корырга керештек. Күңелсез дә, моңсу да, рәхәт тә иде бу кич...

Таң беленер-беленмәс юлга чыктык. Тагын тау, тагын борылмалы юллар... Томан, үргә менгән саен сыегая һәм, тау өстенә җитәрәк, кинәт бетә. Томан, дөресрәге, болыт, аста кала. Аның арасыннан, диңгездән чыгучы әкият пәһлеваннары төсле, ерактагы таулар артыннан калкып килгән иртәнге кояш нурында штыкларын ялтыратып, солдатлар күтәрелә. Югарыдан караганда тирә-яктагы күренеш чыннан да диңгезне хәтерләтә иде. Тау сыртлары, иләмсез зур су хайваннарының килбәтсез гәүдәләредәй, болыт арасыннан бер калкалар, бер баталар. Зәңгәр күккә ашкан ялангач кыялар да нәкъ диңгездәгечә. Алар тирәсеннән салмак кына аккан катлы-катлы болытлар, дулкыннарны хәтерләтеп, көнбатышка авышалар.

Тауны төшеп килгәндә генә автоматлардан аткан, гранаталар шартлаган тавышлар ишетелә башлады. Аларга артиллерия дә кушылып, хәзер генә тып-тын торган тирә-як шартлау, гөрселдәү авазларына күмелде.

Озак та үтми, 47 нче полк радиостанциясе дивизия штабын чакыра башлады. Бик ашыгыч радиограмма кабул итүне сорый. Күрәсең, каршылыкка очрауларын, сугышның ничек баруын хәбәр итәргә теләүләредер. Ләкин дивизия штабы җавап бирми. Аннары без дә, безнең арттан килгән 43 нче полк радистлары да кайта-кайта чакырып карадык. Беребезгә дә җавап юк. Инде нишләргә? Ахрысы, теге көнне без эләккән кебек, дивизия штабы да радистлар телендә «тынлык зонасы» дип йөртелүче каһәр суккан нәрсәгә тап булгандыр. Бер бәла инде ул. Әле генә бик әйбәт ишетелеп торган радиостанциян кинәт кенә тына да кала, радиодулкыннар үтми башлый. Алар, тауларга килеп бәреләләр дә, һич кирәкмәгән якка таралалар яки бөтенләй сүнеп калалар. Шуңа күрә як-яктагы радиостанцияләр бер-берсен ишетми. Мондый хәлләр таулар арасында, кайчагында хәтта тип-тигез далада да, көчле яңгырлар вакытында башка урыннарда да еш була. Бу хәлдән ничек тә чыгарга, шундый четерекле бер мәлдә дивизия штабы белән элемтәне ялгарга кирәк иде.

Барган килеш як-якка карана башладык. Бездән ерак та түгел, бер ягы чак кына сөзәкләнеп, икенчесе кырт текә булып күтәрелгән биек кыя тора. Соколов белән икебез дә шуңа текәлдек. Безнең исәп дивизияне кыяга менеп чакырып карарга иде.

Элемтә начальнигы да шуны чамалап килә икән. Тиз генә штаб начальнигы янына китте. Озак та үтмәде, ул дүрт автоматчы, атка

атланган тагын бер солдатны иартеп килеп тә житте. Колоннадан аерылдык та жыйнаулашып әлеге кыяга таба юнәлдек...

Радиостанцияне арбадан алып, упаковкаларның берсен Соколов, икенчесен үзем күтәреп, кыяның сөзәгрәк ягыннан үрмәләргә тотындык. Аннан-моннан чыгыбрак торган таш кисәкләрен искә алмаганда, тотынырлык бер нәрсә юк, кыя шәп-шәрә. Хәер, урыны-урыны белән ул мүкләнгән. Андый урыннары менү өчен тагын да хәтәррәк. Янгырдан соң мүк төпләре юешләнеп лайлаланган, таеп китәргә генә торабыз. Шулай да көч-хәл белән менеп життек. Аска карарлык та түгел, баш әйләнә. Без үрмәләгән арада полк байтак жир киткән иде. Инде 43 нче полк якынлашып килә.

Радиостанцияне ничек кирәк алай урнаштырып, дивизия штабын чакыра башладык. Дежурда Херувимов иде, бичараның шатлыгы эченә сыймый. Безнең позывнойны әйткәндә мине чак кына исемем белән атамыйча:

— Уборка, Уборка, Уборка, мин Аксиома, мин Аксиома, әйбәт ишетәм, бик әйбәт, Габ...! Син ничек, башкаларны да ишетәсеңме? — дип, беренче дәшүем белән тотлыга-тотлыга жавап бирде.

— Барын да яхшы ишетәм, сине Волга чакыра, радиограмма тапшырасы бар.

— Аңладым. Сиңа бирсен радиограммасын.

47 нче полктан радиограмма алып, шундук дивизиягә тапшырдык. Озак та үтмәде, жавап килде. Шуның белән бергә безне дә кисәттеләр: «Элемтәне өзмәскә!»

Шулай итеп, без кыя түбәсендә калдык. Башка полкларга дигән радиограмманы шуннан торып тапшырабыз. Үзебезгә дигәнен эченә таш төреп аска ыргытабыз. Аны баягы атлы солдат — элемтәче, «чатыр чабып» полк штабына илтә китә. Ә дүрт автоматчы безне саклап кыя янында постта тора. Радиограммаларны югарыдан гына ташлап утыруы ярый иде. Ә менә безнең полк штабыннан дивизиягә тапшыру өчен китерә башлагач, хәлләр авыраеп китте. Радиограмманы алырга я үзебез төшәргә, я булмаса кемдер меңгереп бирергә тиеш иде. Бу бик хәтәр нәрсә. Минүгә караганда төшүе читен. Беребез төшеп китсә, ике кулсыз калачаксың. Урнашкан жиребез тар, жайсыз. Бер-беребезгә тотышып кына диярлек торабыз. Шулай да Соколовка бер төшеп менәргә туры килде. Ничек башына килеп өлгергәндер, безнең турыдан узып баручы 43 нче полк элемтәчеләреннән кәтүкле телефон чыбыгы алып, шуны эләктереп менгән. Хәзер коедан су чыгарган кебек кенә эш итәбез. Чыбыкның бер башына таш бәйләп төшерәбез дә, полк штабыннан килгән радиограммаларны кәтүкне әйләндереп кенә менгерәбез...

Атыш тавышлары акрынлап тына, ерагая башлады. Бераздан ул бөтенләй диярлек туктады. Тик кайдадыр еракта, онытканда бер генә таулар арасыннан ишетелеп куйгалый. Ул арада дивизия штабы белән башка полклар арасында да элемтә урнашып өлгерде. Әллә инде дивизия штабы арадагы тауларны кичеп безгә якынлашты, әллә полклар үзләре икенче тауга күтәрелделәр?! Ничек кенә булмасын, бу безгә кыядан төшәргә вакыт житте дигән сүз иде.

Үзебезнекеләрне куа киттек. Ләкин арабызда әле 43 нче полк бар, аннан кала, безгә таныш булмаган тагын ниндидер частьлар юлны биләп бетергән. Ә юл тар, читкә чыгарлык түгел. Житмәсә төнлә башланып хәзергә кадәр өзлексез сибәләп торган янгыр юлны бөтенләй изрәткән.

Шулай, жае туры килгәндә узгалап, килмәгәндә чит колонналарга кушылып атлыйбыз. Көн бераз ачыла төште, кыялар да, юл биреп ике якка тайпылгандай, бездән ерагая, чигенә баралар. Һәм менә, тарлавык, бүрәнкә кебек кинәт киңәеп, үзәнлеккә алып чыкты.

Японнарның зур гына бер диверсия отряды безнең 47 нче полкка нәкъ шушы үзәнлеккә алып чыга торган тарлавык авызында засада оештырган булган. Ләкин бу алар көткән нәтиҗәне бирмәгән. Күрше авылдан ике кытай крестьяны, таулар арасыннан әйләнеп, полк каршына чыкканнар да засада турында хәбәр иткәннәр һәм самурайларның артларына төшү юлын күрсәткәннәр.

Бәрелеш кыска, ләкин каты булган. Японнарның күбесе үзәнлектә ятып калган, таулар арасына качарга маташучыларны тарлавыктан чыгып өлгергән артиллеристлар юк иткәннәр.

Әмма сугыш корбансыз булмый. Бу бәрелештә безнең якның да асыл егетләре башларын салдылар. Елганың каршы ягындагы калкулыкта яңа гына күтәрелгән туганнар кабере моның шаһите.

## Рәйхан

Безнең Хинганга аяк басу көннәре монда каты яңгырлар башлану чорына туры килде.

Чүл ягыннан Хинганга якынлашканда истә калган бер күренеш хәзер дә хәтердән китми. Таулар арасындагы кысынкылыкка түзә алмыйча алгарак чыгып утырган кебек бик биек бер кыя тора. Түбәсенә кечкенә генә ак болыт кунган. Ерактан караганда кыя, сәләмә чапанын киеп, башына чалма ураган бер дәрвишне хәтерләтә. Әйтерсең лә ул, чүл кырыена чүгәләгән дә, табигать күрсәткән шушы гаделсезлекнең серләрен төшенергә теләп тирән уйга чумган.

Ә монда... Монда менә ничәнче көн инде тоташтан яңгыр коя, ничәнче көн инде коры җиргә яткан, коры кием күргән юк. Көннәр коры торганда атлап та чыгарлык вак-вак елгалар кинәт бүртеп, ярларына сыеша алмыйча тау үзәннәренә җәелделәр. Урыны-урыны белән сутлы балчыктан гына торган тау юллары тоташ тайгакка әверелде. Аннан узу өчен зур саклык, зур тәвәккәллек кирәк. Югыйсә, тау тотмас атларның алдагы йөкләргә, кешеләргә бәрелеп үкенечле хәлләр тудыруы ихтимал. Чөнки юл кара-каршы узгысыз тар. Шуна күрә андый урыннарда солдатлар атларны йөге-ние белән кулларда диярлек күтәреп менгерәләр.

Әнә шундый бер тауны төшеп, икенчесенә якынлашып килгәндә, әчке моң белән сугарылган көр тавышлы берәүнең «Рәйхан» көенә салмак кына, өздереп кенә җырлаганы ишетелде.

Аклы ситсы күлмәгемнең
Якаларын кем уйган...

Җыр бер төрлерәк гаскәри тормыштан, авыр походларда йөреп кырыслана төшкән солдат күңелләрен иркәләп, сыйпап, гасырлар шаһите чал кыяларга килеп бәреләдә таулар арасына китеп югала, коеп яуган яңгыр тавышына кушылып эри иде.

Җыр барган саен якыная, ачыграк ишетелә башлады. Ниһаять, тау итәгендә утлап йөрүче ике ат, читтәрәк йөкле фургон һәм аның бердәнбер тәртәсен күтәртеп корылган ялгыз палатка күренде. Палатканың як-яклары ачык. Астында дүрт-биш солдат утырган. Җыр тавышы әнә шуннан ишетелә.

Артына безнең радиостанция куелган ике көпчәкле арба башында бер аягын салындырып, икенчесен астына бөкләп утырган килеш әсәрләнеп тыңлап килгән олаучы Сарсынбаев түзмәде, палатка ягына ымлап:

— Карасаншы, ногайдың баласын, өленде кандай жаксы айтады, Сәүленде сагындыңба!? — дип кычкырды.

Әйе, бу 43 нче полктан пулеметчы, ә сугыштан соң танылган жырчы булган Габделхак Шаһиев иде.

Габделхак белән без Казандагы 80 нче мәктәптә бергә укыдык. Ул чагында ук инде без аны мәктәп сәхнәсеннән, озын тәнәфес вакытларында куела торган концертларда бик яратып тыңлый идек. Озак та үтми, сугыш башланды. Һәм без — ул чагында әле туп тибеп, сугыш уеннары уйнап йөргән малайлар — хәзер менә үзебез дә чын солдатлар булып, күз күрмәгән, колак ишетмәгән Хинган тауларына барып чыктык.

Сүз уңаенда әйтеп үтим, без, 1943 елны Казанда тупланган бер эшелон егет, барыбыз да Монголия Халык Республикасына, бер дивизиягә килеп төштек. Өстәвенә тагын биредә Ватан сугышы башланганчы ук алынган татар егетләре дә байтак булып, күп кенә роталар, взводлар яртылаш диярлек татарлардан тора иде.

Белмим, Габделхак үзе кемне сагынып моңайгандыр, әмма аның ягымлы, саф тавышы сугышчы күңеленең иң нечкә кылларын чиртеп, азга гына булса да юл газапларын онытгырып, уйларны туган-үскән якларга алып китте, илдә вакытта оялып әле сүз дә кушарга өлгермәгән, шуңа карамастан, йөрәк түрендә саклап, хыялый бизәкләргә төреп йөрткән «ярлар»ны искә төшерде, әйтеп аңлата алмаслык тирән хисләр уятты. Жырның теле уртак бит аның, ул тәржемәсез дә яхшы аңлашыла.

Әнә Сарсынбаевның да күңеле нечкәрде булса кирәк, атларына берике тапкыр чөңгереп дилбегәсен каккалады да жырлап ук жибәрде:

Поезд келед ыжгырып,
Чуен жолды кыздырып,
Озактамай без кайтамыз
Самурайды тоздырып.
О дәрига,
Самурайды тоздырып...

Сарсынбаевның жырын бүлдерделәр. Алда юл янтая башлаган иде, кемдер:

— Әй, дәрига, син үзең анда яр астына тузгыма, атларыңны яхшылабрак тот! — дип кычкырды.

— Үзеңде бел, штыгыңа карга кунган, пилоткаңны алып кэтпесен...

Колонна килеп житкәндә, Габделхаклар, палаткаларын жыеп, атларын жиккән килеш, безне көтеп торалар иде.

— Сез нәрсә, егетләр, сайранга чыктыгыз мәллә?

— Әй, малай, сорама инде, типте бия тәртәгә. Бер атыбыз аргач алыштырып караган идек тә уңмадык. Жигелеп өйрәнмәгән, күрәсең, армый да, бармый да. Үзебезнекеләрдән калдык. Привалга кадәр сезнең белән барырга куштылар...

## Мин оялмадым

Пулеметчылар ротасында Кәрим исемле бер егет бар иде. Армиягә кадәр ул итекче булган. Шуңа күрә аны ара-тирә камыт-һяр кебек нәрсәләр төзәтергә дип сбруйлар мастерскоена күчергәлиләр. Менә шул якташыбызның сәер генә гадәте бар иде. Чак кына буш вакыты булдымы, кешеләрдән читкә китеп утыра да, күзен йомып, әллә йокымсырый, әллә инде уйга чума. Кайчагында үзеннән:

— Әллә авырыйсыңмы соң син, якташ? — дип кызыксына идек.

Ә ул, сүзне озайтмыйча:

— Юк, болай гына,— дип жавап бирә.

Әнә хәзер дә, солдатлардан читкәрәк китеп, үзенең пулеметы куелган фургон көпчәгенә аркасын терәгән дә күзен йомып тын гына утыра. Шул чагында арадан берәү:

— Егетләр, Кәрим Нәвем базарына китте, йокы бүген кыйммәт тора микән, уятып сорыйк әле,— дип Сәлимовка таба борылды. Ә тегенең исендә дә юк. Күзен йомган килеш дәшми-тынмый утыруын белә. Шуннан соң теле тиктормас баягы солдат тагын тотынды:

— Карале, Сәлимов, әллә син теге ефрейторның туганымы?

Бу юлы инде Кәрим, күзен ачып:

— Кайсы ефрейтор? — дип сорап куйды.

— Ник, белмисеңмени?.. Егетләр, сөйлимме, тач безнең Сәлимов инде, аның шикелле шорник та булган әле ул...

— Менә шулай. Булган ди бер ефрейтор. Кая гына куймасыннар, һаман йоклый икән бу. Старшина аптырап беткән моның белән. Ләкин үзе ничектер сәбәбен, җавабын таба икән бит, каһәр: «Юк, йокламыйм, я эчем, я башым авырта, ятып кына торган идем, фәлән-төгән, фәсмәтән», дип аклана икән. Шулай, кәнүшнидә дежур торган бер төнендә тагын килә моның янына старшина. Карый: йоклый бит бу, утырган җиреннән гырылдап йоклый. Тукта инде, бу юлы аклана алмассың дип, чөйдән бер камытны ала да кидертә тегенең муенына. Кидертә дә кычкыра моңа:

— Ефрейтор, ник йоклыйсың?!

Ә ефрейтор күзен ача да:

— Уйлаганым да юк, иптәш старшина, камыт төзәтәм,— ди.

— Ишетәсеңме, Сәлимов, тапкыр икән ләбаса туганың, шуннан өйрәнергә иде сиңа. Югыйсә...— дип көлешә башладылар. Бу юлы Кәрим үзе дә башын артка ташлап рәхәтләнеп көләргә тотынды...

Ул арада дивизия штабыннан радиограмма тапшырдылар. Шуны тотып штаб начальнигы янына киттем. Эчтәлеге шундый иде: «Аеруча әһәмиятле һәм чиктән тыш ашыгыч. Армиянең алдынгы отряды Уданьчэн шәһәре тирәсендә каты сугышлар алып бара. Бөтен полкларга да темпны арттырырга!» — дигәннәр.

Җыена башладык. Ләкин күп кенә атларның моңарчы килгән темп белән дә бара алмаулары мәгълүм булды. Казылмалы, ташлы, тайгак юлдан атлап кайсысының тояклары бозылган, кайсылары я бәрелеп, яисә егылып аякларын имгәткәннәр. Хәзер генә алыштырырга башка атлар юк. Йөкләрен дә киметеп булмый. Чөнки калган атлар үзләре дә көч-хәл белән киләләр. Шуна күрә эштән чыккан атларны, арып хәлдән тайган солдатларны барлап, аерым бер колоннага тупладылар. Алар, әлеге тау итәгендә тагын бераз ял итеп, озын привалга чаклы үз җайлары белән генә полк артыннан барачаклар. Колоннага баш итеп штаб офицерларыннан берәүне билгеләделәр дә, аның карамагына автоматчылар отделениесен һәм расчетлары белән ике пулемет калдырып, полк тагын кузгалды. Якташыбыз Кәрим Сәлимов та пулеметы белән әлеге колоннага эләкте.

Шул ук юл, шул ук газап. Күкнең төбе тишелгән диярсең. Янгыр бер генә минутка да туктамый. Әле вагы, әле эресе сибеп кенә тора. Менә атларның тагын байтагы бармас булды. Ат түзмәгәнне солдат түзә. Пулемет станоклары, патрон тартмалары һәм башкасы пот өстенә пот булып аның җилкәсенә төште...

Тауны менеп тау төштеңме, елгага килеп чыгасынны көт тә тор. Кайсы билдән, кайсы күкрәктән. Һәр җирең болай да лач су булуга карамастан, һич керәсе килми. Хәзер әнә тагын бер елганы кичәсе бар. Солдатлар шунда да әле:

— Саграк, чылана күрмәгез,— дип шаяртырга чамалыйлар.

Алай да уеннан уймак дигәндәй, кайвакытта күңел күтәрә торган бер шуклык эшләп ташлыйлар. Әнә икәү сөйләшеп киләләр:

— Карале, кем, әйдә бу юлы син мине күтәреп чык. Киләсендә чират минеке булыр.
— Нигә, була ул. Тик үземә генә авырга туры килер, әнә Новиковны да алыйк компаниегә. Ризамы, Петя?
— Соң инде... Риза.
Һәм менә, елгага ун-унбиш адым кала ук, беренче булып башлаган солдатны икәүләп күтәреп тә киттеләр. Әмма суга керәбез генә дигәндә:
— Юк, авыр икәнсең, бар, автоматың белән капчыгыңны берәрсенә биреп тор,— дип, кире төшерделәр.
Тегесе болар кушканны үтәп тагын килде.
Елга уртасына гына җиткәннәр иде, сүз куешкандай, тоттылар да егетеңне суга ташладылар. Бичара күздән үк югалды. Елга өстендә плащ-палаткасының итәкләре генә чайкалды. Аннары үзе дә калкып, солдатларның шау-шуы, шаркылдап көлүләре астында, кулларын йодрыклап нәрсәдер кычкыра-кычкыра, елганың икенче ярына чыгып җитә язган иптәшләре артыннан китте...
Уданьчэнга караңгы төшкәндә генә барып җиттек. Ләкин анда инде безгә эш калмаган иде. Японнар, армиянең танклар, үзйөрешле орудиеләр белән көчәйтелгән алдынгы отряды кысрыклавына түзә алмыйча, күп кенә мәетләрен, яралыларын ташлап, Чифын шәһәренә таба чигенгәннәр.
Менә Уданьчэнны да уздык, тигезлек башланды. Атнага якын туктаусыз яуган яңгыр да, ниһаять, тыйлыга төште һәм акрынлап бөтенләй туктады. Гаолян, чумиза, кукуруз кырлары аша сузылган пычрак юлны изә-изә салмак кына атлыйбыз. Караңгылык һаман куера бара. Бүген узган юл кырык биш чакрым булды, диләр. Туктарга да вакыттыр инде. Ләкин үзәнлеккә чыкканга хәтсез вакыт узды, ә колонна башыннан зарыгып көтелгән «Привал!» командасы һаман ишетелми. Винтовка каешларының, капчык һәм противогаз тасмаларының иңбашларны рәхимсез каезлавы гына җитмәгән, тирә-юньне чолгап алган караңгылык та гүя күтәрә алмаслык йөк булып җилкәләргә, күз кабакларына баса, аякларга уралып адымнарны барган саен авырайта кебек. Алгы сафтагыларның берәрсе йокымсырап килгән җиреннән сөртенеп, арттагылары аның өстенә авардай булып сөрлегәләр дә, теге бичара, үкчәләренә басуга түзә алмыйча, сафтан йөгереп чыга. Моны күргән солдатлар: «Ну, чыдам да соң үзе, арунын ни икәнен дә белми, йөгереп кенә бара», «Төшендә җанашын күргән ул, кавышырга ашыга», дип көлешәләр...
Ниһаять, иген кырлары бетеп, полк тагын үргә күтәрелә башлады. Озак та үтмәде, кайсы батальонга юлдан кайсы якка кереп төн кунарга икәнлеген белдергән тансык командалар ишетелде. Батальоннар шундук, үзләренә күрсәтелгән якка борылып, тау итәгенә сибелә бардылар. Менә соңгы роталар да урнашып бетте. Палатка чабуларын беркетеп казык каккан, атлар пошкырган һәм поход кухнялары янында котелоклар шалтыраган тавышлар тынды. Сакчыларны, дежур офицерларны искә алмаганда, полк тирән йокыга чумды...
Колак төбендә генә Соколовның дивизия штабы белән сөйләшүенә уянып киттем. Ул мин уянганны сизде, ахры:
— Командир (уенын-чынын бергә кушып, ул мине шулай дип йөртә), радиограмма бар, штабка илтәсе иде,— дип, телефон колакчыннарын кигән башын минем якка борды. Изрәп йоклап яткан связьнойны уятып тормадым, радиограмманы тотып палаткадан чыктым.
Һәр яктан таулар белән уратып алынган тигез үзәнлеккә җәелгән иген кырларын, әйтерсең, алтынга манганнар. Каршы якта, сыек зәңгәр томанга төренгән тау тезмәләренә җитәрәк, йөзек кашын хәтерләтеп түгәрәк күл ялтырый. Кояш, зәңгәр күккә ашкан таш кыялар

артыннан баш калкытып, мәңге шушы юлдан күтәрелсә дә, бу хозурны әле беренче кат күргәндәй хәйран калып, үзәнлекне күзәтә. Анда уракка төшкән кытайлар бала-чагалары белән гөж киләләр. Үз куллары белән игеп, җан тирләрен түгеп үстергән дөгене ашаган өчен дә авыр җәза көтеп яшәгән әлеге кытайлар өчен туган җирләре өстендә шулай балкып аткан беренче таң, беренче көн иде бу.

Кытайлар бүген иртә уянганнар, баш та күтәрмичә дәртләнеп эшлиләр. Кичәге походның ни өчен шулай чамадан тыш озакка сузылганын мин шунда аңладым. Өлгергән игенне таптатып, болай да ач халыкның соңгы өметен өзмәс өчен, төнге ял кичектерелеп, үзәнлекне узганчы барганбыз икән.

Күз алдымнан кара җиргә калдырганчы японнар таптаткан иген кырлары, җимерек фанзалар, гаурәтләре генә капланган кытай картлары, шыр-ялангач ябык балалар узды. Узды да, үзебезнең газиз Совет Армиясе, аның изгелеге, кешелеклелеге өчен күңелем горурлык һәм чиксез шатлык хисләре белән ташып, күзләремнән яшь бөртекләре тәгәрәде. Алар меңнәрчә чакрымнар атлап талчыккан аякларым очына тамдылар. Әмма мин солдат булганнан бирле беренче һәм соңгы мәртәбә тамган бу саран яшьләремнән оялмадым.

## Якташлар

Радиограмманы илтеп штабтан кайтып киләм. Кояш чыкканга инде байтак узса да, халыкны әле һаман күтәрмиләр. Күрәсең, кичәге марштан соң озаграк ял иттерәсе булганнардыр. Шулай да палаткаларыннан чыгып кояшка битләрен, аркаларын куеп кызынып утыручы солдатлар күренгәли. Әнә безнең палатка белән янәшә генә урнашкан телефонистлар взводыннан да дүрт-биш солдат чыккан. Үзәнлектә кайнашкан кытайларга карап әкрен генә сөйләшеп утыралар:

— Бездә дә хәзер урак өсте бит инде, ә, егетләр,— ди берсе.

— Их, киерелеп торып бер эшлисе иде, ат урынына, арыганчы,— дип куәтли аны икенчесе.

Өченчесе боларга карап көлде дә:

— Ник, аруыгыз җитмәдемени әле? — дип куйды.

Шуннан китте инде, һәркем үзенчә сүз кыстыра:

— Бу ару арумыни, алҗу ич бу!

— Чыгып китәсең бер заманны кырга... Кара инде боларныкын, кырмыни бу. Кызып җиттем дигәндә генә тауга барып төртеләсең.

— Кичә алай бик тиз килеп төртелгән кебек күренмәдең үзе, телең асылынган иде.

— Кичә бит ул...

— Арбага кырын ятасың да... Баш өстендә тургайлар сайрый!..

— Менә монысы кантарлы ялган инде. Бу вакытта тургай сайрамый шул.

— Син үзең кантарлы. Тургае булмаса, чикерткәсе бар аның. Билләһи, малайлар, миңа хәзер үзебезнең тургайлар да, чикерткәләр дә бер. Бакаларына хәтле тын да алмый тыңлар идем.

— Бакалардан бигрәк Мәстүрәңне сагынмадың микән? Хаты да күренми бугай бу арада... Кайткан солдатлардан берәрсе эләктергәндер әле.

— Хат ул, брат, аяксыз. Син әнә аякларың белән дә чак кына киләсең. Болай да бик үк туры түгелләр иде, хәзер бөтенләй камыт булып беттеләр. Ә Мәстүрәгә килгәндә, син инде, брат, борчылма, безнең сүз куешкан, ди аңар Әхмәт исемле бу егет.

Ул тагын нәрсәдер әйтергә җыенып авызын ачкан иде дә, үзәнлек

уртасыннан килгән колоннага күзе төшеп, туктап калды. Бүтән солдатлар да шул якка текәлделәр.

— Егетләр, безнекеләр түгелме соң болар?

Бу, чыннан да, кичә полктан аерылып калган безнең колонна иде. Бик акрын атлыйлар. Каршыларына барасы иде дә, тик әле подъем да булмаган, икеләнебрәк калдык. Юлның азагында бер адым атлавы да ай-һай зур газап. Моны һәркайсыбыз татыган. Шуңа күрә ни булса ул дидек тә унбишләп солдат колоннага каршы йөгердек.

Иптәшләрне танырлык та түгел, талчыкканнар, сүрәннәр. Үзләрен дәртләндерергә тырышып:

— Менә ичмасам пехота, тәгәрәп кенә килә! — дип шаяртуыбызга да җавап бирүче булмады.

Без дә, нидер сизеп, кинәт тынып калдык. Йөкләрен бүлешеп барган килеш алгы сафтагылардан ни булуын сораштыра башладык.

— Әнә арткарак калыгыз, күрерсез,— дип кенә җавап бирделәр.

Юлдан читкә чыктык та арттагыларны көтәбез. Элек җәяүлеләр узды. Аннары башлары, куллары бәйләнгән яралылар утырган арбалар килеп җитте.

* * *

Атларны ял иттергәч, полктан аерылып калган «хәлсезләр» командасы да юлга чыга. Яңгыр, пычрак. Юл, туктауны белмәгән бу яңгырдан тәмам туеп, ышыкланыр өчен үзенә керер урын эзләгән елан төсле, тау тирәли бормалана-бормалана да, кинәт тураеп, тараеп, уелган кыя яныннан шуыша башлый. Аның һәр борылышын, һәр сыгылышын кабатлап, ялгыз колонна килә. Артта калырга һичкемнең хакы юк, ялгызлык дигән нәрсә кешеләргә җитдилек өстәгән. Колонна хәзер кысылган пружинаны хәтерләтә. Ә илле солдат, аның илле бөҗрасы кебек, һәркайсы үзендә аерым бер көч, аерым бер киеренкелек туплаган.

Уңда — таш кыя, сулда, юлдан байтак аста — ургылып, болганып аккан елга. Көннәр коры чакта үзәнлек уртасыннан сабыр гына, юаш кына үрмәләгән бу инеш хәзер як-яктагы тау итәкләренә хәтле җәелгән дә дөньяны шаулата, күңелләргә шом сала. Тирә-юньдә беркем юк. Үзәнлектәге калкулыкларга сырышкан кытай авыллары да, камыш эшләпәләре астына яшеренеп, тирән уйга чумганнар.

Юл һаман тарая, хәтәрләнә бара. Күп җирдә аның кырыйлары ишелеп, чак кына узарлык булып калган. Андый урыннарда йөкләр кыяга сыенып, ышкылып кына үтәләр. Урыны-урыны белән кыя юлның өстендә үк диярлек асылынып тора. Менә-менә җимерелеп төшәр төсле. Бара-бара ул кинәт кенә борылыш ясый да елгага кереп китә. Әмма аны кичәргә батырлыгы җитмәгәндәй, ярты юлда туктап кала. Нәкъ шул җирдән ялгап тар гына күпер салынган. Тар булса да җәяүлеләр, атлылар йөрү өчен бик ярый. Аңа житәрәк бер урыннан танклар төшәргә сөзәклек ясаганнар. Кырыена багана утыртып такта кадаклаганнар да «кичү» дип язып куйганнар. Ләкин бу кичү, күрәсең, бик җайлы булмагандыр. Елганың уртасына житәр-житмәс батып калган Т-34 танкы шул турыда сөйли. Хәзер аның башня түбәсе белән туп көпшәсе генә күренеп тора.

Күпергә элек колонна башында килгән җигүле атлар керә. Беренчеләренә инде чыгып китәргә дә күп калмый. Һәм менә, һич көтмәгәнчә, кыя артыннан ату тавышы ишетелә. Алдагы фургонга җигелгән пар атның берсе шундук егыла. Башкалары да туктап калалар. Ат тотып баручылар аны-моны абайлап өлгергәнче кыя артыннан тагын атарга тотыналар.

Хәзер күпергә үтәрлек түгел. Анда кереп калган олаучылар да, атлары дулаганлыктан, утка каршы ут белән җавап бирә алмыйлар.

Шул вакыт атлар, арбалар өстеннән сикерә-сикерә, яшен тизлеге белән күпернең икенче башына бер солдат уза. Менә ул алдан өченче булып кергән фургонга атылып төшә дә корулы пулеметка ябыша һәм кыя артына төзәп ут ача: андагылар бер мәлгә тынып калалар. Шуннан файдаланып күпергә тагын берничә солдат кереп өлгерә. Хәзер алар да ата башлыйлар. Әмма безнең пулемет кинәт туктап кала. Ул да түгел, пулеметчы сикереп тора да, кулларын алга сузып, күпернең култыксасы аркылы башы белән суга ташлана. Шул секундта ук, нидер акырып, кыя артындагы ташлар арасыннан бер самурай күтәрелә дә, күпергә таба муенын сузып, катып кала. Аннары кинәт сискәнеп күкрәгенә ябыша да таш өстенә каплана.

Озак та үтми, күпернең икенче ягында суга ташланган пулеметчы күренә. Ул бер калка, бер бата. Агым шундый көчле булуга карамастан, үзе һаман бер урында. Аны нидер тота кебек. Һәм менә ул, кинәт кенә кузгалып, элеккечә үк бата-калка ага башлый. Әллә йөзә белми, әллә инде яраланган, агым белән тартышуы, ярга таба омтылуы сизелми. Моны күреп ярдан ике солдат сикерә һәм:

— Сәлимов, браток, бераз түз! — дип аңа каршы кыеклатып йөзәргә тотыналар.

Боларны да агым әләктереп ала. Шулай да, ничек кирәк алай, Сәлимовка якынлашалар. Әмма үзләренең дә хәлләре беткән. Хәзер өчәү бергә агалар. Ә су тирән, елганың нәкъ үзәге. Су өстендә инде аларны бары тик агым гына тотып тора. Шул чагында ярда калган солдатлар:

— Сулгарак, сулгарак, танкка таба йөзегез! — дип кычкыра башлыйлар.

Судагылар әллә шуны ишетеп, әллә инде үзләре күреп, актык көчләре белән танкка таба ыргылалар һәм, менә-менә читләтеп узабыз дигәндә генә, берсе туп көпшәсенә, икенчесе башня түбәсенә тотынып өлгерәләр.

Ул арада күпердәге пулеметка кабат җан керә. Аңа Кәримнең иптәше, икенче пулеметчы Соловьев барып житкән була. Кыя артыннан хәзер анда-санда гына җавап бирәләр. Ә бераздан соң ату тавышлары ул якта бөтенләй тынып кала. Шулай да сак булырга кирәк. Ике солдат күпернең кыяга тоташкан турысыннан елга кырыена сикерәләр дә японнар яшеренгән урынга шуыша башлыйлар. Анда элеккечә үк тынлык. Тик берсенең ара-тирә ыңгырашуы гына ишетелеп куя. Күтәрелеп таш артына күз салалар — биш җирдә биш япон солдаты аунап ята. Бая күпергә таба муенын сузып катып калган теге самурайның аяк очында гына өстенә түгәрәк тотка сыман нәрсә беркетелгән әрҗә тора. Аның бер ягына изоляцияләнгән чыбык тоташтырылган. Ул ташлар арасыннан елгага кадәр сузылган да суга кереп югалган.

Шундый кискен бер вакытта пулеметын калдырып, Сәлимов менә ни өчен суга ташланган икән. Атып ятканда ул күпер астыннан кыя артына таба суга тияр-тимәс кенә булып сузылган чыбыкны күреп ала. Пулеметчы аның бер очы шартлаткычка тоташканлыгын белә һәм дошман кнопкага басып өлгергәнче дип чыбык өстенә сикерә. Чыбык, шартлаткычтан ычкынып, Кәрим кулында кала. Башта ук агып китмичә тоткарланып торуының сәбәбе шунда була. Әмма ул күпердән ташланган вакытта ук инде яраланып өлгерә...

* * *

Юл кырыена чыгып баскан хәлдә, яралылар артындагы олауны көтәбез. Менә ул да якынлашты. Өстенә плащ-палаткалар ябылган. Читтән караганда бөтенләй буш кебек тоелган фургонны, аның янын-

нан башын иеп нәүмиз генә атлаган олаучы солдатны күреп барысын да аңладык. Авыр йөк, авыр хәсрәт төялгән арба иде бу. Анда безнең дүрт иптәшебез, бергә утны-суны кичкән дүрт дустыбыз ята. Һәркләренә әле пәке дә тиеп өлгермәгән, шуңа карамастан солдат тормышының бөтен авырлыкларын татып өлгергән унтугыз яшьлек бу егетләр күзләрен мәңгегә йомганнар. Йөзләре тыныч: әйтерсең лә, алар үлмәгәннәр, әйтерсең лә, алар чиксез зур, чиксез авыр эш башкарып арыганнар да, хәзер инде менә тирән йокыга талганнар. Арбада яткан дүртәүнең берсе Кәрим Сәлимов та гадәтенчә күзен йомып уйга гына чумган төсле. Буш вакыты булган саен, күзен йомып, уйланырга яратучы якташыбыз кукрәгендә әнә нинди арыслан йоклаткан икән!

Әхмәт дусының мангаеннан, бигеннән сыпырып, йөзен яңадан плащ белән каплады да олаучы солдат янына килде. Тегесе аңа күтәрелеп:

— Юлда үлде,— диде.

Арттарак тагын бер фургон килә. Анда да кемдер ята. Өстенә шулай ук плащ-палатка япканнар. Бите ачык, башы бәйләнгән.

— Монысы кем? — дибез.

— Шунда ук дөмектерәсе иде дә бит, лейтенант кушмады, ди олау хуҗасы.— Болай да чыкмаган жаны гына калган иде инде. Хәзер ярыйсы бугай. Егетләрне харап иттеләр, бәдбәхетләр...

Хәле авыр булса да, япон солдаты әле үләргә җыенмый иде. Врачлар карап, яңадан ярасын бәйләгәч, тагын да җанланыбрак киткәндәй булды. Тәрҗемәче аркылы сораштыра башладылар:

— Ничә күпер шартлаттыгыз?

— Соңгысы белән өч буласы иде.

— Нигә шундук шартлатмадыгыз?

— Элек солдатларыгызны кырып бетермәкче идек.

— Ә чыбыкны ник яшермәдегез?

— Өлгермәдек, колонна килеп җитте.

— Император Хирохитоның белдерүе сезгә мәгълүмме?

— Ишеттек.

— Ни өчен корал ташламыйсыз?

— Ул турыда приказ булмады.

Сугышта җиңелүләрен дошманның хәзер солдатлары да аңлаган. Күпер шартлатырга җыенучы үлемдарлар төркеменнән булган әлеге самурай да, гәрчә үзен күптән инде «теге дөнья» кешесе дип санап йөрсә дә, хәзер әнә бу дөньяга чытырдап ябышкан. Һәр сорауга иплән кенә, карышмыйча җавап бирә.

— Шартлаткычларны, сугыш припасларын кайдан аласыз?

— Таулар арасында яшерен базабыз бар иде.

— Ә хәзер?

— Хәзер белмим, аннан чыгуыбызга бүген өченче көн.

— Карта таныйсынмы?

— Разведчиклар мәктәбендә укыдым...

Әсирне сөяп утырттылар да алдына карта җәеп салдылар. Ул аңа бик озак карап торды. Тик шуннан соң гына калтыранган бармагы белән бер урынга төртте.

Бу турыда радио аша шундук дивизия штабына хәбәр иттек. Әлеге базаның озакламый көле күккә очасына бернинди шигебез юк иде.

## Күршеләр

Фашистларның ерак тылларына үтеп, коммуникацияләрен туздырып йөргән атлы армия, аның легендар командующие Исса Александрович Плиев турында Совинформбюро хәбәрләре аркылы да, болай да күп нәрсәләр ишеткәнебез бар иде. Хәзер менә шул армия, Монго-

лия Халык Республикасы гаскәрләре белән берлектә, бездән уң яктарак, күршедә генә һөҗүм итә. Шуңа күрә аларның кайбер частьлары белән юлларыбыз да кисешкәли, әледән-әле хәбәрләшеп тә торабыз.

Әле күптән түгел генә Плиев житәкчелегендәге шушы атлы армия группасының Жэхэ шәһәрен алуы турында ишеткән идек. Бу хакта солдатлар арасында ниләр генә сөйләмәделәр. Имеш, командующий үзенең адъютанты, тагын берничә солдат һәм күпмедер офицер белән шәһәргә барган да, ди, японнарның ун меңнән артык солдаты булган бөтен бер гарнизонын капитуляция ясарга мәҗбүр иткән, ди...

Бу вакыйга, аның турындагы имеш-мимешләр хәтергә ничектер бик нык сеңеп калган иде. Ә чын хәлне мин бары тик егерме елдан соң, Исса Александровичның мемуарларын укыгач кына белдем.

...Текә кыялар тирәсеннән, төпсез упкыннар өстеннән бормаланган юлларны өч-дүрт көн буена туктаусыз коеп яуган яңгырлардан соң күз алдына китереп карагыз! Ә аның әле туктарга исәбе юк, тагын ике-өч көн явар, бәлки. Юллар, атлаган саен очрый торган эреле-ваклы күперләр, кичүләр, барысы да диярлек юылып, җимерелеп беткән. Бу вакытта җирле халыклардан берәү дә Хинган юлына чыкмый. Шуңа күрә японнар Совет һәм Монголия Халык Республикасы гаскәрләренең яңгыр чорында гына түгел, ә ул узгач та әле, һич югында, бер атнасыз да Жэхэ шәһәренә килеп җитә алмаячагына исәп тоталар. Әмма Плиев бернәрсәгә карамыйча һөҗүмне дәвам иттерергә приказ бирә.

Гаскәрләр икегә бүленеп, икесе ике «юлдан» китәргә һәм өченче көнне таң атканда берсе шәһәргә көньяк-көнбатыштан, икенчесе төньяктан килеп чыгарга тиеш булалар. Ә турыдан алдынгы отряд сыйфатында 129 нчы полк һәм кайбер башка частьлар китә. Ләкин беренче эшелонда һөҗүм итүче дивизияләрнең төп көчләре билгеләнгән урынга тиешле вакытка килеп җитә алмыйлар. Инде таң атып килә, акылга сыймаслык шундый авырлыклар белән отылган вакытның әрәм булуы бар. Шул чагында командующий тәвәккәл бер карарга килә: кул астындагы барлы-юклы көч белән булса да атака ясарга һәм, дошман сизенеп өлгергәнче, шәһәргә кереп, гарнизондагы частьларны аерым-аерым корал ташлатырга!

Хәлне ачыклап кайту өчен, генерал үзенең адъютанты капитан Семенидо белән майор Шведовны әле күптән түгел генә шәһәр тирәсенә киткән алдынгы отрядка җибәрә. Алар китеп берничә минут үткәч, оператив группа белән Плиев үзе дә кузгала. Үзәнлеккә төшеп борылышны узгач та, каршыларында Жэхэ шәһәре пәйда була. Аңа кадәр әле ике-өч чакрым бар, шулай да бинокльдән караганда кырый урамнар аермачык күренә. Берсе аркылы әнә япон подразделениесе чыгып бара. Кая ашыгалар алар? Шәһәр халкыннан нигә берәү дә күренми?

Ә алдынгы отряд... Ул кайда соң? Командующий борчылып юлны күзәтә башлый. Ләкин полк беркайда да юк. Әллә инде шәһәргә үк кереп киткәннәрме?.. Ә монысы тагын нәрсә?

Генерал үзләреннән ерак түгел генә кулларын болгый-болгый ни турындадыр бик кызып сөйләүче кешеләр төркемен шәйләп ала. Әмма алар куак артында, юньләп күренмиләр. Шулай да Плиев боларның Маньчжоу-Го гаскәрләре формасына киенгән солдатлар икәнен таный. Шунда ук куаклар арасыннан «виллис» машинасы күренеп тора. Әллә инде Шведов белән Семенидо пленга төшкәннәрме, бу бит алар машинасы?!

— Тизрәк алга!..

Килеп җитсәләр, коралланган маньчжурлар арасында чыннан да безнең офицерлар!

Төркемнән аерылып, Семенидо командующий янына ашыга.
— Ни булды, бу нинди кешеләр?
— Юлда очраттык, иптәш командующий, Жэхэдан килешләре. Японнардан качтык, — диләр.
— Алдынгы отрядта булдыгызмы?
— Өлгермәдек. Кая киткәннәрдер, һич белер хәл юк.
Шуннан соң Плиев та маньчжурлардан сораштыра башлый:
— Безнең полкны күрдегезме? Ул шәһәргә кермәдеме?
— Юк, юк, рус полклар юк, без күрмәдек,— диләр солдатлар.
Гаҗәп. Кай арада югалды соң бу алдынгы отряд? Бәлки, инде шәһәргә үк кергәндер?
Плиев, һөҗүмне тизләтсеннәр дип әйтергә кушып, 59 нчы Совет дивизиясенә бер офицерны җибәрә дә үзе алдынгы отряд артыннан Жэхэга китә.
Озак та үтми, оператив группаның берничә машинасы шәһәр кырыендагы тар урамга килеп керә. Шәһәр капкасы янында бер винтовка, бер кул пулеметы аунап ята. Аларны, күрәсең, әле хәзер генә ташлаганнар, өсләренә тузан да кунып өлгермәгән. Әнә кулларына тасма бәйләгән ике япон солдаты килә. Патрульләр булса кирәк. Совет сугышчыларын күрү белән аларның төсләре китә, ә куллары әкрен генә югары күтәрелә.
Шул арада якындагы ишек алдыннан бер солдат атылып чыга. Ул:
— Туктагыз! — дип Плиев утырган машина янына йөгереп килә дә:
— Иптәш командующий, шәһәрдә япон частьлары. Алар шәһәр читендәге крепостьта. Безнең разведчиклар шәһәр үзәгенә барып кайттылар, япон дивизиясе штабы шунда урнашкан,— ди.
— Алдынгы отряд кайда?
— Без, иптәш командующий, дивизия разведкасыннан, алдынгы отряд турында белмибез.
Плиевның күңеленә шик төшә һәм ул торган саен көчәя бара. «Әгәр дә алдынгы отряд үзенең дивизия командирыннан яңа приказ алып шәһәрне көньяктан урап киткән булса?».
Чигенергә инде барыбер соң, кыю һәм тәвәккәл бер чара күрергә кирәк. Командующий машинасын туктата да адъютантына гарнизон штабына бара торган юлны белешергә куша.
Капитан Семенидо белән тәрҗемәче, машинадан чыгып, әле һаман да кулларын күтәреп торган теге ике патруль янына киләләр. Японнар бик озак һәм буталчык итеп маршрутны аңлатырга тотыналар.
— Үзегез белән алыгыз,— ди командующий моны күреп,— шулай ышанычлырак булыр.
Машиналар тагын кузгалып китә. Урамнарда шомлы тынлык, менә-менә нидер булыр кебек.
Ниһаять, почмаклары югарыга таба бөгелгән чирәп түбәле бер йорт янына килеп туктыйлар. Ишек төбендә — сакчылар.
Безнең автоматчылар машиналарыннан сикерешергә тотыналар. Әмма Плиев аларга кул изәп тавышланмыйча гына приказ бирә:
— Барыгыз да урыннарыгызда калыгыз!
Шуннан соң ул майор Шведов белән капитан Семенидога японнарның өлкән офицерларын чакырып чыгарга куша. Тик алар өлгермиләр, бер төркем офицерны ияртеп, өйдән кыска аяклы, таза гына гәүдәле полковник чыга.
Плиев машинасыннан төшә дә, үзенә доклад ясауларын көткән кеше кыяфәтенә кереп, кыска аяклыга кырыс кына карап тора. Тегесе күзлек пыялаларын ялтыратып бер уңга, бер сулга карый һәм, карашы Плиевныкы белән очрап, туры аның янына атлый.
«Башлап ул сүз башласын, доклад ясаган арада хәзерге мәлгә кемнең хуҗа икәнен яхшырак сизәр», дип уйлый Плиев. Ләкин япон бер

сүз дә дәшми. Шулай да командующийның кырыс һәм боеручан карашына түзә алмыйча телгә килә:

— Мин полковник, дивизия командиры, сезгә ни кирәк? — ди ул, ниһаять.

— Сезнең каршыгызда Совет командованиесе вәкиле. Берсүзсез бирелергә тәкъдим итәм. Каршылык күрсәтү файдасыз. Шәһәрне Советлар Союзы маршалы Малиновский гаскәрләре камап алды.

— Ләкин бит...

Полковник сүзен әйтеп бетерә алмый, аның янына тагын бер офицер килә. Монысы генеральный штаб вәкиле булып чыга. Хәлгә төшенгәч, анысының да күзләре акая. Ул капитуляция турында 44 нче армия командующие генерал Хонгога җиткерү, аннан соң башкомандующий белән императордан рөхсәт алу өчен ике атна вакыт сорый.

— Судзуки кабинетының төшүен беләсезме соң сез? — ди моңа каршы Плиев.— Хәрби министр Анами, югары хәрби Совет члены генерал Иосио Синодзука һәм башкалар үзләрен үзләре үтерделәр. Капитуляция мәсьәләсен килештерү өчен сезнең хәзер беркемегез юк.

Япон офицерлары тирән уйга чумалар. Шулай да әле йөзләрендә өметсезлек билгесе күренми. Алар хәзер каршыларында басып торган Совет сугышчыларының менә шулай кыю һәм тиз хәрәкәт итүләренә исләре китеп аптырашта гына калганнар. Кем белә, гаҗизлектән бу ике самурай ниләр эшләп ташламаслар. Шуңа күрә Плиев аларга ис җыярга ирек бирмәскә тырыша һәм:

— Капитуляция ясарга хәзер үк килешмисез икән, ике сәгатьтән минем приказ көченә керәчәк һәм гаскәрләр шәһәрне штурмлый башлаячаклар,— дип кисәтә.— Ул чагында инде үзегезнең дә, солдатларыгызның да исән калуына өмет булмаячак.

Генеральный штаб вәкиленең йөзендә мыскыллы елмаю чагылып китә. Ул нидер әйтергә җыенып авызын ача, ләкин шул чагында штаб янындагы мәйданга «Катюшалар» куелган машиналар һәм артиллерия батареясы килеп керә. Моны күрү белән самурайлар борчылып берберсенә карашып куялар. Плиев, хәзер инде боларның чын-чынлап шүрләүләрен сизеп:

— Полковник, әгәр дошман бирелми икән, аны тар-мар итәләр, диләр бездә, аңлыйсызмы? — ди.

Самурайлар тагын бер карашып алар да генеральный штаб вәкиле үзләренең шартларын белдерә башлый:

— Ярый, бу хәл мине буйсынырга мәҗбүр итә. Ләкин мин ике нәрсәнең тәгәл үтәлүе очрагында гына корал ташлый алам. Беренчедән, капитуляция шартлары почетлы булырга, ә офицерларның кылычлары үзләрендә калырга тиеш. Икенчедән, сөйләшүләр алып баручы сезнең кешегез дәрәҗәсе һәм чины ягыннан минем белән бертигез яисә миннән дә югарырак хәрби начальник булырга тиеш. Шәһәрне үземнән түбәнрәк офицерга бирсәм, минем үземә, туганнарыма һәм бөтен нәселемә йөз карасы булачак.

— Беренче таләбегезнең үтәлүен гарантияли алмыйм,— ди Исса Александрович.— Тик шуны гына әйтәм: барыгыз да исән калачаксыз. Ә инде икенче шартыгызга килгәндә, борчылмагыз, сезнең каршыгызда — Совет Армиясе генерал-полковнигы Плиев.

Комбинезон кигән кешедән шуны ишетү белән генеральный штаб вәкиле кинәт үзгәреп, яшь солдатлар кебек итекләрен тарткалап куя һәм, үтә түбәнчелек белән:

— Без сезне беләбез, галиҗәнап, беләбез,— дип, кулларын күкрәгенә кушыра.

— Белсәгез, бик әйбәт,— ди Плиев,— гарнизон ике сәгатьтән капитуляциягә әзер булсын. Парламентерларыгызны монастырь янына җибәрегез.

— Ярый, галиҗәнап, ярый...

Ә алдынгы отряд шәһәргә чыннан да кермәгән, ул аны уратып көньяк читенә чыккан да һөҗүм итәргә приказ көтеп туктап калган икән.

Бу турыда полк командиры дивизия командирына шундук хәбәр итә. Ләкин оператив группа инде Плиев белән алга китеп өлгергән була. Нишлисең, сугышта әнә шундый көтелмәгән хәлләр дә килеп чыккалый. Аның каравы, меңләгән сугышчыларыбыз исән кала.

## Япон татарча белми

Моңарчы төш вакытында да рәтләп ял итә алмый идек. Бер, күп булса ике сәгатьләп юанасың да тагын кузгаласың. Ә бүген никтер ашыктырмыйлар. Иртә белән дә соң гына уяттылар, юлга да соң гына чыктык. Сигез-ун чакрым киттек микән — төш житте. Аннан бирле дә инде хәтсез вакыт узды, ә кабат юлга җыенуыбыз сизелми. Тик шунысы бар: дивизия штабыннан радиограммалар гына ешрак ява башлады. Ул да түгел:

— Тиздән смотр үткәреләчәк, бар да тәртиптә булсын! — дип, полкны аякка бастырдылар.

Шуннан китте чистарыш, китте төзәтенү... Тартасы тартылды, борасы борылды, сәгать ярым дигәндә олаучысы олавы, пулеметчысы пулеметы янына, кыскасы, һәркем үз урынын белеп, үзенә тиешлесен җиренә житкереп сафка бастык. Күздән кичерелмәгән бер генә нәрсә дә калмады. Сугыш коралларын инде әйткән дә юк, солдат капчыгыннан алып арбаларга хәтле каралды. Шалтырамыймы алар, тавыш чыгармыйлармы — барысы да җентекләп тикшерелде. Аннары таралырга, тагын бераз ял итәргә, йоклап алырга куштылар.

Солдатка аңа нәрсә, урыны җәелгән, кайда ятса, шунда түшәк. Йокысы да әллә кайда назландырып йөрми, башын төрттеме — китте барды. Җае чыкканда ул сиңа запаска дип тә, казага калганнары өчен дип тә йоклап күрсәтә ала...

Шул ятудан соң кояш баеганда гына уяттылар. Анда да гадәттәгечә ашыгу, ыгы-зыгы юк, барысы да җае белән, иple генә бара. Әмма күңелләр нидер сизенә, шулай ашыкмыйча, каударланмыйча гына нинди-дер бер зур эшкә җыенуыбызны чамаларга була иде.

Озакламый полк штабы урнашкан палатка янына «Виллис» машинасы килеп туктады. Аннан дивизия командиры полковник Баджалидзе белән ике офицер төштеләр. Без, радиостанцияне юлга әзерләп яткан җиребездән туктап, честь биреп катып калдык. Дивизия командиры полк командирының докладын тыңлап бетерде дә, рус сүзләрен грузинча йомшарткалап:

— Ну, как дела, радисты?! — дип сөйләнә-сөйләнә безнең янга килде.

Аннары:

— Моңарчы тырыштыгыз, маладци, шулай әйбәт. Бүген сезгә эш күп булачак, бүген дә сынатмагыз,— дип, мактавы белән без фәкыйрьләрне каушатып, штаб палаткасына кереп китте.

Борылып киткәндә мыек астыннан гына елмаюын күреп калдык. Белмим, әллә безнең кыяфәттән көлдеме, әллә инде эшебездән чыннан да шулай канәгать булып елмайдымы, ул чагында аларын ук тикшереп торырга чамабыз да, вакытыбыз да юк иде. Күрәсең, икесе дә булгандыр. Бердән, иптәшем Соколов бик сузан, ябык, мин үзем исә тәбәнәк, үтә чандыр идем. Шуларга тагын безнең яшьлекне, малайлыкны да китереп кушсаң, солдатлар телендә «сары томшык» дип йөртелгән бер нәрсә килә дә чыга (ул заманда, яше житкәч алынып та, инде алты-

җиде ел хезмәт иткән карт солдатлар безнең ише ел-ел ярымлык кына стажы булган яшь солдатларны шулай атап йөрттеләр). Икенчедән, штаб офицерлары арасында радистларга карата җылы гына караш та урнашып өлгергән иде. Аннары, фронт газетасыннан бер хәбәрче килеп, безнең хакта мәкалә язып чыгарды. Янәсе, без көнен-төнен белмичә тырышабыз, янәсе, нинди генә шартларда да элемтәне өзмибез. Моның шаукымы, күрәсең, дивизия командирына да йоккан булгандыр. Хәер, ул турыда әле бер җае белән сүз булыр, хәзер әнә полкны тезәләр, ашыгырга кирәк.

Һәм менә полк «П» хәрефе рәвешендә тезелеп, әлеге шул «Виллис» машинасына менеп баскан дивизия командирын тыңлый:

— Иптәшләр! Фронт командованиесе куйган гаять катлаулы һәм чиксез авыр бурычның беренче этабын без намус белән үтәдек. Сусыз монгол далалары, Гоби чүле һәм, ниһаять, японнар Совет армиясе үтә алмаслык дип санаган Зур Хинган сырты артта калды. Дөрес, моңарчы безгә дошманның төп көчләре белән бәрелешкә керергә туры килмәде. Әмма безнең алда торган киртәләр җанлы дошман белән бер булды. Без тиңдәшсез чыдамлык күрсәтеп, мөмкин түгел дип караган нәрсәләрне эшләдек. Шуңа күрә Верховный Башкомандующий безгә бүген үзенең рәхмәтен белдерде.

Квантун армиясен тулысы белән камап алу һәм аны кисәкләргә бүлгәләү төгәлләнеп килә. Ләкин әле дошман коралны һаман ташламый. Безнең 17 нче армия алдында торган бүгенге бурыч — самурайларның бердәнбер чигенү юлын кисү. Моның өчен безгә тиз арада Сары диңгезгә чыгарга кирәк. Алда — Чифын һәм Циньцюань шәһәрләре. Иртәгәге таңга без Чифынга житәргә тиешбез.

Сезнең полк бүген авангардта барачак, бәрелешкә беренче булып керүегез мөмкин... Сынатмагыз. Уңыш телим, иптәшләр!..

Хинган сырты артта калса да, тау әле һаман дәвам итә. Ләкин ул көннән-көн түбәнәеп, үзәнлекләр белән аралаша бара. Менә әле дә, бер тауны төшеп, үзәнлеккә кердек, гаолян кыры башланды. Гаолян дигән үсемлек Кытайда күп таралган. Ул үзенең сабагы һәм яфраккыяклары белән бездәге җикән камышын хәтерләтә. Тик аның очында — җикән урынына ат кузгалагыныкы төсле тәлгәшләр. Үзе кукуруз кебек биек, җире килешкән урыннарда җигүле атны дугасы-ние белән күмәрлек булып үсә.

Шулай тавышланмаска тырышып барабыз. Юлның як-ягында әлеге шул гаолян урманы. Моңда кергәч, караңгылык тагын да куера төшкәндәй булды. Ул арада безне дивизия штабы чакыра башлады. Радиограмма кабул итәргә кушалар. Ләкин берни күренми, нишлисең, лампочка кабызырга туры килде. Алай да әле яктылык таман гына. Анысы инде бер хәер, моңа без күнеккән, ә менә телефон колакчыннарындагы чит-ят тавышларга һич тә түзәрлек түгел, шатыр-шотыр иткән атмосфера бушанулары радиограмма алырга ирек бирми. Әнә шулай бөтен игътибарны туплап, тапшырыла торган цифрларны язып калыйм дип азапланганда, атыбыз, моңарчы җайга гына барган жиреннән кинәт чәбәләнеп, бер кызулап, бер туктап интектерә башлады. Ул да түгел, алдан да, арттан да, баш очымнан да, сызгырышып, ялт-йолт килеп пулялар очарга тотынды. Бу хәлгә төшенеп тә өлгермәдем:

— Сүндер утыңны, әллә үләсең киләме?! — дип, кемдер минем аркага камчы белән тамызды.

Сискәнеп башымны күтәрсәм — янымда берәү дә юк. Бары тик колонна койрыгына таба чапкан атның тояк тавышын гына ишетеп калдым.

Радиограмма өзелде. Телефон колакчыннарын салып, як-ягыма карапам, әмма һични аңламыйм. Юлда атлар да, солдатлар да юк, һәммәсе гаолян кырына сибелгәннәр. Ату тавышлары арасыннан офицерларның:

— Беренче взвод, уңнан алга!

— Икенче взвод, сулдан алга! — дигән командалары ишетелә.

Юлда тик без генә калганбыз. Соколов белән олаучы Сарсынбаев икесе ике яктан атның тезгененнән тотканнар да минем радиограмма алып бетергәнне көтәләр. Ул арада, радиограмма тотып, штаб начальнигы йөгереп килде:

— Хәзер үк тапшырыгыз! — ди.

— Ут яндырырга ярамый бит, иптәш капитан.

— Син нәрсә... Хәзер үк тапшыр, тап җаен!

— Озынмы соң ул, иптәш капитан, ятлап булырлыкмы?

— Зиһенең ничектер бит...

Гаолян арасына чүгәләп, плащ-палаткалар белән капладык та, кесә фонаре яктысында радиограмманы карыйбыз. Ул шактый озын иде, күңелдән ятларлык түгел. Шундый ашыгыч, каушаган вакытта бигрәк тә.

— Иптәш капитан, эчтәлеге ничек соң моның? — дим аптырагач.

— Эчтәлегеме? Японнарның менә шушы җирдә безгә засада ясаулары турында.

— Ә кайсы цифрлар координантны күрсәтә?

Штаб начальнигы, планшетыннан тиз генә кызыл карандаш чыгарып, рәттән торган берничә цифрның астына сызды.

— Ярар, алай булгач, ут яндырмый гына тапшырып карыйм.

— Ничек?.. Ачык текст беләнме!

— Юк, иптәш капитан, японнар түгел, үзегез дә аңламассыз.

— Яле, яле, ничек итеп?

— Менә шулай, иптәш капитан,— дип, мин аңа радиограмманың эчтәлеген татарча сөйли башладым:

— Өлкән абзыйга әйт: кысык күзләр безгә менә шушы җирдә (бу урында бая астына карандаш белән сызылган цифрлар әйтелә) гаолян арасыннан ут ачтылар, хәзер сугыш алып барабыз.

Капитан бер миңа, бер радиограммага карап шиккә калды. Аннары иңбашыма сугып:

— Шайтаным да аңламадым, ни булса ул, әйдә, валяй,— диде.

Шулай итеп, радиограмманы штаб начальнигына сөйләп күрсәткәнчә тәвәккәлләдем...

Бераз сирәгәя барса да, ату тавышлары әле һаман дәвам итә. Баш өстеннән, як-яктан пулялар сызгырышып узган саен тәннәр чымырдап, йөрәкләр кысылып куя. Кулыңа мылтык тотып, дошманга каршы башкалар белән янәшә барсаң, алай ук куркыныч булмас иде төсле. Ә болай, өч бөртек кеше төн карасына күз текәп, кая атарга, нәрсәгә атарга белмичә, ниндидер бер адашкан, очраклы пуляның бер дә юкка гомереңне кисүен көтеп ятуы ай-һай авыр икән. Әмма иксез-чиксез булып тоелган бу газаплы минутлар да үтте. Атыш туктап, тирә-юнь кинәт тынып калды. Дошманны әзәрлекли киткән взводлар, роталар бер-бер артлы кире кайттылар. Кешеләрне, атларны барлау башланды. Бәхеткә каршы, солдатлардан үлүчеләр юк иде, ләкин яралылар байтак булып чыкты, берничә ат үлде. Тыныч вакытта кырыгар, иллешәр чакрымлык төнге маршларда йөреп, барган шәпкә дошман белән бәрелешләргә кереп өйрәнүләрнең җимешен бу көнне без тагын бер кат татыдык. Төннәрен дә мәче кебек эш итә белүләре белән һәрвакыт шапырынып килгән һәм моңа зур өмет баглаган самурайлар әнә өч пулемет, биш үлек ташлап качканнар. Болары да безнең тылда дивер-

сисн эш алып бару өчен калдырылган шул үлемдарлар отряды булып чыкты.

Озак та үтми, штаб начальнигы безнең янга тагын килде. Аның артыннан ук атына атланган полк командиры подполковник Костров та килеп туктады. Ул ат өстеннән безгә таба иелеп:

— Җә, кайсыгызга эләктердем мин бая, бик каты түгелме? — дип сораштыра башлады.

— Миңа, иптәш подполковник, миңа,— дим.

— Алайса, үпкәләмә, сержант, гафу ит. Мин бит юри түгел, узышлый кисәтим дидем. Чекерәеп торган мишень идең ич. Сак булырга кирәк.

Аннары штаб начальнигына:

— Бәрелешнең ничек беткәнен дивизиягә хәбәр итегез,— дип, китеп барды.

Полк командиры бик тә таләпчән бер кеше иде. Сүзгә дә бик хәтәр, ачуы килгәндә һич сайлап-нитеп тормас. Ник туганына үкенеп йөрүче җебегәннәргә карата бигрәк тә. Аңа син ут бул, юкны бар ит, уч төбендә кургаш эрет. Юк икән, күзенә чалынма, йомры-йомры сүзләр белән томыра башласа, кая керер тишек тапмыйсың.

Бүгенгедәй хәтердә, походның әле беренче көне генә иде. Шулай, ун-унбиш чакрым киттек микән, кайберәүләрнең аяклары кырылып, аксаклый башладылар. Баралар, баралар да, түзә алмагач, юл кырыена чыгып утыралар. Алар янына санчасть кешеләре җыела, кырылган-суелган җирләрен бәйләргә, бик җәлләгән кыяфәт белән киңәш бирергә тотыналар. Полк командиры моны күзәткәләп килде, килде дә, күрәсең, инде түзмәде, юл кырыенда аягын бәйләтеп утырган бер солдат янына туктады:

— Нишләвегез бу?!

— Менә, иптәш подполковник, аяклары суелган,— ди санитар.

— Шулаймыни!..— ди полк командиры. Аннары солдатка карап:

— Ботинкаң кысмыймы? — ди.

— Кысмый.

— Чолгавың чистамы?

— Чиста, иптәш подполковник.

Шуннан китте, китте командирыбыз... түз генә, санитарын да, солдатын да элеп алды, селкеп салды:

— Үз кадерен үзе белмәс бер җебегән янында биеп йөрергә!.. Марш үз урыныңа! — дип, башта санитарын пранлатты, аннары:

— Ә син, хәсрәт, аяк та киенә белмәгәч... әбиеңә кунакка җыендыңмыни?! — дип тегесен туздырды...

Ә шулай да солдат җанлы кеше иде полк командиры. Какча гәүдәле, инде алтынчы дистәсе белән барган бу өлкән офицер һәрвакыт солдатлар тирәсендә булырга тырыша. Походта да шулай, атын туктатып, колоннаның я уртасында, я артында кала. Бөтенләй хәле бетеп егылыр дәрәҗәгә җиткән берәүне күрсә, шуның яныннан бара башлый. Бераз киткәч:

— Ягез әле, иптәшләр, атны кайсыгыз алып бара торыр икән, аяклар оеды, яздырып аласы иде,— дип сафтан сафка күзен йөртә башлый. Аннары берни булмагандай:

— Менә, син булсаң да ярый, әйдәле, туган, ярдәм ит,— дип, теге арыган солдатны сафтан чакырып чыгара да атына атландыра...

Карап торуга бик кырыс күренгән әлеге кешенең, Гоби чүлен кичкәндә алҗып, сусап егылган солдатлар янына чүгәләп, флягасы төбендә калган суын соңгы тамчысына кадәр өләшеп йөргән чакларын да күрдек.

Ни генә әйтмә, ярата идек без аны. Һәм шүрли дә идек үзеннән.

Ләкин куркып түгел, сөеп, ихтирам итеп, аның алдында оятка калмыйк дип шүрли идек.

Әле менә маскировканы бозган өчен безне дә туздырыр дип торган идем. Ничектер, алай итмәде. Үзенең камчысы белән мине үлемнән саклап калган бу кешене гомеремә онытасым юк.

...Чифынга таң атканда килеп җиттек. Әмма безгә кадәр разведка отряды инде шәһәргә кереп өлгергән иде. Чигенүче дошман частьлары белән ике арада кыска гына бәрелеш булып алган. Японнар Чифын янындагы күперне дә шартлатырга өлгермичә качканнар, хәрби складлары да ничек булган шул килеш безнең кулга төште.

Шәһәрдән чыгып байтак җир киткәч кенә ялга туктадык. Озак та үтми, радиограмма тапшырдылар, радио аша барган элемтәне туктатып, телефон чыбыклары сузарга кушканнар. Димәк, тиз генә кузгалмаячакбыз. Монысы әйбәт, кырык чакрым узганнан соң безгә дә ял бик кирәк иде. Әмма ул миңа тиз генә насыйп булмады. Инде ятам дип кенә торганда, штабка дәшеп:

— Сине дивизия штабына чакыралар, хәзер үк,— диделәр.

Дивизия штабы бездән өч-дүрт чакрымда урнашкан булып чыкты. Радиостанциянең аккумуляторлары да утырган иде, беррәттән шуларны да алыштырып кайтырмын дип, ат сорыйсы иттем. Каршы килмәделәр, барган җиреннән йоклый торган бер мәхлукны иярләп тоттырдылар.

Барам мин шулай. Ләкин күңел тыныч түгел, башта әллә нинди уйлар бөтерелә. Нигә дип чакырталар, нәрсә булды икән? Бер карасаң, борчылыр сәбәп тә юк шикелле, тәүге чакырулары түгел бит, шулай ял вакытларында радиостанция начальникларын җыеп, инструктаж бирү гадәтләре элек тә бар иде ич...

Килеп җитү белән башта радистлар янына туктадым.

— Хәлләр ничек, малайлар, мине нигә чакырдылар икән, белмисезме? — дим.

— Юк шул, белмибез,— диләр иптәшләр.

Ул арада:

— Кем ул анда, кем? — дип, радиостанция машинасыннан элемтә начальнигы килеп чыкты. Чыкты да:

— Әәә, килдеңме, әйдә, белерсең,— дип, мине туп-туры штабка алып китте.

Анда кеше байтак иде. Арада дәрәҗәсе белән иң өлкәне — оператив бүлек начальнигы. Үземне кем чакыруын тәгаен генә белмәгәч, туры шуңа мөрәҗәгать иттем. Майор тыңлап бетерде дә:

— Шушымыни инде ул теге тәти егет,— дип, бармаклары арасында карандашын уйната-уйната, миңа карап тора башлады. Аннары, өстәлдән бер кәгазь кисәге алып:

— Бу радиограмманы кичә син тапшырдыңмы? — дип миңа сузды.

Укып карасам... чыннан да шул.

— Мин тапшырдым, иптәш майор.

— Кем кушты сиңа ачык текст белән эшләргә?!

— Башкача мөмкин түгел иде ич,— дип аңлатырга тырышып карыйм, әмма майор авыз ачарга да ирек бирми.

— Әгәр ул радиограмманы Чифындагы японнар алган булса? Безнең килгәнне белгән булсалар?.. Трибуналга бирерлек бит сине моның өчен! — дип котны алды.

Маңгаема салкын тир бәреп чыкты, тез буыннары калтырый, инде нишләргә? Аптырагач, элемтә начальнигына карыйм, ни әйтсән дә, ул мине яхшы белә. Юк, аның да йөзендә шәфкать әсәре күренми. Бу хикмәтләрем өчен үзенә дә инде, күрәсең, шактый ук эләккәндер.

Шулай хафага чумып торганда, ничектер, үзем дә сизмәстән:

— Японнарда татар радисты юктыр әле,— дип ычкындырдым.

— Булмаса соң... Шуннан ни?
— Радиограмманы мин татарча тапшырдым.
— Татарча?! Кем алды соң аны синнән?
— Херувимов.
— Херувимов? Ул татарча беләмени?
— Белә.
Майор писарьлардан кемгәдер Херувимовны чакырырга кушты.
...Якташым, татар авылында үскән тимерче малае Херувимов хәзер минем янда, ул да җавап тота.
— Бу радиограмманы син татарча алдыңмы?
— Әйе, иптәш майор, татарча. Монысы аның тәрҗемә, төп нөсхәсе радиостанциядә. Рөхсәт итегез?..
Николай чатыр чабып радиостанциягә китте. Күрәм, майор да, элемтә начальнигы да бер-берсенә карап, мыек астыннан гына елмаегандай итәләр. Аннары, исләренә нидер төшкән шикелле, майор өстәленә иелде, ә элемтә начальнигы палатканың бер почмагына поскан телефонист янына атлады. Минем дә эчкә бераз җылы кереп, экренләп тернәкләнә башладым. Кызык бит кеше дигәнең, баш өстемдә әле генә яшенләп, күкрәп торган болытлар таралырга өлгермәгән, авыз инде ерылырга чамалый.

## Кысыр хәсрәт

Дивизия штабында мин бик кызыклы хәбәрләр дә ишеттем. Безнекеләр Харбин шәһәренә десант төшергәннәр һәм Квантун армиясенең штаб начальнигы генерал-лейтенант Хатаны, тагын күпмедер генералны пленга алып, барысын бер самолетка төягәннәр дә Ерак Көнчыгыштагы Совет гаскәрләре Башкомандующие маршал А. М. Василевский янына озатканнар. Хәзер менә алар белән капитуляция шартлары турында сөйләшүләр бара икән. Мукден шәһәренә төшерелгән икенче бер десант отряды Японияга качу өчен самолет көтеп утырган җирен-нән Маньчжоу-Гоның курчак императоры Пу-ины эләктереп алган. Самурайлар фронтның кайбер участокларында корал ташлый башлаганнар, ди.
Полкка мин әнә шулай бер кочак яңа хәбәрләр белән кайтып кердем. Атны хуҗасына тапшырдым да, дивизия штабына үземне ни өчен чакыруларын әйтим дип, элемтә начальнигын эзләп киттем. Әмма аны беркайдан да таба алмадым. Инде төш вакыты якынлашып килсә дә, тирә-як тып-тын, лагерь әйләнәсендә йөргән часовойларны, поход кухнялары янында кайнашкан поварларны искә алмаганда, бар да йоклыйлар. Аптырагач, үземнең турыдан-туры начальнигымны читләтү булса да, штаб начальнигы янына киттем. Әмма штаб палаткасы тирәсендә дә бер автоматчыдан бүтән кеше-кара күренми. Туры палаткага керергә кыймыйча, башта автоматчы янына бардым.
— Штаб начальнигы мондамы, йокламыймы икән? — дим.
— Мондасын монда да, белмим шул, күрәсең, йоклыйдыр.
Борылып китәм дип кенә торганда, палатка эченнән тавыш ишетелде:
— Кем ул анда, радист, синме? Кер әйдә, кер,— дип капитан мине чакырып кертте.
Штаб начальнигы тәбәнәк кенә поход өстәленә җәеп салган карта өстенә иелеп, төсле карандашлар белән нидер сызгалый иде. Читтәрәк бер телефонист утыра. Керүем белән капитанның беренче сүзе шул булды:
— Я, сөйлә, ник чакыртканнар?
Мин Харбинга, Мукденга десант төшерүләре, Хата белән Пу-иның плен алынуы һәм башкасын тезеп киттем. Соңга табарак инде, кем

каршында басып торуымны да онытып, ишеткәннәремә нәтиҗә ясагандай: «Болай булгач, японнарның эше бетте, иптәш капитан!» — дип куйдым.

— Менә бит, ә, каян килгән генеральный штаб начальнигы. Дивизия штабына шуларны әйтү өчен чакырткannармыни үзеңне? Ә мин тагын, беркатлы нәрсә, белми дә торам,— дип, штаб начальнигы көлеп җибәрде. Аннары, минем кинәт сүрелеп, уңайсызланып калуымны күргәч, өстәп куйды:

— Ярар, нигә дип чакырткannар, сөйлә.

— Төнге радиограмма өчен, иптәш капитан.

— Нәрсә диләр, бик каты әләктеме?

— Трибуналга бирәбез дигәннәр иде дә...

— Я, шуннан ни булып бетте?

— Белмим әле, беткәндерме, юкмы, хәзергә эшләп тор, диделәр.

— Син соң, пешмәгән нәрсә, минем рөхсәт белән тапшыруыңны әйтмәдеңмени?

— Әйтмәгән идем шул. Ярамагач ярамый инде ул, нәрсәсен әйтәсен аның...

Капитан бераз уйланып торды да:

— Ярар, Чифын инде алынды, әллә ни булмас, икенче саграк кыланырбыз, хәзер бар ял ит,— дип, мине чыгарып җибәрде...

Ләкин ял дигәне миңа бу юлы да эләкмәде. Үзебезнең палаткага кайтып, башны гына төрткән идем, «подъем» уйнадылар һәм обед ашарга да ирек бирмичә, юлга әзерләнергә куштылар. Монысын инде мин башыма һич сыйдыра алмадым. Менә, менә сугыш бетә дип торганда, капитуляция хакында сөйләшүләр барган бер вакытта, ут капкандай,ниемә дип ашыктыралар?..

Солдатлар хәтсез генә ял итеп алганнар иде. Ә мин көч-хәл белән сөйрәләм. Кичәдән бирле аякта. Тамчы да йокы күрмәгән. Шуның өстенә тагын нихәтле кичереш, нихәтле уйлану, курку һәм, ниһаять, дивизия штабында ишеткән әлеге җылы хәбәрләр... Барысы да бергә укмашып, өсте өстенә өелеп, башны түбәл иткәннәр. Әнә шул миңгерәйгән башымны салындырып, радиостанция күелгән арба янынnan атлыйм. Озак та үтми, минем янга бая полк штабында дежур торган телефонист килде.

— Нишләп болай башыңны салындырдың әле? — ди бу.

— Ял итеп булмады бит менә, арыганмын...

— Беләм ич инде, кайгырма, берни булмас. Син дивизиягә киткәч тә штаб начальнигы белән телефоннан сөйләшкәннәр иде. Ачык текст белән тапшырырга үзем рөхсәт иттем, диде капитан.

— Шуннан?

— Шуннан соң шул инде, бераз әләкте аңа да.

— Татарча тапшырганны әйтмәдемени?

— Юк бугай, андый сүз булмады...

Шулай барабыз. Ә мин һаман уйланам: «Ни булыр да ни белән бетәр? Күпме гомер инде менә элемтәне бер генә сәгатькә дә өзмичә килдек, нихәтле мактау сүзләре ишеттек, нинди генә четерекле шартларда да әмәлен-җаен табып тырыштык. Инде сугыш бетә дип көнә торганда, мә сиңа, телгә кер, эшең дивизия штабына хәтле барып җитсен, имеш. Хәер, соңыннан бераз йомшардылар йомшаруын да, кем белә, «моны болай гына калдырып булмас, чара күрербез», диделәр бит...

Ул да түгел, колонна башыннан: «Адымнарны тизләтергә!» — дигән команда тапшырдылар. Нәрсә булган, ник болай ашыгабыз, һич аңлап булмый. Бу хәлгә олаучы Сарсынбаев та гаҗәпсенеп килә икән. Һәм менә ул, арба башында утырган җиреннән сикереп төште дә:

— Үзең сугыш бетә дип кайттың... Ник чаптыралар, белмим. Әллә

инде, тизрәк килегез, бирeләбез, дип японнар безне көтеп торалармы? Бу килешеңне күреп кире уйламасыннар тагын, бар арбага утыр, ял ит,—"дип казакъча сөйләнә-сөйләнә минем яннан атлый башлады...

Моңарчы әлеерактан гына күренеп торган таулар, кыялар, колонканы як-яктан кысарга теләгәндәй, акрынлап безгә таба якынлаша башладылар. Бара торгач, алар якын ук килеп җиттеләр һәм полк тарлавык эчендә калды. Уң якта да, сул якта да хәзер — кырт кискәндәй текә кыялар. Юл кырыеннан ук, ташлар өстеннән сикерә-сикерә, тау елгасы ага. Кояш баш өстендә генә кыздырса да, монда җиләс, дымсу. Бердән җиңеләеп, сулышлар иркенәеп киткәндәй булды. Тарлавыкка, әйтерсең лә, салават күпере сузылып яткан. Елга, үзен туктатырга теләгәндәй, каршысына чыгып баскан зур-зур шома ташлар өстеннән сикерә-сикерә күбекләнеп, вак-вак тамчылары белән сыртын кабартып ага да ага. Ә тамчылар, бу йөгәнсез ташкыннан азга гына булса да аерылуларына шатланган кебек, кояш нурыннан яшел, зәңгәр, шәмәхә һәм тагын әллә нинди төсләргә кереп балкыйлар.

Менә тарлавыкны да чыктык. Кыялар тагын як-якка чигенә башладылар. Алардан калмыйча елга да сул якка борылып күздән югалды. Без турыга киттек. Каршыдагы калкулыкка күтәрелеп бераз бару белән юлның сул ягына кереп тезелешкән машиналарны, алар тирәсенә куелган яшел палаткаларны күрдек. Бу — дивизия штабы иде. Аннан арырак 43 нче полк урнашкан. Озак та үтми, без дә туктадык. Ләкин бу юлы тиз генә урнашып бетә алмадык. Башта һәр батальонга, һәр ротага палаткалар кую өчен урын билгеләп чыктылар, аннары аерым бер тәртип белән тупларны, арбаларны тезеп куйдык, юынтык сулар, чүп-чар түгү өчен чокырлар казылды, кыскасы, бар да озакка дип эшләнә. Дивизия штабының һәм полкларның шулай бер тирәгә урнашуыннан да тиз генә кузгалмаячагыбызны чамаларга була иде...

Икенче көн инде ял итәбез. Дивизия белән элемтә дә телефон аша бара. Элекке көннәрне искә алып, ахрысы, Соколов белән мине бөтен эштән азат иттеләр. Барлык эшебез хәзер радиодан соңгы хәбәрләр тыңлау да аның белән халыкны таныштыру. Ә хәбәрләр берсеннән берсе куанычлы. Менә японнарның 3 нче, 5 нче армияләре капитуляция ясаганнар, әнә совет гаскәрләре Харбин, Гирин, Мукден һәм Чан-Чунь шәһәрләрен алганнар, Порт-Артурга безнең корабльләр кергән. Икенче бер хәбәр Дальный шәһәрендә атаман Семеновның, ак эмигрантлар бюросы начальнигы генерал Нечаевның, Чита шәһәрендәге элекке комендант генерал Токмаковның һәм башка шундый «элекке»ләрнең кулга алынулары турында сөйли. Кыскасы, японнар хәзер полк һәм дивизияләре, тоташ армияләре белән плен төшәләр икән.

Шулай соңгы хәбәрләр тыңлап утырган җирдән Соколов белән икебезне дә элемтә начальнигы дәштереп алды. Безне дивизиягә җибәрергә кушканнар, шуның өчен чакырткан икән. Теге радиограмма вакыйгасын оныта төшеп, бераз тынычлана башлаган идем. Хәзер менә дивизиягә чакыралар дигәч, үзегезне тәртипкә китерегез дип тә өстәгәч, «моны болай гына калдырып булмас, чара күрербез», дигәннәре искә төште дә эчем «жу» итеп китте.

Нишлисең, әзерләнергә кирәк. Башта Сарсынбаевның көпчәк мае белән ботинкаларны ялтыраттык, аннары керләнеп, каешланып, кояшта уңып беткән ала-кола гимнастеркаларыбызга ап-ак яка тегеп куйдык. Тәртип икән, полный тәртип булсын дип, мыек чыгасы урынны биләп торган барлы-юклы төкләрне дә кырып аттык. Әнә шулай шомарып-чистарып, ят күзләргә күренерлек хәлгә кергәч, автоматларны астык та чыгып киттек без.

Кайсы гына якка күз атма — өсте-өстенә өелгән таулар, кыялар. Алар киң генә мәйданны уратып килгәннәр дә бер-берсенә кушылганнар. Менә шул кыя-таулар белән әйләндереп алынган бу мәйдан хәзер

Бажәеп зур табаны хәтерләтә. Бер якта әнә яшеллеккә күмелгән зур гына авыл күренә. Аның тирәсендә гадәттәгечә вак-вак кисәкләргә бүлгәләнгән иген кырлары җәелеп ята. Авылның уң ягындагы басулар, игеннәрен җыеп алгангамы, яктырып калганнар. Ә сул яктагылары кап-кара. Бу тирәдә японнар белән каты гына бәрелешләр булып алган. Самурайлар чигенгән вакытта, безнең частьларны тоткарлау өчен, өлгереп житкән иген кырларына ут төрткәннәр. Җилле көннәрдә ул тирәдән кара тузан күтәрелә. Бүген исә һава тын, көн аяз, кояшлы. Янган кыр уртасындагы түгәрәк күл дә, кара хәтфә өстенә кадалган алмаз бизәк төсле ялтырап, очкынланып тора...

Дивизиягә килү белән иң элек гадәттәгечә штаб радиостанциясе янына бардык. Анда инде безнең кебек үк полкларда торып эшләүче башка радистлар да җыелган иде. Нигә дип чакыртканнар, ни була? Барыбызның да шуны ачыклыйсы килә. Ләкин тәгаен генә белүче юк. Бу нәрсә мине, мөгаен, башкаларга караганда да күбрәк кызыксындыргандыр. Ниһаять, түзмәдем, Херувимовны бер читкә алып китеп сораштыра башладым:

— Ничек, мин әйтәм, теге радиограмма турында сүз чыкканы юкмы?

— Юк, ул-бу ишетелми.

— Нигә чакырдылар икән, син беләсеңдер инде?

— Юк, малай, белмим. Ниндидер приказ укыйсылар бугай, бар белгәнем шул...

Һәм озак та үтмәде, элемтә батальонын сафка тезеп, приказ укырга тотындылар. Бу әлеге сугышта батырлык күрсәткән, үзен таныткан кешеләрне бүләкләү турындагы приказ иде. Исемлек алфавит тәртибендә төзелгән. Бүләкләнүчеләрнең исем-фамилияләрен атый-атый алфавитның ахырына үк якынлашып килләр. Соколов белән Херувимовның да «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнүен әйттеләр. Инде минем фамилия башланган «Ш» хәрефен узып «Я»га да җиттеләр. Алай булгач, мин шул икенче төрлерәк приказга эләккәнмендер инде, «болай гына калдырып булмас, чара күрербез» диюләре хактыр дип борчылып торганда... ни ишетәм! Иң актыктан гына минем фамилияне дә атадылар. Башта алдагы иптәшләргә карата язылган сүзләрне үк укыдылар, шуның өстенә тагын үземне трибунал каршысына бастыра язган теге радиограмма вакыйгасын да китереп куштылар. Аны сугыш шартларында күрсәткән «тапкырлык» дип бәяләп, минем дә «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнүемне әйттеләр...

## Җил чәчсәң, давыл урырсың

Яңа гына почта алып кайтканнар иде. Солдатлар, чирәм өстенә кырын ятып, кайсы газет, кайсы хат укый. Их, шул туган илдән килгән хатлар!.. Солдат өчен алардан да кадерлерәк нәрсә бар икән!? Хат алган көннәрне, башың күккә тиеп, кая басканыңны да сизмичә йөрисең. Ә кайчакта...

Әхмәткә менә берьюлы ике хат килеп төште. Берсе Мәстүрәсеннән, икенчесе Кәримнең сөйгән кызы Айсылудан. Мәстүрә хатына ул тизтиз генә күз йөртеп чыкты да күкрәк кесәсенә салып куйды. Ә Айсылудан килгән хатны ачаргамы, ачмаскамы белмичә, янындагы иптәшләренә карап, алардан киңәш көткәндәй туктап калды. Кәрим үлгәч, бу кайгылы хәбәрне дусының ялгыз карчык анасынамы, әллә инде Айсылугамы язарга дип, озак кына баш ватты. Аннары, якташларының киңәшен тотып, Айсылуга язган иде. Хәзер менә җавап килгән.

«...Әхмәт җаным, нишлим соң?! Бигрәк авыр ич. Хатыңны укып

чыктым да Кәримнәргә йөгердем. Фәгыйләттәй, мескен, һәрвакыттагыча ялгыз иде. Мин килгәнгә бик куанды. Белми бит, бернәрсә дә белми әле, җанашым. Кәримгә дип оекбаш бәйләп ята, чикләвек кип-тергән... Аның сугышка чыгып китүен белә иде инде, хатларын алып күрсәтте. «Бабасы шул кытай җирендә калган иде, мәрхүм, инде балама гына исән-сау кайтырга насыйп булсын», ди. Кәримнең гармунын чыгарып күрсәтте. «Гармун уйнасалар, урамда Кәримем йөргән күк була», ди. Үземне сәеррәк тотканмындыр, ахрысы, миңа карап сораштыра башлады: «Нишләдең син, Айсылу, күзләрең дә кызарган?» — ди. Түзмәдем, тагын елап җибәрдем. Мин елагач, ул елый. Ашлык чистартканда чүп кергән иде, әле менә сине күргәч, әни искә төште, шуңа елыйм, дим... Ничек түзәр иңде, бичара, ничек түзәр...

Аннан Галәви абыйларга йөгердем, почтаны әле һаман да ул ташый. Кәрим турында язу килсә, зинһар, Фәгыйләттәйгә ишеттерә күрмәгез, дидем. Хәзер ул да ялгыз, мин дә. Кәримгә язган идем инде, белгәнсеңдер, әни үлде бит минем. Килешсә, Фәгыйләттәй белән икенче йортны бер итәрбез дип торам...

Хуш, Әхмәт, Кәрим өчен дә үч алыгыз!»

Бу хатны укуы барыбызга да авыр булды. Башларны иеп тын да алмый утырабыз. Әхмәтнең күзләре дымланган иде. Авылдашы турында без белмәгән нәрсәләрне дә исенә төшереп, бу хәлне кайсыбызга караганда да тирәнрәк кичереп утыра икән. «Кәримнең әтисе дә Халхин-Гол елгасы буенда һәлак булган иде, бабасы белән үзе менә монда, кытай җирендә... һаман да шул бер үк дошман, шул ук самурайлар... Бер нәселдән өч буынның гомерен кистеләр!» — дип куйды.

Һаман да шул бер үк дошман... Ничек кенә капшап карамады ул безне. Әмма Хасан күле янында да, Халхин-Гол буенда да тешен сындырып, Хинган таулары артына качты. Ләкин мәкерле уеннан кире кайтмады, миллионлаган армия туплап, «Уралгача Япония» дигән шашкын уйлар белән саташты, ничә еллардан бирле Советлар Союзына поход турында хыялланды, шуңа әзерләнде. Җил чәчсәң, давыл урырсың, диләр. Һәм чыннан да, Квантун армиясе өстеннән, әйтерсең лә, дәһшәтле давыл узды, баштанаяк коралланган «мактаулы» армия Совет гаскәрләренә каршы атнадан артык түзә алмады. Хәзер менә япон солдатлары үзләренең акылсыз генераллары артыннан Советлар Союзына таба атлыйлар, әмма ялган, явыз пропагандага бирелеп элек уйлаганнарыча җиңүчеләр, басып алучылар булып түгел, ә әсирләр сыйфатында хурлыклы пленга баралар. Истә тотар микән алар бу кәннәрен, онытмаслар микән тарихның бу ачы сабакларын?!.

Шулай уйланып утырганда, штаб палаткасыннан бер телефонист атылып чыкты. Чыкты да: «Җиңү, иптәшләр, җиңү!» — дип кычкыра-кычкыра, рәт-рәт тезелеп киткән палаткалар арасыннан йөгерергә тотынды. Менә ул безнең янга да килеп җитте. Туктаттык та:

— Каян белдең, чынмы?! — дип сорыйбыз.

— Әле генә дивизиядән хәбәр килде. Бүген Японияның һичсүзсез бирелүе турындагы актка кул куелган, 3 нче сентябрь көне Японияне Җиңү көне дип игълан ителгән!

— Бүген ничәсе соң әле?! — ди кемдер.

— Иртән икесе иде, хәчтруш,— дип, телефонист тагын йөгерде...

Палаткалар арасыннан, әйтерсең лә, көчле җил исеп китте. Алар солдатларның кайнашуыннан кинәт селкенә, тирбәнә башладылар. Лагерь корт иледәй кайнап, гөжләргә тотынды. Ул да түгел, әле һаман да тынычлана алмыйча әрле-бирле йөренгән телефонистны әләктереп алып чөяргә керештеләр. Тирә-як «урра» тавышларына күмелде...

Ә шулай да бәйрәмнең зурысы әле иртәгә булачак. Термослар төялгән арба башына кунаклап дивизия штабына китеп баручы старшинаның мәгънәле генә елмаюы да шуңа бер ишарә иде...

Бәйрәмне бергә уздырырбыз дип, иртәгесен мин Херувимов янына киттем. Барып житсәм, радиостанция тирәсен халык сырып алган. Кайсы басып, кайсы утырган килеш радио тыңлыйлар. Концерт бара, бәйрәм концерты. Машина түбәсенә куелган динамиктан көчле, аһәңле җыр агыла:

Тиңсез киң ул минем туган илем,
Кырлары күп, урман, сулары...

Җыр әле украин телендә, әле үзбәк, яисә казакъ телендә шаулый. Солдатларның йөзләре бер уйчанланып, бер яктырып, нинди җыр, нинди музыка яңгыравына карап, үзгәрә тора. Әмма тирә-якта радиодан агылган авазлардан башка «шылт» иткән тавыш та юк. Барысы да бик бирелеп, әсәрләнеп тыңлыйлар. Хисләр ташый, хисләр ургыла... Туган илләреннән аерылып, чит-ят җирләрдәге кыя-тауларны, алкынсалкын суларны, иксез-чиксез ком дәрьяларын кичеп талчыккан, дошман белән якалашып арыган сугышчыларга әнә шундый самими, илаһи минутларны бүләк итүче, күңелләрдә олы, изге хисләр уятучы бу җырчыларны үзләре үк башкарган җырларына урап күкләргә күтәрәсе, зурлыйсы килә...

Чү!.. Ни ишетәм! Таныш аваз, бик күптәннән белеп, ишетеп өйрәнелгән тавыш ич бу?!

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, ямансу көн
Без аерылган көн бит ул.

Әйе менә көе дә, сүзләре дә миңа таныш түгел. Без киткәндә әле бу җыр юк иде.

Су буйлары тыныч була,
Моңсу була кич-иртән,
Кайтырсың, бәгырем, кайтырсың,
Тик көнен белмим, иркәм...

Гөлсем апа Сөләйманова! Ул... аның җырлавы... Халкыбызның яуда йөргән улларына кайнар да, моңлы да сәламе булып яңгырый иде бу җыр. Идел кебек киң күңелле, Идел кебек тирән хисле, тирән моңлы Гөлсем апа! Хәтерлим, кичкә кырын ашыгып кына минем янга кибеткә кергән иде. Армиягә озатасы энесенәме, туганынамы, юл хәстәре күреп йөрүе иде. Озакламый минем дә китәсемне белгәч: «Исән йөреп, сау кайт», энем, дигән иде. Хәзер менә җыры белән сәлам юллый... Әйтерсең лә, илдә калган сөйгән ярларыбызның бөтен уйларын, мәхәббәткә сусаган нечкә сагыну хисләрен үзенә җыйган да, хәзер инде аларны дөньяның икенче читендәге дусларына өләшә:

Җәйгә чыксам, иркен сулап
Йөрим су буйларында.
Лачын кебек батыр егет,
Син минем уйларымда...

Җыр тынды. Әмма аның моңы, күңелнең иң түренә сеңеп йөрәкне әле һаман да сулкылдата иде. Идел бит ул, киң бит ул...

Идел, Идел... Киң дә ул, тирән дә ул чал Идел! Ярларыңда тәгәрәп үскән улларыңнан кем генә сине сагынмый да, сиңа ашкынмый икән?! Идел, Идел... Көмеш пута! Шул путадан билен буып, мәңге нурлы, мәңге дәртле Казаныбыз каршысына баскан пәһлевандай, күз алдында әнә Ослан таулары... Идел, Казан, Ослан таулары... Алар шулай мәңге бергә, җырыңа да, төшеңә дә бергә керәләр...

Концерт һаман дәвам итте, солдат күңеле һаман ургыды, уйлар шулай кайта-кайта туган илкәй белән үрелде...

## Кави Латыйп

### Шыртан[1]

Халыкта бер әкият йөри,
Әле дә аны күпләр сөйли.
Авылларга хәбәр тарала:
Ленин чирли, авыр аңарга.
Күзләрдән кайнар яшьләр тама,
Картлар, яшьләр уйга кала.
Барысы да нишләргә белмиләр,
Дәвалау юлларын эзлиләр.
Кайгылы хәбәр зур юл үтә,
Чувашларга да килеп житә.
Ильичның хәле начар икән,
Әйтегез, нәрсә ашар икән?
Аңа без шыртан әзерлик,
Тормыйк ризык кысан хәзер дип.
Улып[2] шыртан ашаган, ди бит,
Һәм авырмый башлаган, ди бит.
Кешеләр шул карарга киләләр:
Эш башлый иң уңган жингәләр.
Дүрт-биш көндә шыртан өлгерә,
Ленинга илтер тик кем генә?
Кешеләр жыелып урамга,
Шобага тоталар буранда.
Куллар үрли таяк очына —
Шобага чал агайга чыга.
Озын сәфәр карт үткәнме,
Мәскәүгә барып житкәнме?
Ул хакта кешеләр белми.
Тик телдән-телгә әкият йөри,
Халык АНЫ сагынып сөйли.

### Кылыч

Минем эти
Кетү көткән, иген иккән.
Дошман килгәч, яуга киткән,
Башын салган,
Булсын диеп матур тормыш.
Эти, эти, йокла тыныч.
Түрдә тора синең кылыч.

---

[1] Шыртан — чуваш халкының яраткан ашы.
[2] Улып — әкият батыры.

## Эллада

Эллада, эллада,
Сиңа ни булды?
Тимер богаулы
Меңнәрнең кулы...
Тыңла, Акрополь,
Тыңла, Афина.

Фашизм — бомба,
Фашизм — мина!
Балкысын байрак
Тауда һәм җирдә.
Одиссей өе,
Манолис өе,
Һич булмас төрмә!

## Олы юлда бер шәһәр бар

Олы юлда бер шәһәр бар,
Исеме киңәш — Канаш.
Поезд килеп тукталуга
Елмая сиңа чуваш.

Татар туган, кунак бул! дип
Кулыңны юлташ[1] кыса.
Түзә алмый хисләренә,
Якын дус итеп коча.

— Хуш килгәнсең диеп сиңа
Сүз кушалар пиччәләр[2].
Ярылырга тора, имеш,
Сыра тулы мичкәләр.

Ефим сыйлый, Денис җырлый,
Шигырь сөйли Хузангай.
Сырага да, шигырьгә дә
Чуваш юмарт, чуваш бай.

## Камышлыдан аккош киткән...

*Әнвәр Давыдовка*

Шагыйребез кайтыр диеп
Камышлыда гөлләр үскән.
Бакчаларда җиләк пешкән,
Ул утырткан нарат көткән,
Тарантаслы пар ат көткән,
Бала-чага, ир-ат көткән,
Самоварлар кайнап торган,
Сандугачлар сайрап торган,
Халык белән урам тулган...
Таралмаган ләкин томан,
Көтмәгәндә хәбәр килгән,
Авыл буйлап яшьләр йөргән:
«Әнвәр үлгән!..» «Әнвәр үлгән!..»
Камышлыда камыш кипкән,
Камышлыдан аккош киткән...

---

[1] Юлташ (чувашча) — иптәш.
[2] Пиччәләр (чувашча) — агайлар.

**Рәис Сабиров**

# ХӘЗИНӘ ЭЗЛӘП...

Тормышта һәрвакыт шулай бит ул. Җитди эш эзләнүдән башлана. Разведкадан.

Дошманның үз оясында, үлем куркынычы астында, кыю эш алып баручы, һөҗүм планнарына нигез булып ятачак мәгълүматларны табучы курку белмәс тәвәккәл каһарманнарны да, йокы-ялларын онытып, лабораторияләреннән чыкмый ятучы галимнәрне дә, булачак машиналарның иң камил вариантын эзләүче инженер-конструкторларны да, һәм, билгеле, үз тормышларын җир асты хәзинәсен эзләүгә багышлаган кешеләрне дә халык разведчик дип атап йөртә.

Соңгылары инде табигать белән, ныклап торып карасаң, китапларда язылган төсле үк юмарт һәм юаш булудан хәтсез ерак торган табигать белән эш итәләр. Ул табигать дигәннәре, уч иткәндәй, хәзинәләренең иң кыйммәтлесен, кешегә иң кирәген меңнәрчә метр тирәнлектә, үтә каты җир токымнары астында яшереп яткыра. Ә аны табу җиңел эш түгел. Еллар буе бер уңышсызлыктан икенчесенә дучар була килеп, кем әйтмешли, чегән тормышы белән яшәп тә, айлар буе хатыныңны, балаларыңны күрә алмыйча, кеше аягы басмаган урыннарда уннарча разведка скважиналары бораулап та, аларның «кыгыр» булуын, еллар буе эзләнүләрнең нәтиҗә бирмәвен күргәч, үзең сайлап алган шул һөнәреңнән күңелеңне кайтармау, аңа кул селтәмәү өчен кыю җанлы кеше булырга, үзең хезмәт итә торган эшкә чиксез ышанган булырга кирәк.

Тарихчыларның әйтүенә караганда, нефтьнең беренче булып кайда һәм кайчан табылуы турында бернинди мәгълүматлар юк. Кешеләр могҗизалы бу сыек ягулык белән моннан 7—8 мең еллар элек үк таныш булганнар. Сакланып калган риваятьләргә, легендаларга караганда, ул заманнарда ук кешеләр Кече Кавказ тавы итәкләрендә, Иранда, Кытайда, Бохарада, Әрмәнстанда янган «мәңгелек ут» турында хәбәрдар булганнар. Аларның котын алган бу ут нефть һәм янар газның җир өстенә чыгуы белән, һичшиксез, бәйле булгандыр.

Борынгы Мисыр территориясендә казу эшләре вакытында кипкән нефть — битум калдыклары катыш яктырткыч тау токымнары табылган. Евфрат елгасы буенда үткәрелгән археология эзләнүләре безнең көннәрдән 6—8 мең ел элек үк инде бу урыннарда бик гади нефть промыселлары булуын раслаганнар. Европада нефтьнең әчүе нәтиҗәсендә туган продукт — асфальт моннан 4—5 мең ел элек үк билгеле булган.

Бик озак еллар нефть кешеләргә тыныч максатларда гына кирәк булган. Аның белән өйләрне яктыртканнар, аңардан дарулар ясаганнар, аның ярдәмендә таш стеналар корганнар. Ләкин бервакыт кешеләр бу сыекчаны дошманнарга каршы көрәштә дә файдаланып булуын аңлаганнар. һәм менә тарихчылар борынгы Рим галиме Плиниянең язмаларында камалган Лукула шәһәре өчен булган көрәшне сурәтләгән

юлларга тап булалар. Бу сугыш вакытында камалган шәһәрдә яшәүчеләр, крепость стенасыннан т ып, һөҗүмчеләрнең башларына янып торган нефть агызганнар. Безгә тарих буенча илгеле булган «грек уты» да шул ук нефть белән бәйле. Мәсәлән, 941 елда борынгы Византиянең башкаласы Константинопольгә яу белән килгән князь Игорьнең флотилиясе шул «грек уты» белән яндырыла.

Безнең ватаныбыз территориясендә нефть беренче булып Кавказның көньяк-көнчыгышында табыла. Моннан мең ел элек гарәп галиме географ Масуди үзенең Апшерон ярыматавына ясаган сәяхәте турындагы язмаларында бу урыннарда күп нефть табылуы һәм Кече Азия илләренә чыгарылуы турында искә ала. Апшерон ярыматавын биләгән республиканың Әзербайҗан дип аталуы да юкка булмаган, әлбәттә, чөнки иранча «әзер» — «ут» дигән сүз.

Нефтьне промышленность максатларында файдалану 19 гасырның урталарында гына башлана. Аңа кадәр нефтьне бик примитив ысул белән чыгарганнар: коелар казып, сыек ягулыкны шуннан чиләкләр ярдәмендә чумырып ала торган булганнар. Табылган нефтьне махсус чокырларда саклаганнар, ә башка урынга илтәсе булганда аны күн капчыкларга — бурдюкларга тутырганнар.

Каспий диңгезе буенда да шулай булган. Тик 1848 елда гына А. Ф. Семенов фамилияле тау инженеры проекты буенча биредә скважина бораулана. Бу — дөньяда беренче нег скважинасы. АКШта исә мондый скважина 11 ел соңрак — 1859 елда бораулана.

Бораулау нефтьне җир астыннан промышленность ысулы белән чыгару өчен гаять зур мөмкинлекләр ача. Нефть чыгару искиткеч кызу темплар белән үсә. Әгәр 1860 елга кадәр бөтен җир шарында елына 2—5 меңәр тонна нефть чыгарылган булса, 1862 елда бу сан 30 мең тоннага җитә. 1955 елда инде бөтен дөньяда 868 миллион тонна нефть чыгарыла. Ә 1968 елда исә безнең илдә чыгарылган нефть күләме генә дә 300 миллион тоннадан артып китте.

Нефтьнең килеп чыгышы мәсьәләсе озак еллар буе галимнәр арасында зур һәм принципиаль бәхәскә сәбәпче булып килгән. Берәүләр аның килеп чыгуын хайван яисә үсемлек организмнарының таркалу нәтиҗәсе итеп санаганнар. Икенчеләре исә биологик процессларның ролен бөтенләй икрар итмәгәннәр һәм нефтьнең органик булмаган юл белән килеп чыгуын раслап дәлилләр китергәннәр.

Шул рәвешчә, «кара алтынның» барлыкка килүе турында 5 дан артык фәнни гипотеза туган. Безнең гасырның 30 елларында гына совет нефть фәненең атасы саналган академик Иван Михайлович Губкин бу ягулыкның органик юл белән килеп чыгуы турында кире кагылгысыз дәлилләр китергән.

Бу теорияне, И. М. Губкин теориясен, гадәттә «сапропель теориясе» дип, яисә «сапропелит теориясе» дип йөртәләр. Сапропель грекчадан тәрҗемә иткәндә «черек ләм» дигән сүз. И. М. Губкин нәкъ сапропельнең нефть өчен ана матдә булганлыгын исбат иткән.

Бик катлаулы һәм озак дәвам иткән химик процесслар нәтиҗәсенә нефтькә әверелергә сәләтле органик матдә хайван организмында да, үсемлекләрдә дә бар. Алар коры җирдә дә, су бассейннарында да, һавада да яшиләр. Берәүләре бик зур, икенчеләрен микроскоп аша гына күреп була. Хәзер галимнәр 500 000 төрле үсемлек һәм 1 000 000 төрле хайван бар дип саныйлар.

Һәлак булган организмнарның шактый өлеше йомык су бассейннарының төпләрендә яисә ачык диңгезләрнең яр буе өлешендә туплана. Билгеле, бу нигездә тормышлары су белән бәйле булган организмнарның калдыкларыннан тора. Җирдә яшәгән организмнарның калдыклары исә әзчылыкны тәшкил итәләр.

Менә шушы органик калдыклар, балчык белән бергә кушылып, желатинга охшаш ләм — сапропельне хасил итәләр. Вакыт үтү белән су бассейнының режимы үзгәрү сәбәпле, сапропельнең туплануы туктала, аның өстенә башка катламнар, мәсәлән, ком утыра башлый һәм шулай итеп сапропель әста күмелеп кала. Ләкин органик матдәләрнең таркалу процессы тукталмый. һәм бу процесс төрле шартларда төрлечә бара. Температура югары һәм коры булганда ул бик тиз бара, органик матдә газ хаденә керә һәм атмосферага оча. Салкын булганда, мәсәлән, мәңгелек туңлык шартларында, органик кушылмаларның таркалуы, кислород аз үтеп керү сәбәпле, әкрен бара. Сапропель катламы һаман аста кала барып, тыгызлана, аста калган саен югары тем-

пература һәм басым зонасына эләгә, аңа радиоактив нурлар йогынты ясый башлый. Шул ук вакытта черү процессының гадәти юлдашы булган бактерияләрне дә истән чыгарырга ярамый. Алар органик матдәләрне таркатып кына калмыйлар, үзләре дә үрчеп, бу матдәләрнең күләмен тагын да арттыралар. Шулай итеп гасырлар үтү белән ахыр чиктә майлардан, аксымнардан һәм углеводлардан торган органик матдә газ хәлендәге углеводородка әверелә.

Бик кыска гына һәм гади генә итеп әйткәндә, академик И. М. Губкинның теориясе менә шуннан гыйбарәт.

Сапропельләрдән барлыкка килгән нефть күпчелек очракта үзенең «туган җирендә» генә утырып калмый,— аерылгысыз юлдашлары — газ һәм су белән берлектә җир асты буйлап зур сәяхәткә чыгып китә,— галимнәр әйтмешли, үзенең миграциясен башлый. Җир катламнарындагы ярыклар, бушлыклар аша үтеп кайчак җир өстенә үк килеп чыга һәм өлешчә һавага очып бетә, өлешчә әчеп, асфальтка әверелә. Күпчелек очракларда исә ул, зур күзәнәкле булганга, үзенә сыекча һәм газны күп итеп «сеңдерергә» сәләтле катламнарга — коллекторларга эләгә дә, чыгар урын таба алмыйча, шунда торып калырга мәҗбүр була. Мондый коллекторларда өч дус — нефть, газ һәм су, чагыштырма үлчәүләре нинди булуга карап, түбәндәгечә урнашалар: иң аста су, уртада нефть, ә өстә — газ.

Димәк, җир астында бер урыннан икенчесенә сәяхәт итеп йөрүче нефтьне әле промышленность өчен яраклы ятма дип булмый. Мондый ятма барлыкка килсен өчен аның «капкынга эләгүе» кирәк. Тынгы белмәс геологлар, бораулаучы-разведчиклар менә шулай «капкынга эләккән» нефтьне эзлиләр дә инде.

Нефтьнең тарихы турында кыскача менә шуларны әйтеп була. Инде Татарстан нефтенә әйләнеп кайтыйк. Аңа әле яңа гына егерме биш ел тулды. Әйе, республикабыз нефтенең тарихын Шөгердәге фонтан биргән беренче скважинадан башласаң, бу шулай. Ә менә Идел һәм Кама буйларында кешеләр беренче тапкыр нефть билгеләренә тап булган ерак заманнарны күздә тотсаң, безнең нефть елъязмасының башы каядыр 18 гасырларга барып тоташа.

Моннан ике йөз ел элек үк инде кешеләр безнең тирәләрдә «җир асты мае» белән кызыксына, аны эзли, аны үз файдасына «җигү» турында хыяллана башлаганнар.

Бу дулкынландыргыч елъязмага өстән генә булса да күз йөртеп чыгыйк.

Идел-Кама буйларында һәм, аерым алганда, Татарстан җирләрендә сыек ягулык ятмаларының булуы турындагы беренче рәсми мәгълүматлар 17 гасырның 80—90 елларына туры килә. «...Ярлылык һәм байлык турында» дигән мәгълүм китапта Иван Посошков дигән кеше, мәсәлән, болай дип язган: «Нефтьне мин күпләп таптым... меңәр потлап чыгарып була».

«Казаннан күпләп нефть табылуы турында язалар...»[1] Монысы инде безнең көнгә кадәр сакланган икенче бер чыганактан — Петр I заманында чыгарылган «Хәрби эшләр һәм бүтән эшләр турындагы ведомостьлар» дигән китаптан алынган. Хәбәрнең датасы 1703 елның гыйнвары ае.

Билгеле, бу хәбәрләрдә сүз бүген без аңлаган мәгънәдә нефть ятмалары турында түгел, бәлки җир өстенә астан бәреп чыккан нефть турында, ягъни «нефть чишмәләре» дип йөртелгән нәрсәләр турында гына бара. Ә чын хәзинә үзе кайдадыр ерακта, ул заманнарда әле кеше үтеп керә алмаслык тирәнлектә яткан.

Бик күбәүләр җир мае — нефть турында хыялланган, аны табу хакында күп төрле прогнозлар корган.

Г. Романовский, П. Еремеев, П. Паллас, И. Лепехин, А. Иванов, А. Павлов, А. Штукенберг һәм башка күп кенә галимнәр, инженерлар һәм геологлар Казан губернасының һәм гомумән Идел буеның җир асты хәзинәләрен өйрәнүгә күп көч куйганнар, шуңа гомерләрен багышлаганнар.

Нефть белән кызыксынган, бу байлыкны эзләгән һәр кешене халык өчен тырышып йөргән дип әйтеп булмый, билгеле. Үткән гасырның 60 нчы елларында, уллары белән бергәләп, Сок һәм Чишмә елгалары буенда бораулау эшләре алып барган Малакиенко фамилияле Бөгелмә алпавытын да, беренче бөтенденья сугышы алдыннан «Казан ойл филд» («Казан нефть промыселы компаниясе») дигән исем астында акционер

[1] В. В. Данилевский. Русская техника. Ленгосиздат. 1948 ел, 36 бит.

җәмгыять оештырырга да өлгергән инглиз империалистик акулаларын да халык ихтыяҗлары кызыксындырмаган.

Ләкин ничек кенә булмасын, бу эзләнүләр еллар, гасырлар буена нәтиҗәсез кала барганнар.

...Һәм менә бөтен дөньяга яңа эра, социализм эрасы килүен хәбәр иткән Октябрь революциясе.

...Дәһшәтле 1919 ел. Бөтен яктан революция дошманнары тарафыннан камап алынган, ач, ялангач яшь Совет республикасы үзенең киләчәге турында уйлый, илнең байлыгын арттыру турында кайгырта. Яңа туган республиканың зирәк юлбашчысы бөек Ленин кушуы буенча «кара алтын» хәзиналәрен эзләүне дәвам иттерү өчен Идел буйларына геологлар китә.

Менә бер кызыклы документ. Аны әле күптән түгел генә Казан галимнәре Октябрь революциясенең Үзәк архивында таптылар. 1919 елның 26 августында В. И. Ленин адресына җибәрелгән телеграмма. Аңа академик И. М. Губкин һәм Бөтенроссия халык хуҗалыгы советы президиумы члены Сыромолотов кул куйган:

«Мәскәү, Кремль, Ленинга.

Сюкеево нефть ятмасын беренче тикшерүләр тирәнгә бораулауның кирәк икәнен күрсәттеләр. Скважинага урын сайлау өчен профессор Ионскийга өч атна срок эчендә ятманың геологик төзелеше детальләре турында мәгълүматлар хәзерләргә кушылды. Бораулау эшләренә керешү мәсьәләсен конкрет тикшерү, без Мәскәүгә кайткач, Главконефтьтә булачак. Идел аръягының күп кенә пунктларында нефть билгеләренең булуы күптән билгеле. Сугыш аркасында бу пунктлар Главконефть каршындагы Геология комитетының эш программасына кертелгән иде. Скважиналарны урнаштыру өчен аерым урыннар сайлау башта геологик яктан җентекләп тикшеренүләрне һәм разведкалар ясауны таләп итә, һәм бу эшләр Главконефть Тау эшләре Советының һәм, беренче чиратта, Геология комитетының эш программасына кертеләләр. Хәзерге вакытта геолог Бутовка Чистай районында гудроннарның җир өстенә чыгуын тикшерү тапшырылды. Уңай мәгълүматлар алынса, бу районда нефть өчен тирәнгә бораулый башлау мәсьәләсе куелачак. Эшләрнең торышы турында тулы доклад без Мәскәүгә кайткач ясалачак»[1].

Ул вакыттагы искиткеч күп эш, баш әйләнгеч ыгы-зыгы арасында менә бу документка игътибар итү, аңа ышану, аның буенча шунда ук чаралар күрә башлау өчен ленинча алдан күрә белү сәләтенә ия булырга, социалистик Россиянең якты киләчәгенә, аның чиксез мөмкинлекләренә, аның потенциаль көченә ленинча нык ышанырга, шул илнең киләчәктәге экономик үсеше турында ленинча акыллы итеп кайгырта белергә кирәк иде.

Төркстан Үзәк Башкарма Комитеты адресына үзенең мәшһүр телеграммасын җибәргәндә, Владимир Ильич академик Губкин җитәкчелегендәге белгечләр группасы тарафыннан Татарстан һәм Идел буеның бүтән районнарында башкарылган шул эшләрне дә күз алдында тота.

Менә ул телеграмма:

«1919 ел, 29 октябрь.

Главконефть моннан элек Мартукта, Джуста нефть өчен салынган скважиналарның разведка нәтиҗәләрен ачыклау өчен Тимер районында эшләр башлый һәм бер үк вакытта бораулау инструментының бер өлешен гомуми интересларда **Идел районында ашыгыч нефть разведкасы өчен файдалана.** Главнефтьнең бөтен эш программасы җаваплы һәм чиктән тыш ашыгыч характерда... Программаны тормышка ашыруны һәртөрле әкренәйтү Совет Республикасына төзәтеп булмастай зыян китерә... Главнефтьнең тулы җаваплылыгы астында үткәрелә торган эшкә бернинди дә киртәләр һәм волокита кормаска тәкъдим ителә. Каршы эш итү республика эшен харап итү өчен аңлы рәвештә тормоз ясау дип каралачак.

Совнарком председателе Ленин»[2].

Бу инде гасырлар буе дәвам иткән эшке бөтенләй яңа нигездә керешү, аңа яңа эчтәлек салу дигән сүз иде. Бу Идел буенда һәм илебезнең бүтән районнарында

---

[1] «Советская Татария» газетасы, 1960 ел, 14 апрель саны.

[2] XXIV Ленин җыентыгы, 74 бит.

табигый байлыкларны эзләү турында эшче-крестьян власте үзе кайгыртачак, бу мөһим эшне үз кулына алачак дигән сүз иде. Һәм, ниһаять,— моны хәзер һич икеләнмичә әйтергә мөмкин,— бу Татарстанның экономик киләчәге хәл ителде, сукыр лампалы Татарстан, чабаталы Татарстан нефть Татарстанына, химия Татарстанына әвереләчәк, дигән сүз иде.

Гражданнар сугышы, экономик җимереклелек, ачлык аркасында килеп туган коточкыч кыенлыкларга да карамастан, Идел тирәләренә уннарча, йөзләрчә геологлар китә. Алар аерым районнарның геологик карталарын ясыйлар, структура бораулавы алып баралар.

Ләкин бу энтузиастларның башлаган эшләрен уңышлы алып баруга булган ышанычлары күп киртәләргә очрый. Ул вакытта әле геология фәнендә, шулай ук илебездә файдалы казылмаларны эзләү һәм файдалану белән шөгыльләнүче үзәк ведомстволарда Идел буеның нефтькә бай булуына бөтенләй ышанмаучы, аны бу яктан перспективасыз дип санаучы галимнәрнең һәм инженерларның позициясе шактый көчле иде. Менә бер генә мисал. 1918—1920 елларда К. Калицкий һәм Н. Тихонович җитәкчелегендә геологлар группасы Сок һәм Чишмә елгаларының югары агымында, шулай ук Сюкеево тирәләрендә тикшерену эшләре алып баралар. Тикшеренү нәтиҗәсендә бу галимнәрнең нинди нәтиҗәгә килүләрен К. Калицкий кулы белән язылган түбәндәге юллар яхшы күрсәтә: «Казан, Уфа һәм Самара губерналарындагы ятмалар, практик күзлектән караганда, бернинди игътибарга лаеклы түгелләр» [1].

Сүз ялгышып, ашыгычрак нәтиҗә ясаган бер галимнең шәхси фикере турында гына барса, бәлки, хәзер көлке тоелган бу юлларга игътибар итүче дә булмас иде. Геология фәнендә һәм геология комитетында шактый югары урын биләгән бу кешеләрнең ялгыш һәм хәтта зарарлы карашы, кызганычка каршы, тиздән шушы комитет йөзендә үзәк дәүләт органының рәсми документы көченә ия була. Комитет Идел буенда нефть эзләүне бөтенләй туктату турында карар чыгара.

Идел-Урал районында җир катламнарының нефтькә бай булулары турындагы идея беренче тапкыр практикада 1929 елда расланды. Бу елның апрель аенда Уралда Чусовские городки тирәсендә тоз табар өчен бораулана торган скважинадан, һич көтмәгәндә, нефть фонтаны бәреп чыкты. Бу моңа кадәр күрелмәгән шау-шулы язның иң беренче карлыгачы иде.

Көтелмәгән ачыш геологларны канатландырып җибәрдә. Эзләнү эшләре икеләтә, өчләтә артык энергия белән башланып китте. Уңышның моннан да зуррагы, моннан да куанычлырагы тагын 5 елдан соң — 1933 елда килде. Бу юлы чын мәгънәсендә бәйрәм безнең якын күршеләребез — башкорт туганнар җирендә булды. Ул елны Ишимбай шәһәре якынында «кара алтын»ның шактый зур промышленность ятмалары табылды. Күп тә үтмәде, промышленность нефте Сызраньда, аннары Бугуруслан янында һәм, ниһаять, Татарстанның нәкъ чигендә — Туймазада табылды. Бу инде Идел-Урал районына ким сетеп караучы скептик-геологларга зур удар, академик И. М. Губкин теориясенең тантанасы иде. Шушы вакыйгалардан соң, бигрәк тә партиябезнең XVII съездыннан соң, совет халкы телендә яңа сүз — «Икенче Баку» дигән нәрсә йөри башлады.

Еллар үтте. Коммунистлар партиясенең чираттагы XVIII съезды яңадан бу мәсьәләне кузгатты. Ул кабул иткән резолюциядә менә мондый юллар бар: «Идел һәм Урал арасында яңа нефть базасы — «Икенче Баку» төзәргә». Бу инде хыялның бөтенләе белән чынбарлыкка әверелүе, илебезнең якындагы иң мөһим экономик бурычларыннан берсе булып китүе иде.

Разведчиклар Татарстан җирләрендә эзләнү эшләрен торган саен киңрәк җәелдерделәр.

Казан архивларының берсендә сакланган тагын ике документ белән танышып китик.

«ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретарена,
Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы председателенә
СССР Халык Комиссарлары Советының 1937 ел 17 ноябрь № 2042 карарын үтәп

---

[1] К. Калицкий. «Казан, Уфа һәм Самара губерналарының нефть ятмалары». «Известия Геологического комитета». 1920 ел. 39 том. 535 бит.

һәм сезнең республиканың табигый байлыкларына разведка алып баруга чиктән тыш зур әһәмият биреп, Авыр промышленность халык комиссары... 1938 ел 28 июль № 275 карары белән, Татарстан АССРның Махсус геология идарәсен оештырырга боерык бирде. Авыр промышленность Халык Комиссарлыгының Баш геология идарәсе, Сезгә... приказын җибәреп, оештырыла торган идарәнең эзләнү һәм разведка алып бару эшләрен үз күзәтүегез астына алуыгызны үтенә.

СССР Авыр промышленность Халык Комиссарлыгының Баш геология идарәсе начальнигы академик И. М. Губкин. Август. 1938 ел».

«ВКП(б)ның XVIII съездының кенчыгышта «Икенче Баку»ны төзү турындагы карарына туры китереп, ВКП(б) өлкә комитеты һәм ТАССР Халык Комиссарлары Советы

**КАРАР БИРӘЛӘР:**

4... Кама тамагы һәм Шөгер районнарының структуралары 1939 елның ахырына промышленность разведкасына хәзерләнәчәкләр, һәм бу эшләр кичекмәстән башлап җибәреләчәк».

ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советының 1939 ел, 17 апрель карарыннан).

Шул ук 1939 елда Казанда Геология-разведка тресты оештырыла. Соңрак аңа «Татнефтегазразведка» тресты исеме бирелә. Бу махсус предприятиенең оештырылуы нефть эзләү эшләрен тагын да киңрәк күләмдә алып бара башлау өчен зур этәргеч булды.

Бу вакытта инде Татарстан территориясендәге нефть ятмалары булуы ихтимал дип саналган төп районнарның (аерым алганда Шөгер районын) структура-геологик карталарын эшләү тәмамланган иде.

Ләкин тиздән күп планнарны чәлпәрәмә китереп, күп эшләрне куеп торырга мәҗбүр иткән сугыш башланып китте. Әмма илебез мондый шартларда да нефть эзләү эшләрен туктатмады. Буровойларда сугышка киткән бораулаучылар урынын совет тылының чын каһарманнары хатын-кызлар алды. Күз алдыгызга китерегез: буровойда хатын-кыз... Хәер, нәрсәгә гомуми сүзләр? Шундыйларның берсе белән генә танышып үтик...

Әле менә соңгы вакытка кадәр «Татнефтегазразведка» трестының Минзәләдәге бораулау конторасында дизелист булып инде чәченә көмеш йөгергән тыйнак бер хатын эшләп йөрде. Баш әйләндергеч рекордлар куйганы юк аның. Үз урынында тавышсыз-тынсыз гына эшли бирә. Ләкин бу хатынның тормышы, утыз елга якын сузылган хезмәт юлы — үзе бер каһарманлык.

Миһербансыз сугыш Полина Ивановна Мазалованы семьясыннан мәхрүм итә. Ирсез калган яшь тол хатын, туган якларын, йорт-җирен ташлап, илнең көнчыгышына юл тота. Сыеныр урын эзләп, Идел буе шәһәрләрендә, авылларында озак йөри. Ниһаять, язмыш аны Кама буендагы Болдыр авылына, Чистай тирәләренә китерә. Әле революциягә кадәр үк нефть билгеләре булып, разведка эшләре алып барылган тирәләргә.

Телдән телгә күчеп, хәбәр тарала: авылдан ерак түгел генә җирдә разведчиклар җир бораулый башлыйлар икән... Хәбәр Полина Ивановнаны гаҗәпләндерә дә, шатландыра да: ичмасам, шул эштә ничек тә онытылып, йөрәк ярасын дәвалап булмасмы? Һәм ул, озак уйлап тормастан, бораулау бригадасына эшкә керә. Ирләр булып ирләрнең күбесе күтәрә алмастай авыр эшкә. Полина Ивановна барына да түзә, сугыш вакытының кыенлыкларын бернинди шыңшусыз батыр кичерә, ирләр эшенә тиз ияләшә, алардан калышмый эшли. Тәҗрибәле бораулаучылар да бу хатынның тырышлыгына, батырлыгына хәйран калалар. Мазалова бригадада кочегар булып та, дизелист булып та, бораулау эшчесе булып та эшли, үзе ияләшкән коллектив белән бергә республиканың күп кенә районнарында була. Шөгердә дә, Әлмәт якларында да, Акташта, Чаллыда һәм хәтта Куйбышев өлкәсенә чыгып та нефть скважиналары бораулый.

— Булды инде, төрлесе булды,— ди Полина Ивановна.— Бервакыт бригадада тик бурильщиклар гына ирләр иде. Калган бөтен эш хатын-кыз җилкәсендә...

Полина Ивановна Татарстан нефть промышленносте тарихына алтын хәрефләр белән язылачак тарихи август көнен дә яхшы хәтерли. 1943 елның августын. Ул көнне алар яшәгән авылга шаккатыргыч шатлыклы хәбәр килеп төшә: Шөгер районында Хәмидуллин бригадасы, ниһаять, нефть тапкан!! Башка иптәшләре, белән бергә, Мазалова да бу уңышка чын күңелдән шатлана һәм нәкъ менә шул көнне күңеленә хуш килгән авыр профессияне беркайчан да ташламаска дип, үз-үзенә сүз бирә. Һәм ташламый да. Утыз ел чамасы, чәчләренә чал кергәнче, нефть разведчиклары белән кулга кул тотышып эшләп йөри.

...Шөгер нефть ятмасы. Никадәр авырга төште ул геологлар белән бораулаучыларга. Ничек зарыктырып, никадәр тир түктереп килде ул хәзинә!

Хәзер бөтен илебезгә таныш булган Шөгер авылы янында салынган ул тарихи скважина үзе генә дә ике елдан артык вакыт бораулана. Ике ел. Гитлерчыларга каршы сугышның иң авыр чакларына туры килгән, бүген кешегә әйтсәң кеше ышанмас котočкыч читен хезмәт белән үткән ике ел. Чын күңелдән ышану һәм өметсезлеккә бирелү еллары. Кыенлыкларга каршы, ачлыкка каршы, үз-үзеңә каршы, үзеңнең торып-торып әнә шул өметсезлеккә төшүеңә каршы, барын да ташлап, башка бер җиргә күчеп китү теләгенә каршы көрәш еллары.

Геологлар, бүгенге Дәүләт премиясе лауреатлары С. П. Егоров һәм А. М. Мельников, шәхси үрнәк күрсәтеп, кешеләрне кыенлыклар алдында баш имәскә өйрәтәләр, аларның күңелләрен күтәрергә, канатландырырга тырышалар. Мастерлар Гариф Хәмидуллин һәм Яков Буянцев, механика мастерское мөдире Николай Свиягин, ару-талуны белмичә, үз коллективларын әйдәп баралар. Шөгер разведкасының өлкән мастеры С. И. Маковский һәм өлкән инженер И. Г. Шеламонов та алар белән бергә атналар буе буровойдан китми яталар, тәпле киңәшләре, ягымлы сүзләре белән бораулаучыларга рухи азык бирәләр.

Бригадалар вахтада бер берсе белән ярышып эшли. Туган якларына әйләнеп кайтканчы, озак еллар буе Грозный нефть промыселларында эшләп йөргән, шунда шактый зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, бораулау остасы буларак шомарган мастер Гариф Хәмидуллин күп кенә матур башлангычларның инициаторы була.

Менә бер генә мисал. 1943 елның буранлы февраль иртәсендә вахтага килгән бораулаучылар культбудка дип йөртелгән шыксыз гына алачык ишегенә ябыштырылган кәгазьгә игътибар итәләр. Анда: «Әйдәгез, дуслар, кайсы вахта, кайсы бригада нефть ятмасына тизрәк барып җитәр икән?!» Ашык-пошык язылган бу сүзләр арыган, йончыган, скважинаның «бәхетле» булачагына өметләрен югалта башлаган кешеләргә бөтенләй көтелмәгәнчә тәэсир итәләр. Димәк, бу урында нефтьнең булмавы турында ике төрле сөйләү урынсыз, бу хәл ителгән, бәхәссез нәрсә. Хәзер менә мәсьәлә бары тик шунда: ул нефтькә кайсы бәхетлесе тизрәк барып җитәр икән? һәм ярым шаярып башланган бу нәрсә бораулаучылар арасында айлар буе дәвам иткән һәм хезмәттә зур этәргеч булган бик җитди ярышны китереп чыгара.

Гариф Хәмидуллин бригадасы шул ук елның апрель ахырында икенче бер патриотик адым ясый: Май бәйрәме көннәрендә ял итүдән баш тарта һәм ул көннәрдә эшләп алган акчаларын оборона фондына тапшырырга була. Бу тәкъдимгә башка бораулаучылар да кушыла.

Шөгер янындагы скважинаны бораулау тирә-күршедәге барлык авыл хезмәтчәнләренең, бөтен районның, бөтен республикабызның уртак эшенә әверелә. Колхозлар, колхозчылар кулларыннан килгән бар нәрсә белән бораулаучыларга ярдәм итәләр: өмәләр оештыралар, атлар биреп торалар, үзләреннән өзеп булса да, азык-төлек белән тәэмин итәләр.

Һәм менә ул озак, бик озак көтелгән шатлык. Нефть табылды! Татарстан, ниһаять, нефть республикасы. Бик күбәүләрнең гасырлар буе дәвам иткән хыялы тормышка ашты! Дөрес, бу беренче карлыгач, хәзерге күзлектән караганда, әллә ни зур түгел: скважина тәүлеккә нибары 20 тонна нефть бирә. Ләкин эш ул санда гына түгел бит, нефть бар — халык өчен менә шунысы мөһим. Кара алтын эзләүчеләр дөрес юл белән баралар — менә шунсы куанычлы.

Шөгернең тагын бер бик мөһим ягын әйтеп үтәргә кирәк. Андагы беренче скважинаны бораулау уннарча геологлар, инженерлар, бораулаучылар өчен бик зур өйрәнү мәктәбе булды. Биредә Гариф Хәмидуллин һәм Яков Буянцев кебек тәҗрибәле

осталар янында, алар кул астында соңыннан бөтен республикага танылган Н. Михайлов, С. Кузьмин кебек атаклы бораулау мастерлары чын мәгънәсендә профессиональ сабак алдылар.

Дәүләт премиясе лауреаты, яше шактый булса да яраткан эшен ташламаган геолог Сергей Петрович Егоров шундыйларның берсе турында бүген менә нәрсә сөйли:

— Сугыш әле яңа гына туктаган чак. Мин — Шөгер разведкасының өлкән геологы. Безнең разведчиклар инде бу ятмада бишенче скважинаны бораулап маташалар. Кеше җитешми. Шулай да очраган бер кешене аласы килми. Менә көннәрдән бер көнне буровой янына әле погонын да салырга өлгермәгән бер яшь офицер килеп туктады. Бик озак карап торды һәм бер сүз эндәшмичә китеп барды. Икенче көнне тагы килде. Бу юлы сөйләшеп киттек. Күрәм, безнең тирәдә тикмәгә йөрми егет, ниятe җитдигә охшый, үзе һаман разведчикларның эше турында сораша. Читләтеп кенә үзенең җитди бер эшкә тотынырга теләвен сиздерә. Ошады бу егет миңа: шапырынмый, ашыкмый, төпле кеше күренә. Разведкага яңа кеше алганда, ашыкмаска дип, үз-үземә сүз биргән булуымны да онытып, әйтеп ташладым:

— Соң әйдә, безгә кил, безнекеннән дә җитдирәк нинди эш табарсың бу тирәдә?

— Шулаен шулай. Тик ошарбыз микән соң без бер-беребезгә: мин разведкага, разведка — миңа?..

Фәсхетдин Шәрәфетдинов разведкага әнә шулай килә. Бораулау эшчесеннән башлап мастерга кадәр үсә. Татарстанның иң танылган разведчикларыннан берсе булып китә, Социалистик Хезмәт Герое дигән исемгә лаек була. Узган егерме өч ел эчендә уннарча мең метр тау токымын тишеп үтә, республикабыз территориясендә үз бригадасы белән берничә нефть ятмасы ача.

* * *

...Бөгелмә шәһәреннән чыгып, киң асфальт юл белән көнчыгышка таба баручы юлчының игътибарын барыннан да элек бер туктамый баш иеп, җиргә сәлам биреп торучы скважиналар җәлеп итә. Алар көмеш сыман трапларын һәм нефть үлчәгечләрен кояшта ялтыратып, тугандаш Башкортстан җиренә кадәр рәт-рәт булып тезелешеп утыралар.

Шигырьләрдә мактала, җырларда җырлана торган Баулы нефть мәйданы әнә шул инде.

Мөбарәк Кәримов өчен болар: скважиналар, товар парклары, әле һаман андасанда янып торган газ факеллары җыр да, шигырь дә түгел. Аның өчен болар — һәр көн күз алдында тора торган реаль чынбарлык. Үз күз алдында, аның үз куллары белән барлыкка китерелгән чынбарлык. Ләкин көн саен шулар яныннан үткәндә, ул дулкынланмый кала алмый.

Мөбарәк Кәримов оператор. Ул иртә тору белән скважиналары янына ашыга, аларның ничек «сулауларын» тикшерә, кирәк икән аларга «ярдәм итә»: трубаларын парафиннан чистарта, сальникларын тыгызлый.

1966 елның 17 сентябрендә дә ул гадәттәнчә иртә уянды. Тын поселокның буш урамнарыннан үтте, кырга чыкты. Егерме еллык гадәт үзенекен итте: Кәримов салмак кына атлый-атлый бүген, иртәгә, бу атнада эшлисе эшләрен үзалдына санап-барлап барды, кичәгеләрен уйлады.

Менә ул бер скважина янына туктады.

Нәрсәсе белән җәлеп итте соң әле бу скважина операторның игътибарын? Болай тыштан карашка ул бүтәннәрдән бернәрсәсе белән дә аерылып тормый лабаса. Ә чынлабрак карасаң, ул бөтенләй «тынсыз калган» бугай әле. Чыннан да беренче номерлы скважина хәзер эшләми инде. Мөбарәк вахта журналына үз кулы белән ул биргән нефтьнең күләмен күрсәткән соңгы санны язып куйган кеше. 800 мең тонна. Яшәү һәм «эшләү» дәверендә скважина-«аксакал» әнә шул кадәр сыек ягулык бирергә өлгергән. Аз түгел бит! Ләкин Кәримовның скважинага ихтирамы моның өчен генә түгел. Аңа китсә, Баулы нефть мәйданында хәзер нефтьнә миллион тоннадан артык биргән скважиналар да бар.

Кәримовның ихтирамы скважинаның нәкъ менә беренче булганы өчен. Яңа нефть мәйданы — Баулы мәйданы турында хәбәр иткән тәүге карлыгач булганы өчен, Кәримов тормышына яңа мәгънә, яңа эчтәлек салганы өчен.

Ә бүген, 17 сентябрьдә, аның «аксакал»-скважинаның туган көне. Сугыштан соңгы беренче көздә, яңгырлы сентябрь көнендә туды ул. Кәримов бу көнне яхшы хәтерли. Баулыда бик күп кеше хәтерли ул көнне. Моңарчы бер нәрсәсе белән дә әллә ни аерылып тормаган татар авылына шау-шу алып килде ул скважина. Авыл читендә аның гөрелтесе көне-төне ишетелеп торды. Кәримов исә бу шау-шуны ерактан гына тыңлый алмады, шунда барып, бораулаучыларга булышты. Аннан ул шул скважинада оператор булып калды, нефтьче булып китте. Менә егерме ел инде дистәләрчә скважинаның хуҗасы булып йөри...

Шул көнне кич Баулыда митинг булды. Поселок уртасындагы мәйданда обелиск ачтылар. Мөбарәк Кәримов анда кешелеккә кия торган киемнәрен киеп барды, соңгы елларда танымастай булып үзгәргән Баулы урамнарыннан, бу көннең җитдилеген бөтен җаны-тәне белән аңлап, салмак һәм горур атлады.

Нефтьчеләр поселогына ул кичне күп кеше җыелган иде. Беренче скважинаны бораулауда катнашкан кешеләр, бу тирәләрнең байлыкларын үзләштерүдә беренчеләрдән булып көчләрен түккән кешеләр, нефть ятмасының икенче яшьлеге өчен бүген көрәшүчеләр, аталарының, өлкән туганнарының эшләрен хәзер дәвам иттерүчеләр җыелды.

Кыска гына митинг. Аның түренә, мактаулы урынга ветераннар баскан. Оркестр уйный. Обелискны каплап торган җәймә салмак кына җиргә төшә. Анда алтын хәрефләр белән түбәндәге сүзләр язылган:

**«БАУЛЫ ЯТМАСЫН ҮЗЛӘШТЕРҮГӘ КАТНАШКАН БАРЛЫК КЕШЕЛӘРГӘ БАГЫШЛАНА»**

Бу обелиск — геологларга, галимнәргә, разведчикларга, инженерларга, бораулаучыларга, гасырлар буе килгән хыялны чынбарлык итеп, девон тирәнлекләренә үтеп керүчеләргә, аның байлыгын халык файдасына эшкә җигүчеләргә рәхмәт билгесе, совет кешеләренең, Мотаһар Нургалиев, Мөбарәк Кәримов, Степан Баклушин кебекләрнең ныклыгына, батырлыгына һәйкәл.

...Татарстан нефтен табучылар турында сүз чыкканда еш кына: «Ә-ә, кем соң ул Баклушин?! Таптыгыз сөйләр нәрсә. Бәхетле кеше ул — менә шул гына. Кешенең фамилиясендә дә, характерында да түгел ул бәхет дигән нәрсә. Ивановка да, Сидоровка да, Хәкимуллинга да чыгуы бар аның. Аларга чыкса, алар герой, сиңа чыкса — син герой, вәссәлам!» — дигән сүзләрне ишетергә туры килә.

Әйе, разведкада, озак вакыт, чыдамлык таләп итә торган бу кыен эштә, иртәгә нәрсәгә ия буласыңны, нәрсә табасыңны һәм нәрсә югалтасыңны һич әйтеп булмый торган эштә, бәлки, бәхет дигән нәрсә дә бераз кирәктер. Тик менә нигәдер шул бәхет дигәннәре нәкъ Баклушин, Нургалиев кебекләр тирәсендә, куйган максатына ирешү өчен көчен кызганмый торган, тырыш, эшчән, кыю кешеләр, бу эштә бәхет миңа чыгармы, икенче берәүгәме, дип алдан ук күрәзәлек итми торган кешеләр тирәсендә йөрүчән була. Авыр разведкада бәхетне яулау һәр кемнең дә кулыннан килми. Адым саен алдын-артын карап йөри торган, иң башта үзе, үз файдасы турында, аннары гына эш турында уйлый торган артык сак кешеләргә мондый бәхет турында хыялланырга һәм бүтәннәр бәхетенә кызыгып, алардан көнләшеп яшәргә генә кала.

Ә менә моннан егерме елдан артыграк элек, Степан Баклушин Баулыга, соңыннан «бәхетле» булып чыккан әлеге беренче скважинага киткән вакытта, анда барырга ашкынып торучылар күп түгел иде...

Ул чак геологлар нефтьне Урал тавы итәкләрендә, башкорт җирендә эзлиләр иде. Шундагы разведка конторасы директоры көннәрдән бер көнне Степан Филипповичны үзе янына чакыра. «Тыңла әле, Филиппыч, сиңа Ыкның теге ягына китәргә кирәк бит... анда бораударга кирәк. Бүтән җибәрер кеше юк, аңла шуны: берсенең сәламәтлеге җитенкерәми, икенчесенең семьясы, балалары...»

Баклушин контора директорының куптән пәке тимәгән, соргылт тут йөгергән йөзенә карап, бик озак сүзсез утыра. Каршы сүз әйтәсе, баш тартасы, кычкырасы

килә аның: «Башкаларның семьясы семья, ә минеке семья түгел инде алайса,— диясе килә.— Лизама әле яңа уникe тулды, Коля әле быел гына икенче класска китте. Женя биштә генә, ә Света бөтенләй бәке бит әле...,— дип кычкырасы килә аның.

Хатыны да башыннан сыйпамас, тотып сүгәр, кешенең ире ир төсле, семья дип, хатыным, балаларым дип үлеп тора, дияр, син генә өеңдә утырып тора белмисең, мена әле дә, кыш уртасында, бар нәрсәңне ташлап, өч-дүрт йөз чакрым җиргә китәргә ашкынып торасың, дияр...»

Баклушин, директорга сүзсез текәлгән килеш, әнә шуларны уйлый, ә тегесе һаман үзенекен сөйли, яңа урындагы эш шартларын аңлата:

— Бер дә курыкма син, Филиппыч... Без сиңа торыр урын табарбыз, һич югында, үзебез салып бирербез. Шулай булгач, син баш өстендә түшәм бар дип сана. Мин сиңа чын дөресен әйтәм...

Сәер кеше бу директор! Әйтерсең, Баклушин анда, яңа җирдә торырга бернинди урын юклыгын белми. Торакны аны буш урында төзмиләр. Әгәр мена нефть табылса инде — ул вакыт башка хәл. Йортлар гына түгел, әллә нәрсәләрең үсеп чыгар. Тик ул вакытта разведчик инде бүтән җиргә, әлеге дә баягы торыр урын булмаган җиргә киткән булыр.

Хәер, директорның башка чарасы юк, шулай дими, үгетләми һәм хатта алдашмый хәле юк аның. Ә тагын да тәплэбрәк уйласаң, ерак җиргә, бу кыен разведкага аны директор түгел, ил үзе җибәрә... Сугышның әле яңа гына тәмамланган чагы. Дошман җимергән Грозный промыселлары әле яра-җәрәхәтләрен дәвалап бетермәгән... Ә илгә нефть кирәк, нишләсен ил нефтьсез?..

Һәм Баклушин үзе дә сизмәстән әйтә сала:

— Я, ярар, барам.

Һәм китә. Ә ике айдан, аякны җирдән суырып алгысыз көзге пычракта, хатыны балаларын алып килә.

Баулыдагы беренче скважинаны нәкъ өч ел бораулыйлар. Баклушин анда инде өченче мастер булып килә. Кыш буе, бу тирәләрдә шактый еш очрый торган урман хуҗасы — пошиларны өркетеп, бораулау җиһазлары ташыйлар, тракторлар белән өстерәп, авыр машиналар китерталәр, ә кар эрү белән, тагын бораауларга керешәләр... Баклушин беренче көннән соңгысына кадәр буровойдан китми, шунда яши...

Ә 1946 елның 17 сентябрендә... «Советская Татария» газетасындагы кыска бер хәбәр ул көн турында болай дип яза:

**«Татарстанның Баулы районында девон нефтенә разведка бораулавы алып барган «Туймазанефть» тресты нефть разведчиклары коллективы зур производство уңышына иреште. I номерлы бораулау скважинасы 1770 метр тирәнлектә девон чыгышлы нефтьле горизонт ачты.**

**18 сентябрьдә скважинаны сынап карау үткәрелде. Скважинаны ачканда нефть фонтанының биеклеге 40 метр биеклеккә җитте. Тәүлегенә 600—800 тонна промышленность нефте бирә торган скважина эксплуатациягә тапшырылды.**

**I номерлы скважина бораулау мастеры ип. Баклушин тарафыннан эшләнде.»**

Степан Баклушинның чыннан да кулы җиңел булып чыкты. Кайда гына скважина бораауламасыннар — нефть, кайсын гына сынап карамасыннар — фонтан... Степан Филиппович белән бергә Баулы нефть мәйданын «эшкә кушуда» хәзер бөтен Татарстанга билгеле булган ветераннар Мотаһәр Нургалиев, Газыйм Гайфуллин, Петр Костюхин һәм башкалар катнашты. Күп тә үтмәде, геологлар республикабыздагы беренче девон ятмасын картага төшереп тә алдылар. Ә бу эш тәгәлләнеп бетәр-бетмәс Тимәш-Ромашкино вакыйгалары кузгалды...

* * *

Туып үскән авылы Тимәшкә бу кайтуы аның элекке тормыш планнарын чәлпәрәмә китереп җимереп ташлар, аның киләчәген бөтенләй икенче бер сукмактан борып җибәрер дип башына да китермәгән иде Әхәт Гобәйдуллин. Исәбе бик гади генә иде

югыйсә: сугыш елларында хәтсез сагындырган Тимәшендә берәр атна кунак булу, ашыкмый гына барлык туган-тумачаларны йөреп чыгу, салмак кына сызгырып утырган самовар янында чәй эчә-эчә фронтта башыннан үткәннәрне сөйләү, малай чакта ялан аяк йөргән басу-кырларны, урманнарны урап кайту, ә аннан, сусаган күңел бераз тынычлана төшкәч, яңадан сугышка кадәр слесарьлык иткән тирәләргә — Мәскәү якларына сәфәр кылу иде. Ләкин язмыш дигәнең Гобәйдуллинга бөтенләй бүтән юл әзерләп куйган булып чыкты. Ул кайтып төшү белән Тимәштә баш әйләндергеч, искә төшергәндә бүген дә күңелләрне җилкендереп җибәрә торган вакыйгалар башланып китте. Кая гына барма — колхоз идарәсенәме, клубкамы, фермаларгамы — халыкның телендә бер генә нәрсә:

— Күрдеңме, күрше, әллә ниткән тимер пәһлеванны китереп куйганнар авыл очына?

— Күрмәгән кая ул! Тагын шунда җирне бораулыйсылар ди...

— Әйтмә дә, сөйләмә дә, әллә, мин әйтәм, бу юлы җир маен чыннан да табарга исәплиләрме?!

Тимәш халкы өчен «җир мае», «нефть» сүзләре яңалык түгел иде. Әхәт Гобәйдуллин яшендәге кешеләр аларны ата-бабалардан ишетеп беләләр. Әхәтнең әтисе әле революциягә кадәр үк Шандр исемле бай бер килмешәкнең Шөгер тирәсендә тирәнтирән коелар казытып нефть эзләве турында сөйләгән иде. Шул яклардагы шәрә бер биек калкулык әле дә булса «Шандр тавы» исемен йөртә. Ләкин ул чак җир үзенең хәзинәсен читләргә ачарга теләмәгән, ә хәзер...

Әхәт Гобәйдуллин туган авылыннан беркая да китмәде. «Нефть чире» белән йогышланып, шунда калды, разведчик булып китте. Тәҗрибәле слесарьның килүе бораулаучылар өчен дә ярап куйды, эшче кулларының җитешмәве үзен шактый сиздерә иде әле ул чакта. Өстәвенә тагын Тимәш скважинасы беренче йөз метрлардан ук бик нык «көчсезләнә» башлады. Я балчык измәсен бөтенләй тотып бетерә, я инструментны китереп кыса, яисә бүтәнчә «киртә җимерә» башлый. Хәер, шатлыклар да булмый түгел. Тимәшкә разведчиклар бригадасы, ниһаять, тәмам үзәккә үткән иләмсез зур пар машинасы урынына В-450А маркалы яңа двигатель алды. Бу хәл бораулаучыларның хезмәтен икеләтә җиңеләйтеп җибәрде. Буровойда иркенрәк, чистарак булып китте. Бу хәл исә хезмәт җитештерүчәнлеген шактый күтәрергә мөмкинлек бирде.

Тимәш тирәсендә бораулана торган өченче скважина иде инде бу. Беренче ике скважина «кысыр» булып чыкты.

Хәзер, егерме биш ел чамасы вакыт үткәч, барысы да бик гади төсле күренә: барып чыкмаган икән — икенчесенә тотын, өченчесенә... Ә ул чакта? Миллионнарча сумга төшкән ике скважинаны уңышсыз бораулап та шул җирдә үк тагын өченчесенә тотыну өчен бер нәрсә белән дә исәпләшми торган фанатик яисә үзеңнең хаклыгыңа чын күңелдән ышанган, фән һәм практикага оста таянып эш итүче, вакытлы уңышсызлыклар алдында баш имәүче зирәк белгеч булырга кирәк иде. Безгә инде Шөгер нефть ятмасы буенча таныш булган геологлардан А. М. Мельников, С. П. Егоров, И. А. Шпильманнар нәкъ менә шундыйлар булып чыкканнар. Шөгер ятмасын ачканнан соң, ташкүмер һәм девон структураларының бер-берсенә туры килмәвен һәм девондагы структураларның төньяк-көнчыгыш юнәлешенә авышуын ачыклап, алар Шөгердән 40 километр читтәрәк, Тимәш янында тирән скважина бораулый башларга кирәк, дигән кыю нәтиҗә ясыйлар.

Билгеле, алар галимнәрнең тикшерүләрен бик нык исәпләп эш итәләр. «Востокнефть» трестының геологлары В. И. Бутлеров, В. И. Монякин һәм М. Ф. Мартьевләрның һәм шул ук трестның Казан университеты профессоры Е. И. Тихвинская җитәкчелегендәге геология партиясенең күпьеллык тикшеренү нәтиҗәләренә таяналар.

Тимәштәге скважинаның нәрсә бирүе хәзер бөтен кешегә билгеле: 1948 елның 25 июлендә, бораулау эшләренең башлануына ел ярым вакыт үткәч, 3 номерлы скважинадан тәүлегенә 120 тонна дебитлы куәтле нефть фонтаны бәреп чыкты. Дөрес, гомуми тантана белән үткән бу көндә әле бер кем дә разведчикларның илебездә моңа кадәр тиңдәше булмаган уникаль нефть ятмасына тап булуларын белми иде. Мондый фикер, ә аннары мондый ышаныч нефтьчеләргә соңрак килде. Ә аңа кадәр әле эзләнүләрне дәвам иттерергә, табылган нефть ятмасының чикләрен билгеләргә кирәк иде.

Шөгер һәм Баулы Татарстан нефтьчеләре өчен беренче җитди мәктәп булса, Тимәш-Ромашкино исә нефть эшенең чын академиясенә әверелде. Ромашкино нефть фәнендә, нефть эзләү практикасында, нефть ятмаларын эксплуатацияләүдә, скважиналар бораулау эшендә моңа кадәр бәхәссез дип саналган күп кенә кануннарны кире какты.

Ромашкино промыселларында нефть разведкасының чын осталары үсеп чыкты. Инде безгә таныш булган Степан Баклушин, Фәсхетдин Шәрәфетдинов, Әхәт Гобәйдуллиннарның чын талантлары Тимәш мәйданында чәчәк атты. Уникаль ятманың чикләрен билгеләүдә һәм эксплуатация скважиналары бораулауда В. Драгунов, С. Егоян, А. Криушкин, Г. Вәлетдинов, Г. Митяев, В. Васильев, А. Асадуллаев, Ю. Галушко һәм башка күп кенә нефтьчеләр үзләрен өлгергән бораулау осталары итеп күрсәттеләр.

Тимәш-Ромашкино Татарстан нефтьчеләрен дан-шөһрәткә күмде. Ул ятманы ачкан өчен геологлардан С. П. Егоров, А. М. Мельников, И. А. Шпильман, нефтьче-инженерлардан Н. С. Голобоков, Ф. Г. Ефремов, А. В. Лукин һәм С. И. Маковский Дәүләт премиясе лауреатлары дигән мактаулы исемгә лаек булдылар.

Республикада җир асты хәзинәсен эзләү дәвам итте. Һәм шактый ук уңышлы дәвам итте. 1949 елда Л. П. Зоткин бригадасы Кырым-Сарай нефть ятмасын ачты, аннары геологлар Татарстан картасына Акташ, Поповка, Яңа Ибраһим, Чирмешән ятмаларын төшерделәр.

1954 ел яңадан бер зур җиңү алып килде: разведчиклар Яңа Елховой нефть ятмасын ачтылар. Бу Тимәш-Ромашкино мәйданыннан кала республикада икенче зур ятма иде.

Ә аннары чират Камага җитте.

Кама. Алабуга тирәсенә якынлашкан саен, бу мәһабәт елга гүзәлләнә бара. Аеруча аның урман-куаклар белән капланган уң як ярьы. Яшел бүрекле мәңге яшь наратлар, бер-бер артлы тезелешеп, су читенә ук төшеп җиткәннәр. Бу урыннарны халык бөек Шишкин исеме белән бәйләп йөртә. Бу бөек рус рәссамы биредә туып үскән, шунда, Алабугада, үзенең үлмәс рәсемнәрен иҗат иткән.

Әле хәзер дә җәй көннәрендә бу тирәләрдән пароходта йөзеп үткән һәр кеше ирексездән Кама ярларында Иван Иванович Шишкин картиналарына охшаш урыннарны эзли. Юк шул, ул заманнардагы тынлык юк хәзер Кама буйларында. Пейзаж да бөтенләй үзгә. Әнә урман эчендә, андагы иң биек купшы наратлар белән узышып, металл челтәрле нефть вышкалары буй сузып утыралар. Болары инде Шишкин полотноларында бөтенләй юк. Алар барган саен күбәя. Димәк, тиздән пароход Алабугага, Кама буе нефтьчеләренең башкаласына җитәчәк.

Сез пароходтан төшәсез дә аякларны бераз язып өчен бу борынгы шәһәрнең, инде безгә мәгълүм Иван Шишкин һәм 1812 елгы Ватан сугышы каһарманы Надежда Дурова туып үскән шәһәрнең урамнарын урап кайтырга буласыз. Бүгенге Алабуга үзенең икенче яшьлеген кичерә. Үсә, яңара, матурая. Һәм әлеге дә баягы шул җир асты хәзинәсе — нефть аркасында.

Халык телендә: «Кама буйларына нефть килде»,— диләр. Дөрес әйтәләр һәм бер үк вакытта ялгышалар да. Болай әйтү дөрес, чөнки моннан унбиш еллар элек бу тирәләрдә нефтьнең эзе дә, исе дә юк иде әле. Нефтькә бәйле бөтен нәрсә биргә я килде, я китерелде. Әле безне пароходта килгәндә үк таң калдырган мәһабәт вышкалар Каманың тегә ягыннан килделәр, шул вышкаларда беренче скважиналарны бораулаган разведчиклар да — шул як карлыгачлары.

Нефть килде, дип әйтү дөрес үк тә түгел, чөнки нефть — Кама буйларының үз хәзинәсе. Разведчиклар аны шунда, Кама буйларында эзләп тапты, нефтьче-промыселчылар аны шунда җир өстенә күтәрде, халыкка хезмәт итүгә җикте. Аларны, нефтьче-пионерларны, Алабугада бик яхшы беләләр. Менә хәзер дә шәһәр белән гамьсез генә танышып йөргәндә дә, сез бераз гына игътибарлы булсагыз урам почмакларындагы йортларның берсенә куелган «Виктор Землянухин исемендәге урам» дигән язуга күз төшерми калмассыз. Болай гына үтеп китмәгез сез бу язу яныннан, бу исем белән ныклабрак кызыксыныгыз, ялгышмассыз: Кама буе нефте турында күп кенә нәрсә белерсез. Иң яхшысы: сез Алабугадагы разведка бораулау конторасына керегез һәм бу контораның директоры Я. Сәйфетдиновтан янсә баш инженеры Е. П. Фирсовтан: «Нигә бу урамны Виктор Землянухин исеме белән атаганнар?» — дип

сорагыз. Алар бу сорауларыгызга бик теләп җавап бирерләр. Аларны туры китермәсәгез, башкалары сөйләр — Землянухинны белмәгән кеше юк анда.

...1954 елда разведчиклар Каманың уң як ярына беренче бораулау җайланмасын күчерделәр һәм бу тирәләрдә нефтьне ныклап торып эзләргә керештеләр. Бераздан 15 номерлы скважина салынды. Менә шул буровойда мастер булып талантлы бораулаучы-разведчик Виктор Землянухин эшли иде. Ул һәм аның иптәшләре бер ел буе аруны белми каты җир катламын бораулалылар, хәзинә эзләделәр. һәм таптылар. 1955 ел Татарстан нефте тарихына Бондюг ятмасының туган елы булып керде.

Каманың уң як яры нефтькә ифрат бай булып чыкты. Тагын өч елдан, 1958 елның сентябрендә Д. Чуркин бригадасы бораулаган 104 номерлы скважина җир өстенә көчле фонтан ыргыта башлады. Первомайск нефть ятмасы. Шул ук елны И. И. Сидорин бригадасы Алабуганың үзендә «кара алтын» хәзинәсенә тап булды. Ә алардан соң Салауш, Ык тамагы һәм башка ятмалары табылды.

Буровойларның берсендә Виктор Землянухин һәлак булды. Солдат кебек, үзенең постында, үзенең граждалык бурычын үтәгәндә һәлак булды. һәм чын батырлыкны таный белүче Алабуга халкы шәһәр урамнарының берсен Кама буенда беренче булып чын хәзинә тапкан нефтьче-разведчик исеме белән атарга, аның исемен мәңгеләштерергә булды.

* * *

Разведчиклар Татарстан җиренең һәр километрын бик җентекләп капшап йөриләр. Каманың уң як ярында да җир асты байлыкларын үзләштерү кызу темплар белән бара. Республикада гомуми озынлыгы 4,5 миллион метрдан артык 2,5 меңнән артык разведка скважиналары бораулаңган. Татарстан территориясендә 150 дән артык нефть ятмасы ачылган. Хәзер Татарстан разведчиклары нефтьне республика чикләреннән чыгып та эзлиләр. Алар Оренбург далаларында, тугандаш Удмуртия урманнарында, төньяк күршебез Киров өлкәсе җирләрендә дә «кара алтын»ны күпләп табалар.

Үткән еллар эчендә бик күп нәрсәгә ирешелде. Ләкин илебезгә нефть елдан ел күбрәк кирәк. Моторларга азык, зур химиягә чимал кирәк. һәм нефтьне эзләү бер генә көнгә дә тукталмый.

— Хәзер безнең разведчиклар Казан гөмбәзе дип йөртелә торган урынның төньяк өлешендә тирәнгә бораулау эшләре алып баралар,— ди «Татнефтьгазразведка» трестының баш инженеры Павел Андреевич Терказаров. (Сүз уңаенда шуны да әйтик, Павел Андреевич бу трестта менә егерме ел эшли инде. Татарстан территориясендә табылган күп кенә нефть ятмалары теге яисә бу күләмдә аның исеме белән бәйләнгән. Ул разведчикларның эшен яхшырту өчен күп көч куйган кеше.) — Бу район әле аз өйрәнелгән. Моңа кадәр биредә тирәнгә бораулау эшләре алып барылганы юк иде. Хәлбуки, геологлар бу районның, алар теле белән әйткәндә, перспективалы булуы турында зур ышаныч белән сөйлиләр. Аннары безнең егетләр Татарстанның төньяк-көнбатышына, Казан тирәсенә киләчәкләр...

Күптән түгел Татарстан нефтьчеләре республикада нефть табылуның егерме биш еллыгын тантаналы рәвештә бәйрәм иттеләр. Алар белән бергә бу бәйрәмне разведчиклар да билгеләп үтте. Алар бик күп бездә. Тырышлыклары, фидакарь хезмәтләре белән ничәмә ничә нефть ятмасын ачкан, ул байлыкларны ил файдасына «җиккән» бу кешеләрнең барысын да санап бетерергә мөмкин түгел. Алар йөзләп, меңләп. Степан Баклушин, Фәсхетдин Шәрәфетдинов, Виктор Землянухин кебек кыю, батыр кешеләр, Степан Егоров, Василий Драгунов, Полина Мазалова кебек бу кыен эшкә чын күңелдән бирелгән кешеләр. Коммунистлар һәм партиясезләр, руслар һәм татарлар, башкортлар һәм чуашлар — Татарстан һәм Башкортстан җирләрен дә, Удмуртия урманнары белән Оренбург далаларын да берүк төсле якын күргән совет кешеләре.

*(Дәвамы бар)*

Әдхәт Синегулов

# ҖЫР—БОМБА[1]

*1941 елның 22 июнь таңында туган җиребезнең офыклары кояш нурларының яктылыгыннан түгел, планетабызга дөрләп кабынган сугыш ялкыныннан кызарды. Бу афәтле көннәрдә үзләренең Ватан алдында биргән изге антларын татар язучылары да намус белән үтәделәр. Алар дошман белән бәрелешүнең беренче көннәреннән ук халык белән тыгыз бәйләнештә булдылар һәм Ватан бәйсезлеген яклап, сугыш кырларына киттеләр.*

*Бөек Ватан сугышында йөзгә якын татар язучысы катнашты. Аларның күбесе әйләнеп кайтмады. Туган илебезнең изге туфрагын бәдбәхет фашистлардан таптатмау өчен, арсландай сугышып, корбан булдылар.*

*Билгеле булганча, Ватан сугышы елларында күп кенә яшь шагыйрьләр үсеп чыкты. Аларның иҗаты моңа кадәр нигезле өйрәнелмәгән — анда бер, монда бер мәкалә, я обзац кына очрый һәм вакыт үтү белән, ничектер, онытыла баралар иде. Яшь шагыйрь Әдхәт Синегулов, аларның иҗат һәм тормыш юлларын өйрәнеп, махсус китап язды. Бу әсәрләрнең пафосы илсөяр тойгыларга нигезләнгән һәм яшь буынны хәрби-патриотик рухта тәрбияләү өчен бүгенге көндә аларның әһәмияте бермә-бер арта.*

*«Туплар һәм музалар» исемендәге җыентыкка тупланган бу очеркларны нәшрият быел аерым китап итеп бастырып чыгара. Журнал редакциясе әнә шул әсәрләр арасыннан «Җыр — бомба» дигән бүлекне укучыларга тәкъдим итә.*

> **Мин геройларның билгесез булмавын, аларны барысы да белүен теләр идем; аларның һәрнәйсының үз исемнәре, карашлары, уй-тойгылары һәм ышанычлары булган һәм шуңа күрә аларның, хәтта иң билгесезләренең дә, газаплары тарих белгән шәхесләрдән бер дә ким түгел. Сугышта корбан булганнар сезгә дусларыгыздай, туган-тумачаларыгыздай һәм үзегездәй һәрвакыт якын булсын!**
>
> ЮЛИУС ФУЧИК

«...Ватан сугышында ләгънәтле фашизмга каршы корал көче белән генә баруга минем җырлар сөюче йөрәгем түзә алмый, кулга корал тотып, җыр белән, ата-аналарның, сабыйларның күз яшен тизрәк киптерү өчен бомба булган җыр белән дә дошман өстенә барасым килә»[2],— дип язды фронтовик яшь шагыйрь Мансур Гаяз.

---

[1] Кульязма кыскартылып басыла — ред.

[2] Мансур Гаяз. Шигырьләр. Казан. 1959 ел.



Әйе... Бу яшь патриотның җырлары фашист-этләрне дөмбәсләүдә бомбадан бер дә ким түгел иде.

Фашистлар Испания республикасына коточкыч сугыш ачып җибәргән елларда Гаяз үзенең беренче шигырьләре белән күренә башлый. Ул Испаниянең фашизмга каршы корал тотып көрәшүче уллары һәм кызлары турында җырлый. «Испания егетенең җыры» исемле шигырендә яшь автор ерак Пиреней күгендә шатлык таңы атачагын, ерткыч фашистларның җирдән себерелеп түгеләчәген сурәтли, көрәшнең дәвам итәчәген әйтә:

**Ул — безнең йөрәкләрдә,**
**Көрәшкә бергә керер.**
**Аның каны тамган байрак**
**Безнең кулларда йөрер.**

Яшь шагыйрьнең иҗат гомере нибары алты елга сузыла һәм 1937—1943 елларны үз эченә ала. Бу — илдәге бөек бишьеллыклар дәвере, социализмның илдә җиңү чоры, авыл хуҗалыгының һәм промышленностьның зур адымнар белән алга киткән чагы һәм, ниһаять, Бөек Ватан сугышы башланган еллар иде. Шундый кыска вакыт эчендә Мансур Гаяз эпохаль вакыйгаларны, зур омтылышларны үзенә хас осталык һәм күңел көрлеге белән матур итеп җырлый алды.

Мансурның сугышка кадәр язылган «Чиктә», «Флотчы егеткә хат», «Ана уйлары», «Пилот» һәм башка шигырьләрендә туган ил темасы төп урынны били. Аны, барыннан элек, җиңүле һәм данлы көрәш юлы, тормышыбыз муллыгы рухландыра.

Туган ил һәм аңа чиксез бирелгәнлек хисләре — сугыш кырларында кулларына корал тотып һәм штык очлы каләмнәре белән көрәшүче башка яшь фронтовик шагыйрьләр иҗатында да үзенең якты чагылышын тапты. Бу теманы алар Бөек Ватан сугышы елларында тагын да үстереп-киңәйтеп җибәрделәр. Алар үз әсәрләрендә илебезгә каракларча басып кергән шәфкатьсез дошманга карата рәхимсез, куркусыз-батыр йөрәкле булырга, аннан каты үч алырга өндиләр.

Әйтелгәннәрне мисалда күреп китү өчен, М. Гаязның «Ватан» (1942) дигән шигыренә тукталасы килә. Яшь автор ирек сөюче Ватаныбызның Минин һәм Пожарский кебек батырлары һәм Суворовтай атаклы полководецлары, Пушкин һәм Тукай кебек әдипләре белән горурланырга хаклы булуын сөйләп килә дә:

**Басып керде явыз ерткыч дошман**
**Талантларның азат җиренә,**
**Басып йөри пычрак итек белән**
**Бабайларның изге кабренә,—**

дип үзенең тирән нәфрәтен белдерә.

Гитлерчы-фашистларның сугыш елларындагы явызлыклары кешеләр күңелендә мәңге онытылмас. Совет кешеләре Киевтагы, Одессадагы, Черниговтагы һәм башка күп урыннардагы дар агачларын һәм Майданиктагы коточкыч «үлем фабрикасы»н әле булса исләрендә тоталар. Фронтовик шагыйрьнең дә йөрәгендә ачу кайный. Ул да нәфрәтләнеп:

**Буыннарга турый кешеләрне,**
**Тере килеш күмә җирләргә...**
**Мондый оятсызлык, вәхшилекне**
**Әйт, кешелек, нигә тыңларга!! —**

дип, кешелеккә мөрәҗәгать итә.

М. Гаяз иҗатының без күбрәк героик лирикага тартым булуын күрәбез. Бу характердагы әсәрләргә агитацион ендәү, тантаналы рух һәм югары пафослы сөйләм хас...

Мансур Гаяз күпләр исеменнән сөйләргә ярата. Ул, башка фронтовик шагыйрьләр кебек үк, үзенең лирик герое «мин»ендә күпләргә хас уй һәм кичерешләрне, типик тойгыларны чагылдыра. Укучылар аның шигырьләрендә үз рухларының гәүдәләнешен тирәнтен тоялар, дулкынланалар.

Тыныч вакытта шагыйрьнең «мин»е:

Якты теләгемә ирешермен,
Ышанычын аклап халкымның:
Колхозымның иген кырларына
Мин агроном булып кайтырмын,—
(«Синдә матур тормыш кайный». 1938.)

дип белдерсә, бөек сынаулар көне килеп җиткәч, лирик герой, ил патриотлары белән берлектә, Ватанны саклауның алгы сызыгына баса.

Туган илнең ике ягыннан без.
Юлларыбыз бергә очрады.
Бер дошманга карап юнәлтелгән
Кулда үткен штык очлары.
(«Тетрәсен дошман». 1943.)

«Мин»нең йөрәге, шул ук вакытта, Туган илгә тирән сөю, дошманнарга утлы үч белән тулы:

Җан борчыла, йөрәк әрни, сыза,
Вулкан булып көчләр кабына:
Дошманнарны сытып ташлар өчү,
Тирән үчләр кайный канымда [1].
(«Савык, туган». 1943.)

Биредә барысы да: ритм һәм шигъри образлар да, сурәтләү чаралары да, публицистик пафосның тирән лиризм белән аралашуы да бөтенесе бергә сугыш чорының киеренке рухы белән авазлаш.

Фронтовик шагыйрьләрнең 1941—1942 елларда иҗат иткән әсәрләрендә әверүчә сугышның тәүге чоры характерлы сызыклар аша күренде. Бу чор поэзиясенә бигрәк тә халыкның патриотик омтылышларын гәүдәләндергән кайнар йөрәк сүзләре, чакыру шигырьләре — агиткалар хас иде. Ул чорда язылган әсәрләрнең исемнәре үк аларның идея-эчтәлекләрен, формаларын ачык күрсәтеп торалар: «Коралга, халкым, коралга!» (Н. Баян), «Кисеп ташла фашист тилчәсен» (Ә. Фәйзи), «Үлем — фашистларга!» (М. Вәдүт), «Утлы егет алга ашкына» (М. Садри)...

Мансур Гаязның бу елларда иҗат иткән шигырьләренә дә шундый ук хисләр характерлы иде. Аның «Ана васыяте» (1942) шигырендә илне һәлакәттән саклап калу өчен үзенең улларын героик көрәшкә өндәгән ана сүзләре Ватан сүзләре булып яңгырыйлар. Аның «Ана уйлары» (1939) дигән икенче бер шигыре, датасыннан күренүенчә, сугышка кадәр үк язылган. Шунысы кызыклы: «Ана васыяте» дә, «Ана уйлары» шигыре дә үзләренең темалары, идея-эчтәлекләре ягыннан берсе икенчесенең дәвамы булып тора. Сугышка кадәр туган «ана уйлары» улын сугыш кырына озатканда ананың «васыяте» булып яңгырыйлар. Бу ике шигырьдә ана һәм бала образларының эволюцион үсештә бирелгәнлеге күренә. «Ана уйлары» шигырендә ана:

Синең, улым, тазалыгың саклау,
Тәрбияләү — минем бурычым,
Ә син, үскәч, туган илебезгә
Яраклы бер кеше булырсың,—

дигән изге патриотик теләктә булган булса, «Ана васыяте»ндә ул:

Тар-мар ит дошманны, улым,
Таза-сау йөре,
Җиңү белән үтсен юлың,
Аннан кайт кире...,—

дип озатып кала.

[1] Шагыйрьнең иҗат архивындагы шигырь.

Татар шагыйрьләре сугыш чорында да халык авыз иҗаты традицияләрен, татар совет әдәбиятына нигез салучы Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Һади Такташларның иҗат традицияләрен тырышып өйрәнделәр, илебезнең башка милләт халыклары әдәбиятларының иң гүзәл үрнәкләрен үзләре дә иҗади файдаландылар. М. Гаяз иҗатына М. Гафури, В. Маяковский поэзиясенең уңай йогынты ясавы күренә. Ул Маяковскийны «поэзиядә сүнмәс нурлар чәчеп балкучы маяк» дип атый. Яшь шагыйрьнең турыдан-туры Маяковскийга багышлап язган «Байракларда бара» (1943) шигыре бу шагыйрьгә карата зур хөрмәт һәм ихтирам белдерүе булып яңгырый. Сугышчы шагыйрьнең юл капчыгында һәрвакытта китаплар һәм шигырьләр язылган дәфтәрләр йөри. Шулар арасында Маяковскийның да җыентыгы була...

**Онытылмаслык походларда йөрим,**
**Ә китабың бара сумкамда;**
**Алып укыйм аны ял иткәндә,**
**Талчыккан һәм арган булсам да...**

М. Гаязның бу әсәре әлегә кадәр укучыларга билгесез булуы белән дә кыйммәтле. Ул шагыйрьнең иҗат архивындагы төп нөсхәдән күчереп алынды. Бу әсәр тагын шул ягы белән кызыклы, аның бетемен М. Гаяз Маяковскийның үз сүзләре белән тәмамлый. Болай эшләү, беренчедән, шигырьнең эһаңлеген, икенчедән, аның укучыларга тәэсир көчен арттыруга ярдәм итә:

**Яңгыр юа алмас, җилдә уңмас,**
**Йөрәктәге сүзләр җуелмас:**
**«Я всю свою**
**звонкую силу поэта**
**тебе отдаю,**
**атакующий класс!»**

М. Гаяз иҗатына тирән оптимизм, дошманга нәфрәт, авырлыкларны җиңеп чыгарга әзер тору кебек мотивлар хас иде. Бу тойгылар Мансурның «Түләтербез», «Йөрәк нәфрәте» кебек шигырьләрендә югары поэтик көч белән яңгырыйлар:

**Азатлыкны сөйгән горур халык**
**Коллык богауларын кимәскә —**
**Күтәрелде көчле давыл төсле,**
**Күтәрелде изге көрәшкә!**
**(«Түләтербез».)**

Шагыйрь, әнә шулай, дошманнарына һәрвакыт җирәнү, чиркану белән карады.

Гитлерчылар, СССРга каршы сугыш башлаган чакта, бездә милләт белән милләт арасындагы бердәмлекнең җимерелүенә исәп тоткан иделәр. Ләкин нацистларның мәкерле өметләре барып чыкмады. Милләтләр белән милләтләр арасындагы дуслык, туганлык, киресенчә, авыр, сынаулы сугышта тагын да ныгыды. Чөнки партиябезнең ленинчыл политикасы барлык милләт хезмәт иясе халкын бердәм сафка туплады. Телләребез башка булсалар да, теләкләребезнең, максатларыбызның бер булуы ачыкланды. Бурычыбыз: дошманны тар-мар итү иде. Шушы изге идеяне М. Гаяз болай әйтте:

**Телләребез башка, теләкләр — бер,**
**Эчтә кайный йөрәк ялкыны;**
**Якынайдык бер туганнар кебек**
**Ленин әйткән сүзләр аркылы.**
(«Тетрәсен дошман».)

Кан койгыч сугышны без башламадык, аны безгә немец илбасарлары — кешелексезлектә, ерткычлыкта тиңе күрелмәгән фашистлар такты. М. Гаяз шул уңай белән: «Үзе башта тешләгәне өчен эткә күсәк таза эләгә!» — дип язды. Һәм коралдашларын дошман белән рәхимсез булырга өндәде: «Тетрәт аны, һич аяма көчең, чумсын канга — тура, телгәлә!»

Сугышчы яшь шагыйрьләр көрәшнең иң авыр минутларында да: дошман гаскәрләре Мәскәү капкасы төбенә килеп җиткәндә, Сталинградта һәр йорт, һәр бүлмә, һәр

карыш җир өчен дәһшәтле көрәш бирган чакларда да җиңүгә булган ныклы ышанычны югалтмадылар, чөнки алар бөек совет халкының бетмәс-төкәнмәс көчен, ныклыгын тоеп тордылар. Алар йөрәгендә киләчәккә булган өмет һәм ялкын һич вакытта да сүрелмәде:

Өмет белән алга карыймын да
Бөтен борчулардан бушанам.
Кояш чыгуына ышанган кук,
Җиңәренә илнең ышанам!
(«Ватан». 1942.)

Җирдәге тормыш сулышын буарга фашистларның кулыннан килмәде... Яшәү, мәңгелек яшьлек сугыш бураннарын җиңеп чыкты. Фронтлардагы дәһшәтле вакыйгалар һәр көн яңадан-яңа образлар, яңадан-яңа геройлар тудыра килде. Сугыш тормышындагы мона бу яклар поэзиядә катлаулырак формаларны таләп итте. Шуның өчен шагыйрьләр, кыска лирик шигырьләр язу белән беррәттән, тормыш мөнәсәбәтләрен тирәнрәк чагылдырган сюжетлы әсәрләр, легенда, поэма шикелле киң колачлы полотнолар да иҗат иттеләр. Шагыйрьләребезнең Ватан сугышы чорындагы иҗатларына күз салганда, без балладалар белән дә очрашабыз. Ф. Кәримнең «Үлем уены», «Тимер һәм тимерче», М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә», Ә. Фәйзинең «Көлүче тавыклар турында баллада», «С. Батталның «Әкият һәм тормыш турында баллада», Н. Бэяниың «Шофер һәм малай» дигән әсәрләре шушы жанрның үрнәкләре булып торалар. Боларның барысы да Ватан сугышы мотивларына корылган. Күбесе реалистик нигездә, Ватан сугышы героикасында барлыкка килгән образларның батырлыкларын күрсәтә торган сюжетка нигезләп язылганнар. Тик Ә. Фәйзинең «Тавыклар» һәм Ә. Исхакның «Ике сугышчы»сы гына ярым фантастик образлар аркылы сурәтләнә.

Баллада язучылар фронтовик яшь шагыйрьләр арасында да бар. Безгә Касыйм Вахитның «Егет турында баллада»сы (1941), Гиз эль-Габидның «Куш агач» (1944) һәм Мансур Гаязның «Оясыз калган сыерчык»[1] дигән балладалары билгеле.

Кошчык — сыерчык образына үз әсәрләрендә М. Җәлил дә, Ф. Кәрим дә, Ш. Мөдәррис тә мөрәҗәгать иттеләр. Алар ирektәге канатлы кошчык образы аша Туган илгә, туган-үскән якларда калган иң кадерле кешеләргә булган үзләренең йөрәк хисләрен белдерәләр; сугыш хәбәрләрен тасвирлау аша илебезнең авыр, шомлы көннәр кичерүен сурәтлиләр.

Оч син, кошчык,
кочле җырым булып,
Шушы сиңа соңгы теләгем.
Тәнем калсын монда,
(Нәрсә ул тән!)
Барсын илгә минем йөрәгем.
(М. Җәлил. «Кошчык».)

М. Гаяз балладасындагы кошчык образы да сугыш булып узган җирләрдәге ирек хәбәрчесе булып очып йөри. Җир шарында тормыш язы белән бергә ул да туганүскән якларына урап кайткан... Кешеләр генә түгел, хәтта кошлар да нәсел калдыру өчен (бала чыгару өчен) җирдә көрәш алып баралар. Ләкин бу җирдә хәзер сугыш шәүләсе булып хәрабәләр генә торып калган, кош ояларына кадәр янып беткән. Тормышны дәвам итәр өчен, шагыйрь кошчыкка дошман кул-аягы тимәгән якларга китәргә киңәш бирә:

Оч син моннан, назлы кошчыгым,
Биек таулы Урал ягына.
Җыйнак, матур, җылы ояләр
Анда сезне күптән сагына.

---

[1] Шагыйрьнең иҗат архивында.

**Оч син иркен Идел буена,**
**Мактаулы, киң Казан артына —**
**Кайда йезми порх төтене,**
**Кайда уйный киек үрдәкләр,**
**Очып йөри кошлар төркеме...**

Бу кичерешләр, ургып торган бай хисләр, коточкыч сугыш хәрабәләре өчен эчке сыкранулар, бер яктан, сыерчыкны реаль образда чагылдырса, икенче яктан, шагыйрь укучының тойгыларын шул кошчык — сыерчык образы аша кешеләр язмышын, тормыш чынбарлыгын күз алдына китереп бастыра. Җыеп кына әйткәндә, туксан юллык бу баллада — зур көч салып, җитлеккән шагыйрь каләме белән язылган чын сәнгать әсәре.

Монда реаль сугыш картиналарын сурәтләү дә, сәнгатьчә дереслек тә үзенең тулы гәүдәләнешен тапкан. Баллададагы вакыйгалар шагыйрьнең лирик кичерешләре белән бергә үрелеп баралар. Болай эшләү әсәрнең тәэсир итү көчен арттыра, вакыйгаларны укучыга тулы килеш күзалларга ярдәм итә.

Поэзиянең нинди генә жанрына тотынмасын, Мансур Гяз үзен талантлы лирик шагыйрь итеп таныта. Зур һәм кечкенә нәрсәләр турында ул гади, ләкин табигый образлар аша сөйли белде. Аның әсәрләрендә иң элек без лирик охшатулар, образлы чагыштырулар, тирән йөрәк кичерешләрен күрәбез. Үзенең каләмдәшләреннән ул әнә шул яклары белән аерылып тора иде. Фронтовик шагыйрь Шәйхи Маннур «Алга, дошман өстенә» исемле фронт газетасында:

«Яхшы шагыйрь булачагы күренеп торган Мансур Гаязның җырчы йөрәге немец-фашистлары тарафыннан зур бәхетсезлеккә дучар ителгән халкыбыз өчен әрни, аларның михнәтләре өчен дошманнан үч алу дәрте белән яна» [1],— дип язды.

Шагыйрь нинди генә теманы алмасын, әгәр аны җиңел агышлы һәм табигый итеп җырлап бирә икән, ул инде аның иҗади осталыгын, хисләр белән теләкләренең бердәмлеген, үз әсәре өстендә мәхәббәт белән бирелеп эшләвен күрсәтә. М. Гаязга карата да шул сүзләрне әйтә алабыз. Тагын шул кадәресен аеруча басым ясап әйтергә кирәк: Мансур Гаязның ялкынлы шигырьләре дошманны җиңүгә утлы корал булдылар.

«Хәзер көч безнең якта, күрәсез, көн саен шәһәрләр алына, безнең армия алга бара, дошман тар-мар ителә. Тиздән җиңү кояшы балкыр!» [2],— дип яза ул соңгы бер хатында.

Ләкин көрәшчә шагыйрь җиңү кояшының балкуын күрә алмады. Аның дошманнарга бомба булган җырлы гомере, үз Ватанына турылыклы булып, 1943 елның 19 ноябрендә Белоруссиядәге Ускорова авылы өчен барган көрәштә өзелде. Шагыйрьгә шушы урында үз сүзләре белән:

**Чикләнмәде әле яшәвең,**
**Синдә яңа гомер кабынды,**
**Күчердең син бөек сәнгатькә**
**Каләм белән йөрәк канынны.**
**Дошманнарга булдың аяусыз,**
**Тынгы бирмәдең һич аларга,**
**Белә идең үткен сүзләрне**
**Кай җиренә, ничек кадарга.**
**Шаулы тормыш белән шигырьләрең**
**Ерак еллар аша барырлар**
**һәм яшьләрне иҗат эшенә**
**Чакыру тавышы булып яңгырар,—**
(«Сагыну».)

дип әйтәсе килә.

Әйе, Мансур Гаяз шигырьләре алгы героик көннәрдә дә, һичшиксез, безнең «яшьләрне иҗат эшенә чакыру тавышы булып яңгырар».

---

[1] «Алга, дошман өстенә» газетасы. 1943 ел. Ноябрь.
[2] Бу хат шагыйрьнең иҗат архивында саклана.

# ШИГЫРЬНЕҢ КӨЧЕ— ФИКЕРДӘ, ХИСТӘ

*(Рецензия урнына)*

Шагыйрьләр шигырьләрен озынрак язган саен кыска формаларга ныграк сусадым мин. Минем чордашлардан да кыскадан башлап караучылар булды, ләкин тиз киттеләр, тиз оныттылар. Ватан сугышыннан соң поэзиягә килүчеләр арасында бу формаларны яңартырга теләүчеләр бар иде, алар да сүнеп калды.

Дөнья поэзиясенә үзләренең дүртюллыклары, кыска шигырьләре белән кергән Гомәр Хайям, Хафиз, Сәгъдиләр искә төшкән саен, үзебезнең Тукайларның, Дәрдмәндләрнең халык тарафыннан ятланган, җыр булып әверелгән лирик парчалары искә төшкән саен сусау хисе миндә арта гына барды. Ә безнең шагыйрьләрне озын шигырь, озын поэмалар күбрәк тартты. Юллар саны үсте, фикер саекты, хис, ялкын кимеде. Вакыты-вакыты белән шигырь укучы күзеннән төшеп торды.

Ни өчен кыска формалар сагындыра! Шигырь ул — хисләр, фикер концентрациясе, фикернең, хиснең кристаллашкан формасы. Ул шушы кыска формага заманның каршылыкларын, бөтен омтылышларын бер фокуска җыеп әйтә белүе белән кыйммәт. Дәрдмәнднең «Кораб»ына салынган мәгънәне киңәйтеп, һичшиксез, поэма язып булыр иде. Дәрдмәнд поэмалык фикерне сигез юлга сыйдырган, нинди символик яңгыраш формасын тапкан, ярты гасыр инде телдән төшми! Яки шул ук Дәрдмәнднең:

Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад,
Бер янып ат алдылар,
Мин гарип, мең кат янып та
Яндыга саналмадым,—

кебек юлларын без үзебезнең иптәшләргә атлаган саен нинди илһам белән укыйбыз, күңелдән укыйбыз. Шигырь шулай булса гына яшь бит. Моннан соң да ярым романтик, хиссез, юл артыннан куган йөзләгән поэмалар дөньяга килер, укучы барыбер әйләнер дә «Бүзләрем маналмадым»га кайтыр. Сәнгатьнең төп принципларын сикереп узып китәргә мөмкин түгел. Заман түзеп торыр торыр да күпмедер вакыттан соң бер көнне шәфкатьсез рәвештә чистартырга керешер, яңадан поэзия үрнәкләрен бу шигырь Тукайдан, Дәрдмәндтән, Такташтан дип саный башлар.

Поэзиядә эзләнгән шагыйрьләр генә үзенә юл яра. Яңа килүче өчен алдан әзерләнеп куелган әзер бернәрсә дә юк. Хәтта традицион шигырь формаларына таянып күтәрелгән шагыйрь дә, әгәр ул талантлы икән, барыбер беркемне дә шул килеш кабатламаячак. Муса Җәлил белән Фатих Кәрим кебек бер чорда яшәп, бер чорда көрәшеп иҗат иткән ике шагыйрьне күз алдына китерү дә җитә. Бөтенләй икесе ике төрле яңгырый. Минем бөтен курыкканым эзләнми, җиңел юл белән килүчеләр, андыйлардан күбрәк поэзияне кәсеп итеп алучылар, карьеристлар чыга.

Мин ачык карашлары, эстетик принциплары булган, кечкенә шигырьләрендә зур киләчәк күренеп торган, поэзиянең бөтен байлыгын өйрәнеп эзләнүчеләр ягында. Ренат Харисов — шундыйларның берсе.

Ренат Харисов гадәттәге дүртюллыклар, сигезюллыклар авторы түгел. Һәр шигырь аның үз формасын таба, һәркайсы үзенчә бер бөтен.

Яз көне
Кибән-кибән болыт
Җиргә сеңгән.
Көз көне
Җиргә шытып чыккан
Болыт-болыт кибән.

Яки менә икенче характердагы тагын бер шигырь:

Аңымны юа да мана,
Юа да мана
Замана.
Иске төсләр кушыла бара,
Кушыла бара яңага.
Барлык төсләр эремәсе
Ак диләр —
Нинди төскә манмый калуын —
Чамала!
Нинди төстән башладың син,
Замана?

Шигырь формасы — шагыйрьнең дөньяны ничек күрү формасы. Мин яшь шагыйрьнең фикерләрен, шигырьдә эзләнүләрен Дәрдмәндчә — үзенчә диләр идем, интонацион яңгырашларны күп еллардан соң да танып була, тоеп була. Шигырьнең көче фикердә, хистә, яза торган предметның эченә, үзәгенә үтеп керә алуында. Шигырь тыгызлап тутырылган хисләр хисабына карап зурая, масштаб — уйлануның киңлегендә.

Поэзиядә хәзер уйланучылар күбәйде, тыныч юл белән шигырь язып яшәүчеләргә торган саен кыенрак булыр, аларны әкренләп чын талантлар кысрыклап чыгарыр, бу минем күптәнге хыялым, мин аның тормышка ашырына хәзер бик нык ышанам, чөнки яшь поэзиянең өметле вәкилләрен күреп торам.

Әдәбиятның, сәнгатьнең мәйданы киң, тик талантлы кешеләр генә килсен, үзенчә килсен.

Сибгат ХӘКИМ.

Нигъмәт Ихсанов

# ГАДИЛӘРНЕҢ БЕРСЕ

Партия сафларына 1920 елда кергән Шәриф Садыйковка күптән түгел җитмеш биш яшь тулды. Ләкин ул әле хәзер дә хезмәт постыннан китми. Тынгысыз йөрәкле бу коммунист бүгенге көндә ерак Якутиядәге Амга совхозында ашлык склады мөдире булып эшли.

Шәриф Садыйковның тормыш юлы кызыклы һәм гыйбрәтле. Ул ярлы крестьян семьясында дөньяга килә. Семьяда сигез җан, ә хуҗалыкта бер ат һәм бер сыердан башка бернәрсә дә юк. Шул зур семьяны туендырган җирләре дә бер кишәрлектән артмый. Хәер, бу ярлылык алар нәселенә күптәннән калган мирас.

Шәрифнең бабасы үзенең чыгышы белән элеккеге Казан губернасыннан булып, соңыннан ул Агыйдел буендагы Солтановка авылына күчеп килә. Аның да балалары бик күп. Шуларның дүртесе: Ситдыйк, Исламгали, Шакир һәм Әхмәтгали исемле ир бала. Әтиләре вафат булганнан соң алар йорттагы байлыкны бүлешәләр. Садыйк картның болай да ярлы хуҗалыгыннан Шәрифнең әтисе Шакирның өлешенә бердәнбер иске келәт тия. Һәм алар җәйләрен шул келәттә, кышларын исә кешеләрдә өйдәш булып яшиләр. Авыр, бик авыр була Шакирга үзенең семьясын туендыру. Тормыш йөген шундый кыенлык белән сөйрәп барганда аңа тагын зур бәхетсезлек килә: урман агызуда эшләүче өлкән улы суга батып үлә. Бу вакытта аның икенче улы Шәриф әле унике генә яшенә чыккан була.

Шакирга балаларын кайсын кая таратырга туры килә. Кызларының кайберләре асрау яки бала караучы булып урнашалар, ә кайберләре бай крестьяннарның өйләрен юып тамак туйдыра. Шакир исә хатынын, ике кечкенә кызын һәм бердәнбер улы Шәрифне калдырып, Екатеринбург — Сарапул тимер юлы төзелешенә чыгып китә. Хәзер инде хуҗалыктагы бөтен эшләр һәм тормышның бөтен авырлыгы Шәрифнең япь-яшь иңнәренә өелеп кала. Семьяның хәлен азмы-күпме булса да җиңеләйтү нияте белән ул Кәрим байның сарыкларын көтәргә яллана. Беренче җәйдә андый-мондый бәлага юлыкмый. Әмма икенче җәйдә ул көтә торган сарыкларның өчесен бүре буа. Шәриф эшсез кала. Шулай да бераздан ул сәүдәгәр Исмәгыйлов кул астына эшкә урнашу бәхетенә ирешә. Ләкин бу бәхет аңа озак елмаймый. Сәүдәгәр малаеның сүзен тыңлап, төнлә кучер булып киткән өчен ул яңадан эштән куыла. Ул кышны Шәриф эш таба алмый. Ә язын әтисе кайтып төшә. Озак та үтми, язгы кыр эшләре башлана. Үз иманаларына тигән барлы-юклы җирне эшкәртеп, аңа бераз арпа чәчәләр, бәрәңге утырталар. Аннан соң инде әтисе Шәрифне яңадан кая да булса эшкә урнаштыру турында уйлана башлый.

Елгада навигация башланган көннәр була бу. Шакир Садыйков Уфа — Царицын арасында йөрүче пароходның капитаныннан Шәрифне үзенә матрос итеп алуын үтенә һәм үзе тагын бәхет эзләргә чыгып китә.

Матрослар арасында Шәриф үзенең урынын тапкандай була. Ләкин, 1916 елда солдатка чакырылу сәбәпле, аңа пароходтан китәргә туры килә.



Балачак һәм яшьлек елларын искә алганда, солдат дусларына Шәриф болай дип сөйли торган була:

— Минем өлгә беркайчан да кешечә яшәгәнем булмады. Минем тормышым һәрвакыт хуҗасына буйсынган ишәк тормышы белән бер булды. Аерма тик бары шунда гына иде: ишәк бернәрсә дә аңламый, ә мин азмы-күпме фикер йөртә ала идем кебек. Ләкин мин барыбер бер генә нәрсәне дә үзем теләгәнчә эшли алмадым.

Шәриф Садыйков хезмәт иткән утыз бишенче Себер полкы Австрия фронтындагы Ровно шәһәренә җибәрелә. Бераздан бу полкны Румыниягә күчерәләр. Вузово янында 12 мең солдат немецларга әсир төшә. Алар арасында Шәриф Садыйков та була.

Унсигезенче ел башында әсирләрне Сандарья лагерена куып китерәләр. Монда немецлар аларны румын крестьяннарының ашлык һәм терлекләрен талап алу өчен файдаланалар. Җирле халыктан талап алынган байлык Германиягә озатыла. Ашлык келәтләре булмаганлыктан, румын крестьяннары үзләренең ашлыкларын подвалларда, махсус казылган базларда саклыйлар. Әсирләрне кечкенә ак флаглар белән тәэмин итеп, немецлар аларны әнә шул подвалларны һәм базларны эзләп табу эшенә кушалар. Эзләп тапкан кеше ул урынга шул флагны кадап китәргә тиеш була. Ә бу флаглар табылган ашлыкны төяп йөрүче олаулар өчен шартлы билге булып хезмәт итә. Немецларның бу җирәнгеч әмерләрен үтәргә теләмәүчеләрне биеклеге ике метр, киңлеге 30—45 сантиметр булган тар гына тимер шкафка өч сәгатькә ябып куялар яки атып үтерәләр.

Беркемнең дә чит-ят җирләрдә үлеп каласы килми һәм әсирләр, үзләренең тормышларын саклап калу өчен, ирексездән шушы эшне башкарырга мәҗбүр булалар. Бервакыт Шәриф Садыйков белән дә шундый ук хәл була.

Лагерьдан ерак булмаган бер урында ул ашлык күмелгән базга очрый һәм аңа кечкенә флагны кадап, күрше йортның ишек алдына керә. Кинәт ул үзенең каршына йөгереп килүче ябык кына хатынны һәм аның артыннан ияргән берсеннән-берсе бәләкәйрәк биш баланы күрә. Хатын, үзенең кечкенә сабыйларына күрсәтеп, елый-елый бер үк сүзне кабатлый:

— Рус, рус!..

Шәрифнең йөрәге тетрәп куя. Ул үзенең ачлыкта үткән балачагын искә төшерә һәм аның тамагына төер килеп тыгыла. Күз яшьләрен чак-чак кына тыеп кулын селти дә, ашлык күмелгән базга флаг кадамыйча, ишек алдыннан чыгып китә. Ярты сәгать тә үтми, аны лагерь канцеляриясенә чакырып алалар һәм әзер элмәк җилдә тирбәлеп торган йорт стенасы янына китереп бастыралар.

Немец офицеры үзенең солдатларына:

— Баштүбән асарга! — дип команда бирә.

Солдатлар, ашыга-ашыга, элмәкне Шәрифнең аякларына кидерәләр...

Әсирнең күзләренә шундук кан йөгерә башлый, аның башы авырая һәм берничә минуттан ул аңын югалта.

Шәрифне үлемнән әсирләрнең бунт күтәрүләре генә коткарып кала. Алар, янып торган учаклардан утлы кисәүләр алып, немец солдатларына ташланалар. Немецлар коралга тотына, ләкин ярсыган әсирләр чигенмиләр, сакчыларның мылтыкларын тартып алып, аларның үзләрен кысрыклый башлыйлар. Менә шушы буталыш вакытында Вәлиев фамилияле бер әсир йорт түбәсенә менә һәм Шәриф асылынып торган бауны кисеп төшерә. Әсирләр шунда ук тыгыз боҗра булып аны үз араларына яшерә-

лар. Кич белән, инде бөтенесе тынгач, немецлар аны эзләп табалар. Ләкин атмыйлар да, яңадан асмыйлар да, бары тик әлеге шкафка ябып, аны шунда бер сугать тоталар.

Эш шунда: нәкъ шушы көнне Германиядә Вильгельмны бәреп төшерәләр һәм хәрби әсирләрне алмашу башлана. Бу хәбәр Сандарья лагерена да килеп җитә. Русларны, чехларны, болгарларны Румыния аша, төрекләрне Бессарабия аша кайтару турында килешенә.

Рус хәрби әсирләренә бөтен Румыния аркылы җәяү кайтырга туры килә. Юлда алар ачлыктан һәм авырулардан иза чигәләр. Харьковтан алып Мәскәүгә кадәр булган араны җәяү узалар. Чөнки монда ул вакытта поездлар йөрми.

Мәскәү авыр көннәр кичерә. Азык-төлек җитешми, бөтен ризык кайнар су һәм бозылган балыктан гыйбарәт. Шәриф тизрәк өенә кайтып җитү турында хыяллана. Ләкин юлда аны тиф аяктан ега.

Һәм менә Казан. Монда да шул ук хәл: ачлык һәм ялангачлык. Госпитальдә дарулар җитми. Авыруларны дәвалау ифрат авыр шартларда алып барыла.

* *
*

Яшь Совет республикасына акгвардиячеләр теш кайрый. Үзенең баскыннары белән Колчак бу якларга якынлаша.

— Эшчеләр һәм крестьяннар власте куркыныч астында вакытта ничек итеп госпитальдә ятмак кирәк,— дип уйлый Садыйков.— Юк, бүгеннән соң мин монда бер генә минут та артык ята алмыйм! — һәм ул, терелеп килүче үзенең иптәшләре белән, госпитальдән китә.

Озакламый алар Вятка фронтына озатылачак кызылгвардиячеләр отрядына килеп кушылалар. Красноуфимск шәһәре Колчак кулында, Сарапулга да куркыныч якынлаша...

Шәриф Садыйковны тагын йогышлы тиф аяктан ега.

* *
*

Сарапулда — Колчак гаскәрләре. Алар бөтен шәһәр буйлап эзләнәләр, хәтта больницаны да тынычлыкта калдырмыйлар.

Больница врачы Башмакина авыру кызылармеецларны яшереп калырга тели: алар турында ялган исемлек төзи. Әмма аклар больницада ятучы барлык ирләрне ишек алдына алып чыгып тезәләр, аларга киенергә, кораллanырга һәм Колчак ставкасы гаскәрләре сафына басарга кушалар. Ләкин бу тәгъдимне кабул итәргә теләүче табылмый. Шуннан соң аклар һәр ике кешенең берсен саф алдына чыгарып аталар. Госпитальдә дәваланып яткан 150 кешенең 73 е һәлак була. Шәриф Садыйков исәннәр арасында кала.

Сарапулдан чигенгәндә аклар бер төркем әсирләрне Красноуфимск шәһәренә, ә аннан Кулымзиноrа алып китәләр. Бераздан аларны Иркутск янындагы Инокентьевск станциясенә күчерәләр. Шунда коммунист Петров әсирләргә болай дип мөрәҗәгать итә:

— Иптәшләребезне аклар күз алдыбызда аттылар. Шул ук хәлнең тагын да кабатлануы мөмкин. Әллә без шуны көтеп утырырга тиешбезме! Совет власте, һичшиксез, җиңәчәк. Җиңү көнен якынлаштыру өчен без дә көрәш сафына басарга тиешбез. Хәзер, аклар исләренә килеп җитмәс борын, оешкан төстә качар өчен иң уңайлы вакыт. Сез шуңа әзерме, иптәшләр!

— Мин әзер! — дип җавап кайтара Шәриф Садыйков, беренче булып. Аның артыннан башкалар да качарга ризалык бирәләр. Шул ук төнне берничә әсир йокымсырап утырган сакчыларны юк итә. Әсирләр лагерь капкасыннан тавыш-тынсыз гына чыгалар. Иртәнгә алар инде Иркутскига барып җитәләр һәм эшчеләрнең революцион отрядына кушылалар.

1920 елда Иркутск шәһәренә Бишенче армия штабы күчеп килә. Отряд шушы армия составына кушыла. Шушы ук елны, Верхнеудинскины алганнан соң, Шәриф Садыйков коммунистлар партиясе сафына кабул ителә.

* *
*

Атаман Семенов гаскәрләре Чита янында Кызыл Армия частьларын кысрыклый башлыйлар. Бу вакытта Шәриф Садыйков Каландарашвили отрядында атлы разведкада

хезмәт итә. Шушы отряд белән бергә ул Амур өлкәсендәге Михайлово станциясенә кадәр барып җитә. Ләкин тагын авырып китүе сәбәпле, яңадан Иркутскига борылып кайта.

Шәрифнең башында күңелсез уйлар бөтерелә. Аңа үзенең иптәшләреннән, разведкадагы хезмәтеннән аерылу чиксез авыр. Ләкин берни дә эшләр хәл юк, авыру аны больница койкасына бәйләп салган. Азрак терелү белән, командованиедән яңадан фронтка, үз частена җибәрүләрен сорый. Ләкин аңа инде икенче урын билгеләп куелган.

Бу чорда Иркутск өлкәсенә һәм Забайкальега Идел буеннан бик күп татарлар күчеп килә. Ә аларны Иркутскида оештырылган санпропусник аша үткәрергә кирәк. Политбүлек коммунист Шәриф Садыйковны әнә шунда политрук итеп билгели.

* * *

1921 елның ахырлары. Нестор Александрович Каландарашвили Мәскәүдән, Ленин яныннан Иркутскига кайтып төшә. Аңа акгвардиячеләрнең калдыкларын һәм чит ил интервенциясенең ялланган агенты генерал Пепеляев отрядларын кууда төньяк халыкларына ярдәм күрсәтү өчен регуляр армия төзү бурычы йөкләтелгән. Нестор Александрович тирән дулкынлану белән Владимир Ильич белән очрашуы турында сөйли:

— Ленин мине үзенең эш бүлмәсе ишеге төбендә каршы алды. Башын чак кына бер якка кыйшайта төшеп, ике кулы белән креслога күрсәтте һәм утырырга кушты: «Исәнмесез, Нестор Александрович! Ох, озын да соң сезнең фамилиягез, ялгышмасам, Каландарашвили бугай!» «Дөрес, Владимир Ильич». «Ә сакалыгыз сезнең бөтенләе белән фамилиягезгә туры килә. Совет властеның дошманнары сезнең сакалыгыздан гына да алларына-артларына карамыйча элдерәчәкләр»,— дип елмайды ул һәм шунда ук, эшлекле тонга күчеп, миңа Якутиядә килеп туган хәл турында сөйләде. Аннары, әңгәмәсен йомгалап, Колчакка һәм Ерак Көнчыгышта атаман Семеновка каршы көрәше буенча ук инде аның хакында бик күп ишеткән булуын, Себердә акгвардия калдыкларына каршы көрәштә дә Совет властена ярдәм итәчәгенә ышанычын белдерде.

Себер партизаннарының данлыклы командиры Каландарашвили командалыгындагы икенче Төньяк отряды әнә шуннан соң оештырыла. Отряд 100—150 кешелек подразделениеләргә бүленә. Беренче подразделениенең командиры итеп күренекле командирларның берсе Иван Яковлевич Строд билгеләнә. Шәриф Садыйков та шул отрядка эләгә. Бу подразделение сафлары алдында Нестор Александрович Каландарашвили речь белән чыга:

— Миннән һәм сездән, дусларым минем, ак бандаларны һәм интервентларны тулысынча тар-мар итүдә Якутия өлкәсе хезмәт ияләренә булышлык күрсәтүне Владимир Ильич Ленин үзе сорады. Башкомандующий Совлукның беренче махсус отряды үзенә тапшырылган бурычны үтәп чыга алмады... Лена буе крестьяннары кая барып сугылырга белмиләр. Аларның күбесе ак бандаларның талауларыннан куркуга төшкәннәр һәм, кулаклар йогынтысына бирелеп, аклар белән киткәннәр. Аклар, кызылармеецлар алар кеше ашаучылар, чума авыруы алып килүчеләр, дигән сүзләр тараталар. Сезгә, дусларым минем, йөз утыз алты авыл аша олауларда узарга туры киләчәк,— ди башкомандующий Каландарашвили һәм һәртөрле тозакка эләкмәс өчен сизгерлеккә чакыра. Сүзен ул болай дип тәмамлый:

— Безгә халык арасында хезмәт ияләрен изелүдән һәм байлар коллыгыннан коткаручы властьның — Совет властеның төп бурычларын аңлатырга, пропагандаларга кирәк.

Кызылармеец иптәшләр! Шуны исегездә нык тотыгыз: без хезмәт халкын азат итүчеләр. Шуңа күрә сак булыгыз, халыкның бер генә әйберенә дә кагылмагыз... Хезмәт ияләренең интересларын саклауны безгә Коммунистлар партиясе һәм Владимир Ильич Ленин үзе ышанып тапшырды. Без бу ышанычны акларга тиешбез! Алга, җиңүгә, улларым һәм дусларым минем!..

* * *

«Безнең отряд турындагы сүзләр крестьяннарга үзебездән алданрак барып җитә һәм алар безнең юлыбызда төрлечә ярдәм итәләр иде,— дип искә ала Шәриф Садыйков.— Ак бандаларның талавыннан куркуга төшкән крестьяннарның олы җанлылыгы һәм ярдәме кызылармеецларның күңеленә җылылык өстәде. Әйтерсең, чатнап торган салкыннар да алар каршында көчен югалта иде».

Олекминск шәһәрендә стродчыларны аеруча җылы каршылыйлар. Монда отряд шәһәрнең үзендәге һәм якын тирә авыллардагы ярлылар хисабына тулылана, аның сафлары ишәя. Җирле халык биредә аңа азык-төлек белән дә ярдәм итә.

Авыр юл үтеп ял иткәннән соң, Строд отряды 1922 елның 2 мартында Якутск шәһәренә юнәлә. Дошман гаскәрләре белән уратып алынган шәһәр чолганыш хәлендә була. Халык ягулыксыз, мал-туар печәнсез интегә.

Акгвардиячеләр штабының Якутск шәһәреннән үнсигез, ә алгы сызыктагы отрядларының 20—25 километр ераклыкта урнашкан булулары ачыклана.

Ашыгыч рәвештә махсус разведка һәм элемтә группалары оештыру таләп ителә. Ул группаларның берсенә командир итеп Иван Яковлевич Строд Шәриф Садыйковны билгели.

— Шулай, дускай, менә хәзер сиңа элемтә группасы белән җитәкчелек итү йөкләнә,— ди ул аңа, кыска гына итеп.— Үзегез белән алырга теләгән кешеләрнең исемлеген төзегез, аннан миңа күрсәтерсез.

— Элемтә урнаштырып йөргәндә өч тәүлек буена ат өстеннән төшәргә туры килмәде. Ашау да, йокы да онытылды,— ди Шәриф Шакирович, шул хакта искә төшереп.

Дүртенче мартта стродчылар ак бандитларның штабын уратып алалар һәм, ике тәүлеккә якын дәвам иткән сугыштан соң, дошманның төп көчләрен шәһәрдән читкә алып ташлыйлар.

Шәриф Садыйков отряд командирының сугыш-кирәк яраклары, азык-төлек һәм транспорт белән тәэмин итү буенча ярдәмчесе итеп билгеләнә. Бу ышанычны ул намус белән аклый.

Стродчылар Якутия территориясендә халык дошманнарына каршы көрәштә сугышчан данлы юл үтәләр. Ләкин башкомандующий Каландарашвилига бу җирләрдә Совет властеның тулы җиңүен күрергә насыйп булмый. Аның штабы Лена елгасының тар агымында Якутск шәһәреннән 33 километр ераклыкта буржуаз милләтчеләр бандасы тарафыннан оештырылган засадага эләгә. Башкомандующий үзе дә, башкалар да шунда һәлак булалар.

Коммунист Шәриф Садыйков армиядән 1923 елда демобилизацияләнә һәм, төпләнеп, Амга районында яшәргә кала. Шунда өйләнә. 1928 елга кадәр ярлылар комитеты председателе булып эшли. 1929 елда җир бүлү эшендә актив катнаша һәм 1930 елда «Победа» колхозы председателе итеп сайлана.

Якутиянең партия оешмалары Шәриф Садыйковны күп кенә җитәкче постларга билгеләделәр. Коммунист исеменә ул беркайда да тап төшерми, һәр урында үзен оста җитәкче итеп таныта.

Аның халык алдында күрсәткән хезмәтләренә партия һәм хөкүмәт югары бәя бирә. Якутиянең кырык еллыгында аңа Якутия АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасын тапшыралар. Совет властеның илле еллыгында исә, революция казанышларын саклап калу өчен барган көрәштәге хезмәтләре өчен, ул хәрби орден — Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Иң куанычлысы шул. Күпне кичерүенә һәм өлкән яшьтә булуына карамастан, ул һаман да яшьләр кебек җитез, көчле ихтыярлы. Үзенең тырыш хезмәте белән яулап алынган лаеклы ялга ул хәзер дә китәргә теләми. Әйе, аның кебекләргә хезмәттән башка тормыш юк...

Һәм менә җитмеш яшендә ул яңадан партия райкомына килә.

— Өйдә кул кушырып утыра алмыйм. Совхозда миңа нинди дә булса эш бирегез,— ди ул.— Гомерне бушка уздырганчы, кешеләргә ярдәм итәргә, аларга файда китерергә телим.

Шуннан бирле Якутиядәге Амга совхозында чәчләренә куе чал кунган, ләкин картлыкка бирешмәгән өлкән яшьтәге кешене һәр көн саен очратасың. Бу — совхозның ашлык склады мөдире Шәриф Садыйков.

Нияз Хәкимуллин

# ХӨРМӘ ИЛЕНДӘ

Без ИЛ-18 самолетында очабыз. Нинди милләт кешеләре генә юк монда: негр дисеңме, гарәп дисеңме, төрек дисеңме — барысы да бар. Руслар да байтак. Кайсы Кипрга, кайсы Сириягә юл тота. Ә без барсыннан да ераккарак — Иракка барабыз.

Минем уң ягымда утыручы күршем әле яңа гына Мәскәүдә аспирантура тәмамлап, туган иленә — Никосиягә кайтып баручы журналист булып чыкты. Русчаны да әйбәт кенә белә икән үзе. Ә уң ягымда утырган иптәш — урта яшьләрдәге рус агае — Уралдан, Нижний Тагил шәһәреннән икән. Инженер. Моңарчы Иделдә Саратов ГЭСын төзүдә катнашкан, ә хәзер, совет белгече буларак, хатыны һәм ике баласы белән гарәп дусларга ярдәмгә — Сириягә, Ифрат елгасында төзелә торган куәтле ГЭСны төзешергә бара. Минем алдагы йомшак креслоларда — безнең делегация членнары. Без — унбиш кеше. Төрлебез төрле милләт вәкилләре: үзбәк, казакъ, таҗик, төркмән, молдаван, украин, рус һәм мин — татар егете. Милләтебез төрле булган кебек үк, һөнәрләребез дә төрлебезнеке төрлечә: кайсыбыз укытучы, кайсыбыз врач, журналистлар да бар. Кыскасы, фән һәм культура эшлеклеләреннән торган лекторлар группасы без. Максатыбыз: Якын һәм Урта Көнчыгыш халыкларына экономика, мәгариф, медицина, сәнгать һәм культура өлкәләрендә Советлар Союзы ирешкән уңышлар турында сөйләп аңлату.

Самолетыбыз туп-туры көньякка таба оча. Курск, Харьков, Запорожье шәһәрләре артта калды, тар гына тасма булып Днепр күзгә чагылып китте. Аннары, Кырым ярларын үтеп, Кара диңгез өстеннән оча башладык. Аннары, башларын ак кар каплаган Төрек таулары өстеннән, күп санлы мәчет манаралары кояшта ялтырап торган Анкара шәһәре өстеннән үтеп киттек тә, урыны-урыны белән генә эшкәртелгән сусыз, агачсыз чүллекне узгач, Урта диңгезгә барып чыктык. Алда көнбатыштан көнчыгышка сузылган зур утрау күренде. Кипр утравы иде бу. Шунда без, Мәскәүдән күтәрелеп киткәннән бирле беренче тапкыр, җиргә төштек. Халыкара аэропорт исәпләнсә дә, Никосия аэропорты бик гади генә икән: кечкенә, караңгы, чисталык та бик чамалы. Аннары бер дә көнчыгышка хас үзенчәлеге юк, барысы да европача: шактый кыйммәтле сувенирлар да, витриналарга куелган ярым ялангач хатын-кыз рәсемнәре дә, барларындагы аша-эчү әйберләре дә — барысы Америкадан китерелгән...

Һәр ягыннан түбәләрен кар каплаган биек таулар белән уратылып алынган бик зур казанлыкка утырган, алтын мәчет манараларын ялтыратып торган Дамаск — Сириянең башкаласы да артта калды инде. Хәзер без Сирия чүле өстеннән очабыз. Иксезчиксез кызгылт комнан башка, чүлдә бернинди тереклек билгесе юк. Шулай өч сәгать чамасы очканнан соң, самолет канаты астында бер зур гына елга күзгә чалынып китте.

— Ифрат! — диде стюардесса, пассажирларның кинәт тәрәзәгә текәлүләрен күреп.

Ярлары ямь-яшел үсемлекләр белән капланган Ифратны үтеп күп тә бармадык, тагын бер елга — Тигр күренде. Монысының яр буйларындагы үсемлекләр һәм агачлар тагын да куерак, бөтен җире сугару каналлары белән челтәрләнеп беткән. Атаклы

Месопотамия түбәнлеге, дөньяның җәннәте дип атала торган җир менә шушы була инде! Бик борынгы заманда, әле безнең гасырга кадәр үк, бу җирләрдә бик куәтле, бөтен кешелек культурасына йогынты ясаган Ассирия һәм Вавилон дәүләтләре булган. Гарәпләр тарафыннан яуланып алынганнан соң, Месопотамия Багдад хәлифәтенең үзәгенә әверелә. Ул чорда анда сәүдә, һөнәрчелек, фән һәм архитектура, әдәбият һәм сәнгать бик нык үсеп китә. Математика, астрономия һәм диңгезчелек эшен үстерүгә дә бик зур өлеш кертелә. Алгебра, азимут, зенит, цифр, тариф һәм башка шундый фәнни терминнар нә шул чордан гамәлгә кереп калган инде, чөнки гарәпләр математика, астрономия өлкәсендә бик нык алга киткән булганнар. Магазин, бакалея, кофе, халат, тара кебек сүзләрне дә рус сәүдәгәрләре Гарәбстаннан алып кайтканнар. Адмирал дигән сүз чыгышы ягыннан шулай ук гарәпләргә барып тоташа. Ул заманнарда Тигр һәм Ифрат елгалары үзәнлегендә яшәгән халык та хәзергегә караганда җиде-сигез мәртәбә күбрәк булган.

Борынгы тарихчылар бу илне муллык, иркенлек иле дип атаганнар. Месопотамиянең җире дә бик уңдырышлы булган. Сука калагы тигән һәр урында иген котырып уңган...

Әнә шул, заманында атаклы булган ил өстеннән шактый очкач, Иракның башкаласы, исеме әкиятләргә кергән Багдад шәһәренә килеп җиттек.

Менә без шәһәрнең иң җанлы, иң матур урынында — Әл-Рәшид урамында. Багдадны, гадәттә, «әкият» шәһәре дип атыйлар. Ихтимал, заманында шулай булгандыр да. Әмма хәзер бу шәһәргә килгән кеше аны алай дип үк әйтмәс. Багдад, нигездә, бер-ике катлы йортлардан тора. Йортлардан биек булып күтәрелеп торган мәчет манараларын һәм пальма агачларын искә алмаганда, алай бик үк шаккатарлык нәрсәләр юк. Дөрес, үзәк урамнардагы кибетләре, рестораннары, отельләре шактый бай һәм матур җиһазландырылган, аларга игътибар итми китү мөмкин түгел. Әмма мондый зиннәтле биналар алай күп түгел. Үзәк урамнардан аз гына читкәрәк киттеңме — бөтенләй башка шәһәргә килеп эләккән кебек буласың: караңгы, тар урамнар башлана. Тәбәнәк, кечкенә йортлар. Балчыктан салынган ул йортларның тәрәзәләре төбеннән үк диярлек канау уза. Ул канаудан пычрак су агып тора. Үзенә күрә ачык канализация инде бу



*Һарун-Әл-Рәшид — Багдадның үзәк урамы.*

Юк, Багдадның ярлы халык яши торган бу өлеше һич тә әкият шәһәренә охшамаган.

Әмма ул шәһәрнең бүгенге хәлен аңлар өчен, аның үткәненә күз ташлап китәргә кирәктер. Багдад — дөньядагы иң борынгы шәһәрләрнең берсе. Чыннан да, заманында бик шәп, бик матур булгандыр ул. Борыннан калган легендаларга караганда, Багдад элек меңләгән мәчетләре, зур-зур кәрван сарайлары, искиткеч бай базарлары, шаулап торган фонтаннары белән бөтен дөньяда дан тоткан мәшһүр шәһәр булган. «Мең дә бер кичә»нең геройлары да шушы шәһәр урамнарында йөргән. Ә шәһәр белән Һарун Әл-Рәшид үзе идарә иткән. Аңа баш иягә төрле илләрдән дәрвишләр һәм илчеләр, сәүдәгәрләр һәм фалчылар килә торган булган.

Шул ук вакытта Багдад трагик хәлләрне дә бик күп кичергән. 1258 елда бу шәһәргә бик зур һөҗүм ясалган. Андагы 800 мең кеше суелган, шәһәр үзе яндырылган. Чәчәк атып утырган Месопотамия җирләре таланып, чүлгә әйләндерелеп калдырылган. «Дөнья яратылганнан бирле мондый коточкыч үтереш һәм талауның булганы юк һәм дөнья беткәнче дә мондый тамаша булмас», дип язган ул сугыш турында гарәп тарихчыларының берсе.

Хулагу башлаган ул эшәке эшне йөз илле елдан соң Тимур тәмам итә. XVI гасырдан алып безнең гасыр башына кадәр, ягъни дүрт йөз елга якын, Ирак төрек пашалары хакимлеге астында була. Ә беренче Бөтендөнья сугышы елларында Ирак җирендә Төркия белән Англия үзара сугыша башлыйлар. Нәтиҗәдә инглизләр төрекләрне куып чыгарып, Ирактагы бай нефть чыганакларын үз кулларына алалар, ә Багдадны төзекләндерү турында уйлап та карамыйлар. Ирек сөюче ираклылар инглизләргә каршы берничә мәртәбә кораллы восстаниегә күтәрелеп карасалар да, ул восстаниеләр инглиз гаскәрләре тарафыннан бастырыла килә. Ә икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Америка һәм Англия империалистлары Иракны хәрби агрессив блокка — Багдад пактына керергә мәҗбүр итәләр. Иракның хезмәт халкы тагын да ныграк бөлгенлеккә төшерелә. Моңа монгол, фарсы, төрек яулап алучылары һәм инглиз империалистлары гаепле. Дөнья цивилизациясенең бишеге булган Багдадны алар шундый кыен хәлгә калдыра.

1958 елның 14 июлендә Иракта революция була. Баш күтәргән Ирак хәрби частьлары, халык белән бергәләп, үз илләрен колониализмнан азат итәләр. Ирак республика булып игълан ителә һәм Багдад пакты белән элемтәдән чыга.

Без Иракта яз көне булдык. Ләкин андагы яз безнең язга һич тә охшамаган иде. Анда кар бөтенләй юк. Кая карама — чәчәкләр, ә җылылык 20 градустан да югарырак. Иракның җире бик юмарт, анда елына ике-өч мәртәбә уңыш чәчеп үстерергә мөмкин. Шунлыктан базарларында ел буе яңа өлгергән җиләк-җимеш сатыла.

Багдадка килеп төшүебезнең икенче көнендә без табигатьнең гаҗәеп күренешенә юлыктык. Кызыл яңгыр яуды. Әйе, әйе, нәкъ кан төсле кып-кызыл яңгыр! Үзе ул нәкъ бездәге шикелле яңгыр, әмма кызыл. Без яңгыр башланганда машинада бара идек. Яңгыр ява башлауга, машинабыз тукталып калды. Бер безнеке генә түгел, бүтән машиналар да тукталган, чөнки яңгыр шундый куе — биш-алты метрдан ары берни күрә алмыйсың. Кызыл яңгыр бу якларда гадәти хәл һәм аның хикмәте менә болай икән: җил чүл комын туздыргач, аның тузан кебек кенә вак кисәкләре һавага күтәрелеп, болыт сыман очып йөри. Менә шул тузан болыты белән чын болыт кушылып, яңгыр ява башлаганда тузан бөртекләре дә яңгыр тамчыларына ияреп җиргә төшәләр һәм, шулай итеп, кызыл, пычрак яңгыр ява.

Яңгыр яумаса да, тузан болытлары күтәрелгән вакытта самолетлар оча алмый — күк йөзе караңгылана. Ә андый вакытларда аэропортта халык шыгрым тулы була. Без дә шундый чакта туры килдек. Безнең аэропортларда да һава шартлары самолетлар очарлык булмаганда халык күп була бит. Шунлыктан ул хәл гаҗәпләндермәде безне. Безнең игътибарны икенче нәрсә — халыкның күзгә ташланып торган ике төрлелеге җәлеп итте. Берәүләре бик купшы, зиннәтле киенгән, ә икенчеләре коточкыч начар кием кигәннәр. Зиннәтле киемлеләре аэропорт эчендә, йомшак урыннарда, әйбәт җиһазланган залларда утыра, ә ярлылар тышта, яңгыр астында, калтырап, үткән-барган баерак кешеләргә кулларын сузып, хәер теләнеп торалар. Багдадта гомумән ярлылар күп һәм алар бик кыен хәлдә яши. Торыр җирләре булмаганлыктан, урамдагы тротуарларда төн үткәрүчеләрне бик еш очратырга мөмкин анда. Әмма



*Гарәпләрнең милли киеме менә шушындый.*



*Гарәп студентлары.*

бу хәлгә байларның һич тә исләре китми, алар бары тик үз эшләре белән генә мәшгуль.

Багдад урамнарында һәрвакыт халык бик күп була, барысы да дип әйтерлек үзләренең милли киемнәрен киеп йөри алар. Кайбер ирләр итәкләре үкчәләренә җитеп торган озын күлмәк, аның өстеннән халат яисә «абу» дип атала торган кара яки коңгырт төстәге йон тукымадан тегелгән плащ кигән. Кайберләренең абу якалары һәм иңбашлары алтынлаган тасма белән бизәлгән. Алары — байлар. Барлык гарәпләр дә башларына «күфия» — баш яулыгы — ябып, җил очырып алып китмәсен өчен аны «агаль» — йоннан үрелгән җеп — белән бәйләп йөриләр. Кайбер ирләр озын күлмәк өстеннән заманча пинжәк кия. Соңгы мода буенча тегелгән бик шәп костюм киеп, ап-ак күфия ябып йөрүчеләр дә шактый еш очрый. Яшь гарәпләр, бигрәк тә студентлар, кара-соргылт төстәге европача костюм һәм һәркайсы ак күлмәк киеп, галстук тагып йөри.


Хатын-кызлар да милли һәм европача кием кияләр. Күбесе кара озын күлмәк киеп, йөзләренә «абайя» дип аталган кара чапан бөркәнеп йөри. Абайялары бик озын, башларыннан аяк йөзләренә тикле төшеп тора. Кайберләре абайяларын алгы яктан ачып, иркенләп, ә кайберләре бары тик битләрен генә күрсәтеп, бөтен гәүдәләрен томалап йөриләр. Аякка һәм кулга беләзек тагып йөрү — хатын-кызлар өчен бик модалы санала. Кайбер яшь хатыннар, һинд хатын-кызлары сыман, уң борын яфрагына алка, алтын каптырма яки кыйммәтле асыл таш тагып йөри. Күп кенә хатын-кызларның, бигрәк тә авыл тирәсендә яшәүчеләрнең, битләренә татуировка ясалган. Кияүгә чыккан кайбер хатын-кызларның да авыз кырыйларына һәм битләренә кара тушь белән сызыклар сызылган. Бу хатын-кызга чит ирләрнең күзе төшмәсен өчен шулай эшләнә икән. Ә аяк түбыкларына яисә табан асларына шулай ук тушь белән төрле бизәкләр төшерелгән. Һәм ул, үзләренчә, бик модалы, затлы исәпләнелә. Заманча



*Гарәп хатын-кызлары.*

киенгән хатын-кызлар да еш очрый. Алар кыска күлмәк киеп, тырнакларын, иреннәрен һәм кашларын буяп йөриләр. Чәчләре киселгән, аякларында биек үкчәле туфли, кулларында сумка. Әмма алары да һәркайсы әлеге абайяны бөркәнеп, хәтта кайберләре битләренә пәрәнҗә дә ябып йөриләр.

Гарәпләр, гадәттә, әйберне кулларына тотып түгел, бәлки, кәрзингә салып, баш түбәләренә күтәреп йөриләр. Алар моңа шулкадәр күнеккәннәр, хәтта сәгатьләр буена үзара сөйләшеп торсалар да, кәрзиннәрен баш түбәләреннән төшермиләр. Шунысы гаҗәп, алар ул кәрзиннәрен куллары белән бөтенләй тотмыйлар. Кул аларга ике генә тапкыр — әйберне баш түбәсенә күтәреп куйганда һәм аннан төшергәндә генә кирәк!



*Гарәпләр әйберне гел баш өстендә йөртә.*

Багдад урамнарында машиналар да бик күп. Баеraклар я үз машиналарында яисә таксида йөри, ә ярлылар икешәр катлы автобусларда. Безне шунысы гаҗәпкә калдырды: шоферлар бернинди урам хәрәкәте кагыйдәләренә дә буйсынмыйлар. Кем ничек һәм кайдан барырга тели — машинасын шулай алып бара. Безнең автоинспекторлар ул хәлне күрсә, чәчләре үрә торыр, нишләргә белмәсләр иде. Билгеле бер кагыйдә булмауның бәласе дә зур: Багдадта автокатастрофалар бик еш булып тора икән.

Багдад байлары таксига да, автобусларга да утырмый. Аларның ялт итеп торган үз машиналары бар. Ул машиналар кайда гына туктаса да, шундук чүпрәк тоткан малайлар йөгереп киләләр дә, хуҗалары килгәнче, аларны чип-чиста итеп сөртеп куялар һәм китеп торалар. Гадәттә машина хуҗасы аларга әз-мәз акча биреп китә.

Багдадның яңа урамнары иркенрәк, киңрәк. Ә иске урамнары шундый тар, әгәр кара-каршы килсәләр, ике машина сыярлык та түгел. Андый урамнардагы һәр йорт каршында балконнар бар. Урамның уң ягындагы йорт балконы белән сул ягындагысы күбесенчә бер-берсенә орып ук эшләнгән. Шунлыктан урамнары көндез дә гел караңгы, күк йөзен бөтенләй күреп тә булырлык түгел. Шул ук вакытта ул балкон-түшәмнәрнең файдасы да бар: алар көндез кояш чамасыз нык кыздырган вакытта күләгә биреп, халыкны эсселектән саклыйлар. Әнә шундый «түшәмле» урамнар почмакларында кечкенә-кечкенә базарлар урнашкан. Урын кысан булу сәбәпле, бананнар да, карбызлар да, хөрмәләр дә җиргә, тротуарга куелган. Йорт стеналарына сатарга алып килгән сарык түшкәләре элгәннәр. Әгәр телисең икән, синең күз алдыңда үзеңә ошаган урынын кисеп алып, ит хуҗасы сиңа шундук шашлык та кыздырып бирә. Ә шашлык өлгергән арада сиңа шул ук хуҗаның хуш исле тәмле чәен эчә торырга мөмкин. Теләгең генә булсын!

Базарларда, урам чәйханәләрендә бер гарәп хатын-кызын да күрмәссең. Аларга мондый урыннарда йөрергә ярамый, ислам дине рөхсәт итми. Әмма ир-атлар рәхәтләнә инде! Алар сәгатьләр буе гына түгел, көннәр буе үзара сөйләшеп, төтене су аркылы үткәрелә торган тәмәке тартып утыралар. Кайберләре шунда ятып йокы да симертеп ала. Аларга вакыт кызганыч түгел, чөнки алар барыбер эшсез йөрүчеләр. Берәр бай кеше килеп, эшкә дәшмәсме дип өмет итеп утыралар. Әгәр юлыңны дәвам итеп, Әл-Рәшид урамының аргы башына барып чыксаң, «Сук» дип атала торган атаклы Багдад базарына барып керәсең. Сук — шәһәрнең берничә кварталына сузылган ябык базар. Ул меңнәрчә вак кибетләр белән тулган. Һәр хуҗа үзенең кибет өстен хәленнән килгәнчә ябарга тырышкан. Калай, шифер, брезент түбәле кибетләр дә, гади чүпрәк белән ябылганнары да бар анда. Сукта көндез дә караңгы. Шунлыктан кайбер кибет хуҗалары көндез дә ут яндырып утыралар. Нәрсә генә юк ул кечкенә кибетләрдә! Аларның кайберләрендәге бөтен товары күп булса ун-унбиш долларлыктыр инде, әмма аның хуҗасы барыбер көннәр буе шунда көн үткәреп, сатып алучыларны көтеп утыра. Шундый кечкенә кибетләр белән рәттән, бик бай һәм зур кибетләр дә бар, әлбәттә. Товарлары төрле булган кебек үк, ул товарларның бәяләре дә төрлесеннән төрлечә. Кем күпмегә тели — шулай сата. Тик сатулаша гына белергә кирәк. Ул синнән башта ун динар сорый, ә сатулаша белсәң аның әйберен беркен динарга алып китәргә мөмкин. Шунда ук төрле һөнәр ияләре дә тулып ята. Теләгән кешегә, үз урыннарында утырган килеш кенә, тегеп тә, кисеп тә, ябыштырып та бирәләр. Йорт кирәк-яраклары да, төрле сувенирлар да ясый алар.

Базардагы тавышка колаклар тонып бетә. Барысы да үз товарын




*Ярлы гарәпләр транспорты.*

мактап кычкыра, сине үз кибетенә чакыра. Баерак кешеләрнең кибетләре янында сатып алучыларны чакырып, өндәп торучы малайлар да байтак. Кыскасы, барысы да сата. Ә алучы юк. Әйбер кирәксенмәгәннән, һәркемнең үз әйбере күп булганнан алай түгел, әлбәттә. Алырга теләүче күп, әмма акчалары юк. Әгәр дә синең берәр әйбер сатып алырга җыенганыңны сизенсә, кибет хуҗасы артыңнан калмыйча ияреп йөри һәм барыбер нәрсәсен булса да алып китәргә мәҗбүр итә. Ул базарның законы шундый!

Багдадның Җөмһүрият мәйданыннан сул якка китсәң — Тигр елгасы буена барып төртеләсең. Ул елга шактый киң. Андагы көймәләрнең исәбе-хисабы юк. Барысында да балыкчылар утыра. Олы кешеләр балыкны җылым белән, ә малайлар, яр буеннан торып, кайсы кармак белән, кайсы сөңге белән тота. Сөңге дигәнем — бамбук агачының башына беркетелгән һәм башлары бик әйбәтләп очланган дүрт-биш тимер чыбык. Таякның икенче башына җеп бәйләнгән һәм ул малайларның кулына чорналган. Малайлар шул «кармак»ны тотып, яр буеннан яки күпердән карап торалар да судан балыкны күреп алу белән тиз генә аны ыргыталар. Шулай итеп, икешәр-өчәр килолы балыкларны эләктереп алалар. Алар моны шундый оста эшлиләр — беркайчан да балыкка тидермичә калмыйлар. Тотылган балыкларны, бозылмасын өчен, шунда ук бәйләп суга салып куялар. Алырга теләгән кешегә шунда ук сатып та җибәрәләр. Әгәр куырган балык ашарга ниятең бар икән, шунда яр буенда учак ягып, куырып та бирәләр. Таба да, май да кирәкми, учак янына казык кагып, балыкны шунда элеп кенә кыздыралар.

Иракның дәүләт дине — ислам. Халыкның 94 проценты шул динне тота. Дини бәйрәмнәр анда бик күп, әмма алар барысы да эш көне санала. Бары тик җомга көн генә — ял көне. Ул көнне завод-фабрикалар да эшләми, кибетләр дә ябык була. Җомга көнне барлык мөселманнар да мәчеткә гыйбадәткә җыйнала.

Дөньядагы күп кенә илләрдә акча, байлык барлык нәрсәдән дә көчле булып, тормыш законы булып тора. Ә Иракта дин барыннан да көчлерәк. Анда һәр кеше туганнан алып үлгәнчегә кадәр шаригать законнарына буйсынырга тиеш. Ләкин шунысы кызык: дини йолалар ничек кенә катгый булмасын, егерменче гасыр техникасы анда үтеп кергән инде. Мәсәлән, мин Иракта мәчет манарасына менеп азан әйтүче мәзинне күрермен һәм, җае чыкса, фотога төшереп тә алырмын дип әметләнгән идем. Шуңа күрә фотоаппаратыма ерактан төшерү өчен махсус телеобъектив та алып барган идем. Багдадта йөзләгән мәчет



*Багдадта мәчетләр бик күп.*

бар. Әмма мин аларның берсендә дә азан әйтеп торган мәзинне күрә алмадым. Азанны мәзин түгел, бәлки мәчет манараларына беркетелгән громкоговорительләр әйтә анда. Мәзиннәр асрап мәшәкатьләнәсе юк. Магнитофонга язылып куелган азанны еллар буена сөйләт тә сөйләт!

Мәчетләрнең күбесенең гөмбәзләре алтыннан эшләнгән. Кайбер мәчетләрнең гөмбәзләрен ясау өчен егермешәр тонна алтын киткән ди! Әмма урам тулы ач, ярлы, йортсыз-җирсез халык хәер сорап, теләнеп торган вакытта ул алтын гөмбәзләрнең ялтыравы тоныкланып кала.

Әйе, Иракта ислам бик көчле. Шәригать законнары кая барсаң, ни эшләсәң дә үзләрен сиздереп тора. Мәсәлән, анда фотога төшерү катгый рәвештә тыела, гөнаһ санала икән. Үз кешеләренә дә, чит ил туристларына да фотоаппарат йөртү, рәсемгә төшерү рөхсәт ителми. Безне дә махсус кисәтеп куйдылар. Мин дә бу рәсемнәрне алып кайта алмаган булыр идем. Әмма, бәхеткә каршы, Ирак журналистлары белән очрашырга туры килде. Шулар ярдәм итте миңа. Очрашу вакытында бер прогрессив газета редакторы бездән, Ирак сездә нинди тәэсирләр калдырды! дип сорады. Мин аңа:

— Тәэсир әйбәт, әмма нигә безгә фотога төшерергә рөхсәт ителми. Сезнекеләр Советлар Союзына килгәч, бездә теләсә кай җирне, хәтта Кремльне дә төшерергә рөхсәт ителә. Ә сездә бернәрсәне дә төшерергә ярамый икән,— дидем.

Редактор беraз уйланып торды да:

— Ярар, берәр әмәлен табарбыз ничек тә! — диде.

Ә икенче көнне иртән газета редакциясенең бер хезмәткәре миңа «Сәхафәт» дип эре хәрефләр белән язылган сары кәгазь китерде. Шул кәгазьне фотоаппарат сумкасына ябыштырырга кушты. «Сәхафәт» безнеңчә журналист, корреспондент дигән сүз.

Минә шуннан соң минем эшләр җайланды инде. Кайда һәм нәрсә төшерәсем килсә дә, миңа сүз әйтүче булмады. Алай гына да түгел, гарәпләр үзләре үк мине төшер дип үтенә башладылар. Күрәсең, мине газета корреспонденты дип уйлаганнардыр һәм газетада рәсемнәрен чыгарырга теләгәннәрдер.

Ислам дине рәсемгә төшерүне генә түгел, бүтән бик күп нәрсәне дә тыя. Әмма шул ук ислам дине буенча бер ирга берничә хатын алып торырга рөхсәт ителә. Багдад шәһәренең үзәгендә, хөрмә агачлары арасында ике катлы бер йорт бар. Ул йортның хуҗасын бөтен шәһәр халкы белә икән. Хикмәт шунда, ул йорт хуҗасының сигез хатыны бар. Шул сигез хатыннан кырык ике бала туган һәм аларның барысы да ир балалар. Карап торырга алай шаккатарлык кеше дә түгел ул, авырлыгы нибары илле килограмм гына икән.

Андый күп хатынлы кешеләр бер ул гына түгел, күп анда. Теләгән кешегә ничә хатын алса да рөхсәт ителә. Тик туй ясарга һәм хатынына кыйммәтле бүләкләр, кием-салымнар алырга акчасы гына булсын. Әмма бик күп гарәпләрнең берничә хатын түгел, бер хатын алырга да хәле җитми шул. Әгәр дә



*Хәзер эш көйле — минем сумкада «Сәхафәт».*

инде өйләнгән икән, алар хатыннарын аермаска тырышалар, чөнки бүтән хатын алу өчен тагын зур расход чыгарырга кирәк булачак. Шунлыктан анда хатын аеру бик сирәк хәл.

— Иракка килеп тә Вавилонны карап кайтмау — җинаять булыр иде! — диде безнең белән барган бер иптәш һәм бер көнне шунда киттек. Вавилон Багдадтан ерак түгел, нибары туксан биш километрда гына икән. Кукуруз, ясмык, хөрмә кырлары аша барганнан соң, автобусыбыз «Вавилон» дип язылган багана янында тукталды.

— Сез хәзер изге җирдә, борынгы Вавилон дәүләте җирендә басып торасыз,— диде гид, без автобустан төшүгә сөйли башлап.— Әнә теге чокыр-чакырлы урыннар — борынгы каналлар урыны. Ә менә шушы юл буеннан ук башланып киткән балчык стена элек бөек шәһәрне әйләндереп алган булган һәм койма хезмәтен үтәгән. Заманында бу урын дөнья цивилизациясенең үзәге булган. Көннәрне җиде көнлек атнага, елны унике айга, түгәрәкне өч йөз алтмыш тигез кисәккә бүлү һәм шул кисәкләрнең һәркайсын градус дип атый башлауны шушында, Вавилонда уйлап тапканнар. Биек каланчага менеп, күк җисемнәре хәрәкәтен өйрәнергә керешү дә шушы җирдән башланган...

Аннары гид безне бер катлы йортка — музейга алып керде. Анда борынгы Вавилон корылмаларының макетлары куелган. Аларга карагач хәйран калмыйча мөмкин түгел. Безнең эрага кадәр дүрт мең ел чамасы элек барлыкка килгән һәм ике мең ел чамасы элек юкка чыккан Вавилон дәүләте заманында, чыннан да, бик бай һәм югары культуралы дәүләт булган. Аның шулай икәнлеген музейдагы күп санлы экспонатлар — йорт-җир әйберләре, алтын, көмеш бизәнү әйберләре һәм гаҗәеп зур осталык белән эшләнгән хайван сурәтләре «әйтеп» тора. Ә хәзер шул дәүләт урынында таш, балчык һәм ком өемнәре генә. Шәһәр үзе аста күмелеп калган. Вавилон дәүләте җире хәзер дә Ирак дәүләте тарафыннан сакланып тора, чөнки җир астындагы бик күп хәзинә әле дә тулысынча казып алынмаган. Хәзер анда казу эшләре алып барыла. Шәһәрнең кайбер урамнары казылып, чистартылган иде. Ул тар урамнарның стеналарына ясалган хайван сурәтләре хәзер дә күренеп тора әле.



*Вавилондагы асылма бакчалар урыны.*

Хәрабәләрдән бераз читтәрәк биек пьедестальда кара таштан ясалган бик зур арслан скульптурасы бар. Заманында Вавилон дәүләтенең куәтен күрсәтеп, куркытып торырга тиеш булган ул. Вавилон дәүләтеннән калган күп кенә хәзинәләрне бик күп талаганнар, күбесен чит илләргә дә алып киткәннәр. Әмма, күрәсең, бик зур булгандыр инде, әлеге арсланга тимәгәннәр. Куркыныч арсланнан талаучылар да курыккан булса кирәк.

Заманында Вавилонда асылмалы бакчалар булган һәм алар җир йөзендәге җиде могҗизаның берсе булган дип сөйлиләр. Хәзер ул бакчаларның урынын казыганнар һәм аларның эленеп тормаганлыгы ачыкланган. Калын таш стена карнизларена балчык түшәп кенә утыртылган булган алар. Ә ул бакчаларның утыртылу тарихы болай. Навуходоносор исемле Вавилон патшасы таулы, урманлы җирдә туып үскән Амитис исемле кызга өйләнгән дә аны Вавилонга алып кайткан. Вавилонда тора башлагач, Амитис үз илендәге агачларны, тауларны сагына башлаган. Менә шуннан соң патша, хатынының күңелен юатыр өчен, әлеге «эленеп» тора торган бакчаларны ясаткан.

Еллар үткән, Вавилон яулап алучылар кулы астына эләккән. Бәла өстенә бәла дигәндәй, аннары Ифрат елгасы ташып чыгып, Вавилон стенасын җимергән дә шәһәрнең бер өлешен юып алып киткән. Тора-бара Ифрат агышын үзгәрткән дә Вавилоннан бөтенләй еракка киткән. Шәһәр, коргаксып, ком бураннары хөкеменә калган һәм тора-бара бөтенләй ком белән күмелгән. Заманында чәчәк атып утырган Вавилон дәүләте әнә шулай юкка чыккан.

Багдадтан без Басра шәһәренә бардык. Басра — Тигр һәм Ифрат елгаларының тамагына урнашкан. Аны Иракның диңгез капкасы дип йөртәләр. Ирак күп кенә илләр белән сәүдә эшләре алып бара. Шунлыктан Басра портында, Ирак корабларыннан тыш, чит ил кораблары да һәрвакыт бик күп була. Без барганда анда өч Совет теплоходы Ирак завод-фабрикалары өчен кирәкле әйберләрне бушатып торалар иде. Ирактан алар хөрмә алып кайтачаклар. Ә Иракта хөрмә агачлары бик күп. Тигр-Ифрат елгаларының һәр ике ярында да хөрмә плантацияләре җәелеп ята.

— Иракны,— диде безне алып йөрүче гид,— кайчакта хөрмә республикасы дип атыйлар. Һәм ул, чыннан да, шулай. Дөньядагы бөтен хөрмәнең 80 проценты безнең



*Хөрмә плантацияләрдә.*

илдә үстерелә. Утыз өч миллион чамасы хөрмә агачы бар безнең илдә һәм аларда өч йөз илле сорт хөрмә үсә. Хөрмә агачы утырткannan ары өч елдан соң сиксән-туксан ел рәттән хөрмә бирә. Һәр агачтан елына уртача йөз-йөз егерме килограмм хөрмә җыеп алалар. Хөрмә безне туендыручы гына түгел, аның агачын төзү материалы итеп тә, ягулык итеп тә кулланабыз. Ә яфраклары белән түбә ябабыз, ботакларыннан кәрзиннәр үрәбез...

Ирак турында сүз алып барганда нефтьне искә алмый үтү мөмкин түгел. Капиталистик дөньядагы нефть запасының 10 проценты Иракта һәм ул нефть чыгару буенча дөньяда бишенче урынны алып тора. Анда ел саен 70 миллион тонна чамасы нефть чыгарыла. Күп еллар буена империалистик илләр шул нефть өчен үзара талашып килделәр. Хәзер исә нефть ятмаларын тулысы белән Ирак халкы кулына алу өчен көрәш бара.

Иракта безгә бик күп мәртәбәләр җирле халык белән сөйләшергә туры килде. Уку йортларындамы, хөрмә плантацияләрендәме, авылллардамы яки Багдад урамнарындамы — кайда гына сөйләшергә туры килсә дә, гарәпләр безгә ике бармакларын бергә куеп:

— Руслар белән гарәпләр дус! — дип әйтәләр иде.

Ирак республикасы әле яшь. Колониаль системадан котылуына нибары ун гына ел әле аның. Шунлыктан хәзергә гарәпләрнең тормышы шактый авыр. Әмма гарәпләр — бик тырыш һәм эшчән халык. Алар хәзер үз тормышларын яхшырту өчен зур һәвәслек белән эшлиләр. Тырышлыклары бушка китмәс — Ирак яңадан бай, куәтле илгә әйләнер дип ышанасы килә.

◆◆◆◆◆◆◆◆◆◆◆

# ВӘГЪДӘ ҺӘМ ОМТЫЛЫШ

**Заманында бер шагыйребез болай язган иде:**

Узды Тукай, Такташ язган чорлар
Һәм кайтмас та алар гомергә.
Сак булыгыз, гамьсез гулливерлар,
Лилипутлар килә шигырьгә.

**Аннан бирле байтак гомер үтте, һәм шул вакыт эчендә татар шигъриятенә бер төркем сәләтле яшьләр килеп керде: Роберт Әхмәтҗанов, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Р. Харисов, Р. Мингалимов, Г. Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Р. Вәлиев... Язган әсәрләренең сыйфаты, идея һәм сәнгатьчә көче ягыннан чыгып карaганда, бу шагыйрьләрне инде лилипутлар гына дип әйтеп булмас! Бу шагыйрьләр инде шигырь арбасының артыннан гына чапмыйлар, ә бәлки: аны төпкә җигелеп тартып баралар.**

**Аларның иҗатында мин Тукай сатирасының яңгырашын ишетәм, Такташның кыю һәм көчле фикерләрен очратам, Дәрдмәнд лирикасының гүзәллеген тоям, аларның әсәрләрендә Җәлил иҗатына хас зур гражданлык хисен сизәм...**

**Шуның белән бергә, классикларыбыз туплаган мирасны үзләштереп, яшь шагыйрьләр, җитди һәм кыю рәвештә, үз тавышларын, үз юлларын эзлиләр. Билгеле, эзләнүләр юлында уңышлар уңышсызлыклар белән чиратлашып бара...**

**Бу шагыйрьләрнең байтагы турында матбугатта фикерләр әйтелгәләде... Алар, күбесенчә, капма-каршы характердарак... Бу фикерләрдән бераз читтә калганы һәм иҗаты турында матбугатта җитди фикер әйтелмәгәне — Гәрәй Рәхим турында бер-ике сүз әйтәсе килә...**

Сөйләштек без грек храмнары,
Атом тузаннары хакында,
Яңа тормыш ничек булачагын
Бу гасырның теге ягында.
Бер ярсыдык, бер шаркылдап көлдек,
Бер моңаеп калдык тын гына.
Кызыл миләш кызыл тәлгәшеннән
Миләшләрен койды табынга.

**Гәрәй иҗаты турындагы сүзне шушы шигырьдән башлап китүем очраклы хәл түгел: чөнки укучылар Гәрәй Рәхимне нигездә лирик шагыйрь буларак беләләр. Шушы кечкенә шигырьдә дә без күпме уйланулар күрәбез...**

**...Миңа фикер лирикасы ошый! Һәм, бәлки шуның өчендер дә, мин Гәрәй Рәхим шигырьләрен көтеп алам. Аның лирик герое балавыз сыкмый. Гәрәйнең лирикасы, тар кичерешләр әрҗәсен җимереп, киң колач алырга тырыша. Аның лирикасы ваемсыз, битараф түгел. Гәрәйнең лирикасы кешенең шәхси кичерешләренә гади иллюстрация генә булып калмыйча, кеше рухына тирән керергә омтыла торган лирика-лазер!**

Мәхәббәттә синең белән
Сарайлар коралмадым.
Мин Таһир булган чакларда
Син Зөһрә булалмадың.
Ләкин син дә минем белән
Чатырлар куялмадың.
Син Зөһрә булган чакларда
Мин Таһир булалмадым.

**Гәрәйнең «Миләш төбендә», «Көзге урман», «Болыннарны атлар табырлаган» кебек шигырьләре дә фәлсәфи лирика белән тукланганнар...**

Гәрәй кырык беренче елны туган, ул сугыштан соңгы буын вәкиле... Бу буын сугыштан соңгы елларның ачлыгын, салкынын, кайгысын нык татыды... Һәм сугышка каршы ноталар Гәрәй шигырьләрендә дә урын алалар:

— Юк, мин үлемгә ышанмыйм! — дидем,
Катафалклар мыскыллап көлде.
— Юк, мин үлемне теләмим! — дидем,
Хәрби заводлар сүземне бүлде.

Яшь буын шагыйрьләренең, бер-берләреннән шактый аермалары булса да, уртак охшаш яклары да күп. Ул уртаклык барыннан да бигрәк тормышка фәлсәфи һәм аек караш белән карый белүдә күренә. Тормышны бар катлаулыгы белән кабул итеп, рухи күтәренке шигырьләр яза алалар бу шагыйрьләр. Гәрәй — шуларның берсе. Аның менә бу бәләкәй шигырен генә укып карыйк:

Тукайлар да киттеләр,
Җәлилләр дә киттеләр,
Җырлары бар, үзләре юк,—
Сәнгать корбаннар сорый.

Тормыш көрәшсез булмый,
Көрәш корбансыз булмый.
Яшь титаннар, сез сафтамы?!
Сәнгать корбаннар сорый.

«Ә буш кырда буран дулады» шигыре зур сагыш, лирика белән сугарылган:

Чемоданны куеп йөземә,
Кире киттем килгән эземнән,
Кире киттем капка төбеңнән.

Авыл буйлап туең уйнады,
Гармуннарга тынгы булмады.
Ә буш кырда буран дулады,
Өзеп-өзеп бүре улады...

Әлеге шигырь бер карауда гаять ямансу кебек. Кайбер тәнкыйтьчеләр әйтмешли, пессимизм исе килә аннан. Ләкин шушы бәләкәй генә шигырьдә күпме киеренкелек, күпме тирән кичерешләр! Әмма алданган ир-егет һич тә мескен булып күренми. Бу кеше куәтле һәм горур адәм! Юк, ул алданмады, ул кызганыч түгел. Теге кыз кызганыч, ул хатын шундый мәгърур, көчле ярата белә торган кешесен югалтты. Һәм шигырьдә кайдадыр ишарә бар: кайчан да булса, ул хатын үкенер, ялгышын аңлар!..

Тормышта Гәрәй Рәхим — гаять кызык, беркатлы, шаян кеше. Ләкин шигырьләрендә ул, бигрәк тә дус-ишләренә багышлаган шигырьләрендә, үзсүзле, хәтта кырыс, рәхимсез дә!

Ир-егетләр утларга да
Керә, дисең.
Каршыңда тик су гына бит —
Ник кермисең?!

Теләге бар диңгез аша
Күрә, дисең.
Дереслек бит нәкъ каршыңда —
Ник күрмисең?!

Нигездә лирик шагыйрь булса да, вакыт-вакыт Гәрәй төкселәнә, иронияга күчә ала:

Олыларны хөрмәт итәбез,
Эшебездә әйбәт эшлибез,
Яшьләргә каты бәрелмибез —
Әдәп белән генә яшибез.
Мәҗлесләрдә төптән уйланган
Дөрес сүзләр генә сөйлибез,

Тормыштагы бөтен эшләрдә
Бик акыллы, иплә кеше без.
Утызга да тулмый яшебез,
Шулкадәрле төгәл яшибез,
Әллә артык кызык кеше без,
Әллә бер дә кызык түгел без.

Яшь шагыйрьләребезнең иҗатын күзәтеп барганда, шул нәрсә күзгә ташлана: безнең шагыйрьләр кыска шигырь өлкәсендә үзләренең көчле икәннәрен исбат иттеләр инде. Ләкин шунсы кызганыч, әле татар шигырендә, яшьләр иҗатында, бәхәс кузгатырлык поэма күренми. Яшь шагыйрьләр асыл ташларны яхшы эшкәртә, шомарта беләләр, ләкин әле алар гади кирпечләр белән зур шигъри архитектура биналары сала белмиләр. Гәрәй бу турыда күптәннән сөйләнеп, борчылып йөри инде. Һәм зур күләмле шигъри әсәр язарга вәгъдә дә биргәне бар:

Йөрәкләр турында язасым бар әле —
Атылган йөрәкләр,

Ватылган йөрәкләр,
Сатылган йөрәкләр турында...

Ул вәгъдәсен онытмагандыр, үз сүзендә торыр, дип өмет итик...

Соңгы елларда әдәбият мәйданына килгән шагыйрьләрнең тагын бер уртаклыклары күзгә бәрелеп тора: шагыйрьләр гел шигъри әсәрләр иҗат итү белән генә мәшгульләр. Алар башка жанрда эшләргә шүрлиләр һәм күбесе, мин театрны белмим яки мин бит проза яза алмыйм, дип әйтәләр. Шуңа күрә аларның иҗаты берьяклырак.

Г. Рәхим исә төрле жанрларда эшләргә омтыла. Ул хәзер — өч китап авторы, аларның икесе — проза әсәрләре тупланган җыентык. Прозаик Гәрәй Рәхим турында сөйләгәндә, шагыйрь Гәрәй Рәхим янәшәдә генә. Аның прозасы шигъри фикерле, кыска, шигъри образлы проза, бигрәк тә «Омтылыш» китабындагы[1] лирик парчалары. Форсаттан файдаланып, мин бу китапка кергән бер-ике парчасына күз ташлап китмәк булдым.

«...Сандугач — табигатьнең сайрар патшасы, ләкин салкын яңгырлар көн буе ялангач ботакларны тараган, кайчандыр эре чәчәкләр күтәреп торган гөл сабаклары соргылт кура гына булып калган көзге көннәрдә инде сандугачлар да тыналар. Аның каравы, тәрәзә каршыгыздагы шәрә ботакта әле яңа гына авылга килгән шул каралы-сарылы песнәкне күргәч, сезнең күңелегез шатланып куя: «Табигать әле бөтенләй үк үлмәгән икән...»

Бу юлларны укыганда, гомумән, «Омтылыш»тагы лирик парчаларны укыганда, ирексездән уйлап куясың: Гәрәй натуралист икән, ә аның бу парчалары натуралист язмалары икән, дисең. Бу бер караудa гына. Эчкәрәк кереп, уйланып укысаң, һәр парчаның фәлсәфи әсәр икәненә ышанасың. Менә әле генә китерелгән кисәк — натуралист күзәтүе кебек, ләкин сандугач, песнәк турындамы соң бу парча! Сандугач, песнәк турында булса да, ул парчаны укыган кешедә чагыштыру туа: тормышның авыр вакытларында купшы киенгән, гел җырлап кына йөри торган «сандугачлар»мы, әллә юньләп җырлый да белмәгән, кеше күзенә артык ташланып яшәмәгән гади «песнәкләр»ме безгә өмет естн, кыенлыклардан коткара!!

Янсә «Сыерчык» парчасындагы түбәндәге җөмләләр күпме хисләр уята, уйланырга мәҗбүр итә:

«...Урамда апрель. Эре панельле йорт түбәсендә сыерчык сайрый. Өзгәләнә. Урамнан узучылар аңа карап сокланалар: «Тормышыбызның яңаруына сыерчык та шатлана, күр, ничек дәртләнеп җырлый»,— диләр.

Ә мин белмим, сыерчык кешеләр тормышына шатланып җырлыйдырмы, әллә үзенең зәңгәр төстәге оясын сагынып сайрыйдырмы».

Тормышыбыз матурланган чорда, күпләргә бәхет ташыйм дип, кайчакларда без кайберәүләргә зыян эшлибез һәм зыян эшләгәнебезне зур уңышлар шаукымында күрми калабыз, күрергә теләмибез. Кешеләр үзләренә зур-зур оялар коралар, ашыгалар, сөенәләр, сыерчыкның бәләкәй генә такта оясын исләренә дә алмыйлар. Әле шатланалар: «...күр, ничек дәртләнеп сайрый»,— диләр. Ә баксаң, сыерчык аларны каргый икән...

Гәрәй гади бер детальгә тукталып күзәтә башлый һәм шул деталь аша гыйбрәтле бер фикер китереп чыгара. Гади комбайн утыргычы турында Гәрәй менә нәрсә ди:

«Ярый әле җирдәге кресло өчен көрәш синең дермантин утыргычың өчен түгел! Никадәр бюрократ артыр иде. Ә бит кешеләр кырларда ашлык күкрәп утырган бер чорда синең утыргычыңның бер көн буш торуын затлы бәрхетләр белән тышланган креслоларның ай буе буш торуына караганда ныграк кызганалар. Кешеләр өчен син бик күп нәрсәләрдән кадерлерәк».

Чыпчык, песнәк, сыерчык, комбайн утыргычы — барысы да Гәрәй күңелендә хикәя булып туганнар. Бу хикәяләрдә прозаик Гәрәйгә шагыйрь Гәрәй нык ярдәмләшә.

Гәрәй Рәхимнең «Вагъда»се бар, «Омтылыш»ы бар!

Прозаик та, шагыйрь дә булырга аның ныќлы нигезе дә бар!

Роберт БАТУЛЛИН.

---

[1] Г. Рәхим. Омтылыш. Хикәяләр һәм лирик парчалар. Казан, 1969 ел.

# ЙОЛДЫЗЛАР НИЧӘҮ?

Нинди гадәттер, укучы буларак, мин үзем китапның мәгънәсен аның исеменнән үк эзли башлыйм. Матур исемгә кызыгып, алдана язган чаклар да булгалый. Шулай да исеме дә матур булган китапларны күбрәк яратам.

Ә хәзер минем кулымда Хәкимҗан Халиковның китабы, аның беренче шигырьләр җыентыгы[1]. Исеменә караганда, җисеме дә күңелгә ошап калыр кебек. Хәер, «Яшь ленинчы» газетасында, үзе эшләгән «Ялкын» журналы битләрендә аның шигырьләре әледән-әле күренгәләп торды. Һәм бәләкәчләр ул шигырьләрне яратып укыганнар иде дисәк, һич тә хата булмас.

Бу китапчык мәктәпкәчә яшьтәгеләр өчен дип, нәниләргә атап язылган. Шунысын искә алганда, ул игътибарга бигрәк тә лаеклы. Чөнки нәниләр өчен бик аз языла һәм, аз язылганга күрә, бик аз басыла да.

Хәкимҗанның бу шигырьләрен, безнеңчә, ике төркемгә бүләргә мөмкин: юмор һәм лирикага. Болай бүлеп карау бик шартлы нәрсә, билгеле. Чөнки аның лирик дигән шигырьләрендә дә юмор-сатирага хас бизәкле-бизәкле таңкәләр күзгә ташлана. Артык сайланып-нитеп тормастан, теләсә кайсы шигырьне, мәсәлән, «Яз хәбәре» дигәнен алып карыйк. Бу — төбендә лирик шигырь, әмма баштагы өлеше әчеңнән генә елмайта да торган.

Нишләр инде кыш бабабыз,
Ут капкан сакалына,
Ала-кола тунын сөйрәп,
Каядыр чаба гына...

Көенең агылышы йөгерек, житез — дулкын кебек; детальләр алдан ук исәпләнгән — төгәл. Ә инде соңга таба тон үзгәрә, тукранның җылы якка киткән кошларга «телеграмма сугу» кадәресенә җиткәч, автор житдиләнә төшә. Х. Халиковка гомумән юмор-сатира җиңелрәк бирелә. «Җәйге буран», «Кояш алган», «Торна белән Челән» һәм башка шундый шигырьләрен укыганнан соң, моңа тагын бер кат ышанасың...

Тагын шунысы куандыра: Хәкимҗанның шигырьләре буш сүзләрдән генә тормый, аларның һәркайсында диярлек поэтик фикерләү бар. Һәркайсы үзгә, һәркайсының үзенә бер тәм. Малай-шалай, пәке белән уеп, агачка кирәк-кирәкмәс сүзләр яза, коймаларны чуарлап бетерә... Моны без ничә ишеткән, ничә кат укыган инде. «Йолдызлар ничәү?»нең авторы да шуны ук сөйли, ләкин шулхәтле үзенчә, гүя син бу хакта беренче мәртәбә ишетәсең.

...Пәке түзми,
Шунда кинәт
Йомыла да
Тамга сала
Тәкыйның
Үз кулына да.

«Тәкый һәм пәке» шулай тәмамлана. Һәм бөтен табыш та аның әнә шулай очлануында. Автор малайны какмый-сукмый, гадәттәгечә, син тегеләй, син болай да дими, тәртип бозучының «җәзалаучы»сын да вакыйганың үзеннән, шул процесстан эзли. Нәтиҗәдә, акыл өйрәтү урынына, сурәт, хәрәкәт һәм образ берлеге алгы планга чыга. Бусы инде зуррак сабак, укыгач, онытылмый торган сабак.

Х. Халиков кыска яза. Һәм аның язганнарын парчалар дип кенә дә атарга булыр иде. Ләкин кыскалык үзе дә бик чагыштырмача нәрсә: озын шигырь дә кыска, һәм, шуның кебек, кыска шигырь дә артык озын тоелырга мөмкин. Бәхеткә каршы,

[1] Хәкимҗан Халиков. Йолдызлар ничәү? Татарстан китап нәшрияты. 1969.

Х. Халиковта мондый авыру барлыгы бик сизелми.

Шулай да кимчелекләр, аксаган урыннар бөтенләй үк юк түгел. Шуларның иң борчып торганы вакыйганы ике арада чыккан аңлашылмаучанлыкка кору. Мисал өчен, «Акбай бирми» исемле шигырьне алыйк. Әнисе кызына эт эчәгесе җыеп кайтырга куша, күп тә үтми, кыз елап кире керә:

— Эчәгесен бирми Акбай,
Гел ерә,—

ди. Кыз эт эчәгесенең нәрсә икәнен аңламаган булып чыга. Бу шигырь болай матур язылган, бөтен нәрсәсе җитеш. Әмма инде күп мәртәбә кулланылган мондый җиңел алымнан барыбер баш тартырга кирәк һәм Хәкимҗан аны үзе дә белә.

Ә гомумән әйбәт, балалар рәхәтләнеп укырлык китап бу. Сүз күбрәк табигать күренешләре, җанварлар турында гына бара икән дип, бер дә аптырап калырга кирәкми. Уйлап-уйлап карасаң, бала-чаганың беренче күргәне дә бит ай-йолдыз, җәнлек-җанварлар...

Х. Халиков байтак еллар мәктәптә укыткан, балаларның нәрсәгә һәвәс булуын, нинди эшкә теләр-теләмәс кенә тотынганлыкларын әйбәт белә. Шуның аркасында, күрәсең, тормышка шагыйрь күзе белән дә, педагог буларак та карый һәм бик яхшы итә. Киләчәктә укучылар аңардан тагын да матуррак әйберләр көтә алалар.

Хәзер Хәкимҗан икенче китабын, «Шук бабай» дигәнен әзерли. Анда, әлегә дә баягы, йолдызлар турында да шигырь бар:

...Йолдызларны җилләр өреп
Сүндерделәр, ахрысы.

Бусы да күңелгә ятышлы. Ләкин өлә әйтәсе килгән сүз башка. Поэзия дигән олы юл башына чыккан иптәшебезнең җилләр үз йолдызларын гына өреп сүндерә күрмәсен, киресенчә, күбәйгәннән-күбәйсеннәр генә... Күгә яктырак булыр.

Тәүфикъ КАМАЛИЕВ.

Юныс Әхмәтҗанов

# ТАБЫННАРЫБЫЗ ТУРЫНДА

*Журналыбызның узган елгы 9 санында совет сәүдәсе отличнигы, РСФСР сәүдә министрлыгының үзәк кулинария Советы члены, Ленин орденлы аш остасы Ю. Әхмәтҗанов турында очерк басылып чыкты. Бу очерктан соң журнал редакциясенә дә, авторның үзенә дә бик күп хатлар килде. Аларда укучылар татар халык ашларын, милли табынны ничек әзерләү турында киңәшләр сорыйлар. Ашларны ничек әзерләү турында Ю. Әхмәтҗановның «Татар халык ашлары» исемле китабыннан укып белергә мөмкин. Без бу санда укучыларга аның табын әзерләү мәсьәләсенә карата киңәшләрен тәкъдим итәбез.*

Кешенең яхшы тормышы, аның сәламәтлеге турында кайгырту — Совет хөкүмәтенең һәм коммунистлар партиясенең бөтен эшчәнлеге әнә шуңа юнәлдерелгән. Безнең илебездә кеше үзенең материаль һәм рухи таләпләрен мөмкин кадәр тулы канәгатьләндерсен, ул сәламәт булсын, үзен гел шат һәм бәхетле хис итсен өчен нәрсә кирәк, барысы да эшләнә: «Барысы да кеше өчен, барысы да кешенең бәхете өчен».

Сәламәтлек, хезмәткә сәләт, көр күңел, озын гомер башлыча кешенең туклануына бәйле. Һәр тере организм үзенең яшәү дәверендә энергия бүлеп чыгара, һәм шул процесста организмны тәшкил иткән матдәләрне югалта. Ә нормаль яшәү өчен ул матдәләрнең даими тулыланып торуы кирәк. Менә ни өчен кеше гомер итү дәвамында үз авырлыгына караганда мең ярым мәртәбәгә артыграк азык-төлек кабул итә. Ләкин күп ашау һәм яхшы ашау гына сәламәтлекне тәэмин итми әле, иң мөһиме: дөрес итеп, кирәгенчә һәм вакытында туклана белергә кирәк.

Халыкның көнкүреше, аның материаль культурасы социаль һәм экономик факторлар йогынтысында барлыкка килә һәм үсә. Шуңа күрә дә һәр халыкның йорт-җир төзелеше дә, кием-салымы да, ашау-эчүе дә үзенчәлекле. Әмма бер халык та, бүтән халыклардан аерылып, үз кабыгы эченә генә бикләнеп яшәми. Халыкларның экономик һәм культура аралашуы процессында бер халыкка хас ашлар, табын әзерләү тәртипләре икенче халыкка да күчә. Мәсәлән, хәзерге татар табынында яшелчә ашлары шактый урын алып тора. Шулай ук борын-борыннан татар халкына гына хас булган өчпочмак, пәрәмәч, бәлеш һ. б. лар кебек ашларны хәзер кайсы халыклар гына яратып ашамый икән!

Һәр халыкның үз традициясе, үз бәйрәмнәре, күңел ачу көннәре, аларны үткәрүнең үз тәртипләре бар. Советлар Союзы халыклары, эксплуатациядән азат тормыш төзеп, иң якты, иң шатлыклы көннәрендә яңа бәйрәмнәр булдырды. Бөек Октябрь бәйрәмендә кемнәр генә үзләрендә күңел күтәренкелеген сизми, кемнәр генә үзендә туган ил белән горурлану тойгылары, тирән патриотик хисләр кичерми.

Шатлыклы шау-шу белән, ап-ак чәчәкләргә төренеп, язгы хезмәт бәйрәме — 1 Май уза. Сигезенче март, Совет Армиясе көне, Яшьләр көне, Шахтерлар көне, Төзүчеләр көне, Сатучылар, Нефтьчеләр, Тимер юлчылар көне һ. б. лар.

Татар халкының да үзенең милли традицияләре белән бәйле бәйрәмнәре бар. Сабан туе хәзер республикабызда яшәүче кырыктан артык милләт вәкилләренең гомуми бәйрәменә әверелде.

Совет халкына коллективизм хисе хас. Совет кешеләре бәйрәмнәрне, үзләренең шатлыклы көннәрен үзләре генә, үз семьясы белән генә түгел, хезмәттәшләре, дуслары белән бергә җыелышып үткәрәләр. Бу бик табигый. Әйтик, берәр хезмәт алдынгысы югары хөкүмәт бүләге белән бүләкләнгән икән, бу бөтен коллективның горурлыгы түгелмени! Никах, бала туу, укуны тәмамлау, диссертация яклау һ. б. лар аерым бер шәхеснең генә шатлыгымыни!

Тагын бик матур традиция бар: безнең якташларыбыз борын-борыннан хезмәтне бәйрәмгә әверелдерәләр. Шул ук сабан туе да хезмәт бәйрәме ич. Аннары авылларда булсын, шәһәрләрдә булсын иң авыр, мәшәкатьле эшләрне без борын-борыннан өмә җыеп үткәрәбез. Мәсәлән, нигез салу өмәсе, ызба өмәсе (өй күтәрү өмәсе), каз өмәсе, сүс өмәсе һ. б. лар. Бу өмәләрдә гармонь уйнап тора, җыр гөрләп тора, җор-мәзәк сүзләр бер минутка да тынмый — эш үзе күңелгә дәрт бирә торган уенга әверелә.

Бәйрәм уңае белән кунакка килүчеләрне, өмәгә катнашучыларны сыйлый да белергә кирәк бит. Дусларың, якыннарың белән табын янында утыру бәйрәм өстенә бәйрәм, бик зур күңел юанычы бит ул!

Хөрмәтле укучылар, сезнең һәрберегезнең гаилә бәйрәмнәрендә, өй туйларында, туйларда кунакта булганыгыз шиктыйдыр инде. Һәм искәргәнсездер: берәүләрдә табын бик күңелле уза, икенчеләрдә күңелдә ниндидер сәер тойгы кала. Моның сәбәбе турында уйлаганыгыз бармы?

Әлбәттә, моның сәбәпләре бик күп. Шуларның берсе һәм, әйтергә кирәк, иң мөһиме — табынның ничек әзерләнгән булуы.

Татар ашлары бик күп төрле. Шуңа күрә бәйрәмнәрдә кунак чакырганда табындагы аш төрләре никадәр күбрәк булса, шул кадәр күңеллерәк.

Табын өстәлен, гадәттә, кунаклар килгәнче бер сәгать, сәгать ярым алдан әзерләп куялар.

Кунаклар чакырыр алдыннан шуны уйларга кирәк: бүлмә ничә кеше сыйдыра ала? «Күңел киң булса, урын иркен»,— дигән мәкаль бу мәсьәләдә урынлы түгел. Урын тыгыз булса, бу кирәгеннән артык ашыгу, шау-шу тудыра, кунакларның кайберсе игътибар җитмәүгә үпкәләве мөмкин: ыгы-зыгы арасында һәрберсенә игътибарның җитмәве бик табигый.

Өстәл уртасына җиләк-җимеш белән ваза, аның белән рәттән борыч, горчица, серкә савытлары куела. Өстәлнең ике ягына махсус савытлар (вазалар) белән җанлы чәчәк бәйләмнәре (ясалма чәчәк һич тә ярамый, юк икән, бөтенләй чәчәксез булуы яхшы), уртага салкын ашлар салынган савыт-сабалар куела, як-якка нечкә итеп туралган кара һәм ак ипи салынган савытлар урнаштырыла.

Өстәл кырыйлары буйлап бер-берсеннән бер үк ераклыкта кунаклар санынча зур һәм кечкенә тарелкалар тезелә. Тастымаллар өчпочмаклы яки дүрт почмаклы итеп төреп куела.

Тарелканың уң ягына кашык һәм үткен ягын тарелкага каратып пычак, ә сул ягына чәнечке урнаштырыла. Бокаллар, рюмкалар, фужерлар тарелка алдына тезелергә тиеш.

Менә кунаклар килеп бетте. Хәзер табын өстенә капланган япманы алырга да була. Хәл-әхвәл белешеп, күргән-белгәннәрне гәпләшеп, салкын закускаларны капкалап алганнан соң, беренче аш — токмачлы кайнар шулпа китерелә. Аннан соң гөбәдия я бәлеш, аннары кайнар ит — төрлек ите яки кош ите чыгарыла. Ит янына эре итеп туралган бәрәңге куела һәм аңа суган белән кишердән әзерләнгән соус салынган була.

Шуннан соң кунакларга карбыз-кавын яки компот-ширбәт тәкъдим ителә.

Шулай итеп мәҗлеснең беренче өлеше тәмамлана.

Тәнәфес вакытында, кунаклар уен-көлке, җыр-бию белән күңел ачкан арада, өстәл өстендәге артык әйберләр җыеп алына.



*Чәй өстәле.*

Мәҗлеснең икенче өлеше — чәй эчү. Чәй янына камырдан әзерләнгән ризыклар: чәк-чәк, талкыш кәләвә, пәхләвә, паштетлар, конфет, шикәр, как, бал, вареньелар, лимон, җиләк-җимешләр куела.

Мондый мәҗлесне һәртөрле уңай белән — Октябрь бәйрәме, Беренче Май, 8 Март бәйрәмнәре, кода-кодагыйларны туган-тумачалар белән таныштыру һ. б. лар уңае белән уздырырга мөмкин.

Башка төрле уңай белән дә чакырыла торган мәҗлесләр күп. Алар — туйлардан: бәби туе, бишек туе, никах туе, өй туе, көмеш туй, алтын туй, сабан туе һ. б. лар; өмәләрдән: нигез өмәсе, йорт күтәрү өмәсе, каз өмәсе, урак өсте өмәсе, печән чабу өмәсе һ. б. лар; кичәләрдән: дуслар белән очрашу кичәсе, тәбрик итү кичәсе, яңа елны каршы алу кичәсе һ. б. лар. Бу мәҗлесләрнең күбесе махсус ашлар хәзерләүне таләп итә. Мәсәлән, бәби ашы, кияү ашы һ. б. лар.

**Туй табыннары.** Никах туе һәр кеше тормышында иң шатлыклы көн. Туйлар һәрвакыт күңелле шау-шу, уен-көлке белән уза, туй ул — чын бәйрәм. Шуңа күрә туй мәҗлесе кирәгеннән артык тыгыз булмаска тиеш, анда кунаклар урындыкка кадакланып куелгандай моңаеп утырмасыннар. Барысын да кунакларга күңелле булсын дип әзерләргә кирәк.

Табынга каклаган каз, салкын каз ите, бәрәңгесез токмач (токмач бик вак итеп яки кош теле формасында ромбалап турала), парда пешерелгән ит (бәрәңге белән дә ярый, бәрәңгесез дә), тутырган тавык һ. б. лар куела. Ә чәй янына чәк-чәк, татлы паштет, кәләвә һ. б. югарыда әйтелгән ашамлыклар тәкъдим ителә. Кунакка килүчеләр, гадәттә кодалар, туйга пар каз, пар паштет, пар бәлеш алып киләләр. Алар да табынга чыгарыла. Билгеле, баллы майдан башка туй табыны мөмкин түгел. Ләкин кайбер туй мәҗлесләрендә табынга баллы май чыгарылгач, хәзер дә әле кунаклар акча салырга керешәләр. Бу һич тә килешми торган гадәт. Баллы май элек-электән кунаклардан акча өмет итеп түгел, ә ике яшьнең тормышы бәхетле, баллы май кебек татлы булсын дип табынга куела.

Бәби һәм бишек туйларында табында татлы ризыклар өстенлек алып тора, кунакларга чәй янына төрле төсләр белән бизәлеп әзерләнгән әлбә, татлы талкан, кәләвә, камырдан ясап пешерелгән роза чәчәге, урама, гөлбәнәк һәм башка төрле ашамлыклар тәкъдим ителә.

Ә әй туе, көмеш туй һәм алтын туй табыннарында исә итле ашлар өстенлек итә: шулпалы пилмән, вак пәрәмәч, парланып пешерелгән кош ите яки терлек ите, кыздырылган балык. Мондый туйларда гадәттә табынга гөбәдия яки бәлеш чыгарылмый.

Сабан туе — халкыбызның традицион бәйрәме. Ул язгы кыр эшләре беткәч, печәнгә төшәр алдыннан уздырыла. Аңа бер-ике ай электән үк әзерләнә башлыйлар. Сабан туенда өстенлек алган ашлардан: каклаган каз, казылык, тозлаган ит, сөт, катык, сөзмә, кайнатылган май, йомырка, коймак-кабартма, паштет, бәлеш һ. б. лар. Гадәттә сабан туенда чакырып кунак җыю юк. Ул — хезмәт бәйрәме, дуслык бәйрәме. Бу бәйрәмдә һәркем һәр өйдә кунак.

**Өмә табыннары.** Татар халкы, әйтеп киткәнебезчә, борын-борыннан авыр эшләрне күмәк, өмә ясап башкара торган булган. «Авыр эшне күмәк кул җиңгән»; «Күмәк эш — күңелле эш»; «Өйләдән калсаң да, өмәдән калма»,— дигән халык. Бик тапкыр һәм мәгънәле сүзләр.

Өмәләр күп төрле. Мәсәлән, нигез өмәсе яңа йортка нигез салу уңае белән җыела. Каз өмәсен каз суйганда, сүс өмәсен киндер, җитен талкыганда җыялар. Безнең бурыч өмәләрнең барысын да санап чыгу түгел, «Элек хезмәт — аннан хөрмәт»,— дигән сүз дә бар бит әле халыкта. Менә шул эш кешеләрен, өмәгә катнашучыларны ничек хөрмәт итәргә? Менә шул турыда берничә сүз.

Өмәчеләргә зур-зур кисәкләргә бүлгәләнгән ит салып шулпа пешерелә, аш янына кайнар кабартмалар куела. Эшләүчеләргә, гадәттә, чәй урнына әйрән чыгарыла. Бу — нигез яки өй күтәрү өмәсендә.

Безнең халыкта каз өмәсен бик күңелле итеп үткәрәләр. Кызлар, яшь киленнәр җырлый-җырлый каз йолкыйлар, каз эшкәртәләр, ә егетләр гармонь уйныйлар, аларга булышкан булып йөриләр.

Өмә беткәч, кызлар, яшь киленнәр, егетләр чишмә буена казларны юарга төшеп китәләр. Алар менүгә табын әзерләнгән була. Табынга каз шулпасы куела, баш, канат, аяклардан шулпалы зур бәлеш пешерелә. Ә чәй янына каз маенда пешкән кайнар коймак чыгарыла.

Тагын шунысын да әйтергә кирәк: яңа тормыш, колхозлашу яңа традицияләр алып килде. Урып-җыюлар үткәч, колхозларда уңыш бәйрәмнәре үткәрелә. Анда алдынгыларга бүләкләр тапшырыла, «Кыр батыры» һ. б. төрле мактаулы исемнәр бирелә. Бу бәйрәмнәр шул ук яңа өмәләр бит инде. Аларның табыннары да мул итеп әзерләнә. Бу табыннарда шулай ук милли традицияләр, милли ашлар өстенлек итә. Тик аларда кунаклар күбрәк, табынның күләме зуррак була.

Тула өмәсе, урак өмәсе, сүс өмәсе кебек өмәләр хәзерге заманда инде үткәрелми. Колхозларда аларның кирәге юк — барысын да машина эшли. Шуңа күрә аларга тукталып тормыйбыз. Хәер, ул өмәләрдә дә табын шундый ук тәртиптә диярлек әзерләнгән.

**Кичәләр.** Кичке мәҗлесләр гадәттә төн уртасына кадәр сузылалар. Кичке мәҗлесләрдә табынга шулпа чыгарылмый, вак бәлеш, өчпочмак, катык яки шулпа белән пәрәмәч бирелә, аннары чәй өстәле әзерләнә.

Яңа елны каршы алу кичәсе сәгать унберләрдә генә башлана. Алда әйтелгәнчә, анда да шулпалы ашлар әзерләнми. Табында җиңел ашлар өстенлек алып торырга тиеш. Мәсәлән, кош ите, балык. Алар пешерелгән яки кыздырылган булырга мөмкин. Аз булсын, ләкин ләззәтле булсын — ашларны шул принциптан чыгып әзерләргә һәм бүләргә кирәк. Табында җиләк-җимеш ризыклары мул булсын!

Табынга әзер ризыкларны чыгаруның да үз тәртибе бар. Гадәттә, һәр азык-төлек өчен махсус савытлар була. Салкын ашлар сай һәм кечкенә тарелкаларга салынырга тиеш. Шулпалы ашлар табынга зур миски белән чыгарыла һәм һәр кунакка аш тарелкаларына бүлеп бирелә. Ит калҗалары, кош ите бәрәңге белән зур сай табакка салып чыгарыла һәм һәр кеше шуннан алдындагы тарелкага кашык белән үзенә кирәк кадәр ала. Шулпалы бәлеш тә, гади бәлеш тә табасы белән табынга куела, башта өсте киселә, аннары яны, иң соңыннан төбе кисеп-кисеп таратыла. Ә гөбәдия исә табынга кисәкләргә бүлеп чыгарыла.

Компот, ширбәт касаларга, стаканнарга бүлеп бирелә. Ә чәй ашлары (кош теле, роза һ. б. лар) матур итеп вазаларга тезеп куела, өсләренә шикәр комы сибелә. Катлы паштет, биек паштет, алма, балан бәлешләре һ. б. лар, матур, төгәл итеп киселеп, һәр кунакка кечкенә тарелка белән тәкъдим ителә.

**Эчемлекләр турында.** Табын эчемлек белән дә, эчемлексез дә булырга мөмкин. Мәҗлес өчен эчемлек әзерлисең икән, аның да рәтен белергә кирәк: азык тәме белән эчемлек тәме тәңгәл килергә, бер-берсен тулыландырырга тиеш. Кызыл коры виноград виносы, мәсәлән, итле, майлы ризыклар белән яхшы. Ул майлы калдыкларны үтемлерәк итә. Шампанское эчемлеген элек-электән Европада булмасын, Россиядә булмасын, бәйрәм виносы итеп кулланалар. Бу җиңел, үтә күренмәле вино, бокалларга салгач, уйнап тора. Ул табынга бәйрәм төсе бирә. Гадәттә төшке ашлар алдыннан сыра тәкъдим ителә. Сыра булганда спиртлы эчемлекләр һич тә чыгарылмый.

Безнең бурыч эчемлекләрнең һәрберсенә характеристика бирү түгел. Тик шуны әйтергә кирәк: табынга эчемлекләр хәзерге вакытта шешәсе белән чыгарып утыртыла. Шампанскоедан башка эчемлекләрнең бөкесе ачылган булырга тиеш. Кунакны эчемлек белән сыйлап, артык кыстарга кирәкми.

**Табын янында үз-үзеңне тоту.** «Кунак ишегеңне ачса, син йөзеңне ач»,— ди халык. Хуҗа кеше кунакны ачык йөз белән аяк есте каршы алып, исәнлек-саулык теләп озатып кала.

Кунак һәрвакыт чакырылган вакытта килеп җитәргә тиеш. «Көттергән кунак үзен сүктергән»,— дип халык юкка гына әйтмәгән. Әгәр дә инде теге яки бу сәбәп белән соңга каласың икән, кулга кул хуҗа белән генә күрешергә кирәк. Кунаклар белән баш иеп кенә исәнләш, күкрәгеңә кулың куеп башка кунаклардан гафу үтен дә үзеңә тәкъдим ителгән урынга утыр.

Алда әйтелгәнчә, беренче салкын ризыклар, яшелчә ашлары ашала. Табындагы зур тарелкадан аны алдыңа куелган кечкенә тарелкага махсус кашык яки чәнечкә белән үзеңә кирәк кадәр аласың. Кыяр, помидор кебек бөтен яшелчәләр һәм йомырка пычак белән ваклап турап ашала. Икмәк бармак калынлыгында гына туралып кул җитәрлек урынга куелган була һәм аны чәнечкесез, кул белән генә алырга, сындырмыйча әз-әз кабып ашарга кирәк.

Кош ите сөягеннән тотып ашала. Гомумән, сөякле иткә пычак һәм чәнечке кирәкми.

Табын янында үз-үзеңне тыйнак тот, бер вакытта да онытылып китеп кычкырып җибәрмә, үзеңне бүтәннәрдән өстен куйма, башкаларның сүзен бүлдермә. Әле бер ягыңа, әле икенчесенә борылып юк-бар сүз белән күршеләреңне борчыма.

Менә өстәлгә шулпалы аш чыгарыла. Аш кунак кушуы буенча бүленә: чөнки салынган ашны калдыру килешми. Аннары тирән тарелкалар җыеп алына. Сай тарелкаларга бәлеш, гөбәдия бирелә, ит чыгарыла.

Компотның һәм ширбәтнең башта сыек өлешен эчәргә, ә җимешләрен бал калагы белән генә ашап, төшләрен тарелкага куярга кирәк, чөнки табында төкеренеп утыру килешми. Карбыз яки кавынның төшләре пычак яисә кашык очы белән чистартыла.

Табынга кәгазь салфетка һәм кул тастымалы куелган була. Кәгазь салфетка — ашаганда ирендәге майны һәм бармак очларын сөртү өчен. Тастымалны исә аш тамып өс буялмасын өчен алга салып утырырга кирәк, аның белән ара-тирә маңгай тирләрен сөртеп алырга була.

Өчпочмак, вак бәлеш, пәрәмәч кебек ризыкларны кул белән тотып ашарга кирәк. Кабартма-сумса кебек камыр ашларына да пычак, чәнечке кирәк түгел.

Чәйне стаканга яки чынаякка бер бармак калынлыгы тутырмыйча салырга кирәк, чөнки аңа лимон яки алма турап өстәлә. Гадәттә шикәрне тешләп, бал яки вареньены бал калагы белән кабып эчәләр.

Кунак кайвакыт табынны бар кеше алдында кирәгеннән артык мактарга керешә. Бу нәрсә килешми, моның белән ул хуҗаны уңайсыз хәлгә куюы мөмкин. Әгәр сиңа табын, сый-хөрмәт чыннан да бик ошый икән, бу турыда киткән вакытта хуҗаның үзенә генә әйтергә кирәк.

Без халкыбызның мәҗлес җыю, табын әзерләү осталыгы, бу өлкәдәге тәҗрибәсе турында кыскача гына әнә шуларны әйтә алабыз. Ләкин болар һәркем өчен, һәр очрак өчен мәҗбүри кагыйдәләр түгел, әлбәттә. Үзеңнең мөмкинлекләреңнән чыгып эш итәргә кирәк. «Юрганыңа карап аягың суз»,— ди бит халык. Мөһиме шул: хуҗа кунаклардан, кунаклар хуҗадан һәм бер-берсеннән канәгать булсыннар, мәҗлес һәркемдә күңелле истәлек булып саклансын.

## Шәүкәт Галиев

### Шөпшә

Кергәч тә бер
Көпшәгә
Шөпшә төшкән
Шебһәгә —
Иң өстә дә,
Төптә дә
Юк монда бер
Шөпшә дә...
Югы юк та,
Бары бар —
Бире кил дә
Ары бар —
Монда ядрә,
Дары бар!

Соңардың ла,
Чыкма ла,
Үрмәләмә,
Чапма ла —
Аучы басты
Чакмага...
Һәй, менә шул
Чакларда,
Ядрә тәрткәч
Артыннан,
Шөпшә чыгып
Атылган!!
Ай-һай тыгыз
Килгәндер...
Шөпшә филгә
Тигәндер,
Филне бәреп
Еккандыр,
Фил торалмый
Яткандыр,
Әй ачуы
Чыккандыр!
Үч әмәлен
Тапкандыр,
Янап күкрәк
Каккандыр:
— Мин дә керәм
Көпшәгә,
Атылам шул
Шөпшәгә!
Шөпшәгә!!
Шөпшәгә!!!

### Яңгыр яуганда



Яңгырдан качалар
Кешеләр.
Яңгырдан качалар
Песиләр.
Качалар маэмайлар,
Чебешләр —
Барсы да чыланган,
Юешләр...
Үрдәкләр һәм казлар
Качмый тик —
Дөньясын шунда су
Басмый ник!

# Ничә мәче?



Әбиемнең мәчеләре
Тезелгәннәр, карагыз —
Мин күрсәтәм, сез карагыз,
Абайламый калмагыз!
Чамалагыз,
Чамалагыз,
Бармакларны бөгә-бөгә,
Бергә-бергә санагыз:

— Менә бусы —
Соры мәче,
Менә бусы —
Сары мәче,
Менә бусы —
Ак мәче!

Соры мәче —
Батыр мәче,

Сары мәче —
Куркак мәче,
Ак мәчесе —
Сак мәче!



Батыр мәче —
Шаян мәче,
Куркак мәче —
Наян мәче,
Сак мәчесе —
Шук мәче!



Сорауны тагын кабатлыйм,
Мәчеләр барсы ничәү?
(Белмәгәннәр юк та бугай,
Барсы да әйтә: ...!)






## Зөһрә

Бәп-бәләкәй булса да
Зуп-зурлар кебек Зөһрә —
Укый да белә Зөһрә,
Яза да белә Зөһрә.

Әгәр чыксаң шәһәргә
Укыр нәрсә аера күп:
БАКАЛЕЯ,
АПТЕКА,
УНИВЕРМАГ,
АЭРОПОРТ...

Ерактан ук күрә дә
Шул якка таба бора:
— Күрәмсең, тагын бер «А»,
Әнә ул кайда тора!

Өйгә кайткач, киштәдән
Китаплар барып ала,
Алдына ачып сала,
Һәм тагын танып ала:

— Бу да «А» ди, бу да «А» —
Табуына куана.
Чөнки әле хәзергә
Шул гына таныш аңа...

Карандашын учлый да
Язып куя зур «А»ны.
Яза бер бит тутырып —
Бик ярата ул аны.

...Укый да белә Зөһрә,
Яза да белә Зөһрә,
«А»ны гына белсә дә,
Әмма белә — гомергә!

## Борын

Кызык та карта буенча
Сәяхәт кылулары,
«Язганны кем дә табар!» дип,
Карамый Сылу аны...

Укытучы дәшкәч кенә
Тешләп булмый терсәкне:
— Күрсәт Гибралтар бугазын,
Дежнев борынын күрсәт, ди.

Кыяр-кыймас кына чыгып
Зуп-зур карта янына,
Сылу каушап карап тора
Америка ягына...




Иптәшләре пышылдыйлар:
— Борыл, уңгарак борыл!
Бугазга төер тыгылды,
Түбәнгә төште борын...

Икелене ник алганны
Өйдә дә төпченәләр...
Җитмәсә, эчне пошырып,
Кысыла кечкенәләр:

Итәктән тарта Вәлия:
— Үзем әйтеп бирәм, ди,
Менә — бугаз, менә — авыз.
Өйрән бирәм-бирәм, ди.

Шелтәләр дә бик җирендә,
Көлсәләр дә урынлы...
Мондый чакта иң дөресе —
Картага төрт борынны!

## Җәен

Күпме йөрсәк тә без
Җәен,
Каптыралмадык
Җәен.
Җәен эләкмәсә
Җәен,
Язын табарбыз
Җәен!

**Радик Фәизов**

# БИШ МИНУТ

хикәя



Һай, бу иртә торулары! Әле йокының чиреге дә туймаган, күрәсе төшләрне күреп бетмәгән, ә инде, рәхим итеп, җылы юрган астыннан чыгарга да кирәк. Ах, тагын биш кенә минут...

Хатыны Һаҗәрбикә Нурминың йокысын иң тәмле җирендә бүлдерде.

— Әй дим, торырга вакыт.

Нурми сул күзенең кырыен гына ачып сәгатькә карады. Әле алты да тулмаган түгелме соң? Нигә инде шулкадәр иртә... Миһербаны юк бу Һаҗәрбикәнең.

— Карчыгым, җан кисәгем! Тагын биш кенә минут...— дип ялварды Нурми елак тавыш белән һәм юрганын башыннан ук бөркәнеп тагын татлы йокыга чумды.

— Тор, җансыз! Соңга каласың бит!

Бу юлы инде Һаҗәре җилләр уйнатып Нурминың өстеннән юрганын бер селтәнүдә йолкып алды. Тегесе, ачу белән, ялт итеп сәгатькә карады һәм дәррәү сикереп торды. Алты тулып биш минут! Тагын чирек сәгатьтән поезд китә!

Итәгенә ут капты Нурминың. Бер кулы ботинка бавын бәйли, икенчесе йомырка арчый. Ике каба, бер йота. Җәтрәк, җәтрәк! Аркадий Райкин тизлегендә костюмын киеп, эшләпәсен бер колагына гына элде дә башы белән ишекне сөзде.

Бәхете әле, урамнар буш иде. Галстугын бәйли-бәйли, телен иңенә салып чатыр-чапканын тамаша кылучы булмады. Инде станциягә життем дигәндә генә, поезд «ту-у» итеп кычкыртты да кузгалып та китә башлады. Нурми иң соңгы вагонга көчкә эләгеп китә алды.

Вагонга кереп бер җиңел сулауга, тагын йөрәге урыныннан купты. Ә билет?! Менә хәзер тотып билет тикшерә башласалар... Ну, бетте башлар! Штрафы күпме соң әле, ләгыйньнең? Нурми кабаланып әүвәл ян кесәләренә, аннары куен кесәсенә тыгылды һәм... чәчләре үрә торып, эшләпәсе күтәрелүен аермачык тойды. Кесәсендә җилләр сызгыра, ә янчык комод өстендә онытылып калган иде. Кичәгенәк, күз алдындарак булсын дип, үзе шунда куйган иде бит. Ах, бу биш минут!

Нурми тәмам куркуга төште. Менә ревизорлар килеп керер. Акчасы да булмагач, аны бер сукбай кебек сакка алып, шәһәргә китерерләр. Унбиш сутканы чәпеп, утыртып ук куярлар. Өйдән акча килгәнне көтеп, суыр аннары суган суын. Хурлыгы ни тора бит, хурлыгы... Чү, әнә киләләр дә түгелме соң?.. Кая качарга хәзер, кая? Менә бу

апаның капчыгы артына. Юк, күрерләр, сыртыннан ук каптырып алырлар. Эскәмия астына... Ә бу кадәр халык алдында шушы буең белән анда ничек кермәк кирәк? Костюм да пычранып бетәр... Уф, үтеп китәләр түгелме соң болар? Ура, кондукторлар гына икән әле.

Юл буенча шулай кан калтырап, ярты картайды Нурми. Вагон ишеге ачылган саен зил-зиләсе кубып, як-ягына каранды. Янәшәсендә утырган сөт сатучы хатыннар, авыз эчләреннән нидер укынып, ерак урыннарга күчеп беттеләр. Инде шәһәргә килеп җиткәч, поезд туктап бетмәгәнне дә көтмәде, вагоннан сикереп, җәтрәк табан ялтыратты.

Вокзалдан ике квартал җир киткәч кенә үзенең ялан баш икәнен абайлап алды. Каһәр, эшләпә вагонда онытылып калган! Ярар инде, күрәсе казадыр. Баш исән булгач, эшләпәсе җәл түгел. Нурмины бүген нәкъ сәгать унга начальник янына отчет белән чакырганнар иде. Сонга калмавы кыйммәт.

Начальник, олы яшьтәге, бик шәфкатьле кыяфәтле кеше, аны ике кулын биреп каршы алды. Нурми да, хәрбиләрчә ялт итеп кенә, портфелендәге отчет кенәгәләрен аның алдына китереп салды. Тегесе аларга бер күз ташлап кына алды да, күзлеген ачу белән читкә куеп, Нурмига текәлде. Начальникның йөзендәге шәфкатьле елмаюдан жиллләр искән, карашы соң дәрәҗәдә аптырау, хәтта рәнҗеш белән тулган иде.

— Минем алтынчы классны бетергәнгә утыз ел инде, Нурми Сабитович,— диде ул, нигәдер бик олылап. Башка чакта үз итеп, «Нурми туган»,— дип кенә дәшә иде.

— Ә-ә... нигә алты класс кына? Нинди утыз ел ул? — диде Нурми, берни аңламастан.

Начальник бармагы белән ул китергән кәгазьләргә төртте. Нурми якынрак килде һәм... телдән язды. Өстәлдә аның алтынчы класста укыган кызының дәфтәрләре чәчелеп ята иде! Тә-тә-тә...

Шундый чакта аның җире дә ярылып китми ичмасам. Әгәр ярыла калса, Нурми ике дә уйлап тормас иде. Кызының нәкъ үзенеке төсле шушы крокодил тышлы портфелен кочаклар иде дә җәһәннәмнең күзенә сикерер иде. Ну, бу биш минут!

Бер танышыннан акча юнәтеп, дачный поезд вагонына кереп утыргач кына бераз аңына килде Нурми. Хәтта шатланып ук куйды. Нәкъ уртадагы тәрәзә янында аның эшләпәсе эленеп тора иде. Күрче, үзенә хәләл мал икән. Бая гына калдырып киткән диярсең.

Нурми эшләпәне җәһәт кенә башына киде дә тәрәзә янына утырды. Перронда морожный сатучы кызларга карап, бүгенге оялуларын оныта төшкәндәй булды. Шунда, сискәндереп, кемдер аңа дәште:

— Бу минем урын иде, егетем. Рәхим итеп, күчеп утыра алмассыңмы? — диде ап-ак чәчле бер агай аңа. Нурми, гафу үтенеп, тәрәзәдән читкәрәк күчте. Бик сәерсенеп бераз аңа карап утыргач, агай янә әйтә куйды:

— Синең башыңдагы эшләпә дә минеке иде ул, энекәш. Рәхим итеп, салып бирә алмассыңмы?

Нурминың колакларына ышанасы килмәде! Эшләпәне җәтрәк агай алдына ташлады да, гафу үтенергә дә онытып, икенче вагонга сызды. Артыннан бөтен вагон шау итеп сызгырып калды.

Нурми юл буе башын учлап кайтты. Көне җилгә очты. Ояттан әле тагын бер ай буена битләр янар. Ә эчтә ач бүреләр улый...

Ах, бу биш минут!

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1970 ЕЛДА

## ЖУРНАЛЫБЫЗНЫ УКУЧЫЛАРГА РЕДАКЦИЯДӘН ХАТ

Быел, ягъни 1969 елда, «Казан утлары» журналы 80 меңнән артык тираж белән чыгып килде. Татар телендә басыла торган бердәнбер әдәби журнал буларак, ул Советлар Союзының барлык почмакларында таратыла һәм, билгеле булганча, аңа илебездәге теләсә кайсы почта бүлегендә язылырга мөмкин. Журналны пропагандалау һәм таратуны оештыру эшендә, язучыларыбызның һәм редакциянең үзләреннән тыш, авыллар һәм шәһәрләрдәге, районнар һәм өлкәләрдәге элемтәчеләр, партия һәм совет органнары, җәмәгать оешмалары, җәмәгатьчелек тәртибендә матбугат таратучылар актив катнаштылар һәм катнашалар. Без аларга моның өчен Язучылар союзының һәм редакциянең зур рәхмәтен тагын бер кат белдерәбез, журналга 1970 елга яздырганда да аларның шундый ук тырышлык һәм активлык белән эшләячәкләренә ышанабыз.

1970 елда илебез һәм бөтен прогрессив кешелек дөньясы бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулу бәйрәмен тантана итәчәк. Бу уңай белән без журнал битләрендә «Ленин — бөек юлташыбыз» дигән даими бүлектә иң яхшы әдәби әсәрләрне, истәлекләр һәм язмаларны, Казаннан киткәч Ленин булган урыннардан (Шушенское, Псков, Уфа, Ленинград, Мәскәү, Польша, Финляндия һ. б.) язучыларыбыз репортажларын тагын да күбрәк итеп бирәчәкбез. Алар мәктәпләрдә һәм клубларда Лениниана кичәләре үткәргәндә бик кирәкле яңа кулланма булырлар. «Төрле телләрдән һәм төрле илләрдән» сайлап алып тәрҗемә ителгән яңа әсәрләр бу теманы тагы да киңәйтәчәк һәм баетачак.

Киләсе елда республикабыз тагын бер истәлекле датаны — Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулу көнен шаулатып бәйрәм итәчәк. Ленин васыятьләрен үтәп, промышленностьны, авыл хуҗалыгын, культура һәм фәнне күтәрү буенча эшчеләр белән игенчеләр, иҗат кешеләре белән галимнәр ирешкән зур уңышларны, халкыбызның батыр улларын, дуслык һәм тугандашлык хисләрен зурлаган материаллар 1970 елда журналда аеруча күп булачак бик табигый. Сез аларны министрларыбыз, бөтен илгә данлы кешеләребез белән беседа формасында, замандашларыбыз турында очерклар яки язучыларыбызның, сәнгать эшлеклеләренең әдәби портретлары дигән циклда укырсыз.

Төп урын, әлбәттә, халкыбызның үткәнен һәм бүгенгесен чагылдырып заман темасына язылган яңа әсәрләргә биреләчәк. Андыйлар редакция портфелендә хәзер үк бар инде: мәсәлән, Мирсәй Әмирнең «Җан көеге» повесте, Газиз Мөхәммәтшинның «Йөрәктәге эзләр» романы, Нурихан Фәттахның тарихи темага «Идел суы ака торыр» дигән романы, Эдуард Касыймов («Сорбонна профессоры»), Әмирхан Еники («Җиз кыңгырау»), Барлас Камалов («Күршеләр»), Вакыйф Нуруллин («Күпер чыкканда»), Фәнил Мансуров («Хәерле юл»), Мөхәммәт Мәһдиев («Авылым көндәлеге»), Мөсәгыйть Хәбибуллин («Тормыш чоңгыллары»), Рафиать Кәрамиев («Кичке утлар») повестьлары, Сибгат Хәкимнең, Нури Арслановның, Саҗидә Сөләймановаының, Илдар Юзеевның яңа поэмалары һ. б. Без барлык прозаиклардан яңа хикәяләр, барлык шагыйрьләрдән яңа шигырьләр һәм җырлар көтәбез. Арада «Елмаеп-көлеп кенә...» бүлегенең юмористик һәм сатирик әсәрләре, «Балаларга укыгыз» дигән циклда мәктәпкәчә яшьтәгеләр өчен шигырь һәм хикәяләр журналның һәр санында диярлек була килде һәм булачак.

Безнең китап нәшриятыбызда хәзер һәр өч көн саен бер яңа матур әдәбият китабы чыгып тора. Без киләчәктә укучыларыбызны шуларның иң зур күпчелеге белән, я рецензия, я китап күзәтү, я аннотация бирep таныштырып барырга телибез. Шулай ук борынгы әдәби мирас, хәзерге халык иҗаты, әдәби тәнкыйть материаллары да күбрәк урын алырга тиеш.

Кыскасы, язучыларыбыз һәм редакция коллективы журналда басыласы барча төр материаллар тагын да киңрәк масштаблы, тирәнрәк эчтәлекле булсын өчен тырышалар. Урыннарда да журналны күбрәк тарату һәм киңрәк пропагандалау буенча тагын да зуррак тырышлык күрсәтелсен иде.

* * *

*Журналга язылу шушы елның 1 сентябреннән башлана. Язылу бәясе: бер елга — 6 сум, аерым санның бәясе — 50 тиен. Язылганда, каталогтан тизрәк эзләп табсыннар өчен, журналның 73210 номерлы индексын әйтергә кирәк. Теге яки бу сәбәп белән журналга урыннарда язылу мөмкин булмаса, түбәндәге адрес белән акча җибәреп тә язылырга мөмкин: Казань, ул. Куйбышева, дом 17/25, Татарское областное отделение «Союзпечать».*

*Журнал редакциясе үзе подписка акчасын кабул итми.*

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ДУСЛЫК СӘЯХӘТЕ

Июль ахырларында Татарстанның әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре һәм тел белеме галимнәреннән бер төркем Идел акчарлагы «Метеор»да сәяхәткә чыктылар.

Бу сәяхәтнең максаты — нефть тудырган шәһәрләр белән танышып йөрү.

Идел өстендә «Метеор» тирбәлә. Салоннарда иҗат кешеләре гәпләшә. Бер салонда Мирсәй Әмир, Атилла Расих, КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин, Гариф Гобәй, композиторлардан Рөстәм Яхин, Хөснул Вәлиуллин һәм музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина нәрсәдер турында бик җитди сөйләшәләр. Шулар янында ук җырчылардан Эмил Җәләлетдинов, Риф Сафиуллин, музыкант Рәзинә Сабитовская һәм скрипач Шамил Мөнасипов үзләренең программаларын тикшерәләр. Ә урта салонда шагыйрьләрдән Нәби Дәүли, Галимҗан Латыйп, прозаик Сафа Сабиров, композитор Бату Мулюков, художниклардан С. Гатауллин, А. Прытков, Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының директор урынбасары Илбарис Надиров, шул ук институтның гыйльми секретаре Азат Әхмәдуллин һ. б.лар да нәрсә турындадыр җай гына гәпләшеп утыралар. Шашка-шахмат өстәлләре тирәсендә дә җанлылык. Анда Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре Гариф Ахунов, Әхсән Баянов, Мәхмүт Хәсәнов, Малик Хәмитов, Мөдәррис Әгъләмовлар көч сынаша.

«Красный ключ» пристанена пионер лагерьләреннән бик күп пионерлар килгән. Аларның кулында урман, кыр чәчәкләре.

Түбән Кама шәһәре үзенең киң проспектлары, тугызар, бишәр катлы матур йортлары, мәктәпләре, техник училищелары, техникумнары, яңа төзелешләре белән кунакларны бик җылы каршы алды.

Кунаклар шул көнне үк тимер-бетон конструкцияләре эшләп чыгара торган завод белән таныштылар. Бу завод эшчеләре үзләренең хезмәт җимешләре белән Түбән Кама шәһәрен генә түгел, илебезнең башка зур төзелешләрен дә тәэмин итә икән. Аның футбол кырыннан да зуррак булган цехларында хезмәт гөрләп тора. Андагы техниканың көче чын-чынлап гаҗәпләнерлек.

Түбән Кама Химия комбинаты да үзенең гигантлыгы белән, гаҗәеп киләчәге белән һәркемдә зур тәэсир калдырды, һәркемне дулкынландырды.

Культура работниклары Түбән Камада ике очрашу үткәрделәр: берсе — шәһәрнең Химиклар клубында, икенчесе — Химия комбинаты клубында. КПССның Түбән Кама шәһәре комитеты беренче секретаре Н. Юсупов шәһәр халкы исеменнән культура работникларына иҗатларында уңышлар теләде. «Безнең шәһәр иҗатыгызда чагылыш табар!» дигән ышаныч белдерде.

КПССның Татарстан өлкә комитеты



*Әдәбият һәм сәнгать вәкилләре «Дуслык» нефть үткәргеченең башланган урынында.*

культура бүлеге мөдире М. Мусин шәһәр хезмәт ияләрен язучылар, композиторлар, художниклар, артистлар, галимнәр белән таныштырды. Соңыннан культура работниклары тамашачыларга үзләренең әсәрләрен укыдылар, композиторларыбызның җырларын башкардылар, татар әдәбиятының, музыкасының, гомумән, культурасының бүгенге торышы турында сөйләделәр.

Кунаклар үзләрен иң беренче булып каршы алган пионерлар янында да булдылар, алар алдында чыгыш ясадылар, аннары «Красный ключ» кош фабрикасын карадылар. Быел үзенең 50 еллык юбилеен үткәргән бу совхозның тулысы белән машинага көйләнгән тавык кетәкләре дә кунакларда зур соклану тудырды.

Түбән Кама белән Әлмәт арасындагы юл асфальт кына түгел, ул бетоннан коелган. Ә юлның ике ягында — ямь-яшел урманнар, иксез-чиксез иген кырлары. Автобус алга ыргыла. Менә Зәй ГЭСы. Аның су саклагычы диңгез булып әллә ничә чакрымнарга җәелгән. Шуннан инде Әлмәт районы чиге башлана. Район вәкилләре үз автобуслары белән «чик буенда» кунакларны көтеп торалар икән. Сәяхәтчеләр Түбән Кама кешеләре белән хушлашып, юлны дәвам иттеләр. КПССның шәһәр комитеты вәкиле Сания Хәкимова кунакларны юлда очраган промыселлар, буровойлар, колхозлар белән таныштырып бара. Әлмәтлеләр үз яклары белән чын-чынлап горурланалар. Бу бик табигый дә: аларда Татарстан нефтенең үзәге, дөньядагы иң зур «Татнефть берләшмәсе». Татарстан нефте — илебездә чыгарыла торган нефтьнең өчтән берен тәшкил итә. Ә бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 тулачак елда — 1970 елда — алар 100 миллион тонна нефть бирергә ышандыралар. Бер «Әлмәтнефть» үзе генә дә Баку биргән кадәр нефть бирә. Аннары шунысы да бар: «Дуслык» нефть үткәргеченең башы да Әлмәттә бит. «Әлмәтнефть» идарәсе үзе генә дә илнең нефть эшкәртү заводларына һәм «Дуслык» нефть үткәргече буйлап социалистик илләргә ел саен 20 миллионнан артык «кара алтын» озата. Бу турыда килгән кунакларга Сания Кадыйровна да, «Татнефть» берләшмәсе начальнигы Әгъзәм Вәлиханов та, КПССның Әлмәт шәһәр комитетының беренче секретаре В. В. Ермаков та күп сөйләде.

Нефтьчеләрнең эшләре, тормышлары белән танышканда үен-көлке, шаярулар тынып тормады. Әнә Мирсәй Әмир Азәлин бригадасы бораулый торган вышка янында нефтьчеләр каскасы киеп рәсемгә дә төшкән. Нефтьчеләр турында ике роман, күп хикәя һәм очерклар язган Гариф Ахуновка бригада җитәкчесе шул каскаларның берсен бүләк иткән.

Һәрнәрсә сокландыргыч, һәрнәрсә дулкынландыргыч һәм гаҗәпләндергеч анда — нефтьчеләр янында. Менә Миңлебай газбензин заводы. Бу чын мәгънәсендә гигант завод. Казан Оргсинтез заводына да, Түбән Кама Химия комбинатына да, илебезнең башка бик күп шәһәрләренә дә бутаны да, пропаны да, башка бик күп кыйммәтле продуктлары һәм, ниһаять, безгә яга торган



*Сулдан уңга: М. Әмир, С. Хәкимова, М. Мусин.*

газы да биредән китә. Ә аның кешеләре! Директоры Фәйзулла Галиуллин үзе дә институтны ун ел гына элек тәмамлаган. Киң карашлы, зур колачлы, киләчәккә карап эш итә торган һәм шул ук вакытта бик мөлаем, кешелекле егет ул.

Өр-яңа техникага, гел автоматка көйләнгән бу заводта эшләүче белгечләр — егетләр һәм кызлар — башлыча шушы ук тирә-якта туып-үскән, Әлмәттә, Казанда укыган элеккеге авыл малайлары, авыл кызлары. Үзләренә тапшырылган шундый зур заводның данын алар бөтен союзга таратканнар.

Бөгелмә шәһәре дә нефть белән тыгыз бәйләнгән. Биредәге Татарстан нефть фәнни-тикшерену институтының (Тат. НИИ) фәнни эшләр буенча директор урынбасары Р. Максудов кунакларны үзләренең эшләре белән, андагы лабораторияләр, катлаулы электрон хисаплау машиналары белән таныштырды. Хәзер биредә 4 фән докторы, уннарча фән кандидатлары эшли икән. Алар нефть геологиясе, «кара алтын» ятмаларын эзләү, скважиналар бораулау, нефть һәм газ эшкәртү проблемалары буенча уңышлы эшләп киләләр.

КПССның Татарстан өлкә комитеты оештырган бу сәяхәт иҗат эшлекләләре өчен чын-чыннан бик гыйбрәтле булды. Иҗат эшлекләләре бик күп нәрсәләр белделәр, күпне күрделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНДӘ

Татарстан язучылары союзы идарәсенең чираттагы утырышында «Казан утлары» журналының 1, 2, 3, 4 саннары тикшерелде. Докладчылардан М. Әмир бу саннарда проза әсәрләренә җитәрлек урын бирелмәвен журналның кимчелеге итеп күрсәтте.

«Ә басылып чыкканнардан күңелгә иң яхшы тәэсир калдырганнары,— диде ул,— Р. Төхфәтуллинның «Гомернең 48 минуты» хикәясе һәм М. Хәбибуллинның «Үксезлеч язы» повесте булды. Шулай ук Ф. Хөснинең «Гыйльмениса» повесте да игътибарга лаеклы әсәр».

Икенче докладчы Ш. Бикчурин башлыча хикәяләргә һәм очеркларга тукталды. Ул да шулай ук М. Хәбибуллин, Р. Төхфәтуллин әсәрләренә уңай бәя бирде, М. Хәмитовның «Мировой Әмир», К. Тимбиковаың «Алтын сәгать» очеркларының уңышлы булуын билгеләп үтте.

Әхмәт Исхак исә поэзия әсәрләре турында сөйләде. «Бу саннарда,— диде ул,— йөздән артык шигырь, өч зур поэма басылып чыккан. Ә. Давыдовның «Йокысыз төннән соң» шигъри романыннан фрагментлар, С. Хәкимнең «Дугада жиде көн» әсәре уңышлы. Ә. Маликовның «Чигүле кулъяулык» поэмасы эшләнеп бетмәгән, ышандырырлык итеп мотивлаштырылмаган урыннары күп». Аннары ул Г. Латыйп, Р. Гатауллин, Г. Сәгыйров, Г. Афзал, Р. Вәлиева, Б. Сөләйманов, Р. Гәрәй, М. Шабай һ. б.ларның шигырьләренә тукталды, алардагы уңышлы һәм кимчелекле якларны күрсәтте.

Гази Кашшаф үзенең докладын журналда басылган тәнкыйть әсәрләренә багышлады, Н. Исәнбәтнең «Тукайның бер шигыре», Г. Бәшировның «Гөлжамал кайсы як кызы» мәкаләләренең танып белү ягыннан әһәмиятен әйтте, Г. Халитның Әмирхан Еникига, Р. Мингалимовның Ә. Давыдовка, С. Хәкимнең Ф. Кәримгә багышланган мәкаләләре хәтердә кала. Ә. Исхак белән Г. Ишмөхәммәтовның академик басмаларга карата мәкаләсе үтә кирәкле проблемалар күтәрә. Ләкин журналда китап күзәтү бүлеге шактый ук загыйфь — Г. Кашшаф докладының дәвамында башлыча анә шулар турында сөйләде.

Фикер алышуга Ф. Хөсни, Г. Бәширов, Н. Фәттах, Г. Иделле, Ш. Маннур, Г. Ахунов, Х. Туфан һ. б.лар катнашты.

## ФИНЛЯНДИЯ ҺӘМ ТАТАРСТАН

Финляндиядә тугыз йөзгә якын татар яши. Аларның ата-бабалары ул якларга моннан йөз еллар элек вак сәүдә эшләре белән барып чыкканнар һәм шунда берничә шәһәрдә урнашып калганнар. Тумыш-чыгышлары буенча күбесе элеккеге Нижгород губернасының (хәзерге Горький өлкәсе) Сергач тирәсендәге татар-мишәр авылларыннан.

Соңгы елларда Финляндия татарлары арасында безнең Татарстан республикасы, аның культура, фән, әдәбият, мәгариф өлкәсендәге казанышлары белән кызыксыну көчәйгәне сизелә. Узган ел апрель аенда анда Габдулла Тукай исемендәге бер җәмгыять төзелеп актив кына эш башкарып җибәрде. Бу җәмгыятьне оештыручыларның берсе Хельсинки университетында алтай-төрки телләр укытучысы, философия фәннәре лиценциаты — Гомәр Таһир әфәнде. Соңгы вакытларда ул ике мәртәбә Казанда булып китте, Тукай турында язачак фәнни хезмәте өчен материаллар җыйды, белгечләр белән очрашты.

1968 елның маенда Г. Тукай җәмгыяте чакыруы буенча ТАССРның атказанган артисты Айрат Арсланов җитәкчелегендә бер төркем татар совет артистлары Хельсинки һәм Тампере шәһәрләрендә концертлар бирделәр.

Быел Тукай җәмгыятенең чакыруын кабул итеп, шагыйрьнең туган көненә багышлап Хельсинкида үткәрелгән җыелышта катнашу өчен Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры урынбасары, филология фәннәре кандидаты И. Надиров һәм шул институтның гыйльми хезмәткәре, тел белгече И. Абдуллин бардылар. Алар Финляндиядә ике атна булдылар. И. Надиров Хельсинки һәм Тампереда «Г. Тукай һәм татар халык җырлары» дигән лекция укыды, И. Абдуллин Г. Таһирның Тукай теленә багышланган хезмәтен баету буенча ярдәм күрсәтте. Безнең галимнәр Хельсинки университетының алтай, угро-фин телләрен өйрәнүче галимнәре белән очраштылар, тел, әдәбият, тарих институтында алып барылган фәнни эшләр турында чыгыш ясадылар. Тампереда В. И. Ленин музее белән таныштылар.

## ПЕРМЬНӘН КУНАКЛАР

Пермь китап нәшрияты 1970 елда В. И. Ленинның 100 еллыгы уңае белән, Кама буенда яшәүче тугандаш татар, башкорт, удмурт һәм коми-пермяк халыклары поэзиясе үрнәкләреннән «Дүрт җил» («Четыре ветра») исемле җыентык чыгарырга әзерләнә. Күптән түгел Татарстанга Пермь язучылары С. М. Гицц һәм А. М. Домнин иптәшләр килеп китте. Алар рус телендә чыгарылачак бу китапка татар шагыйрьләреннән Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов, Н. Дәүли, З. Нури, Ш. Галиев, Х. Камалов, И. Юзеев, Ә. Баянов, С. Сөләйманова, М. Шабаев, Р. Харисов һәм Зөлфәт шигырьләрен сайлап алдылар.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Июнь аенда яшь язучылар Роберт Батуллин, Гәрәй Рәхим һәм Рөстәм Мингалимов Актаныш һәм Чаллы районнарында В. И. Ленинның тууына 100 ел һәм ТАССРның төзелүенә 50 ел тулуга багышланган әдәби кичәләр оештырдылар. Клубларда, культура сарайларында, пионер лагерьларында, җәйләүләрдә китап укучылар белән очраштылар.

Яшь язучылар Яр Чаллы районы милиция бүлеге хезмәткәрләре белән дә очраштылар. Бу очрашуда милиция хезмәткәрләре белән язучылар арасында кызыклы әңгәмә булды. Әңгәмә барышында татар әдәбиятында милиция хезмәткәрләренең кыен һәм фидакарь хезмәте турында әсәрләрнең аз булуы әйтелде, чыгыш ясаучылар язучыларның бу кызыклы темага кыюрак мөрәҗәгать итүләрен теләделәр.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210